ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Ленар
Җамалетдинов

# *Татар әкиятләрен барлау юлында*

Казан
2015

УДК 398.21=512.145(081)
ББК 82.3(2Рос=Тат)я44
Җ 17

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Төзүче**
*филология фәннәре кандидаты **И.И. Ямалтдинов***

**Җамалетдинов Л.Ш.**
**Җ 17** Татар әкиятләрен барлау юлында / төз. И.И. Ямалтдинов. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 264 б.
ISBN 978-5-93091-187-9

Әлеге җыентыкта галим, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ленар Җамалетдиновның әкиятләрне җыю, бастырып чыгару, өйрәнү өлкәсенә караган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре, аның турында язылган язмалар, басылып чыккан хезмәтләре турында мәгълүматлар тупланып бирелде.

**ISBN 978-5-93091-187-9**

© ТР ФАнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел,
әдәбият һәм сәнгать институты, 2015

## ТРАДИЦИЯЛӘР ДӘВАМ ИТӘ

Халык авыз иҗатында борынгылыгы, мавыктыргыч дөньясы, сюжетлары, композициясе һәм башка үзенчәлекләре белән аерылып торган әкият жанры бар. Ул татар халык иҗатында да киң урын алган.

Әлеге төр әсәрләрне җыю һәм өйрәнү эше инде ике гасырга якын дәвам итә. Мәгълүм булганча, бу өлкәдә рус һәм чит ил галимнәре зур эшчәнлек күрсәткәннәр, XIX гасырда хезмәт куйган В.В. Радлов, Р.Г.Игнатьев, М.И. Иванов, В.Н. Витевский, Н.Ф. Катанов, П.А. Поляков, А.Г. Бессонов, Г. Балинт, Һ. Паасонен, И.Кунош исемнәре безгә яхшы таныш.

Татар галимнәреннән әкиятләрне җыю эшен күренекле мәгърифәтче галим К. Насыйри башлап җибәрә. XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында Г. Фәезханов, Т. Яхин, М. Корбангалиев, Г. Рәхим һ.б. әкиятләрне туплап бастырып чыгару өлкәсендә зур эш башкаралар.

1920 еллардан әкиятләрне җыю һәм бастырып чыгару эшен Гыйльми Үзәк галимнәре, 1930 елларның икенче яртысыннан язучы-фольклорчылар Г. Толымбай, Г. Бәширов һ.б. дәвам иттерә. 1939 ел азагыннан алып бүгенге көннәргә кадәр татар халык иҗатын, шул исәптән әкиятләрне өйрәнү нигездә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘҺСИ) белән бәйле. Аерым алганда, әкиятләрне җыю һәм бастырып чыгару, фәнни өйрәнү, рус теленә тәрҗемә итү өлкәсендә институт галимнәре Х. Ярми (Х.Х. Ярмөхәммәтев), Х. Гатина, Э. Касыймов, Ф. Әхмәтова, Л. Җамалетдинов, А. Садыйкова җитди көч салдылар.

ТӘҺСИнең фольклор секторы институт белән бергә оеша. Х. Ярми җитәкләгән бу секторның төп эш юнәлешләре түбәндәгечә билгеләнә: халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен фәнни экспедицияләр оештыру; фольклор текстларын әзерләп бастыру һәм халык иҗаты

белән бәйле проблемаларны фәнни өйрәнү. Күрсәтелгән юнәлешләр тормышка ашыру буенча планлы рәвештә эш башлана. 1940 еллар уртасында ук Х. Ярми белән Г. Бәширов ике томлы «Татар халык әкиятләре»нең беренче китабын басмага әзерли һәм 1946 елда ул нәшер ителә. 1956 елда «Татар халык әкиятләре»нең икенче китабы басылып чыга, 1958 елда беренче томның тулыландырылган басмасы дөнья күрә. Әкиятләргә антологик характердагы «Татар халык иҗаты» җыентыкларында да (1938, 1940, 1951, 1954) зур урын бирелә. Әкиятләрне туплау һәм өйрәнү тарихы Х. Ярминең татар фольклорын фәнни-теоретик яктан өйрәнүгә багышланган «Татар халкының поэтик иҗаты» (Казан, 1967) монографиясендә киң яктыртыла.

1976–1988 елларда ТӘҺСИ тарафыннан 12 томлык «Татар халык иҗаты» җыйнамасы басыла, шуларның өчесе әкиятләрне үз эченә ала. Томнарының баштагы икесен Хәмит Ярми белән Халидә Гатина төзи.

Хәмит Ярминең шәкерте язучы Эдуард Касыймов татар халкының сатирик әкиятләре тупланган «Абага чәчәге» җыентыгын төзеп бастыра (1962), «Татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор» темасына кандидатлык диссертациясе яклый (1966).

1970 елларда Ф.В. Әхмәтованың әкиятләрне тикшерүгә багышланган хезмәтләре дөнья күрә. Бер-бер артлы «О генетических корнях татарских сказок о животных» (1971), «Сходные поэтические фомулы в татарских и башкирских богатырских сказках» (1973), «О героическом в богатырских сказках сибирских татар» (1973) темасына тезислар басыла. 1975 елда РСФСР халыклары фольклоры җыентыгында «О татарских бытовых сказках», 1976 елда «Татар теле һәм әдәбияты»ның бишенче китабында «Маҗаралы әкиятләр турында» мәкаләләре укучыга барып җитә.

Ленар Шәйхи улы Җамалетдинов институтның халык иҗаты бүлегенә 1970 елда килә. Хәмит Ярми аңа әкият жанрын өйрәнүне, аерым алганда «Казан татарларының тылсымлы әкиятләре» темасын тәкъдим итә. Ленар Җамалетдинов фольклор дөньясының өч тармагына да, ягъни әкиятләрне җыюга, китап итеп дөньяга чыгаруга, фәнни тикшерүгә җитдилек белән карап, 40 елдан артык хезмәт куя. Аның төп хезмәтләре татар халык әкиятләре, фольклор һәм әдәбият бәйләнешләре өлкәсенә карый. Галим беренчеләрдән булып әкиятләребезне фәнни төркемли, аларның төрләренә багышлап махсус мәкаләләр яза. 1981 елда нәшер ителгән 12 томлык «Татар халык иҗаты» фәнни җыелманың «Көнкүреш әкиятләре» томын басмага әзерләүче дә ул.

1993 елда фәнни һәм иҗади тәҗрибә туплаган галим «Татар халык әкиятләре һәм Г. Тукайның әдәби әкиятләре» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Хезмәтендә бөек шагыйребезнең әдәби әкиятләр иҗат итүдә сайлаган төп принцибын ачыклый, «Шүрәле» поэмасына таянып, Тукайның татар әдәби әкиятенә нигез салучы булуын дәлилли.

Ленар Шәйхи улы татар фольклорына караган бик күп чит ил чыганакларын, шулай ук Рус география җәмгыяте һәм Россия Фәннәр академиясе архивларында сакланган татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен табып, фәнни әйләнешкә кертә. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында венгр тюркологы Игнац Кунош тарафыннан татар әсирләреннән язып алынган һәм Венгрия Фәннәр академиясе архивында сакланган фольклор материалларын дөньяга чыгара («Әсирлектән кайткан әкиятләр». Казан, 2002). Татар әкиятләрен халыкара фәнни әйләнешкә кертүдә бик зур әһәмияте булган «Татар халык әкиятләренең сюжет күрсәткече»н төзү белән шөгыльләнә, әлеге проблемаларга бәйле фәнни мәкаләләр бастыра.

Л. Җамалетдиновның фәнни тикшеренүче буларак башкарган һәм шактый үзенчәлеккә ия тагын бер күркәм гамәле бар: ул әкият өлкәсендә эшли торган чит ил галимнәреннән Ханс-Йорк Утер (Германия), Леонардас Саука (Литва), Һенрих Янковский (Польша), Эдина Даллош (Венгрия), Сеит Каскабасов, Едыге Турсунов (Казакъстан) һәм башкалар белән тыгыз иҗади хезмәттәшлек итә.

Ул Татарстан районнарына, шулай ук Россиянең татар халкы күпләп яши торган төрле төбәкләренә оештырылган 20 гә якын фәнни экспедициядә катнаша. Нәтиҗәдә 3000гә якын берәмлекне эченә алган бай хәзинә туплый, шул исәптән 200 гә якын зур күләмле әкиятләр язып ала. Л. Җамалетдинов татар әкиятләренең 17 җыентыгын әзерләп дөньяга чыгара, аларның гомуми күләме 400 дән артык басма табак тәшкил итә.

Хәзерге вакытта ТӘҺСИнең халык иҗаты бүлегендә 15 томнан торган «Татар халык иҗаты» җыйнамасы рус телендә әзерләнә. Бу җыйнаманың әкиятләргә багышланган беренче өч томын шулай ук Ленар Җамалетдинов эшләде. Әлеге томнарның өчесе дә җәмәгатьчелеккә барып иреште (2008, 2010) һәм уңай бәя алды. Әкият томнарының фәнни аппараты аерым игътибарга лаек: томнарга кереш мәкалә, һәр әкияткә искәрмәләр бирелеп, сюжетларның типологик анализы һәм текстларда тәрҗемә ителми бирелгән сүзләрнең аңлатмалары урнаштырылган. Өченче томда барлык өч том өчен дә уртак итеп эшләнгән «Топонимнар күрсәткече», «Исемнәр күрсәткече», «Предметлар күрсәткече», «Әкиятчеләр исемлеге»,

«Әкият җыючылар исемлеге», «Татар халык әкиятләрендәге сюжетларның җыелма күрсәткече» һәм «Әкиятләрнең әлифба тәртибендәге күрсәткече» бар. Әлеге рус телендәге әкият томнары татар әкиятләрен дөньякүләм фәнни әйләнешкә кертүдә мөһим бер адым булып тора.

Гомумән алганда татар халык әкиятләрен җыю, бастырып чыгару, өйрәнү өлкәсендә җитди эшләр башкарылган. Әмма бу өлкәдә алга таба ирешәсе үрләр дә байтак әле, бигрәк тә татар әкиятләрен фәнни яктан, монографик планда өйрәнү таләп ителә. Шулай ук архивларда кала биргән әкиятләрне фәнни әйләнешкә кертеп, татар халык әкиятләренең сюжет күрсәткечен төзү, татар әкиятләрен дөньяга таныту өчен чит телләргә тәрҗемә итү кебек мәсьәләләр дә бар.

Бүгенге көндә ТӘҺСИдә татар телендә 25 томнан торган «Татар халык иҗаты» җыйнамасын төзү эше бара. Әлеге җыйнамада әкиятләргә каралган 5 томны халык иҗаты бүлегенең баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова төзи. Аның җитәкчелегендә бүлек аспиранты Гөлнара Яхшисарова «Татар халык тылсымлы әкиятләренең генезисы һәм мифологик нигезләре» темасына кандидатлык диссертациясе әзерли. Халык иҗаты бүлеге хезмәткәрләре экспедицияләрдә катнашып, бу өлкәдә яңа эзләнүләр алып бара, институтның «Мирасханә»сендә игътибар көтеп ятканнарын фәнни әйләнешкә кертә, киң җәмәгатьчелеккә җиткерә – әнә шулай итеп Х. Ярми, Г. Бәширов, Э. Касыймов, Л. Җамалетдиновларның традицияләре уңышлы дәвам итә.

**_Ким Миңнуллин,_**
_Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы_

# ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

## Жанрның төрләре һәм аны өйрәнү тарихы

Әкият – халык авыз иҗатының борынгы, шул ук вакытта киң таралган һәм мавыктыргыч жанрларыннан берсе.

Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләре тупланган, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган. Әкият явызлыкны гаепли, гаделлекне, хаклыкны яклый, кешеләрне игелекле, тугры һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

Халыкның иҗтимагый фикер үсешен өйрәнүдә дә әкиятләр зур роль уйный. Гомумән, иҗтимагый-политик карашларның формалашуын һәм үсешен халык авыз иҗаты әсәрләреннән башка тулы өйрәнү мөмкин түгел.

* * *

Халык арасында кеше ышанмастай нәрсә сөйләнсә, гадәттә, «әкият бу» диләр. Телдә «әкият» һәм «ялган» сүзләре синоним булып йөри, чөнки әкияткә гомумән уйдырма хас.

Әкияткә уйдырмалар кайдан килгән соң? Аларны кем чыгарган? Кайчан һәм ни өчен? Әкиятләрне тикшергәндә без шул сорауларга җавап табарга тырышабыз. Бу исә жанрның тарихын өйрәнү дигән сүз. Тарихын белмәгәндә, аның асылына төшенү дә мөмкин булмас иде. Шуна күрә биредә, кыскача гына булса да, әкият узган юлны күздән кичереп үтик.

Әкиятләр кешелек тарихының бик борынгы заманнарында, әле җәмгыять сыйныфларга бүленмәгән дәвердә үк барлыкка килгән.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, борынгы фольклор тулаем кешенең практик максатларына хезмәт иткән (дөньяны танып белү, борынгы кешенең дөньяга карашы чикләрендә чынбарлыкның төрле күренешләрен аңлату; практик эшчәнлектә нәтиҗәлелеккә омтылу;

кыенлыкларны җиңәргә теләү һ.б.). Шулай булгач, әкият тә беренче чиратта гамәли вазифа үтәгән.

Әлбәттә, борынгы әкиятне вазифасы гына түгел, эчтәлеге ягыннан да бүгенге көндә без белә торган әкият белән тиңләштерергә ярамый. Сүз бүгенге әкиятнең «баба»сы турында бара. Ә ул нинди булган соң? Әкиятләрне тикшерүгә багышланган хезмәтләрдә әлеге «баба»ны күзаллаулар бар. Мәсәлән, тылсымлы әкият турында В.П. Аникин түбәндәгечә яза: «Йола-магия һәм мифологик төшенчәләр һәм күзаллауларның бөтен суммасы белән катлауландырылган көнкүреш характерындагы хикәя тылсымлы әкиятнең борынгы бабасы булган; бу әкияткә кадәрге дидактик уйдырмалар кешелек тормышының иң күп төрле күренешләре турында хөкем йөрткән, мәгълүм кагыйдә һәм тәртипләрне үтәүне таләп иткән»[1].

Тылсымлы әкиятнең борынгы «баба»сын әле әкият дип тә атап булмый. Гомумән, кешелек дөньясының борынгы чорында фольклор мөстәкыйль жанрларга бүленмәгән була. Алай гына да түгел, хәтта «саф» фольклор үзе дә булмый әле. Ул чорда идеология формалары аерымланмаган булу сәбәпле, сәнгать, фәлсәфә, дин, фән һ.б.ларның яралгыларыннан торган һәм бер бөтенне тәшкил иткән иҗтимагый идеология генә яши. Менә шул идеологик синкретизм составында соңга табарак мөстәкыйль үсеп китәчәк жанрларның яралгылары барлыкка килә. Фольклор әлеге идеологиянең телдәге гәүдәләнеше буларак яши башлый.

Борынгы кеше дөньяның, кешенең һәм гомумән җанлы һәм җансыз табигатьнең барлыкка килүен, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, кешеләр тормышындагы төрле хәлләрне – барысын да мифологик карашлар нигезендә аңлаган, һәм аларның аңлатмалары миф – мифик риваять (миф-быличка) формасында йөргән. Бу хикәяләрнең бер өлеше изге итеп саналган. Алар теләсә кайда, теләсә кайчан һәм теләсә кемгә сөйләнмәгән. Мондый хикәяләрне сөйләү изге йоланы үтәү белән бергә алып барылган һәм бары тик балигъ булган кешеләргә генә җиткерелгән, ягъни мифлар ритуал белән тыгыз бәйләнештә булган. Гамәли вазифа үтәгән бу мифик риваятьләр әкиятнең иң борынгы формасы дип санала[2].

Әкиятнең шуннан соңгы үсеше ничек барган соң?

Иҗтимагый практиканың, беренче чиратта, матди җитештерүнең үсүе нәтиҗәсендә, кешенең рухи дөньясы киңәя һәм, шуның белән бәйле рәвештә, эстетик ихтыяҗ туа. Бу ихтыяҗны канәгатьләндерү

---

[1] Аникин В.П. Русская народная сказка. М., 1959. С. 119.

[2] Мелетинский Е.М. О генезисе и путях дифференциации эпических жанров.– Русский фольклор. Материалы и исследования. V. М. – Л., 1960. С. 86, 87.

өчен рухи азык, әлбәттә инде, шул чордагы бердәнбер чыганактан – идеологик синкретизмнан алынырга тиеш була.

Эстетик ихтыяҗ торган саен үсә һәм төрлелек таләп итә башлый. Нәтиҗәдә идеологик синкретизм составындагы фольклористик яралгылардан төрле жанрлар үсеп чыга. Шуларның берсе – әкият.

Чын мәгънәсендәге әкиятнең туу вакыты – ул нәкъ менә изге хикәянең (әкият «баба»сының) нәфис хикәягә әверелеп киткән чагы[1]. Бу хәл исә изге хикәянең ритуалдан аерылуы нәтиҗәсендә була. Чөнки йоланы барлыкка китергән шартлар вакытлар узу белән бетә (аларнын иң мөһиме – аучылыкның бердәнбер яки төп яшәү чыганагы булудан туктавы). Бу исә, үз чиратында, әүвәлге изге мәгънәдәге йоланың да бетүенә китерә, йоладан аерылган хикәя шулай ук үзенең «изге»леген җуя һәм барлык кешеләр өчен дә сөйләнелә башлый. Әкиятнең шушы рәвешчә мөстәкыйль жанр булып формалашып житүе борынгы община строеның таркалу чорына туры килә[2]. Менә шул чордан башлап, әкият гамәлилектән арына һәм беренче чиратта эстетик вазифа үти башлый. Әлбәттә, аның идея вазифасы да (әхлякый, социаль һ.б.) мөһим урын тота.

Шулай итеп, әкият идеологик синкретизм белән арасын бөтенләй өзә һәм, берничә гасыр дәвамында камилләшә барып, тулаем сәнгать өлкәсенә карый торган бүгенге матур әдәбият кебек үк, чын мәгънәсендәге художестволы жанр булып җитешә.

Әкият сюжетында уйдырма мөһим урын тота. Уйдырма ул – фантазия жимеше. Ләкин фантазия үзе генә уйдырманы тудыра алмый. Моның өчен иң элек тормыш материалы кирәк. Ә тормышта әкияткә кулай материал һәрвакыт булган: кеше белән табигать, иске белән яңа арасындагы көрәш, искенең кире кагылуы нәтиҗәсендә туган комизм, тормышта очрый торган игътибарга лаеклы төрле вакыйгалар, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, кешеләрнең дөньяга карашындагы үзгәрешләр һ.б. Мәсәлән, аналар ыруы (матриархат) аталар ыруы (патриархат) белән алышынган чорда, әлбәттә, ыру башлыгы булган карчыкка мөнәсәбәт кискен үзгәрә, бу чынбарлык күренеше инде кире кагыла, һәм ул көлү объектына әверелә. Әкияттә хәтта тышкы кыяфәте белән дә коточкыч булган персонаж – убырлы карчык барлыкка килә[3].

---

[1] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. Л., 1946. С. 336.

[2] Мелетинский Е.М. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 87.

[3] Бу – убырлы карчык персонажының килеп чыгуын аңлата торган бердәнбер версия түгел. Әлеге персонаж шактый катлаулы. Аңа В.Я. Проппның «Исторические корни волшебной сказки» дигән хезмәтендә зур урын бирелә.

Хыял, фантазия нәтиҗәсендә генә барлыкка килгән «саф» уйдырмалар да була. Ләкин алар да реаль тормыш белән тыгыз бәйләнгән. Дошманны бик тиз юк итү, күп көч куймыйча гына төрле ризыклар булдыру, ерак җиргә тиз генә барып җитү теләге, мәсәлән, эченнән гаскәр чыга торган мөгез, төрле-төрле ашамлыклар чыга торган тырыс, оча торган палас яисә бик тиз йөртә торган итек һ.б. шундый тылсымлы әйберләрне уйлап чыгаруга этәргеч биргән. Ягъни бу очракта кешенең хыялы аның теләге юнәлешендә хәрәкәт иткән. М. Горький сүзләре белән әйткәндә, «борынгы әкиятләрнең, мифларның, легендаларның... төп мәгънәләре борынгы хезмәт кешеләренең үз хезмәтләрен җиңеләйтергә, аның житештерүчәнлеген көчәйтергә, дүрт аяклы һәм ике аяклы дошманнарга каршы коралланырга, шулай ук сүз көче белән дә, төрле «ырымнар» ярдәме белән дә табигатьнең кешеләргә дошман булган стихиячел күренешләренә йогынты ясарга омтылуларына кайтып кала»[1].

Күргәнебезчә, әкиятләрдәге уйдырма – ул ниндидер мәгънәсезлек түгел, бәлки реаль тормыш, реаль чынбарлык күренешләренең, шулай ук кеше хыялларының үзенчәлекле чагылышы. Әкияттән тормыштагы тәңгәллекләрне эзләү нәтиҗәсез һәм хәтта мәгънәсез эш булыр иде.

Әкиятләр күп гасырлар дәвамында зур үзгәрешләр кичергән, һәм һәр чор аларда үзенең эзен калдырган. Шуңа күрә, бүген без белгән әкиятләрдә, борынгы катлам белән беррәттән, сыйнфый җәмгыятьләргә хас билгеләрне дә һәм хәзерге тормыш детальләрен дә таба алабыз.

* * *

Татар халкы – әкиятләргә бай халык. Ләкин бу хәзинә бик соң җыела башлаган. Беренче басма әкиятләр белән без Мартиньян Ивановның 1842 елда Казанда чыккан «Татарская хрестоматия» дигән китабында очрашабыз. Бу китап дәреслек сыйфатында нәшер ителгән. Шуңа күрә андагы әкиятләрнең (барысы 8 текст) кайда, кайчан һәм кемнән язып алынганлыгы күрсәтелмәгән.

Салихҗан Күкләшевнең «Диване хикәяте татар» дигән хрестоматиясендә (Казан, 1859) шулай ук шактый урынны фольклор материаллары били. Алар арасында М. Иванов хрестоматиясендә булган әкиятләрнең дә кайберләре урын алган.

Себер татарлары фольклорын өйрәнүдә академик В.В. Радлов күп көч куйган. Ул узган гасырның 60 елларында Көнбатыш Себернең татарлар яши торган урыннарында булып, халык иҗатының

---

[1] Горький М. Әдәбият турында. Казан, 1953. Б. 191.

төрле жанрларына караган бик күп әсәрләр язып алган. Галим 19 авылдан җыелган фольклор үрнәкләрен аерым бер том итеп бастырып чыгарган[1]. Бу томда башка жанр әсәрләре белән бергә 40 ка якын әкият тә урнаштырылган.

XIX йөзнең 70 еллары башында, Казан татарлары телен өйрәнү максаты белән, Идел буена венгр галиме Габор Балинт килә. Ул шулай ук үзенең эшен халык иҗаты әсәрләрен туплаудан башлый. Казан шәһәрендә һәм Казан губернасының Мамадыш, Лаеш өязләрендә яшәгән керәшен татарларыннан язып алган фольклор материалларын галим 1875 елда дөнья күргән «Казан татарлары телен тикшерү»[2] исемле хезмәтендә файдалана. Бу китапта халык иҗатының һәр жанрына аерым бүлек билгеләнгән. Әкиятләр бүлегендә барысы 34 текст урын алган. Әкиятләрнең халык сөйләгәнчә язып алынуы һәм латин хәрефләре нигезендә эшләнгән транскрипция белән бирелүе Г. Балинт хезмәтенең әһәмиятен бермә-бер күтәрә.

1877 елда Казанда үткәрелгән IV Археология съездында В.Н. Витевскийның докладысы[3] шулай ук керәшен татарлары фольклоры белән бәйле. Үзенең хезмәтенә, кушымта итеп, ул, җырлар һәм табышмаклар белән бергә, 2 әкият тә терки. Әкиятләрнең берсе – халык арасында киң таралган «Кәҗә белән сарык» әкияте. Бу әсәр басма чыганаклардан беренче мәртәбә әнә шул съезд материаллары җыентыгында күренә.

1890 елда Габделгаллэм Фәезхановның 12 әкият, 3 бәет һәм 500 дән артык мәкальне берләштергән «Хикәят вә мәкалэт» исемле китабы чыга. Бу китаптагы берничә әкият тексты Таип Яхинның башлыча тәрҗемә әсәрләрдән торган «Сабый вә сабыяләр өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗаиб булган гыйбрәтләр» (Казан, 1897) дигән җыентыгында да басылган. Н.Ф. Катанов хезмәтендә[4] Г. Фәезханов китабындагы әкиятләр кабат дөнья күрә.

XIX йөздә басылган әкият җыентыкларының иң зуры – Т. Яхинның балаларга атап нәшер ителгән «Дәфгылькәсәл мин эссабый вә

---

[1] Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872.

[2] Balint Gabor. Kazani-tatar nyelvtanulmanyok. I. Füzet. Kazani-tatar szövegek. Budapest, 1875. (Алга табан: Г. Балинт).

[3] Витевский В.Н. Сказки, загадки и песни нагайбеков Верхнеуральского уезда Оренбургской губернии // Труды четвертого археологического съезда. Том II. Казань, 1891. С. 257–280.

[4] Катанов Н.Ф. Материалы к изучению казанско-татарского наречия. Часть первая. Образцы книжной и устной литературы казанских татар. Казань, 1898.

сабыят» (Казан, 1900) дигән китабы. Анда йөзгә якын текст урнаштырылган. Дөрес, алар арасында тәрҗемәләр дә шактый күп. Ләкин шулай да бу китап үзенең күләме, оригиналь әкиятләрнең саны һәм сыйфаты ягыннан тәкъдир ителергә хаклы.

Күренекле мәгърифәтче К. Насыйри да әкиятләр җыю белән шөгыльләнгән. Ул туплаган уннан артык әкият нигезендә, П.А. Поляков тарафыннан «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» дигән хезмәт тә языла. Бу хезмәт, әлеге әкиятләрнең, гарәп шрифты белән оригиналь тексты, шулай ук «академик транскрипция» дип йөртелгән транскрипциясе һәм рус теленә тәрҗемәсе теркәлгән хәлдә, 1900 елда басылып чыга[1].

XIX гасырда татар халык әкиятләрен җыю һәм бастырып чыгару шуның белән тәмамлана дияргә мөмкин. Шулай да бу урында фин галиме Һейкки Паасонен эшчәнлеге турында әйтеп китәргә кирәк. Ул 1899 елда татар теленең мишәр диалектын өйрәнү максаты белән Самар губернасының Бөгелмә өязенә караган берничә авылда булып (бу авыллар хәзер Татарстанның Чирмешән районына һәм Самара өлкәсенә керә), халыктан җырлар, бәетләр, әкиятләр язып ала. Әмма бу әкиятләр галим үзе исән вакытта дөнья күрә алмый, бары тик 1953 елда гына Эйно Караһка тарафыннан әзерләнеп, «Татар-мишәр халык поэзиясе» исеме белән басылып чыга[2]. Бу хезмәттә 21 әкият һәм 9 бәет урнаштырылган.

Шулай итеп, XX гасыр башына кадәр татар халкының төрле этник төркемнәренә караган әкиятләр җыела, аларпың күбесе басылып чыга, һәм әкиятләрне фәнни өйрәнү өлкәсендә беренче адымнар ясала.

XX гасырга чыккач дөнья күргән әкият китаплары һәм тикшеренүләр, Г. Рәхимнең 4 текстны берләштергән «Халык әкиятләре» (Казан, 1915) исемле җыентыгыннан башкалары, барысы да Октябрь революциясеннән соңгы чорга туры килә.

1924 елда М.А. Васильев татар әкиятләрен һәм легендаларын, бергә туплап, рус телендә чыгара[3]. Анда Татарская Учительская Школа укучылары тарафыннан җыелган 70 тән артык текст урнаш-

---

[1] Насыров А.К. и Поляков П.А. Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов. Известия Общества археологии, истории и этнографии. Т. XVI, вып. 2, 3, 4–6 (приложения). Казань, 1900.

[2] Mischärtatarische Volksdichtung, gesammelt von H. Paasonen / Übersetzt und herausgegeben von Eino Karahka. Helsinki, 1953.

[3] Васильев М.А. Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды. Казань. 1924.

тырылган. Андагы әсәрләрнең кайда, кайчан язып алынулары, шулай ук ул әсәрләрнең рус һәм чит ил галимнәре тарафыннан төзелгән төрле фольклор җыентыкларындагы параллельләре күрсәтелү аның фәнни әһәмиятен тагын да күтәрә. Кызганыч, М.А. Васильев башлаган мөһим эш шуннан соңгы чорда дәвам иттерелмәгән. Гомумән бу хезмәт XX гасырның азагына кадәр татар әкиятләренең рус телендәге иң соңгы фәнни басмасы булып кала.

30 елларның икенче яртысында оста әкиятчеләрне табуда һәм әкиятләрне югары сыйфатлы итеп язып алуда Г. Толымбай шактый гына эшчәнлек күрсәтә. Аның тарафыннан җыелган материаллар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондында саклана (коллекция 21, папка 1–2, саклау берәмлеге 1–76). Аларның кайберләре басылып та чыкты.

Шуннан соңгы чорда халык әкиятләрен җыю һәм бастырып чыгару, шулай ук аларны фәнни өйрәнү беренче чиратта Г. Бәширов[1], Х. Ярми[2], Э. Касыймов[3], Ф. Әхмәтова[4] исемнәре белән бәйле. Әдәбият мәсьәләләренә һәм гомуми фольклорга багышланган кайбер тикшеренүләрдә дә әкиятләр турында аерым фикерләр очрый.

Татар фольклорын (шул исәптән әкиятләрне) туплау һәм өйрәнү тарихы Х. Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» (Казан, 1967) дигән монографиясендә киң яктыртыла. Шуңа күрә биредә бу мәсьәлә кыскача гына бәян ителде.

Әкиятләрнең беренче басмалары чыккан вакыттан алып бүгенге көнгә кадәр теге яки бу дәрәҗәдә фәнни әһәмияткә ия булган

---

[1] Халык әкиятләре. Төзүчесе Г. Разин [Г. Бәширов]. Казан, 1940; Аныкы ук: Тылсымнар дөньясында. Сайланма әсәрләр. 2 том. Казан, 1965. Б. 233–247.

[2] Татар халык әкиятләре. Төзүчеләре Г. Разин [Г. Бәширов], Х. Ярми. Беренче китап. Казан, 1946; Икенче китап. Казан, 1956; Татар халык әкиятләре. Беренче китап [тулыландырылган икенче басмасы]. Казан, 1958; Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967. Б. 83–109.

[3] Абага чәчәге. Татар халкының сатирик әкиятләре. Төзүчесе Э. Касыймов. Казан. 1962; Касыймов Э. Татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор: кандидатлык диссертациясе. Казан, 1966.

[4] Ахметова Ф.В. О генетических корнях татарских сказок о животных.– Тезисы докладов итоговой научной сессии ИЯЛИ за 1970. Казань, 1971. С. 59–61; Сходные поэтические формулы в татарских и башкирских богатырских сказках // Тезисы докладов научно-теоретической конференции «Взаимовлияние и взаимообогащение национальных литератур и искусств в развитом социалистическом обществе. Казань, 1973. С. 62–64; О героическом в богатырских сказках сибирских татар // Тезисы докладов итоговой научной сессии ИЯЛИ за 1972 год. Казань, 1973. С. 85–88; О татарских бытовых сказках // Фольклор народов РСФСР. Вып. II. Уфа. 1975. С. 58–61; Маҗаралы әкиятләр турында // Татар теле һәм әдәбияты. Бишенче китап. Казан, 1976. Б. 195–202.

җыентыкларда якынча исәп белән 500 ләп әкият дөнья күргән[1] (кабат басылган һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән текстлар бу исәпкә кермәде). Болардан тыш дәреслекләрдә һәм вакытлы матбугат битләрендә дә байтак кына әкиятләр басылган. Хәзерге көндә югарыда телгә алынган фольклор фондында гына да әкиятләрнең язмалары 2 меңгә якын санала[2]. Фәнни экспедицияләр нәтиҗәсендә бу байлыкка ел саен дистәләрчә әсәр өстәлеп тора. Казан дәүләт университетына караган Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә дә 50 ләп әкият бар. Казан, Мәскәү, Ленинград һ.б. шәһәрләрнең архивларында шулай ук татар әкиятләренең кулъязмалары саклана. Казан һәм Башкорт дәүләт университетларының, Казан һәм Алабуга педагогия институтларының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары да уку программасы буенча оештырыла торган фольклор экспедицияләре вакытында өлкән буын вәкилләреннән байтак кына әкиятләр язып алалар.

Җыелган бу хәзинә – халкыбызның гаять кыйммәтле рухи байлыгы. Фольклорчылар алдында бу байлыкны тагын да ишәйтү, аны мөмкин кадәр тулырак бастырып чыгару һәм төрле яклап өйрәнү бурычы тора.

* * *

Әкият дигән сүз гарәпчә хикәят (حكاية – сөйләп бирү, хикәя) сүзенең фонетик яктан үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Өлкән буын вәкилләре арасында әкиятне хикәят дип атаучылар әле бүген дә очрый.

Керәшен татарлары әкиятне **мәсәл** яки **мәсәлә** дип йөртәләр. **Мәсәлә** – гарәптән кергән мәсәл сүзенең үзенчәлекле әйтелеше. Мәсәл исә мисал, үрнәк дигән мәгънәне белдерә. Шул нигездә халык иҗатының (соңрак язма әдәбиятның да) бер жанры (әдәп, әхлак өйрәтү өчен читләтеп сөйләнгән хикәяләр) мәсәл дип аталган. Әкиятләрнең элегрәк мәсәлгә тиңләштерелеп йөртелүе халыкта бу әсәрләрнең бигрәк тә дидактик вазифасына өстенлек бирелгәнлеге турында сөйли. Чиләбе өлкәсендә яшәүче керәшеннәрдә (нагайбәкләрдә) әкият мәгънәсендә **мәсәлә** атамасының **әкият** сүзе тәэсирендә үзгәргән варианты – **мәсият** тә йөри. Атама буларак, **әкият**

[1] Ләкин татар фольклористикасында жанрларның тулысынча аерымланмаган булуы сәбәпле, элек әкият дип йөртелгән әсәрләрнең бер өлешен бүген инде без әкият дип атый алмыйбыз. Шуның өстенә, XX гасырның 20 нче елларына басылган әкият җыентыкларында тәрҗемәләр дә очрый.

[2] Бу сан эченә басылып чыккан әкиятләрнең төп (кулъязма) нөсхәләре дә керә (барысы 150 ләп текст).

сүзенең үз варианты ла барлыкка килгән: Мордва АССРдагы Темников мишәрләре сөйләшендә ул **әйхәт** формасын алган.

Себер татарлары әкияткә **йомак** диләр. **Йомак өю, йомак ишү** әкият сөйләүне аңлата. Ә **йомак әйтү** – табышмак әйтү. Чувашларда да шулай ук: юмах – әкият, тупмалли юмах (тапмалы йомак) табышмак дигән сүз[1]. Бүгенге көндә бер-берсеннән бик нык аерылып торган бу ике жанрның, әкият белән табышмакның, әнә шулай исемнәре тәңгәл килү аларның кайчандыр бер ноктадан чыккан булуларына ишарә итә. Аларның уртак исеме **йомак** фольклорның бик борынгы чордагы синкретик хәлен, ягъни жанрларның аерымланмаган, дөресрәге аерымланып җитмәгән чорын чагылдыра. Ләкин моны идеологик синкретизм белән тәңгәлләштерергә ярамый.

Шулай итеп, **йомак** – әкиятнең беренче, ягъни борынгы гамәли вазифасына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән һәм бүгенгәчә сакланып калган иң борынгы исеме. **Мәсәл-мәсәлә, хикәят** дигән атамалар исә әкиятнең соңгырак дәвердәге исемнәре. Ә **әкият** – иң соңгы, яңа исем. Бу сүз басма чыганакларда беренче мәртәбә А. Троянскийның 1833–1835 елларда нәшер ителгән сүзлегендә очрый, һәм аңа «басня, сказка, небыль, небылица, пустошь, вздор» дигән аңлатма бирелгән[2].

Әкият – фольклорда катлаулы күренеш. Шуңа күрә ул әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бүгенге көнгә чаклы аның берсүзсез кабул итәрлек фәнни билгеләмәсе дә юк. Хәзерге вакытта совет фольклористикасында башлыча әкияткә Э.В. Померанцева тарафыннан бирелгән билгеләмә кулланылышта йөри. Ул түбәндәгечә: «Әкият – ул халык поэтик авыз иҗатының төп жанрларыннан берсе булып, уйдырмага таянган, тылсымлы, маҗаралы яисә көнкүреш характерындагы эпик, башлыча чәчмә сәнгать әсәре. Әкият дип телдә яши торган сәнгатьле прозаның төрле төрләрен (хайваннар турындагы гыйбрәтле хикәяләр, тылсымлы әкиятләр, маҗаралы повестьлар, сатирик мәзәкләр) атыйлар, шунлыктан аның үзенә генә хас хосусиятләрен билгеләүдә аерымлык килеп чыга»[3].

Әкиятнең төп сыйфатларын шактый тулы чагылдырса да, бу билгеләмәне әле камил дип әйтеп булмый.

Әкиятләрне төркемләү – шундый ук хәл ителеп бетмәгән мәсьәләләрнең берсе. Татар фольклористикасында да әкиятнең жанр

---

[1] Бу турыда: Исәнбәт Н. Татар табышмаклары турында. // Татар халык табышмаклары. Җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Казан, 1970. Б. 10.

[2] Троянский А. Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских. Т. I. Казань, 1833. С. 58.

[3] Краткая литературная энциклопедия. Т. 6. М., 1971. 880 столб.

чикләре соңгы вакытка кадәр анықланмыйча килде. Легенда, мифик риваять (аерым алганда, ияләр турындагы хикәяләр) махсус өйрәнелмәү сәбәпле, әлеге жанрларга караган әсәрләр шулай ук әкиятләр рәтендә йөртелде, һәм бу хәлнең әле дә тәмам ачыкланып җиткәне юк.

Фәнни-тикшеренү максатларында әкиятләр күп халыкларда нигездә өч Төргә бүлеп карала: хайваннар турындагы әкиятләр, тылсымлы әкиятләр һәм көнкүреш әкиятләре. Әлбәттә, бу бүленештә шартлылык шактый зур. Чөнки тикшеренүчеләр әкиятләр арасында үзенчәлекле сыйфатларга ия булган байтак кына төркемнәрне аералар (мифик, легендар, тарихи, героик, мажаралы, сатирик, юмористик, новеллистик, табышмак, көлдергеч, алдавыч һ.б.), һәм бу төркемнәрнең кайберләре әлеге өч төр кысаларына гына сыеп бетә алмый. Шулай да күзәтү характерындагы хезмәтләрдә һәм әкият җыентыкларының төзелешендә нигез итеп жанрның өч төргә бүленешен алу гадәткә кергән. Фәндә әлеге төрләрне мөстәкыйль жанрлар итеп санау да бар[1]. Без исә аларны бер жанрның аерым төрләре итеп карыйбыз.

## Хайваннар турындагы әкиятләр

Татар халык әкиятләре составында хайваннар турындагы әкиятләр бик аз. Язмалар саны буенча исәпләгәндә, алар чама белән әкият репертуарының нибары 5 процентын тәшкил итә. Бу әсәрләрнең күләмнәре дә зур түгел.

Халык арасында «Салам-Торхан», «Аю, Бабай, Төлке», «Кәтән Иваныч», «Төлке», «Шәрә бүре», «Торна белән Төлке», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрендәге сюжетлар аеруча киң таралган.

Мондый әкиятләрнең төп геройлары – кыргый җанварлар, йорт терлекләре һәм җәнлекләре, кошлар, сөйрәлүчеләр, балыклар, бөҗәкләр. Ләкин татар әкиятләрендә соңгы өч төр популяр түгел.

Хайваннар турындагы әкиятләр әкият жанрының гына түгел, бәлки гомумән фольклорның иң борынгы күренешләреннән санала.

Кеше хайваннар дөньясыннан аерылгач та, әле беренче чорларда алар белән бер үк шартларда, бер әйләнә-тирәдә яшәгәнлектән, аның фикерләвендә хайваннар белән бәйлелек зур урын тоткан. Борынгы кеше үзендәге сыйфатларның хайваннарда да булуына ихлас күңелдән ышанган. Хайваннарны ул үзе кебек үк сөйләшә һәм фи-

---

[1] Пропп В.Я. Жанровый состав русского фольклора // Русская литература. 1964. № 4. С. 60.

керли ала дип исәпләгән (антропоморфизм), хәтта үзен алар белән туганлык мөнәсәбәтендә тора дип уйлаган,– ягъни ул дәвердә инстинктив кеше, вәхши үзен табигатьтән аермый.

Хайваннар белән туганлык мөнәсәбәтенә ышану борынгы община строе чорында һәр ыруның ниндидер берәр хайванны үзенең нәсел башы итеп санавына китергән (тотемизм). Бу хайванны, ягъни тотемны, үтерергә ярамаган, чөнки ул әлеге ыруны яклаучы һәм саклаучы дип ышанылган. Тотемга ышану нәтиҗәсендә хайваннар культы барлыкка килгән.

Аучылык яшәешнең хәлиткеч чыганагы булган заманда борынгы кеше төрле хайваннарның үзенчәлекле сыйфатларын, йөрешкыланышларын, бер-берсенә мөнәсәбәтләрен һәм аларның тормышы белән бәйле башка якларны бик яхшы белгән. Ау вакытларында, әлбәттә, еш кына игътибарга лаеклы хәлләр, трагик һәм комик вакыйгалар булган. Менә шул факторларның барысы да (антропоморфик күзаллаулар, тотемистик һәм хайваннарга бәйле башка ышанулар, реаль күренеш һәм вакыйгалар) хайваннар турында төрле характердагы хикәяләрнең барлыкка килүенә китергән.

Хайваннар турындагы бүгенге әкиятләр үзләренең борынгы рәвешеннән (хайваннар турындагы хикәяләрдән) бик нык аерылалар. Бүгенге әкиятләрдә сүз хайваннар турында барса да, аларда инде чынлыкта кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр сурәтләнә, икенче төрле әйтсәк, бу әсәрләрдә читләтеп әйтү, киная, ягъни аллегорик сыйфат өстенлек алган. Ләкин элек заманда әлеге әкиятләр бары тик хайваннар турындагы әсәрләр генә булганнар.

Хайваннар турындагы әкиятләрнең генезисында өч этапны аерымларга мөмкин.

Иң элек, һичшиксез, теге яки бу хайван турында төрле ышанулар туган. Мондый ышануларның бер өлеше, югарыда искә алганыбызча, тотем белән бәйле рәвештә барлыкка килгән (әйтик, тотем хайванны үтерергә яисә аңа нинди дә булса зарар китерергә ярамау, аның төрле әгъзаларының тылсымлы кодрәткә ия булуы һ.б.ш.ларга ышану). Татар халкында да, башка халыклардагы кебек үк, тотемизмга бәйле кайбер ышанулар хәтта бүгенге көнгә чаклы сакланып калган. Мәсәлән, пошины үтерергә ярамый дигән ышануның яшәве мәгълүм[1]. Куркудан авыруга сабышкан кешеләрне аю яки куян тырнагы белән имләгәннәр[2]. Бизгәк тотып ятучы кеше аркылы татарлар аю үткәргәннәр, авыруның өстенә аю яки бүре тиресен япканнар,

---

[1] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967. С. 350.
[2] Мухамедова Р.Г. Татары-мишари. М., 1972. С. 188.

ә калтыраткан вакытта куенына елан тиресе салганнар[1]. Төрле очраклар уңае белән корбан чалу өчен элек-электән каз, үрдәк, тавык, сарык тәкәсе, үгез һәм ат киң файдаланылган. Галимнәрнең фикеренчә, бу йолаларда, һичшиксез, борынгы гадәт – тотемның итен авыз итеп карау гадәте чагыла[2]. Дәвалану һәм гөнаһлардан арыну өчен, елга бер генә мәртәбә булса да тотем итен ашау кирәклегенә ышану элек заманда байтак халыкларда (шул исәптән төркиләрдә дә) киң таралган булган[3].

Тотемизм билгеләре татар халкының гамәли-декоратив сәнгатендә дә чагылмый калмаган. Болгар чорына караган бизәнү әйберләрендә арыслан, юлбарыс һәм үрдәк башлары очрый. Агачка сырлап-кисеп ясалган бизәкләрдә күбесенчә төрле кош сурәтләрен күрергә мөмкин[4]. Гомумән, кош образы Болгар сәнгатендә күренекле урынны тоткан, һәм ул, мөгаен, сакчы вазифасын үтәгәндер. Үрдәк сурәтенең колак алкасында, ә лачын, байгыш, ике башлы кош һәм пар күгәрчен сурәтләренең башлыча тәрәзә йөзлегендә очравы шуңа ишарә итә.

Әлбәттә, хайваннарның сыннарын һәм төрле әйберләрдә очрый торган сурәтләрен ясау чагыштырмача соңгырак чорда башланган. Бик борынгы дәвердә исә сакчы-амулетлар сыйфатында тотем хайванның аерым өлешләре: сөякләре, тешләре, тиресе, мөгезе һ.б. әгъзалары файдаланылган. Галимнәрнең фараз итүенчә, ул заманда йорт түбәләренә ат һәм кошларның баш сөякләре куелган[5]. Татарларда яшелчә, икмәкләр уңсын өчен, бакча яки кыр читәне казыкларына ат башы сөяге элеп кую гадәте булу[6] да нәкъ менә шуны раслый. Өй түбәсенә яисә ишек өстенә болан, сыер һәм тәкә мөгезләре кую хәтта аерым урыннарда бүгенге көнгә кадәр сакланган.

Татарларда шулай ук бүре тешенә бәйле ышану да яши. Татарстанның Буа районында, мәсәлән, кесәсендә бүре теше йөрткән кешегә дошман сүз әйтә алмый дигән ышану бар.

Тылсымлы әкиятләрдә геройга ярдәм итүче, аңа уңыш һәм бәхет китерүче әйберләр сыйфатында кош канаты, каурый, йон, балык тәңкәсе, мөгез кебек әгъзалар зур урын алып тора.

---

[1] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956. Б. 197.
[2] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. С. 351.
[3] Соколова З.П. Культ животных в религиях. М., 1972. С. 37.
[4] Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. Казань, 1969. С. 97, 101. (Алга табан: Ф.Х. Вәлиев).
[5] Соколова З.П. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 39–40.
[6] Насыйри К. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 199.

Алтын Урда чорындагы акчаларның кайберләренә шулай ук җәнлек һәм кош сурәтләре төшерелгән. Е.Д. Турсунов фикеренчә, мәсәлән, козгын сурәте төшерелгән тәңкәләрне нәсел башы итеп козгын саналган кабилә яки ырудан чыккан ханнар суккан булырга тиеш[1], Татарстан территориясендә хайван исемнәре белән аталган байтак кына авыллар бар. Дөрес, генетик яктан аларның барысын да тотем белән бәйләп карау хата булыр иде. Шулай да Минзәлә районындагы Аю авылының атамасы башкортларның үсәргән кабиләсенә караган **айыу** ыруы исеменә, ә Апас районындагы Ябалак авылы атамасының килеп чыгышы башкортларның **ябалак** ыруы исеменә яки XIII–XIV гасырларда Татарстан һәм Башкортстан территориясенә үтеп кергән кыпчак һәм кыпчаклашкан төрки кабиләләр исеменә мөнәсәбәтле дип фараз ителә[2].

Күргәнебезчә, тотемизм эзләре тормышның төрле өлкәләрендә очрый. Әмма бу мәсьәләдә бер факт игътибарга лаек: соңгырак дәвергә караган материалларда гына түгел, Болгар чоры табылдыкларында да хайван сурәтләренең күбесе стильләштерелеп, гомумиләштерелеп, шартлы рәвештә генә эшләнгән. Шунлыктан аларның төрләрен аеру гаять читен. Чигеп ясалган сурәтләрдән җайдаклы пар ат, ярканат һәм балык кебек затларны да, артык бизәкләнгәнлектән, зур кыенлык белән генә танырга мөмкин[3]. Бу исә тотемизм эзләре Болгар чорында ук инде бөтенләй диярлек (ләкин бөтенләй үк түгел) югалган дигән нәтиҗәгә китерә. Моңа, беренчедән, халыкның утрак тормышка бик иртә күчүе һәм, икенчедән, ислам диненең мәҗүсилек тәртипләре белән аяусыз көрәш алып баруы өстәмә сәбәп булган.

Югарыда сөйләнгәннәрдән ачыкланганча, яшәүнең төп чыганагы аучылык булган борынгы җәмгыятьтә тотемистик ышанулар утилитар максатларда зур урын тоткан. Без менә шул ышануларны һәм хайваннарның төрле сыйфатлары, йөреш-кыланышлары, башка хайваннарга һәм кешегә мөнәсәбәтләре нигезендә туган бүтән төрле ышануларны, шулай ук хайваннар катнашындагы реаль вакыйгалар нигезендә барлыкка килгән көнкүреш хикәяләрен хайваннар турындагы әкиятләр генезисында беренче этап итеп карыйбыз.

Тора-бара тотемистик һ.б. ышанулар нигезендә төрле легендалар иҗат ителгән. Шундый әсәрләрдән халык арасында шактый таралган «Аю белән хатын» дигән легенданы искә алып узыйк. «Әүвәле

---

[1] Турсунов Е.Д. Генезис казахской бытовой сказки. В аспекте связи с первобытным фольклором. Алма-Ата, 1973. С. 54.

[2] Саттаров Г.Ф. Татарстан АССРның антропотопонимнары. Казан, 1973. Б. 16.

[3] Вәлиев Ф.Х. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 97.

заманда бер хатын урак урырга баласы белән барган, ди. Ул ура башлагач ук, аның янына бер аю килгән, ди. Ул аюның аягына шырпы кадалган икән, ди. Ул хатынга аягын күрсәтеп килгән, ди, хатын аның аягыннан шырпысын алган, ди. Шуның өчен аю хатынга бер умарта бал китереп биргән, ди»[1].

Бу легенда антропоморфик күзаллау нигезендә барлыкка килгән. Менә шуның ише легендалар һәм мифлар хайваннар турындагы әкиятләр генезисында икенче этапны тәшкил итә.

Өченче этап хайваннар хакындагы хикәяләрнең сүз сәнгате әсәрләре булып җитешүе, ягъни аларның гамәли вазифадан арынып, эстетик вазифа үти башлавы белән билгеләнә. Бу әсәрләр хайваннар турындагы ышанулар, көнкүреш хикәяләре, мифлар һәм легендаларның органик кушылмасыннан гыйбарәт. Бу этапта инде фантазиягә киң юл ачыла, һәм әкиятләр ирекле үсеш ала. Шулай итеп, эстетик һәм идея вазифаларын үти торган сәнгать әсәрләренең бик борынгы төрләреннән берсе – хайваннар турындагы әкиятләр барлыкка килгән. Соңрак, җәмгыятьнең социаль-тарихи үсеше нәтиҗәсендә, бу әкиятләргә аллегорик сыйфат өстәлеп, кайберләре мәсәлгә дә әверелә.

Татар халкының хайваннар турындагы әкиятләрендә тотемистик мотивлар бик аз сакланган. Шулардан иң күренеклесе итеп хатын-кызның аю белән никахы турындагы мифологик сюжетны күрсәтергә мөмкин. Бу сюжет генетик яктан тотемистик мифка барып тоташа[2]. Әлеге сюжетка корылган татар әкиятләрендә аю хатын-кызны, кагыйдә буларак, урманда урлап китә. Шуннан соң алар аюның өнендә яши башлыйлар. Алардан туган бала бик тиз үсә һәм гаять көчле баһадирга әверелә. Моңа мисал итеп «Аю улы Атыләхмәтгәрәй» дигән әкиятне алырга мөмкин. Бу әкияттә хайван белән кеше арасындагы никах мөнәсәбәте һәм мондый никахтан туган баланың искиткеч көчле булуы гына түгел, бәлки кешенең хайван өнендә булу факты үзе генә дә әлеге сюжетның тотемизм белән тыгыз бәйләнеше турында сөйли[3].

Миф һәм легендалардагы уңай персонажлар әкиятләрдә тискәре булырга да мөмкин. Игътибар итсәк, татар легендаларында акыллы, изге, көчле персонажлар булган аю һәм бүре хайваннар турында-

---

[1] Балинт Г. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 23.

[2] Лебедева Е.П. Архаические сюжеты эвенкийской сказки о животных // Языки и фольклор народов сибирского Севера. М.– Л., 1966. С. 195.

[3] Бу факт В.Я. Проппның «Исторические корни волшебной сказки» дигән хезмәтендә шулай шәрехләнә (Б. 208).

гы әкиятләрнең берсендә дә уңай яктан сурәтләнми. Әкияттә алар – аңгыра, ахмак, юньсез, куркак. Мәсәлән, «Төлке», «Аю белән Төлке», «Аю, Бүре, Төлке», «Хәйләкәр төлке» әкиятләрендә аю һәм бүре төлке тарафыннан алдана. «Батыр әтәч» дигән әкияттә шул ук аю һәм бүре кәҗәдән куркып, качарга мәҗбүр булалар. «Җүләр бүре» әкиятендә дә эт, кәҗә тәкәсе, дуңгыз бүрене көлкегә калдыралар, һәм аңгыралыгы нәтиҗәсендә, бүре һәлак була.

Димәк, легендаларда хөрмәт ителә торган җәнлекләр әкиятләрдә шаяру объектына әверелә. Тарихның прогрессив үсеше нәтиҗәсендә хайваннар турындагы әкиятләрдә миф һәм легендалардан килә торган архаик мотивлар акрынлап үзләренең мифологик сыйфатларын югалта баралар.

«Аю, Бабай, Төлке», «Шәрә бүре», «Мәче, Юлбарыс һәм Кеше» кебек әкиятләр нәкъ менә табигать көчләренең буйсындырылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип уйларга нигез бар. Бу чорда инде, кеше, әлбәттә, хайванга караганда акыллырак, тапкыррак булырга тиеш. Андый әкиятләрнең кайберләрендә көчле хайванга каршы карт (ягъни, физик яктан йомшак, ләкин акыллы һәм зирәклеге белән көчле) кеше куелу моны тагын да ачык күрсәтә. Әлеге әкиятләрдә аю, бүре, юлбарыс кебек көчле хайваннар кеше тарафыннан алданалар һәм үтереләләр.

Шулай итеп, кайчандыр изге саналган хайваннар кешелек җәмгыяте үсешендәге билгеле бер чорда үзләренең элекке дәрәҗәләрен җуялар һәм көлке объектына әвереләләр, алай гына да түгел, хәтта хөкем ителәләр, үтереләләр. Бу инде тотемизмның тулысынча кире кагылуы дигән сүз, һәм бу төр әкиятләр бары тик шул шартта гына туа алган.

Төп персонажлары йорт хайваннары булган әкиятләрнең күбесе үзләренең килеп чыгышы белән соңгырак чорга карый. Ул вакытта инде кешенең аңы шактый үскән һәм мифологик күзаллауларның зур өлеше онытылган була. Шуңа карамастан, андый әкиятләрнең кайберләрендә архаик мотивлар сакланып калган. Мисал итеп «Кәҗә белән Сарык» әкиятен күрсәтергә мөмкин. Юлда капчыкларына бүре башы табып салган кәҗә белән сарык бүреләрне куркуга салалар һәм качарга мәҗбүр итәләр. Аю һәм бүреләр эзәрлекли башлагач, алар агач башына менеп яшеренәләр. Агач төбендә эзне югалткач, аю, бүреләр уртасына утырып, ногыт карый башлый[1]. Шул чак сарык тәкәсе боларның өстенә егылып төшә. Зирәк кәҗә

---

[1] Ногыт карау (ногыт салу) – ногыт борчагы ярдәмендә күрәзәлек итү.

тәкәсе агач башыннан: «Ногыт караучысын тот!..» – дип кычкыра. Ерткычлар янә куркып качалар.

Бу әкияттә үзенчәлекле рәвештә тотемистик мотив чагыла. Төрки ыруларда кәҗә тәкәсе һәм сарык тәкәсе тотем хайваннар булган. Татарларда сарык тәкәсе йонын им-том итүдә файдалану, «Күк тәкә» дигән җыен булу, өй башына һәм башка урыннарга тәкә мөгезен кую гадәте дә шул турыда сөйли.

Әкияттә кәҗә тәкәсенең акыллы һәм зирәк, ә сарык тәкәсенең беркатлы һәм булдыксыз итеп сурәтләнүе борынгы дуалистик мифлар табигате белән бәйле. Бу хайваннар дуалистик мифлардагы шундый ук сыйфатларга ия итеп сурәтләнгән ике туганны гәүдәләндерә[1]. Мәгълүм булганча, кешелек җәмгыятенең балачагындагы дуалистик оешма дәверен чагылдырган мифларда капма-каршы фратрияләрнең нәсел башы итеп саналган ике туганның берсе көчле, акыллы, тәҗрибәле, зирәк, җитез итеп, ә икенчесе көчсез, ахмак, авыр хәрәкәтле, булдыксыз итеп сурәтләнгән.

«Хәйләкәр әтәч» дигән әкияттә исә йоту мотивы сакланган: аю, бүре һәм төлке әтәч эченә керәләр һәм, әтәч кушкан чакта эченнән чыгып, аның әмерен үтиләр. Йоту мотивы тотемизм белән турыдан-туры бәйләнгән[2].

Хайваннар турындагы әкиятләрдә архаик мотивлар бер тотемизм белән генә чикләнми. Бу әсәрләрдә хәйләле шаяру, трюклар традициясе дә шактый урын алган. Бик борынгы күренеш булган хәйләле шаяру дуалистик миф һәм көнкүреш хикәясе тәэсирендә барлыкка килгән[3]. Ләкин ул әлеге миф яки көнкүреш хикәяләре белән бәйле сюжетларда гына дәвам итеп калмаган, бәлки бу традиция нигезендә хайваннарның оста, хәйләле кыланышлары һәм шаярулары турында күп кенә яңа сюжетлар да туган. Мондый сюжетлар өчен материал, башта ук әйткәнебезчә, борынгы аучылар һәм терлекчеләр тарафыннан кыргый хайваннарның һәм кошларның тышкы сыйфатларын, йөреш-кыланышларын конкрет күзәтүләре нәтиҗәсендә тупланган.

«Торна белән Төлке» әкияте әнә шундыйлардан. Торна белән төлке бер-берсен кунакка чакырышалар. Төлке тары боткасын сай табакка салып, торнаны сыйлый. Әлбәттә, торна бер ярманы да эләктерә алмый, ризыкны төлке үзе ялап бетерә.

Торна исә, үз чиратында төлкене кунакка чакырып, чумарны гөбегә сала. Нәтиҗәдә, торна үзе туклана, ә төлке ач кала.

---

[1] Турсунов Е.Д. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 50.
[2] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. С. 208.
[3] Турсунов Е.Д. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 65.

Әсәрдә сыйнфый мотивлар юк, шулай ук бернинди мораль нәтиҗә дә ясалмый, бары тик хәйләгә каршы хәйлә генә бар.

Хәйләле шаяру күренешен без «Кәҗә белән Сарык» әкиятендә дә очраткан идек. Әмма төлке белән бәйле әкиятләрдә бу традиция аеруча зур урын алган.

Хайваннар турындагы әкиятләрдә тагын башка төрле архаик мотивлар да очрый. Бүрене яисә аюны алдавыч чокырга төшереп, яндырып үтерү («Кәҗә белән Бүре», «Аю белән өч кыз»), шулай ук бүдәнәнең төлкене куркыныч урынга алдап китерүе («Бүдәнә белән Төлке») кебек эпизодлар примитив ау ысулларын чагылдыра торган, әмма шактый трансформацияләнгән бик борынгы сюжетлар булырга охшый.

Сыйнфый җәмгыять шартларында хайваннар турындагы әкиятләрнең чикләре киңәя, һәм бу әсәрләр инде аллегорик формада төрле сыйныфлар арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыра башлыйлар. Бер якта аю, бүре, төлке, арыслан, юлбарыс кебек көчле ерткычлар торса, икенче якта без ат, сыер, сарык, кәҗә, эт, мәче, әтәч кебек йорт хайваннарын күрәбез. Файдалы булганга күрә, йорт хайваннары мондый әкиятләрдә уңай яктан сурәтләнә, алар кыргый хайваннар белән көрәштә һәрвакыт җиңеп чыгалар. Мәсәлән, «Кәҗә белән Сарык», «Кәҗә белән Бүре», «Җүләр Бүре» һ.б. әкиятләрдә йорт хайваннары кыргый ерткычларны (башлыча бүрене) куркыталар, алдыйлар яки һәлак итәләр. Әгәр көрәш кыргый җанварларның үз араларында барса, җиңү, кагыйдә буларак, көчсез хайван ягында була.

Хайваннар турындагы әкиятләрдә иң популяр киек – төлке. Ул барлык әкиятләрнең яртысыннан артыграгында бар. Ә яртысына якынында аю һәм бүре катнаша. Калган кыргый җанварлар һәм кошлар (куян, арслан, юлбарыс, бурсык, кабан дуңгызы, сукыр тычкан, гөберле бака, торна, тукран, бүдәнә, ябалак, чыпчык, песнәк, күке, ала карга һ.б.лар) бер-ике мәртәбә генә очрый.

Төлке барлык әкиятләрдә диярлек хәйләкәр, алдакчы, ялагай итеп сурәтләнә. Күпчелек очракта ул үзенең максатына ирешә. Аю һәм бүре, киресенчә, тупас, ахмак, хәтта куркак; еш кына алар алданалар, куркып качалар яки үтереләләр. Моның мисалларын без әле генә искә алынган әкиятләрдә күреп үттек. Аюны һәм бүрене йорт хайваннары гына түгел, төлке дә алдый, хурлыкка калдыра, хәтта һәлакәткә илтә. Мәсәлән, «Төлке» дигән әкияттә, төлке киңәше буенча, балык тотам дип койрыгын бәкегә тыгып утырган аю, кешеләр кыйный башлагач, бозга каткан койрыгын өзеп кача. «Төлке белән Бүре» дигән әкияттә шул ук тозакка эләккән бүрене кешеләр кыйнап үтерәләр.

«Аю белән Төлке», «Аю, Бүре, Төлке», «Наян төлке», «Хәйләкәр төлке» һ.б. әкиятләрдә аю һәм бүре шулай ук төлке тарафыннан алданалар.

Арыслан һәм юлбарыс әкиятләрдә иң көчле хайваннар итеп сурәтләнәләр һәм рәхимсез тиран образын гәүдәләндерәләр. Алар барлык хайваннар өстеннән хакимлек итәләр. Үзеннән көчсез хайваннарны эзәрлекли, ә аю һәм бүре кебек киекләрне бик оста алдый торган төлке дә арыслан йә юлбарыс алдында баш иярга, ялагайланырга, үз мәнфәгате өчен башкаларны әләкләргә мәҗбүр була һәм бәла-казадан имин кала.

«Арыслан, Төлке, Бүре» дигән әкияттә төлке бергә аулаган корбаннарны бүлгән вакытта аларның барысын да арысланга бирә. Биредә ул оста күзәтүче, мохитны сизгер тоеп, һәр шартка яраклаша белүче, үзенә кирәк чагында көчлеләр алдында тәлинкә тотудан да тартынмаучы хәйләкәр һәм ялагай түрәне яисә эшкуарны гәүдәләндерә.

Икенче бер әкияттә дә үзенең зирәклеге һәм мәкере белән төлке кыен хәлдән уңышлы чыга. Авыру арысланның хәлен белергә килүчеләр арасында төлке күренмәгәч, бүре аңа төлкене яманлый. Моны белгән төлке, арысланга килеп, үзенең дару эзләп кичегүен, әгәр ул бүренең арт аягындагы сеңере белән дәваланса, терелячәген әйтә. Арыслан шунда ук бүрене тотып, аның арт аягындагы сеңерен өзеп ала.

Бу әкиятләрдә изүче сыйныфларның үз эчендәге, ягъни эксплуататорларның төрле катлаулары арасындагы каршылыкларга ишарә ителә.

Ләкин төлке йорт хайваннары белән конфликтка керсә, һичшиксез, җиңелә. Шушы уңайдан төлке һәм әтәч образлары сурәтләнгән «Гакыллы хәйлә хикәяте» дигән әкиятне карап узыйк. Төлке – әтәчнең явыз дошманы. Ул хәйләкәр һәм мәкерле, үз максатына ирешү, ягъни әтәчне ашау өчен корбанын мактаудан, аның адресына төче комплиментлар әйтүдән дә тартынмый. «Мин шәһәрдән кайтып киләмен, синең бик хуш авазыңны ишетеп, тавышыңнан ләззәт алаем дип, синең яныңа килдем», – ди төлке дивар өстендәге әтәчкә.

Төлкенең комплименты максатка омтылуның башы гына. Шуннан соң ул үзенең тагын да мәкерлерәк хәйләсенә керешә: янәсе, патша барча халыкларның үзара дус яшәргә тиешлеге турында фәрман кылган. «Әтәч дус, син дивар өстеннән төшеп, минем яныма кил, ике дус бергә кочаклашып йөрик, патша фәрманын җиренә җиткергәнне илгә күрсәтик», – ди ул. Ләкин әтәч тәҗрибәле, ул төлке сүзләренә алданмый. Алай гына да түгел, дошманына каршы

үзе хәйлә кора: кинаяләп кенә, авыл ягыннан эт килүен белдерә. Төлке, әлбәттә, тизрәк качу ягын карый. Шулай итеп, беркемгә дә зарар итми торган йорт кошы әтәч үзеннән күп мәртәбә көчлерәк ерткычтан өстен булып чыга, төлкенең хәйләсе никадәр генә нечкә булмасын, ул, аңардан да остарак хәйлә корып, дошманын җиңә, аны көлкегә калдыра.

Төп геройлары әтәч һәм төлке булган икенче бер әкияттә («Әтәч белән Төлке») без әтәчне агач башында күрәбез. Монда да төлке тәмле телле: «Әй, дус, агач башыннан төшмисеңме, җәмәгать булып бергә намаз укыр идек», – ди ул. Әтәч биредә шулай ук төлкенең йомшак ягыннан файдалана: «...имам агач артында йоклап ята, имамны уят», – ди. Төлке барып караса: агач артында бер эт ята.

Бу әкияттә әтәчнең качып барган төлкегә: «Кая барасың, җәмәгать булып намаз укырбыз», – дигән сүзләре көчле сарказм белән сугарылган. Төлке монда да кыен хәлдән тапкырлык белән чыгарга тырыша: «Тукта, сабыр ит, тәһарәтем бозылды, тәһарәт яңартып килим», – ди ул. Ләкин төлкенең бу җавабы үзенең куркаклыгын фаш итү булып кына яңгырый.

Гомумән, төп персонажлары әтәч һәм төлке булган барлык әкиятләрдә төлке әтәч тарафыннан хурлыклы рәвештә җиңелүгә дучар була.

Йорт хайваннары гына түгел, кайчак тукран, бүдәнә кебек кошлар да хәйлә ягыннан төлкене уздырып, аны кыен хәлдә калдыралар.

Ә менә «Хәйләкәр әтәч», «Аю, Бабай, Төлке» дигән әкиятләрдә без төлкене ярдәмче вазифасында күрәбез. «Салам-Торхан» дигән әкияттә исә төлке, патшаны алдап, ярлы егетне шул патшаның кызына өйләндерә.

Шулай итеп, хайваннар турындагы әкиятләрдә төлке образы ике төрле тасвирлана. Әкиятләрнең күбесендә ул мәкерле, хәйләкәр һәм усал ерткыч булса, кайбер әкиятләрдә кешегә ярдәм итә торган акыллы, тапкыр һәм җитез хайван итеп тә сурәтләнә.

Хайваннар арасында ерткычлык табигате аеруча калку чагылган персонажлардан иң күп очрый торганы – бүре. Халык үзенең күпьеллык тәҗрибәсе нигезендә, эксплуататорларның кешелексезлегенә тирән ышанган, һәм бу ышану хайваннар турындагы әкиятләрдә дә чагылмый калмаган. «Җүләр бүре», «Шәрә бүре» дигән әкиятләрдә бүре комсыз, шул ук вакытта ахмак һәм беркатлы итеп сурәтләнә. Аны төрле хайваннар бик җиңел алдыйлар һәм рисвай итәләр.

Мондый сатирик пландагы әкиятләр идея ягыннан көнкүреш әкиятләренә бик якын тора. Аларда да ярлы белән бәрелештә бай көлкегә кала, ә гади халык вәкиле акылы һәм зирәклеге белән

җиңүгә ирешә. Борынгы аллегорик сюжетларның төп образлары сыйнфый җәмгыятьне сурәтләү өчен дә кулай булып чыккан.

Хайваннар турындагы күпчелек әкиятләр сыйнфый җәмгыять шартларында төрле сыйнфый төркемнәрнең үзара мөнәсәбәтләрен ачык гәүдәләндерә. Аларда сыйнфый дошман мораль яктан гаепләнеп кенә калмый, бәлки физик яктан да җәзага тартыла һәм юк ителә.

Бу төр әкиятләрнең тагын бер мөһим сыйфаты бар: аларда аллегория аша кешеләргә хас гомуми кимчелекләр дә тәнкыйть ителә. Бу очракта хайваннарның гадәтләре, йөреш-кыланышлары кешеләрдә очрый торган тискәре сыйфатларны күрсәтү өчен файдаланыла.

Мәсәлән, «Әтәч патша» дигән әкияттә үзен иң матур, иң батыр дип санаучы әтәч образы аша кәпрәю, масаю, шапырыну кебек сыйфатлардан бик үткен көленә. Мактану өчен сылтау булган сыйфатлар чынлыкта аларның иясенә бернинди дә файда китерә алмый, нигезсез мин-минлек бик тиз көлке объектына әверелә. Әкияттә бер үк вакытта тәлинкә тотучылар да мәсхәрәгә кала.

Хайваннар турындагы әкиятләрдә ялкаулык, эш сөймәү кебек сыйфатлар аеруча көчле ирония белән сурәтләнә. «Песәй» дигән әкияттә мондый эпизод бар: песи, әтәч, күркә, торна, үрдәк бер тауда яши башлыйлар. Көннәр суыта башлагач, песи өй салырга тәкъдим итә. Ләкин песигә өйне берүзенә генә салырга туры килә. Суыклар башлангач, теге хайваннар берәм-берәм килеп, аңардан өенә кертүен үтенәләр, керт-мәсә өйне җимерү белән куркыталар. Песи барысын да кертергә мәҗбүр була.

Әкияттә аллегорик рәвештә, хезмәтнең мәгънәсе, зарурлыгы һәм матурлыгы бик ачык күрсәтелә, хезмәт сөймәүчеләр исә хурлыкка кала, аларга карата күңелдә тискәре фикер уяна.

Мондый әкиятләрдә кешеләрдә очрый торган башка кимчелекләр дә тәнкыйть ителә. Яхшылыкның кадерен белмәү, игелекне оныту кебек сыйфатларны да халык кискен гаепли («Кәҗә һәм Сарык»). «Батыр әтәч» дигән икенче бер әкияттә ялганчылык һәм куркаклык гаепләнә.

Кешеләргә хас гомуми кимчелекләр йорт хайваннары образларында гына түгел, кыргый хайваннар образларында да чагыла. Мәсәлән, «Аю белән Төлке» әкиятендә алдакчылык, мәрхәмәтсезлек һәм хыянәт фаш ителә. Хәйләкәр төлке үзе белән бергә яшәүче аюдан яшереп, бал һәм майны ашап бетерә дә, авыру дустына яла ягып, аны бөтенләй ташлап китә.

Бу әкияттә төлке гаепләнә, чөнки аның хәйләсе һәм җитезлеге усал нияткә хезмәт итә.

Югарыда телгә алынган әкиятләрдә сатира сыйнфый дошманнарны түгел, ә төрле тискәре сыйфатларга ия булган кешеләрне камчылауга юнәлдерелә. Шуңа күрә ул әсәрләрдә сарказмга караганда ирония өстенлек итә. Бу төркем әкиятләр халык моралеп, халыкның әхлякый критерийларын раслыйлар. Аларны, сатирик булудан бигрәк, юмористик әсәрләр дип билгеләргә мөмкин.

Конфликт характеры җәһәтеннән хайваннар турындагы әкиятләр әнә шулай ике төркемгә (сыйнфый конфликтлы һәм сыйнфый булмаган конфликтлы әкиятләргә) аерылса, персонажларның составы ягыннан аларны өч төркемгә бүләргә мөмкин: 1) персонажлары кыргый хайваннар булган әкиятләр; 2) персонажлары йорт хайваннары булган әкиятләр; 3) персонажлары кыргый һәм йорт хайваннары булган әкиятләр.

Сюжет структурасы ягыннан караганда, бик аз гына санда кумулятив әкиятләр аерымланып тора («Курбала», «Песәй»).

Хайваннар турындагы әкиятләрне аларда кеше образының булу-булмавына карап та төркемләргә мөмкин.

Бу урында кыскача гына кеше образына тукталып узыйк.

Кеше хайваннар турындагы әкиятләрнең сан ягыннан дүрттән өч өлешендә катнаша. Ләкин аның катнашуы төрлечә: әкиятләрнең кайберләрендә ул телгә генә алына, яки аның берәр эш башкаруы турында хәбәр ителә; йә булмаса ул берәр ситуациядә күренеп ала, ягъни аның катнашуы эпизодик характерда була; ә кайберләрендә кеше, төп персонажларның берсе буларак, әсәрнең буеннан-буена катнаша.

Эпизодик характерда булганда, кеше әкиятнең баш өлешендә яисә азагында очрый. Әсәрнең башында кешенең роле экспозицион вазифа үтәү белән чикләнә. Мисал өчен «Җүләр бүре» дигән әкиятне алыйк. Карт үзенең картаеп хәлсезләнгән, инде хезмәткә ярамый башлаган этен, урманга алып барып, агачка бәйләп калдыра, һәм әкияттә кешенең миссиясе шуның белән бетә. Шуннан соң төп эпик өлештәге вакыйгаларда без бары тик хайваннарны гына күрәбез. «Кәҗә белән Сарык», «Курбала», «Батыр әтәч» һ.б. кайбер әкиятләрдә дә шул ук күренешкә тап булабыз.

Әкиятнең азагында катнашкан очракта, кеше персонажының әһәмияте арта. Ул төп конфликтның чишелешендә үзәк урынны тота, һәм мондый әкиятләр кешенең хәлиткеч эше белән тәмамлана. Мәсәлән, «Төлке белән Бүре» дигән әкиятнең азагында койрыгы бозга каткан бүрене ирләр кыйнап үтерәләр. Шул ук сюжетка корылган һәм «Төлке» дип исемләнгән икенче бер әкияттә бәкегә суга килгән хатын көянтә белән аюны кыйный, һәм аю койрыгын өзеп

кача. «Шәрә бүре» дигән экият тә кешенең җиңүе белән тәмамлана: тегүче, үлчәү алам дигән булып, бүрене тимер аршыны белән кыйнап үтерә. Бу экиятләрдә кешенең катнашуы эпизодик характерда гына булса да, аның көче һәм акылы бик ачык күренә. Төгәлрәк әйтсәк, хайваннарның кеше белән очрашу моменты сюжет үсешендә кульминацион ноктаны тәшкил итә. Бүре, мәсәлән, көч ягыннан төрле дәрәҗәдәге персонажлар белән очраша, һәм хәлиткеч очрашу кеше белән була.

Хайваннар турындагы экиятләр арасында кеше көчен күрсәтүгә генә багышланганнары да очрый. Аларда кеше әсәрнең буеннан-буена катнаша. Шундыйлардан иң характерлысы «Мәче, Юлбарыс һәм Кеше» дигән экият. Мәче юлбарыска үз хуҗасының аңардан да көчлерәк икәнен әйткәч, юлбарыс кеше белән көч сынашырга тели. Кеше, өенә кайтып, «көчен алып килгәнче», юлбарыс аңа үзен бәйләп торырга рөхсәт итә, һәм бәйләнгән юлбарысны кеше кыйнап үтерә.

Кешенең үзеннән күп мәртәбә көчле булган ерткычлардан өстен чыгуы, акылы һәм тапкырлыгы белән аларны җиңүгә ирешүе башка халыкларда да киң таралган сюжетлардан торган «Аю, Бабай, Төлке» (АА 1030+154 + 154 1)[1] экиятендә дә бик тәэсирле тасвирлана.

Ләкин кеше катнашкан экиятләрнең барысында да кеше җиңүче сыйфатында гына сурәтләнми. Мәсәлән, сыйнфый конфликтка корылган «Хәйләкәр әтәч» экиятендә бай образы бар. Аның антиподы – әтәч. Бай, бер атнага дип, әтәчтән алтын балдак сорап ала, ләкин кире кайтарып бирми. Алай гына да түгел, әтәчне үтерергә теләп, аны атлар абзарына, казлар янына, аннары тәкәләр абзарына яптыра. Болай да эш барып чыкмагач, әтәчне коега ташлыйлар, янып торган мичкә аталар һәм соңыннан кайнап торган казанга салалар. Әмма тылсымлы әтәч һәлак булмый, киресенчә, аның эченнән аю, бүре, төлке чыгып, байны һәм аның гаиләсен кыйнап үтерәләр.

Гадәттә, экиятләрдә хайваннар белән кеше конфликтында кеше җиңеп чыга. Ә хәзер тикшереп үтелгән экияттә кеше, халыкка дошман шәхес булганлыктан, җиңелүгә дучар ителә. Халык уенча, комсыз, тәкәббер бай бер вакытта да акыл һәм зирәклек ягыннан өстен чыга алмый. Шунлыктан ул нинди дә булса хайван тарафыннан алдана яки җәзалана.

---

[1] АА – Андреев Н.П. Указатель сказочных сюжетов по системе Аарне (Л., 1929) дигән хезмәтнең, фәндә кабул ителгән шартлы кыскартмасы. Саннар сюжет номерларын күрсәтә.

Сыйнфый булмаган конфликтка нигезләнгән «Төлке», «Хәйләкәр төлке», «Эт белән Тукран», «Бүдәнә белән Төлке» кебек кайбер әкиятләрдә дә кеше шулай ук өстенлек ала алмый, алдана. Ләкин бу әсәрләрдә инде кешеләргә хас гомуми кимчелекләрдән – ачык авызлык һәм комсызлыктан көленә.

Кеше персонажы фабуланың буеннан-буена барган тагын ике тип әкият турында әйтеп үтәргә кирәк. Алар – аюның хатын-кыз белән никахы һәм төлкенең ярлы кешене өйләндерүе турындагы әсәрләр.

Аю һәм кеше мөнәсәбәтенә караган әкиятләр, генетик яктан борынгырак булу белән бергә, берничә сюжетка корылганнар. Мәсәлән, алдарак та искә алынган «Аю улы Атыләхмәтгәрәй» (АА 650 А) дигән әкияттә аюның бер кызны урлап китеп, аның белән тормыш итүе сурәтләнә. Алардан туган бала – Атыләхмәтгәрәй 25 көндә 25 яшьлек баһадир булып җитешә. Ул, әнисе белән бергә качып, авылга кайтып барганда, артларыннан куып җиткән аюны карагай белән сугып үтерә.

Бу темага багышланган башка сюжетлар да бар. Мәсәлән, «Аю һәм өч кыз» (АА 311) дигән әкияттә бертуган өч кызны урлаган аю, олы кызның хәйләсе нәтиҗәсендә, үзе дә сизмәстән, посылка итеп кызларның өчесен дә берәм-берәм әниләренә кайтарып куя. Үзенең алданганын сизеп дүртенче кат килгәндә, кызлар аюны, алдан ук казып куелган тирән чокырга төшереп, яндырып үтерәләр.

«Карчык белән Аю» (АА 160 1) дигән әкияттә исә аю башта ук уңышсызлыкка дучар ителә: юлда очраган карчык, кызларымны бирермен дип, аны алдап китә. Кичен аю кызлар йоклый торган келәт янына килсә дә, җиңелеп, качарга мәҗбүр була, чөнки, кызларның үртәве өстенә, этләр өрә башлый.

Аю һәм кеше мөнәсәбәтләренә багышланган бу типтагы әкиятләрдә кеше һәр очракта да аюны җиңүгә ирешә. Ләкин бу әсәрләр, «Мәче, Юлбарыс һәм Кеше» шикелле әкиятләрдән аермалы буларак, кешенең көчен күрсәтү, аны зурлау максатында махсус иҗат ителмәгәннәр, бәлки аю белән кеше мөнәсәбәтләре турындагы борынгы легендалардан килеп чыкканнар.

Кеше персонажы даими булган әкиятләрнең тагын бер тибы төлкенең ярлы кешене өйләндерүе темасына багышланган. Бу тема нигезендә бер сюжет (АА 545 В) белән чикләнә, һәм аңа «Салам-Торхан» әкиятенең вариантлары керә. Монда төп герой – төлке. Кеше исә соң дәрәҗәдә пассив, ул бары тик төлке күрсәтмәсе буенча гына эш итә. Бу тип әкиятләрнең иң характерлы билгесе – хайванның (төлкенең) гаять дәрәҗәдә кешеләштерелүе. Әгәр «Салам-Торхан»

әкиятендәге төлке нинди дә булса бер кеше тибы белән алыштырылса (мәсәлән, Таз, Алдар һ.б.)[1], сюжетка бернинди дә зарар килми. Шуңа күрә бу әсәр көнкүреш әкиятенә охшаган. Бары тик төлке персонажы гына аны хайваннар турындагы әкиятләр рәтендә йөртә.

Башка халыкларда да югарыда искә алынган сюжетларга (АА 650 А, АА 311, АА 160 1, АА 545 В) нигезләнгән әкиятләрнең бер ишләрендә тотемистик миф һам легендалар сыйфаты булса, икенчеләре көнкүреш әкиятләренә якын тора.

Гомумән, төрле халыкларның әкиятләре арасында охшашлык бик зур. Хайваннар турындагы әкиятләрдә исә бу аеруча ачык күренә. Мәсәлән, татар халкының төлке турындагы әкиятләре арасында халыкара каталогларда теркәлмәгән бер генә оригиналь сюжет та юк. Мондый уртаклыкның бер өлеше типологик характерда булса, икенче өлешен алынмалар тәшкил итә. Алынма сюжетлар төрле халыклар белән аралашу, сәүдә һәм культура бәйләнешләре нәтиҗәсендә кереп, уртак хәзинәгә әверелгән. Татар халкының хайваннар турындагы әкиятләре арасында бигрәк тә Көнчыгышның борынгы язма ядкярләренә («Кәлилә вә Димнә», «Хәятел хайван», «Тутыйнамә», «Бабурнамә», «Кырык вәзир» һ.б.) нисбәт ителә торганнары еш очрый[2] (мәсәлән, «Наян төлке», «Дус киекләр», «Арслан, Бүре, Төлке», «Арслан, Төлке, Бүре» һ.б.).

Инде кыскача гына хайваннар турындагы әкиятләрнең кайбер художество үзенчәлекләренә тукталыйк.

Әкиятләрнең күбесенә хас башлам, гадәттә, бик кыска була: «Борын заманда», «Борын заманнарда», «Борын-борын заманда», «Борын-борын заманнарда», «Элекке заманда», «Әүвәлге заманда», «Бер заманда», «Бервакытны», «Бер көнне», «Көннәрдән бер көнне» һ.б.ш.

Бу әкиятләрдә экспозиция дә кыска, җыйнак, һәм ул булачак вакыйгаларның урынын, вакытын, шартларын мәгълүм итә. «Бер Төлке авыл буйлап ага торган инеш буенда йөри икән. Вакыт – яңа гына караңгы төшеп килә торган кичнең башы» («Төлке белән Бүре»). «Әүвәл заманда булган бер ярлы. Моның киеме дә, өе дә булмаган. Салам җәеп, шул саламлыкта гына көн күреп тора икән бу. Шулай да аның булган бер кәҗәсе» («Салам-Торхан»), «Соры бүре бик күп йөргән, ары чапкан, бире чапкан, бер дә ашар нәрсә тапмаган» («Шәрә бүре»).

---

[1] Фольклор фондында андый әкиятләр бар (мәсәлән, 1976 елгы экспедиция материаллары арасында).

[2] Ахметова Ф.В. О генетических корнях татарских сказок о животных. С. 61.

Экспозиция бары тик төп персонаж белән генә таныштырырга да мөмкин. Мәсәлән: «Борын-борын заманда бик матур, бик батыр бер этәч булган» («Хәйләкәр этәч»).

Кайбер әкиятләрдә башламнан соң ук төенләнеш килә: «Борын заманда күрше авылдан кайтып килгән чагында, бер карчыкны аю тотып алган, ди» («Карчык белән Аю»). Яисә: «Бер көнне Мәче белән Юлбарыс очрашалар» («Мәче, Юлбарыс һәм Кеше»).

Күп әкиятләрдә вакыйгалар үсешенә персонажларның кабатланган очрашулары хас. Мәсәлән, «Шәрә бүре» дигән әкиятне алсак, анда бүре иң элек айгырны очрата, һәм бу айгыр аны, тибеп, һушыннан яздыра. Шуннан соң очраган үгез бүрене мөгезләре белән чөеп җибәрә. Кәҗә дә аны, алдап, бик кыен хәлгә куя: азан әйтәм дип кычкырып, үзенең хуҗасын чакыра. Төлке исә бүрене тәмам хур итә: яндырып, шәрә калдыра. Ниһаять, бүренең соңгы очрашуы һәлакәт белән тәмамлана: тегүче аны аршыны белән кыйнап үтерә.

Шулай итеп, әсәрдә төп персонажның калган персонажлар белән һәр очрашуы киеренкелекне арттыра бара, һәм соңгысында инде конфликт үзенең иң югары ноктасына – кульминациягә җитә. Бүренең үлеме исә – сюжетның чишелеше.

Кайбер әкиятләрдә чишелештән соң нәтиҗә ясала, мораль чыгарыла. Мәсәлән, «Төлке» дигән әкият болай тәмамлана: «Шуның өчен әйткәннәр: “Булыр-булмаска ышанып, кулыңдагыдан аерылма”, – дип». «Хәйләкәр этәч» әкиятенең азагы да шундыйрак характерда: «Менә, алтын балдакка кызыксаң, шулай була ул».

Хайваннар турындагы әкиятләрдә, сирәк кенә булса да, тылсымлы әкиятләргә хас традицион бетемнәр очрый: «Бүген бардым, кичә кайттым, бик сыйладылар, казык башына утырып чәй эчтем... («Салам-Торхан»), «Бүген барып, төнәген кайттым, баш авыртып макмыр булдым» («Салам-Торхан»).

Әкияттә персонажларның кабатланган очрашулары фразалар кабатлануга китерә. Кумулятив әкиятләрдә бу аеруча калку чагыла. Мәсәлән, «Песәй» әкиятендәге песигә очраган һәр хайван бер үк сорауны бирә: «Песәй дус, кая барасың болай чаба-чаба?» Песәйнең җавабы шулай ук барысына да бер ук: «Борчак явы килә, шуннан качып китеп барам, – ди».

Хайваннар турындагы әкиятләргә бигрәк тә диалог формасындагы сөйләм хас. Бу алым әсәрне аеруча җанлы һәм мавыктыргыч итә.

Диалог формасы геройларның реаль тормышын, алар яши торган табигый мохитны ныграк тоярга, ачыграк күзалларга ярдәм итә.

Әкиятләрдә хайваннар тавышына охшатылган аваз ияртемнәре дә шул ук максатларда файдаланыла. Мәсәлән, бүре бик каты имгәнеп, «ух, ух!» дип ята («Наян төлке»), яисә «у-у...у... ач калдым...» – дип улый («Шәрә бүре»), аю лап-лап басып килә («Карчык белән Аю», «Батыр әтәч»), торна «тук» иттереп чукый («Торна белән Төлке»), кәҗә «икики, мики-ки», – ди («Кәҗә белән Сарык»), мәче «мырау-мырау» дип ашый («Кәтән Иваныч»), әтәч «ки-ке-рикүк!» дип кычкыра («Әтәч патша») һ.б.

Әкиятләрдәге персонажлар телендә ритмлы һәм рифмалы сөйләм дә очрый. «Кәҗә белән Бүре» экиятендә, мәсәлән, кәҗә үзенең балалары янына һәрвакыт болай дип җырлап кайта:

Таудан тауга йөримен –
Тау җимеше җыямын.
Кырдан-кырга йөримен –
Кыр җимеше җыямын.
Бер имиемә сөт җыям,
Бер имиемә май җыям.

«Курбала» дигән экияттә Курбала (Камыр бала) һәр персонаж белән очрашканда үзе турында җыр җырлый, һәм аның җыры, яңа персонажларның исемнәре өстәлеп, торган саен зурая бара. Соңгы җыр түбәндәгечә:

Мин итлектән[1] себерелгән,
Каймакка басылган,
Курдан ясалган;
Башлыктан[2] киттем,
Бабайдан киттем,
Куяннан киттем,
Аюдан киттем,
Синнән китәм дә китәм.

«Аю белән өч кыз» дигән экияттә аюның сүзләре шулай ук тезмә формага салынган. Аю кыз кереп яткан капчыкны күтәреп, беркадәр араны узгач:

Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем,
Му-му, –

[1] Итлек – келәт.
[2] Башлык – карчык.

дип кабатлый. Бу такмакта ырым йә балалар уены мотивлары ишетелгәндәй була. Капчыктагы кыз әлеге сүзләрдән соң: «Күрекле күзем күрәләй», – дип җавап бирә, һәм аю, кыз йорт җиллегеннән (чорма тәрәзәсеннән) карап тора икән дип, капчыкны ачарга базмый.

Хайваннар турындагы әкиятләрнең теле гади һәм образлы. Образлылыкка төрле троплар ярдәмендә ирешелә. «Әтәч патша» дигән әкияттә, мәсәлән, кызыклы чагыштырулар бар. Ялагай табыклар үзләренең башлыклары әтәчне болай мактыйлар: «Синең аякларың тимердән дә ныграк», яисә: «Синең тавышың арыслан тавышыннан да гайрәтлерәк». Әлбәттә, әтәчкә карата кулланылган мондый чагыштырулар елмаю уятмый калмый.

Әкиятләрдә очрый торган эпитетлар хайваннарның табигатенә туры китереп яки әкият таләпләренә яраклаштырып сайлана: ач бүре, ахмак бүре, җүләр бүре, хәйләкәр төлке, таза ат, акыллы кәҗә, бик батыр хәйләкәр әтәч, бик шәп айгыр һ.б.

Эпитетлар табигать күренешләрен сурәтләгәндә дә еш кулланыла: олы болын, яшел болын, салкын җилләр, калын агач, юан имән, киң тугай, матур көннәр, суык кыш, ап-ак кар, калын арыш уҗымы һ.б.

Әкиятләрдә, сирәк булса да, метафоралар да очрый: кабыргаларын санау (кыйнау), кызыл бүрек (башы канаган бүре), кызыл ыштан (аягы канаган бүре) һ.б. Соңгы икесе бер үк вакытта метонимия булып тора. Перифраз формасындагы метафоралар да күренгәли: бөек падишаһ, мактаулы хан, куәтле солтан (әтәч), имам (эт).

Хайваннар турындагы әкиятләрдә гипербола күп кулланыла. Мәсәлән, бүре төлкегә: «Мин сине бер кабуда юк итәм», – ди («Наян төлке»). Икенче бер әкияттә төлке бүрегә: «Койрыгыңның һәр бөртек йоны саен бер балык ияреп чыгар», – ди («Төлке белән Бүре»). «Кәтән Иваныч» исемле әкияттә төлке мәче турында сөйләгәндә: «Бер ашаганда бер сарык, бер үгез ашый икән», – ди. Ә «Аю улы Атыләхмәтгәрәй» дигән әкияттә герой «ай үсәсен көн үсеп, егерме биш көндә егерме биш яшьлек баһадир була» һәм үзе турында: «Мин кешеләр арасында яши алмам шул, берсен суксам, бишесе үләр», – ди.

Әкиятләрдә сәнгатьле сурәт чаралары образларның җанлы, вакыйгаларның тәэсирле булуына ярдәм итә.

Бүгенге көндә хайваннар турындагы әкиятләрнең күбесе балалар репертуарына күчкән. Алар яшь буынны эстетик һәм әхлакый яктан тәрбияләүдә мөһим урын тота.

*(соавтор Х. Ярми)*

## Тылсымлы әкиятләр

«Әкият» сүзен ишетүгә, безнең күз алдыбызга үзенең серле дөньясы белән нәкъ менә тылсымлы әкият килеп баса һәм бу тикмәгә түгел: тылсымлы әкиятләр – әкият жанрының үзәге ул. Беренчедән, алар сан ягыннан да күбрәк – барлык әкиятләрнең яртысыннан артыграгын тәшкил итәләр; икенчедән, күләмнәре белән дә зуррак; өченчедән, алардагы фантазиянең гаҗәеп байлыгы, шомлы һәм дәһшәтле, шул ук вакытта кызык һәм мавыктыргыч булуы күнелне әсир итә.

Чыннан да, ни генә юк ул әкиятләрдә: кара урман эчендә яшәүче явыз убырлы карчыклар, Каф тавы артында яисә җир астындагы биләмәсендә хакимлек итүче коточкыч диюләр, авызыннан ут чәчеп, кешеләрне ашарга әзер торучы күп башлы аждаһалар дисеңме, күз ачып йомганчы теләгән җиреңә илтеп куючы сәмруг кошлар, оча торган паласлар, күпме теләсәң шулкадәр гаскәр чыгара торган мөгезләр дисеңме – барысы да бар. Әкият герое әнә шундый персонажлар белән мөнәсәбәткә керә, тылсымлы әйберләр ярдәмендә төрле могҗизалар эшли.

Әлбәттә, мондый «тузга язмаган» нәрсәләрнең чынбарлыкта булуы мөмкин түгел. Әкиятләрдәге традицион башлам һәм бетемнәр дә шуңа ишарә итә. Мәсәлән, «Камыр батыр» әкиятенең бер варианты болай башлана: «Борын-борын заманда, кәҗә команда, әби-бабай тумас борын, әти белән икәү генә торган чагында, бар иде бер карт белән карчык»[1]. Әсәрнең дөнья гизәргә чыгып киткән герое «атна китә, көн китә, ай китә, ел китә, бер саплам җир китә». Ниһаять, әкият түбәндәгечә тәмамлана: «Кызны Камыр батырга биргәннән соң, утыз көн уен итеп, кырык көн туен итеп, тумаган ала биянең итен пешереп, бик каты сыйлаганнар, ди.

Туйларында мин дә булдым, аш-суның чиге юк, бәлешләренең төбе юк, мичкә-мичкә бал куйганнар, үзләре чүмеч белән чумыралар, миңа сабы белән генә эләкте».

Әкиятче әнә шундый традицион формулалар, башлам һәм бетемнәр аша анда сөйләнгән нәрсәләрнең тормышта булмаганлыгын искәртә.

Әкияткә хас шушындый уйдырмалар кайдан килгән соң? Аларны кем чыгарган? Кайчан һәм ни өчен чыгарган? Тылсымлы әкиятләрне тикшергәндә, без беренче чиратта әнә шул сорауларга җавап эзләргә тиешбез.

---

[1] Мисаллар һәм өземтәләр «Әкиятләр»нең беренче китабыннан (Казан, 1977) һәм икенче китабыннан (Казан, 1978) алынды.

* * *

Борынгы кешенең яшәеш-көнкүреше төрле ышанулар җирлегендә формалашкан гаҗәеп күп йолалар белән тулы булган. Шуларның иң киң таралганы – үсмерләрне, балигълык яшенә җиткәч, олылар рәтенә күчерү йоласы. Фәндә бу йола **инициация** дип атала.

Балигълык йоласы үзенең кырыслыгы белән аерылып торган. Иң элек үсмерләрне махсус эшләнгән йортка җыйнап (мондый йорт яшәү урыныннан читтә, күбесенчә урман эчендә булган), айлар буе җаваплы сынауга әзерләгәннәр: ыруның серләрен ачканнар, изге мифларын сөйләгәннәр, йоланы үтәү тәртипләренә һәм төрле һөнәрләргә өйрәткәннәр. Хатын-кызларга һәм балаларга бу йортка керү катгый тыелган. Әзерлек чоры үткәч, тантаналы шартларда егетләрнең берәр тешен сугып төшергәннәр, шуннан соң аларны мифик зат яки ыруның тотемы[1] рәвешендә төзелгән корылмага кертеп чыгарганнар, сөннәтләгәннәр һәм берәр бармагын кисеп алганнар[2].

Борынгы кеше, тотем хайван «йотып чыгаргач», үзенә тотемның җаны керә дип исәпләгән. Әйтик, ыруның тотемы бүре булса, йола үтәлгәннән соң, үсмер үзен бүре дип хис иткән. Ул үлеп яңадан терелгәндә кешенең җаны тотемга, ә тотемныкы кешегә күчә, ягъни кеше белән хайван арасында җан алмашу процессы башкарыла дип уйлаган. Борынгы кеше әнә шулай үзе белән тотем арасында күзгә күренми торган симпатик элемтә булуына ышанган[3].

Яшәү чыганагы нигездә аучылык булган заманда кешенең киекләрне кулга төшерү осталыгы гаять мөһим мәсьәлә булган. Ә тотем хайванның ашказаныннан чыккан кеше, сихри сәләткә ия булып, беренче чиратта нәкъ менә киекләр өстеннән хакимлек итә ала, дип ышанылган. Шуңа күрә, йола үтәлгәннән соң, үсмерләр олылар рәтенә күчкән дип саналган һәм аларга өйләнергә рөхсәт ителгән.

Күп кенә фәнни хезмәтләрдән күренгәнчә, классик тылсымлы әкиятләрнең нигезендә чынбарлыкның әнә шул күренеше ята.

Әлбәттә, без хәзер татар әкиятләрендә балигълык йоласын саф хәлендә очрата алмыйбыз, ул күп гасырлар дәвамында зур үзгәрешләр кичергән. Бу табигый дә. Чөнки реаль вакыйгаларның әкият материалына әверелүе өчен озак вакытлар үтү һәм яңа буын кешеләренең аларны яңача аңлавы (ягъни йоланың кире кагылуы) таләп

---

[1] Тотем – ыруның нәсел башы дип саналган һәм шул ыру кешеләре тарафыннан олыланган берәр хайван, үсемлек яисә җансыз әйбер.

[2] Балигълык йоласының үтәлү формасы төрле урында төрлечә булган. Биредәге мисал В.Я. Проппның «Исторические корни волшебной сказки» дигән хезмәтеннән (Л., 1946) алынды.

[3] Фрэзер Дж. Золотая ветвь, вып. IV, М., 1928. С. 216–227.

ителә. Шуның өстенә, әкият барлыкка килгәннән соң да дистәләрчә гасыр узган инде. Йола да күптән онытылган. Шулай да аның аерым күренешләре, мотивлары төрле әкиятләрдә бүгенге көнгә чаклы сакланып калган.

Тылсымлы әкиятләрнең күбесенә түбәндәге сюжет хас: булачак герой, үсеп җиткәч, ил гизәргә чыгып китә, төрле маҗараларга очрый, патша кызын дию яки аждаһалардан коткара яисә патша куйган авыр бурычларны үти һәм, нәтиҗәдә, әлеге патша кызына өйләнеп, үзе патша булып кала.

Геройның өйләнү юлында очраган кыенлыклар әкиятләрдә аеруча калку тасвирлана. «Турай батыр» әкиятендә, мәсәлән, өеннән өйләнү максаты белән чыгып киткән геройны һәм аның юлдашларын карурман эчендәге бер йортта мифик зат – Үзе бер карыш, сакалы биш карыш карт үтереп китә. Ә «Дутан батыр» әкиятендә шул ук максат белән сәфәргә чыккан геройны һәм аның туганнарын «калын урман»да Җалмавыз карчык йота.

Әкиятләрдә балигълык йоласының тотемизм белән турыдан-туры бәйле булуы да чагылыш тапкан, билгеле. «Өч күгәрчен» әкиятендә геройны урман эчендәге йортта өч күгәрчен-егет төрле тылсымга өйрәтәләр. «Егет шулкадәр тырышып өйрәнә боларның һөнәрләрен, өч ай дигәндә, үзләреннән артык белә бу. Егет хәзер теләсә нәрсәгә әверелә ала: үсемлекме, ... хайванмы, киекме – барысы да була ала бу». Шул ук өч күгәрчен-егет патша кызын эзләүче батырлар тарафыннан туракланып ташланган геройны эзләп табып, «үзләренең һөнәрләре белән тегене яңадан кешегә әверелдерәләр».

Халыкның көнкүрешендә күгәрчен, тотем кош буларак, еш кына сакчы вазифасын үтәгән, һәм бу традиция бик озак вакытлар дәвам иткән: тәрәзә йөзлегенә ясалган пар күгәрчен сурәтен хәтта әле бүгенге көндә дә очратып була. Бу урында шуны да искәртеп узыйк: чыгышлары белән болгарларга мөнәсәбәтле булган бисерманнардә, мәсәлән, үрдәк, гөберле бака, күгәрчен изге хайваннар итеп саналган һәм аларның сурәтләре киемнәргә төшерелгән[1].

Әкиятләрдә йотып терелтү мотивы да очрый. Мәсәлән, «Таңбатыр», «Әйгәли батыр» әкиятләрендә убырлы карчык ике аягы да киселгән геройны, шулай ук аның кулсыз һәм сукыр юлдашларын йотып төкергәч, тегеләр элекке кебек сәламәт кешегә әвереләләр.

Бу сюжет һәм мотивларның барысы да балигълык йоласына барып тоташа дип уйларга нигез бар.

[1] Белицер В.Н. К вопросу о происхождении бесермян // Труды института этнографии. Т. I, М., 1947. С. 190.

Әкият героеның, кияү булганнан соң, кызның әтисе урынына тәхеткә утыруы да әкиятченең хыялын гәүдәләндерүче уйдырма гына түгел. Тарих тирәнлегеннән бу мотивның асылына туры килә торган күренешне дә табарга мөмкин.

Тәхет варислыгы бик күп илләрдә борынгы община җәмгыятенә хас тәртипләргә нигезләнгән булган. Шуларның иң мөһимнәре – **экзогамия** гадәте, үзенчәлекле никах һәм кардәшлекнең хатын-кыз ягы буенча саналуы. Экзогамия кагыйдәсе буенча, ирләр бары тик чит ырудагы хатын-кызга гына өйләнә алганнар. Үз ыруындагы хатын-кызга өйләнү катгый рәвештә тыелган. Ә никах үзенчәлеге, ир кешенең үзе туып үскән гаиләне яисә ыруны ташлап, яшәү өчен хатыны туып үскән гаиләгә китүеннән гыйбарәт. Болар – мәҗбүри кагыйдәләр булган. Кешенең чыгышы да ата ягыннан түгел, ана ягыннан исәпләнгән. Шуңа күрә патша власте да аның үз улына түгел, бәлки киявенә күчкән. Шулай итеп, теләсә нинди чит-ят кеше, патшаның кызына өйләнү белән бергә, соңыннан патшалыкка да ия булып калган[1].

Бу күренеш әкиятләргә чынбарлыктагыча, үзгәрмичә килеп кергән. Мәсәлен, «Кол-патша» әкиятендә тәхет патша кызын алучы колга күчә. Ә «Ике туган» әкиятендә патша үзенең киявенә ярты патшалыгын бирә. «Көнгә күренмәс Сылу-көмеш», «Ярлы егет белән патша кызы», «Урман каравылчысы», «Патша малае белән хезмәтче малай», «Корчаңгы тай» һ.б. әкиятләрдә нәкъ менә шул хәл гәүдәләндерелә.

Әлбәттә, егет патша кызына җиңел генә өйләнә алмаган. Патша кызына өйләнү һәм тәхеткә ия булу өчен аның шәхси сыйфатлары гаять зур роль уйнаган. Күп кенә халыкларда, күрәсең, тәхет кенә түгел, бәлки һәртөрле титуллар да физик көрәштә (йөгерүдә, атта узышуда) җиңеп чыгучыга бирелгән. Әкиятләрдә булачак кияевен сынау өчен патша тарафыннан төрле ярышлар оештырылу яисә башка төрле авыр бурычлар үтәтү мотивлары әнә шул, кайчандыр реаль тормышта булган хәлләрнең чагылышы булса кирәк. «Кара таяк» әкиятендә, әйтик, патша үзенең кызына өйләнергә теләүчеләр өчен атка атланган хәлдә чокырны сикереп чыгу шартын куя. «Йөзми» дигән әкияттә патша геройга кызын бирүдән элек, аны үзенең бер карчыгы белән йөгерешергә мәҗбүр итә. «Кырык уллы кеше» әкиятендәге таләпләр дә көч сынашуга бәйле: «...егет патшага кереп әйтә: “Давай батырларыңны”, – ди. Патша батырларын китерә. Өч көн чик куя. Әгәр дә өч көн эчендә патшаның батырын екса, йөгереген дә узып китсә, кырык

---

[1] Фрэзер Дж. Золотая ветвь, вып. I, М.–Л., 1931. С. 180. (Сыйнфый җәмгыятькә кадәрге дәвер турында сүз барганда, «патша» төшенчәсе ыру (кабилә) башлыгы мәгънәсендә аңланырга тиеш.)

мичкә скипидәрне дә эчеп бетерсәләр – шул чагында патша кызны бирергә вәгъдә кыла».

Кайбер әкиятләрдә исә герой, кызны алу өчен, шахмат уенында патшаның үзен җиңнәргә тиеш була. Монда инде мәсьәләне физик көрәш түгел, ә акыл көрәше хәл итә. Бу мотив, әлбәттә, чагыштырмача соңгырак чорга карый. Патша кызын алу өчен төрле һөнәргә ия булу шарты да, физик ярышлар белән чагыштырганда, соңрак барлыкка килгән булырга тиеш. Зирәклекне табышмак белән сынау – шулай ук реаль күренешнең чагылышы дип карала[1].

Әкият генезисында мифлар аеруча мөһим роль уйнаган. Тылсымлы әкиятләрдә миф билгеләрен шактый табарга мөмкин. Әйтик, геройның юлга чыгуына сәбәп булган ниндидер әйбер югалу – борынгы мифлар өчен дә бик характерлы сыйфат. Тылсымлы әкиятләрдәге могҗизалы туу («Йөзми», «Батыр егет», «Патша малае белән хезмәтче малай» һ.б.) һәм сирәк булса да очрый торган этиологик, ягъни җанлы һәм җансыз нәрсәләрнең барлыкка килү сәбәпләрен белдерүче бетемнәр («Зөһрә») – шулай ук мифлардан килә торган билгеләр.

Мифларның асыл сыйфатлары (беренче чиратта изгелеге) югалуда, ягънн аларның әкияткә әверелүендә, күрәсең, үзәк геройлары башта ук гадәти, хәтта исемсез кешеләр булган мифик риваятьләр (былички) традициясенең дә роле булгандыр[2].

Әкиятләрдә мифлар белән бәйле тагын бер мөһим компонент бар. Ул да булса – кече туган персонажы. Мәгълүм булганча, кече туганның төп уңай персонаж булуы дөньядагы күп халыкларның әкиятләренә хас. Кече туганны идеаллаштыруның сәбәпләрен ачыклау максаты белән күп кенә хезмәтләр язылган. Шуларның берсе – Е.М. Мелетинскийның «Герой волшебной сказки. Происхождение образа» (М., 1958) дигән китабы. Анда автор, башлыча рус материалына нигезләнеп, кече туганны идеаллаштыру минорат һәм майорат көрәше нәтиҗәсендә килеп чыккан дигән концепциясен тәкъдим итә. Аның карашынча, майорат, ягъни мирасның олы туганга күчү тәртибе, кече туганны өлештән мәхрүм иткән һәм шуңа күрә әкиятләрдә кече туган идеаллаштырылган, чөнки жанр эстетикасының нигезе рәнҗетелгәннәрне яклауга кайтып кала.

С.А. Каскабасов исә, казакъ материалына таянып, кече туганны идеаллаштыру минорат, ягъни милекнең мирас буенча кече туганга

---

[1] Колесницкая И.М. Загадка в сказке. «Ученые записки ЛГУ», серия филологических наук, вып. 12. Л., 1941.

[2] Мелетинский Е.М. Миф и сказка // Фольклор и этнография. Л., 1970. С. 145.

күчү тәртибе яшәгән вакытта ук булганлыгын яклый һәм идеаллаштыру ике этапта барган дигән нәтиҗәгә килә[1].

Е.Д. Турсунов нигездә соңгы фикерне яклаcа да, беренче этаптагы идеаллаштыруны әкият эстетикасы нигезенә каршы килә дип саный һәм бу мәсьәләдә кырыгынчы еллар башында А. Золотарев тарафыннан тәкъдим ителгән гипотезаны куәтли[2]. Бу гипотеза буенча, төрле халыкларның әкиятләрендә олы яки кече туганның уңай яки кире тип булуы бу геройларның дуалистик мифлардагы[3] хәленә бәйле[4].

Татар тылсымлы әкиятләренең идеаль героена – кече туганга килсәк, ул, күпчелек очракта, мирастан мәхрүм ителгән шәхес түгел. Бу нисбәттән, аны чыннан да борынгы төркиләрнең дуалистик мифларыннан ук килгән дип фараз кылырга мөмкинлек бар. Чөнки төркиләр мифологиясендә кече туган – уңай герой[5].

Әгәр кече туган образы дуалистик мифлар белән бәйле икән, ул вакытта геройлары ике туган булган әкиятләр борынгырак булырга тиеш. Дөрестән дә, «Ике туган», «Аучы» кебек әкиятләрне алып карасак, аларда архаик мотивларның өстенлек итүен күрербез: геройларның аучы булуы, ярдәмгә хайваннар килү, мәетне агачка элеп кую, үлгән кешене терелтү – болар барысы да бик борынгыдан килә торган мотивлар.

Мондый тип әкиятләрнең күбесендә туганнар өчәү («Таңбатыр», «Алтын алма», «Яхшылыкка – явызлык» һ.б). Ләкин татар әкиятләре арасында геройлары дүрт («Ак бүре»), унбер («Унберенче Әхмәт»), унөч («Унөч»), утыз («Утыз ул»), кырык («Кырык уллы кеше»), йөз («Йөзми») булган әкиятләр дә бар.

Әлеге әкиятләр арасында «Кырык уллы кеше» бер үзенчәлеге белән аерылып тора: анда уңай герой – олы туган. Бу хәл татар әкиятләрендә бик сирәк очрый. Аны җентекләп тикшерәсе бар: әкият борынгы заманнардан ук киләме, әллә ул Идел буе болгарларына соңгырак чорда күрше халыклардан кергәнме? Чөнки уңай

---

[1] Каскабасов С.А.. Казахская волшебная сказка. Алма-Ата, 1962. С. 139.

[2] Турсунов Е.Д. Генезис казахской бытовой сказки. В аспекте связи с первобытным фольклором. Алма-Ата. 1973. С. 139.

[3] Дуалистик миф – кешелек җәмгыятенең бала чагындагы дуалистик оешма дәверен чагылдырган иң борынгы миф. Аның геройлары бер кабилә эчендәге фратрияләрнең нәсел башы итеп саналган ике туган булып, аларның берсе көчле, акыллы, тәҗрибәле, зирәк, җитез, ә икенчесе көчсез. ахмак, авыр хәрәкәтле, булдыксыз итеп сурәтләнгән.

[4] Золотарев А.М. Родовой строй и первобытная мифология. М., 1964. С. 277.

[5] Турсунов Е.Д. Генезис казахской бытовой сказки. С. 138.

геройның олы туган булуы мари, мордва, удмурт һәм чуваш легендаларына хас[1].

Инде тагын бер мәсьәләгә тукталыйк. Тылсымлы әкиятләрнең күбесендә уртак бер үзенчәлек күзгә ташлана: герой, һәрвакыт диярлек, урманга барып чыга. Ә урман – балигълык йоласы башкарыла торган урын булу белән бергә, борынгы кешеләр фикеренчә, үлеләр дөньясына керү юлы да[2].

Реаль тормышта балигълык йоласыннан соң өйләнү – әкиятләрдә кызны үлеләр дөньясыннан алып кайтуга охшатыла. Йоланы үтәмичә, ягъни әлеге дөньяга бармый торып, хатын алырга мөмкин түгел. Әкиятләрдә ул нәкъ шулай чагыла да: герой күп кенә очракта дию кулындагы кызны алып кайта («Турай батыр» һ.б.).

Дию – тылсымлы әкиятләрдә иң күп очрый торган персонажларның берсе. Ул, кагыйдә буларак, кешеләрдән еракта («Утыз ул», «Нурсылу», «Дию патша», «Тәмәке янчыгы»), җиде диңгез артындагы сигезенче диңгез утравында («Өч күгәрчен»), диңгез төбендә («Өч каләм»), Каф тавы артында («Ак бүре»), тау башында («Мәрмәр тавы башында») яисә җир астында («Таңбатыр», «Алтын алма», «Өч дус») яши һәм, гадәттә, пашта кызларын яки аның малларын урлап китә.

Дию патшалыгы кешеләр яши торган җирдән үзенең күренеше белән дә нык аерыла. Мәсәлән, «Ак бүре» әкиятендә югалган анасын эзләп чыккан герой, алтмыш колачлы ала айгырга ябышып, гаять куркыныч киртәләрне уза. «Бу сулар, утлар, таулар – бар да дию патшалыгыннан адәм үтмәсен өчен эшләгән эшләр...» – ди айгыр малайга. Ләкин алга таба айгыр да бара алмый: «Миңа моннан ары барырга рөхсәт юк. Син инде минем өстемнән төш тә бу ком тавының аргы ягына чыгарга тырыш. Ул ком тавының аръягында яман диюләр, усал арысланнар, аждаһалар яталар. Алар янына чыга алсаң, анаңны табарсың», – ди ул. Сәмруг кош сурәтенә кергән Ак бүре дә: «Каф тавының башына илтеп куярмын, аннан ары барырга миңа рөхсәт юк», – ди.

Бу – әлбәттә, үлеләр дөньясының алгы чиге. Моннан соң инде дию хакимлеге башлана. Анда керү – үлем дигән сүз. «Егет тау башында бик күп ат, адәм сөякләре күреп, хәйран-вәйран булып торганнан соң, ике кулына ике ат сөяге алып, таяк итеп таянып, тауның бер ягына таба төшеп китте», – диелә әкияттә. Күп башлы диюләрнең бакыр, көмеш, алтын сарайларында кол кызлар «озын өстәлгә салып, адәм итләре юып яталар».

---

[1] Золотарев А.М. Родовой строй и первобытная мифология. С. 277.
[2] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. С. 96.

«Мәрмәр тавы башында» дигән әкияттә дә герой дию биләмәсендә тирә-якта аунап яткан кеше сөякләрен күрә.

Бу күренешләрнең барысы да диюнең үлеләр дөньясы хакиме булуы турында сөйли.

«Өч дус» әкиятендә дию герой килгәнне аның исеннән белә: «Фу, адәм исе килә, кая ул адәм, китерегез аны миңа, хәзер мин аның күлен күккә очырам», – ди. Борынгы кешенең ышануынча, тере кешеләрнең исе үлеләргә үтә җирәнгеч тәэсир итә, имеш[1].

Әкиятләрдә дию яши торган урынга карата «ат килсә, тоягы көя, кош килсә, канаты көя торган җир» («Ак бүре») диелә, яисә «аннан кайтмак юк инде» («Мәрмәр тавы башында») дип раслана.

Дию кайда гына булмасын, әкият герое – баһадир егет, юлда очраган теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп, аның биләмәсенә керә һәм, аны үтереп, кызны да, башка тоткыннарны да азат итә.

Шулай итеп, кеше бик борынгы заманнарда ук үлемсезлеккә омтылган, хыялында гына булса да үлеләр дөньясы хакимен тар-мар итеп, аның кулындагы кешеләрне яңадан тереләр дөньясына кайтарган.

Тылсымлы әкиятләрнең кайберләрендә дию – бер үк вакытта асыл хәзинәләр хуҗасы да. Аның милкендә бик күп алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, төрле асыл ташлар саклануы турында әйтелә. Гадәттә, диюнең үзе яши торган сарае да шундый ук затлы әйберләрдән төзелгән була. Кайбер әкиятләрдә герой, җир астына төшкәч, иң элек андагы хәзинәләрне чыгара («Камыр батыр», «Турай батыр»)[2], ә кайберләрендә диюнең алтын, көмеш һәм бакыр сарайларын йомыркага әйләндереп алып китү күренеше очрый («Таңбатыр», «Ак бүре»).

Борынгы фарсыларның ышануларында да дию нәкъ менә җир асты байлыклары белән бәйләнгән. А.А. Семеновның бер хезмәтендә диюләр (дәүләр) турында түбәндәге юллар бар: «Аларның торагы – таулар эчендә, җир карынында һәм күлләр төбендә. Дәүләр анда җир хәзинәләрен (алтын, көмеш һәм кыйммәтле ташларны) саклыйлар. Дәүләр бөтен кешелекне дошман күрәләр һәм кешеләр белән беренче очрашуда аларны үтерәләр яисә үзләренең чирка映ыч торакларына алып китәләр»[3].

Күренә ки, фарсыларда дию шулай ук кешеләрнең дошманы һәм ул, беренче чиратта, үлеләр дөньясы белән бәйле булырга тиеш,

---

[1] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. С. 52.

[2] Бу әкиятләрдә дию урынында Үзе бер карыш, сакалы биш карыш карт сурәтләнә. «Турай батыр»да аңа карата «диюләр патшасы» диелә.

[3] Семенов А.А. Этнографические очерки Зарафшанских гор, Каратегина и Дарваза. [М.], 1903. С. 73.

чөнки җир асты хәзинәләре турындагы төшенчә үлем турындагы күзаллаулардан да элегрәк барлыкка килә алмаган булса кирәк.

К. Насыйри иранлыларның дию татарларга «мөселманлык аркылы» килгән дип саный[1]. Ләкин дию һ.б. затларның татар мифологиясенә керүендә мөселманлык бердәнбер канал булмаска мөмкин, чөнки төрки кабиләләрнең, шул исәптән борынгы болгарларның, иран кабиләләре белән аралашуы аларда әле ислам дине таралмаган чорларга ук карый.

Борынгы күчмә иран кабиләләрендә дәү (дию), һинд эпосындагы кебек үк, мәҗүси алла булган. Аның исеме Һинд-Европа телләрендәге уртак тамырга кайтып кала (латинча «deus» – алла, Зевс, Юпитер) һәм «Күк» дигән мәгънәне белдерә. Соңрак иран кабиләләренең утрак тормышка күчкән өлеше дәүләрне дошманлык һәм нәфрәтне гәүдәләндерүче усал аллалар итеп саный башлаган. Шулай итеп, әлеге затлар күктән җир асты дөньясына «сөрелгәннәр».

Күп кенә тылсымлы әкиятләрдә геройның дошманы сыйфатында убырлы карчык персонажы очрый. Кайберләрендә ул «җалмавыз», «сихерче карчык» яисә «карчык» дип кенә йөртелә. Ләкин асылда бу исемнәр бер үк затны белдерәләр.

Күбесенчә урмандагы кечкенә өйдә яшәүче убырлы карчык (җалмавыз) усал һәм рәхимсез. Ул кешеләрне йота («Дутан батыр», «Яхшылыкка – явызлык»), яисә аларның канын эчә («Таңбатыр», «Әйгәли батыр»). Ләкин мәҗбүр иткәндә, карчык йоткан кешеләрне сау-сәламәт рәвештә кире дә чыгара. Өстәвенә йотылган кешеләрнең физик кимчелекләре бетә: сукыр – күзле, кулсыз – куллы, аяксыз – аяклы була.

Мондый эпизодларда убырлы карчыкның балигъулык йоласын үтәү белән бәйле зат булганлыгы шактый ачык сиземләнә. Бу йола үзе ирләр тарафыннан үткәрелсә дә, ыру башлыгы карчык «ирләр союзы» (балигъ булган ирләр оешмасы) әгъзаларының уртак анасы исәпләнгән[2].

Иске тәртипләр бетеп, йола күренешләре әкият сюжетларына күчкәндә, әлеге карчык тискәре типка әверелә: аның кылган барлык эш-хәрәкәтләре явызлык максаты белән генә бәйләп аңлатыла башлый. Әкиятләрдә убырлы карчык кешеләрне пешереп ашый («Батыр солдат»), аздыра, юлдан яздыра («Гөлчәчәк»), суга батыра («Йөзми»), ташка әйләндерә («Ике туган»), үзе дә төрле сурәткә керә – хайванга (соры бүрегә, тычканга) һәм төрле нәрсәләргә (дегет

---

[1] Насыйри К. Сайланма әсирләр. 2 том. Казан, 1975. Б. 53.
[2] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. С. 94.

мичкәсенә, утка) әверелә ала («Гөлчәчәк», «Мәче һәм ярлы егет», «Батыр солдат»).

Алдарак без балигълык йоласыннан соң үсмернең мәгълүм бер хайванга әверелүенә ышанганлыгын күрсәтеп үткән идек. Икенче төрле әйтсәк, үлем кайбер стадиясендә хайваннарга әверелү дип аңланган. Бәс шулай икән, үлеләр дөньясына керү юлын саклаучы карчык бер үк вакытта әнә шул хайваннарның да хуҗасы булып чыга. Бу хәл әкиятләрдә чагылмый калмаган. Мәсәлән, «Көнгә күренмәс Сылу-көмеш», «Алтын алма» кебек әкиятләрдә әлеге карчык бик күп мал-туар хуҗасы итеп сурәтләнә.

Кагыйдә буларак, явыз убырлы карчык персонажының язмышы бер төрле тәмамлана – ул әкият герое тарафыннан мотлак үтерелә.

Әмма әкиятләрнең кайберләрендә карчыкның кешеләргә ярдәм итүе турындагы борынгы сюжетлар да сакланган. Мәсәлән, «Үги кыз», «Көнгә күренмәс Сылу-көмеш», «Әйгәли батыр», «Камыр батыр» әкиятләрендә әлеге карчык кешеләргә игелек күрсәтә.

Шулай итеп, убырлы карчык персонажы балигълык йоласы һәм үлеләр дөньясы турындагы күзаллаулар белән тыгыз бәйләнгән. Бу персонаж үзенең үсешендә ике этап кичергән: башта ул, йолага аваздаш рәвештә, кешеләргә ярдәм итүче, бүләк бирүче буларак гәүдәләнсә, соңрак, матриархаль тәртипләр беткәннән соң, явыз итеп сурәтләнә башлаган.

Балигълык йоласы һәм үлеләр дөньясы белән бәйле тагын бер персонаж турында әйтеп үтәргә кирәк. Ул – әкиятләрдә күп очрый торган елан персонажы. Бу урында шуны да игътибарга алыйк: елан образы күп очракта иран мифологиясеннән кергән аждаһа образы белән кушылган. Шуңа күрә кайбер әкиятләрдә бу персонаж аждаһа-елан дигән кушма исем белән дә йөртелә («Камыр батыр», «Патша малае, аның апасы, юлбарыс һәм башкалар»).

Халыкта еланның йөз ел яшәгәч аждаһага әйләнүе турында ышану бар. Ә аждаһа, янәсе, дөньяда мең ел яши, ләкин ул татарлар торган жирдә булмый[1]. Аждаһаның татарлар торган жирдә булмавына ышану, аның нәкъ менә читтән кергәнлегенә ишарә итү булса кирәк.

Еланның үсеш баскычлары мәкальләрдә дә чагыла. Мәсәлән:

> «Елан йөз яшәсә – аждаһа,
> Мең яшәсә юха булыр»[2].

---

[1] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 2 том. Б. 46.

[2] Татар халык мәкальләре. Җыючысы һәм төзүчесе Нәкый Исәнбәт. 1 том. Казан, 1959. Б. 572.

Аждаһа – геройның дошманы. Ул күбесенчә берничә башлы итеп сурәтләнә (әкиятләрдә ике, өч, дүрт, алты, җиде, тугыз, унике башлылары очрый). Аждаһа гадәттә дингездә яисә су (елга) буенда яши һәм кешеләргә бер тамчы да су бирми. Су алыр өчен кешеләр ана кызларын корбан итәргә мәҗбүрләр. Чират патша кызына җиткәндә, әкият герое аждаһа белән сугышып, аны үтерә һәм кызларны афәттән коткарып кала. Кагыйдә буларак, егет үзе коткарган кызга өйләнә дә.

Аждаһа – бирән тамак, аның бар омтылышы – кеше ашау. Кешеләрне ул ерактан ук суырып ала. Аның авызыннан ут чәчелеп тора. Кайбер әкиятләрдә герой, үзен аждаһа йотканнан соң, эчтән кылыч белән буйдан-буйга ярып чыга («Чәчәк күлмәк», «Кырык уллы кеше»). Әгәр аждаһа тауда яшәсә, ул корбаны янына очып килә («Ике туган»).

Фарсыларның да аждаһа турындагы күзаллаулары нигездә шундый[1].

Аждаһа әкиятләрдә бары тик дошман персонаж итеп сурәтләнсә, елан һәм уңай, һәм тискәре образ буларак очрый. Уңай образ булганда, елан геройга ярдәм итә («Елан патшасы Шаһмара», «Сер тотмас», «Ак елан», «Ятим бала» һ.б). Бу рольдә әкиятләрдә күбрәк Ак елан күренә. Аның нигезе тотемистик ышануларга кайтып кала. Мәсәлән, «Елан патшасы Шаһмара» әкиятендә герой Ак еланны кайнатып суын эчә һәм хайваннар телен аңлый башлый. Ә авыру патша, елан итен ашагач, сәламәтләнеп, «элеккедән дә тазара төшә».

Биредә без хайваннар өстеннән хакимлек итү өчен, шулай ук төрле авырулардан терелү өчен тотем итен авыз итү кебек бик борынгы йола калдыгы белән очрашабыз.

Шулай итеп, елан (аждаһа) образы катлаулы, һәм ул, убырлы карчык образы кебек үк, берничә катламнан тора. Шуларның берсе, әлбәттә, балигъльк йоласы белән бәйле: аның нигезендә үсмерләрне елан (аждаһа) йотып чыгарса, яисә, киресенчә, үсмерләр тотем (елан) итен ашаса, алар әнә шундый тылсымлы сәләткә ия була ала дигән ышану ята.

Елан (аждаһа) образы шул ук вакытта үлем дөньясы турындагы күзаллаулар белән дә бәйле. Беренчедән, ул, әйткәнебезчә, су буенда яши һәм кешеләрне үткәрми. Шушы үзенчәлегеннән чыгып, убырлы карчык үлеләр дөньясының керү юлын сакласа, елан аның эчке өлкәләрен саклый, дип уйларга нигез бар. Икенчедән, алдарак та искәрткәнебезчә, борын заманда кешенең җаны төрле хайваннар

---

[1] Семенов А.А. Этнографические очерки Зарафшанских гор, Каратегина и Дарваза. С. 77.

сурәтенә керә дип күз алдына китерелгән, ягъни кеше үлгәч, аның җаны берәр хайванга әверелә дигән караш яшәгән. Үлеләр дөньясы һавада дип уйланылганда – җан шул тарафка кош булып очкан, ә җир астындагы дөньяга – елан, кәлтә һ.б. сөйрәлүчеләр сурәтендә юнәлгән. Соңрак, шушы күзаллаулар берләшеп, канатлы аждаһа персонажы барлыкка килгән («Ике туган»).

Борынгы кеше мәетләрдән бик курыккан. Аларның ышануынча, үле кеше тере кешенең җанын урлый, ягъни үлеләр тереләрне үтерә булып чыга. Әгәр үлгән кешенең җаны елан рәвешенә керә дип күз алдына китерелгән икән, димәк, тере кешенең жанын да елан ала дигән сүз. Дөресрәге, елан кешенең жанын урлый дип уйланылган. Әкиятләрдәге патша кызларын урлаучы елан (аждаһа) персонажы – әнә шундый күзаллауларның чагылышы («Серле балдак»). Шуның белән бергә, татар әкиятләрендә кызларны урлаучы ролендә кош персонажын да очратырга була («Кара кош»).

Алда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, елан (аждаһа) образының үсешендә шулай ук ике этап аерымланып тора: бик борынгы заманда ул, тотем буларак, кешеләргә яхшылык эшләүче итеп уйланылса һәм хөрмәт ителсә[1], соңга таба кешенең дошманына әверелә. Бу икенче этапта, тотемизм кире кагылгач, еланның кешене йотуы ерткычлык акты итеп санала башлаган, һәм нәтиҗәдә әкиятләрдә елан белән сугышу турындагы сюжетлар барлыкка килгән. Тарихчы А. Халиков, инглиз галиме Ричард Фрей фикерләренә таянып, җайдакның аждаһа белән сугышу сюжеты болгарларга иран халыкларыннан сасанилар дәверендә кергән дип уйлый[2].

Вакытлар үтү белән әсәрнең үзәгенә алынган вакыйга – герой белән мифик затлар арасындагы көрәш – сыйнфый җәмгыять шартларындагы төп антагонистик сыйныфлар бәрелеше итеп кабул ителә башлаган. Чөнки кеше фикерләвенең тарихи үсеше дәвамында могҗизага бәйләнешле образлы күзаллаулар да үзгәреш кичерә.

Сүз уңаенда әйтеп үтик: соңгырак чорда, әнә шундый яңача аңлау өчен шартлар тугач, әкият тормышка якыная төшә – тылсымлы әкиятләрнең кайберләрендә, мәсәлән, традицион патша образы, трансформацияләнеп, монарх-патша образына әверелә. Шулай итеп, тылсымлы әкиятләрнең бер үзенчәлеге рәвешендә, сыйнфый конфликтка корылган әсәрләр барлыкка килә.

---

[1] Ковалевский А.П. Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921– 922 гг. Харьков, 1956. С. 131.

[2] Халиков А.Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казань, 1976. С. 12.

Югарыда сөйләнгәннәрдән аңлашылганча, үлеләр дөньясы турындагы күзаллау тылсымлы экиятләрдә киң чагыла. Әкиятләрдә еш очрый торган төрле тылсымлы әйберләр алып кайту мотивы да шул ук чыганак белән бәйле. Мәсәлән, «Патша малае һәм аның фәкыйрь күршесе» дигән экияттә герой, бик еракка барып, төрле ашамлыклар чыга торган тырыс, ә «Патша белән солдат» экиятенең герое нәрсә теләсәң шул чыга торган тартма алып кайта. Мондый сюжетлар мәдәни геройлар турындагы мифларга барып тоташа[1].

Тылсымлы экиятләрнең бер тармагы булган батырлар турындагы экиятләрдә (мәсәлән, «Ак бүре», «Камыр батыр», «Турай батыр», «Таң батыр», «Алтын алма», «Өч дус», «Өч күгәрчен» әсәрләрендә) геройның икенче дөньяга – еш кына җир асты дөньясына сәяхәте һәм аннан кыз алып кайтуы – шаманның үлеләр дөньясына барып, авыру кеше җанын алып кайтуын гәүдәләндерә. Димәк, бу төр экиятләрнең генезисында шаман легендаларының да сизелерлек роле булган дип әйтергә мөмкин.

Тотемизм, инициация, шаманизм – болар барысы да дини күренешләр, дөресрәге – кабилә диннәренең формалары. Димәк, без бу урында экиятнең дин белән бәйләнеше мәсьәләсенә килеп керәбез. Бу бәйләнеш ни дәрәҗәдә соң?

Күргәнебезчә, кабилә диннәрендә зур урын алган төрле күзаллаулар экиятләрдә киң чагыла. Хәзер кыскача гына шуларның тагын берничәсенә тукталып узыйк. Сүз биредә **тыю** (табу), **тылсым** (магия) һәм **анимизм** турында барачак.

Табу – борынгы халыкларның ышануы буенча, тыелган эш, әйтергә ярамаган сүз, кулланырга ярамаган әйбер. Борынгы кеше тормышындагы эш-хәрәкәтләрнең әнә шулай катгый тыюлар белән чикләнүе – аның табигатьтә һәр адымда очрый торган күп төрле куркынычлардан гарантияләнмәгән булуы нәтиҗәсе. Тыюны бозу сәбәпле зур бәхетсезлеккә юлыккан кешеләр турында ул дәвердә күп төрле хикәяләр барлыкка килгән.

Чынбарлыкта булган бу күренеш экиятләрдә дә чагылмый калмаган. «Урман каравылчысы» дигән экияттә геройның әтисе үзенең улына урмандагы мәгълүм бер сукмактан йөрмәскә куша. «Дию патша» экиятендә геройга очраган зур сакаллы карт шулай ук: «Куркыныч сукмактан китмә»,– ди. «Сүз тотмас» экиятендә исә бака тиресен беркемгә дә күрергә ярамау турында әйтелә. Әкиятләрдә

---

[1] Тәүге тапкыр ут, су һ.б. нәрсәләрне булдырган беренче бабалар мифологиядә мәдәни геройлар дип йөртелә. Аларның эшләре сурәтләнгән архаик әсәрләрне мәдәни геройлар турындагы мифлар дип атыйлар.

тагын серне чишү («Сер тотмас»), мәгълүм бер амбарны яисә сарайны ачу («Тәмәке янчыгы»), атны йөгәне белән сату («Сихерче мулла», «Кучер малае») кебек эшләргә карата да тыю очрый. Әкият героеның маҗаралары башлануга сәбәп әнә шул тыюның бозылуы нәтиҗәсендә туа.

Борынгы кеше тормышында тылсым шулай ук зур урын тоткан. Тылсым ул – дөнья белән идарә итүче көчләрне кеше үзенең ихтыярына һәм максатларына буйсындыра ала дигән ышануга нигезләнгән күзаллаулар, хәрәкәтләр һәм ысуллар системасы. Ул бик күп йолаларның мөһим состав өлеше булып тора.

Әкиятләрдә очрый торган күрәзәлек, ырым һәм сихер – барысы да тылсым белән бәйле.

Тылсым үзе ике принципка нигезләнә. Беренче принцип буенча, ул охшашлыктан барлыкка килә, ягъни нәтиҗә сәбәпкә охшаш була. Мондый тылсымның барлык күзаллауларын һәм алымнарын Дж. Фрэзер охшатып кабатлана торган яисә гомеопатик тылсым дип аталган төргә кертә[1]. Мәсәлән, кыргый кеше үзенең дошманын үтерергә теләсә, балавыздан курчак рәвешендә әлеге дошманның сынын ясап, утка ыргыткан һәм шуннан соң дошман үзе дә шул ук язмышка дучар була дип ышанган.

Без тикшерә торган әкиятләрдә гомеопатик тылсымның чагылышы булган бик күп мисаллар табарга мөмкин. «Кара кош» әкиятендә сыбызгы сызгыртып давыл чыгару, су өстенә таяк белән сугып күпер ясау күренешләре белән очрашабыз. Кайрак ташлагач – тау ясалу, taрактан – урман, көзгедән – диңгез барлыкка килү дә әкиятләрдә аеруча еш очрый. Бу мисалларда тылсымлы әйберләр белән табигать күренешләре арасындагы охшашлык күзгә бәрелеп тора.

Икенче принципның нигезендә бер-берсе белән озак вакытлар тыгыз мөнәсәбәттә булган әйберләр, бигрәк тә кеше һәм аның үз әйбере, алар арасындагы элемтә беткәннән соң да, бер-берсенә тәэсир итешәләр дигән ышану ята. Әйтик, борынгы кешеләр үзләренең киселгән чәч-тырнакларын, дошман шулар аркылы зарар китермәсен өчен, бик нык яшерә торган булганнар. Алар әнә шулай сихри телепатиягә, ягъни әйберләрнең бер-берсенә еракtан торып тәэсир итә алу үзенчәлегенә ихлас күңелдән ышанганнар. Бу принципка нигезләнгән күзаллаулар һәм алымнар Дж. Фрэзер тарафыннан тәэсирле, йогынтылы яисә **контагиоз тылсым** дип исемләнгән[2].

[1] С.А. Токарев бу төрне «имитатнв тылсым» дип атый (Токарев С.А. Ранние формы религии. М., 1964. С. 93).

[2] Тылсымның бу төрен еш кына «парциаль тылсым» дип атыйлар (Токарев С.А. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 92).

Бу галим тылсымның әлеге ике төрен бергә берләштереп, аны **симпатик** тылсым дип атый. Әкиятләрдә кайрактан тау ясалуда да, юлга чыккан кеше үлгәч, аның өйдә калдырган әйберләреннән (мәсәлән, каурыйдан) кан тамуда да әнә шул яшерен, күзгә күренми торган симпатик бәйләнешкә ышану чагыла.

Вакытлар узу белән, әкият персонажларының тылсымнарында үзгәрешләр дә барлыкка килә: тылсымлы әйберләр инде турыдан-туры нәтиҗәне түгел, ә бәлки иң элек нәтиҗәне барлыкка китерүче ярдәмчеләрне тудыралар. Хәтта ярдәмчеләр дә эшне бер мизгелдә генә башкара алмыйлар, аларга моның өчен күпмедер вакыт таләп ителә башлый.

Мондый күренешләр бигрәк тә геройның авыр бурычлар үтәве вакытында очрый. Мәсәлән, «Өч күгәрчен» әкиятендә патша йөкләгән авыр бурычны герой түбәндәгечә башкара. «Төн урталары җитеп, бөтен кеше йокыга китү белән, бу егет күгәрченнәрдән алып кайткан камчысын алып чыгып, бер генә селтәп җибәрә. Селтәп җибәрүе була, җир йөзендәге пәриләрнең барысы да моның каршысына килеп басып: “Ни боерасың?” – дип сорыйлар. Егет әйтә: “Таң атканчы патша сараеннан да яхшырак итеп миңа бер сарай салыгыз, ди. Патша сарае белән безнең сарай арасында алтын күпер булсын, ди. Аның өстеннән алтын буяулар белән буятылган машиналар йөреп торсын, ди. Күпер астыннан зур-зур пароходлар үтеп торсын, елганың ике ярында алмагачлар үсеп торсын, алмалары пешеп торсын”, – ди. Дию пәриләре: “Ярар, була ул”, – дип калалар.

Хәзер дию пәриләре тотыналар да егет әйткәннәрне **ике сәгать эчендә** эшләп ташлыйлар, ди, патша кушканнан да берничә өлеш яхшырак итеп эшлиләр, ди».

«Дию кызы, бөлгән бай малае һәм мулла» дигән әкияттә без шулай ук персонажга ярдәм итүче пәриләр белән очрашабыз.

«Ак бүре» әкиятендә дә шуңа охшаш эпизод бар: «...егетләрнең анасы, тышка чыгып, диюдән алып кайткан балдагын бармагыннан алып сызгыртып җибәргән иде, – җирдәге чүпкә сан бар, гыйфриткә сан юк,– шулкадәр күп **гыйфритләр** килеп моның катына җыелдылар.

– Ләббәйкә, хәзрәт, ни боерасыз? – диделәр».

Шулай итеп, әкияттә тылсымны да яңача аңлау барлыкка килә. Ягъни тылсым үзенә күрә мотивлаштырыла башлый. Икенче төрле әйткәндә, югарыда мисал итеп китерелгән тылсым күренешләреннән, кеше тели торган, ләкин әлегә аның хыялында гына туган нәрсәләр кинәт кенә юктан бар була алмыйлар, бәлки аларны булдыру өчен кемнәргәдер күп көч куеп, күпмедер вакыт дәвамында эшләргә кирәк, дигән хакыйкать аңлашыла.

Шуны да әйтеп узыйк: ярдәмчеләрнең «илаһи затлар» яисә «әшәке затлар» булуына карап, тормышта тылсым ак һәм карага аерылган. Шул яктан караганда, без әкият героеның төрле «әшәке затлар» ярдәмендә эшләгән тылсымын кара тылсым чагылышы дип билгели алабыз. Инде аларның идеаль геройга хезмәт итүләре мәсьәләсенә килсәк, бу күренеш әлеге затларның дуалистик табигате белән бәйле.

Җыеп әйткәндә, әкияттәге тылсым күренеше бик борынгы булса да, шул тылсымны барлыкка китерүдә катнашучы ярдәмче мифик затларның килеп керүе, безнеңчә, чагыштырмача соңгырак күренеш, һәм аны әкият героеның мифик сыйфатлары югала барудагы этапларның берсе дип аңларга кирәк.

Инде өченче мәсьәләгә күчик. Борынгы кеше табигатьтәге һәрнәрсәне җанлы итеп күзаллаган. Фәндә бу күренеш анимизм дип атала. Анимистик караш буенча, кешенең һәм әйберләрнең җаны чыгып-кереп йөри дип уйланган. Мәсәлән, кешенең җаны вакытлыча гына чыкса – кеше йоклый, ә бөтенләй чыкса – үлә, имеш.

Абстракт фикер йөртү сәләте зәгыйфь булган кыргый кеше җанны конкрет материаль әйбер итеп күз алдына китергән: аны күрергә, тотып карарга һәм тартмага салып сакларга мөмкин дип уйлаган. Шулай булгач, җан кеше тәнендә генә түгел, аннардан тыш та яшәргә мөмкин, һәм болай итү хәтта зарур да, чөнки кешене тормышта күп төрле куркынычлар сагалап тора. Шәхси иминлеген тәэмин итү максатыннан чыгып кеше үзенең җанын тәненнән тыш, аерым бер ышанычлы җирдә, мәсәлән, берәр хайван, үсемлек яисә предмет эчендә саклый ала[1].

Җанны тәннән аерым итеп күз алдына китерү тылсымлы әкиятләрдә еш очрый. «Унберенче Әхмәт» әкиятендә җен патшасы үзенең дүрт җанын үрдәк оясындагы дүрт йомырка эчендә саклый. Җитмәсә, әлеге үрдәк оясы йөз илле чакрым ераклыктагы күлнең бер утравында урнашкан, ә күлне дүрт кабан дуңгызы саклап тора икән.

«Утыз ул» әкиятендә дию пәрие патша кызына үзенең җаны кайда икәнен түбәндәгечә сөйли: «Минем җаным, ди, бик еракта шул, ди. Диңгез аркылы чыккач, өч ботаклы бер зур агач булыр, ди. Шул агачның өстендә өч башлы кара елан булыр, ди, шул кара елан астында, ди, кара мәче булыр, шул кара мәче минем жаным булыр», – ди.

Мисаллардан күренгәнчә, персонаж, үзен үлемнән саклау өчен, җанын тәненнән чыгарып, куркынычсыз урынга куя. Ләкин герой, ахыр чиктә җанын кулга төшереп, аны юк итә, һәм шул вакыт җан иясе (күп очракта дию) үзе дә һәлак була.

[1] Фрэзер Дж. Золотая ветвь. Вып. I. С. 193–194.

Җанының кайда саклануын белү максаты белән патша кызы биргән сорауларга дию еш кына ялган һәм буталчык җаваплар бирә. Мәсәлән, әлеге «Утыз ул» экиятендә дию үзенең җанын башта себеркедә, ә аннан соң кисәү агачында, ди. Бары тик ышаныч казангач кына, кыз аның серен алуга ирешә. Бу очракта дию шикләнүчән һәм үтә сак эш итүче кыргый кешегә бик охшый. Ләкин серне алу экияткә кирәк булган өчен генә эшләнә, югыйсә кыргый кеше беркайчан да чит-ят кешегә «җанының кайда саклануын» әйтмәгән, һәм аны бу серен ачарга беркем дә мәҗбүр итә алмаган.

Әкиятләрдә геройның, юлга чыкканда, берәр нәрсәне түшәмгә кадап яисә матчага кыстырып китүе очрый. Мәсәлән, «Турай батыр» экиятендә герой, сәфәргә чыкканда, матчага каз каурыен кыстырып калдыра. Герой үтерелгәч, каз каурыеннан кан тама башлый. Бу күренеш шулай ук җанны вакытлыча берәр әйбер эченә «урнаштырып» китүгә ишарә ясый. «Ике туган» экиятендә туганнар бер-берсеннән аерылышканда юл чатына пычак кадап китәләр. Аларның берсен сихерче карчык ташка әверелдергәч, пычакның ярты ягы күгәреп чыга (бер пычакта икесенең дә җаны яши, янәсе). «Өч күгәрчен» экиятендә исә, герой үтерелгәч, аның түшәмгә кадап калдырган пычагы бер идәнгә, бер түшәмгә кадала башлый.

Шулай итен, җанның тәннән тыш берәр җирдә саклана алуы турындагы күзаллау – экиятне бизәү өчен генә хезмәт итә торган гадәти уйдырма түгел, бәлки борынгы заман кешесенең ышануларындагы догматларның, ягъни бәхәс ителми торган кагыйдәләрнең берсе булган.

Кыскасы, кабилә диннәрендәге төрле йола-гадәтләр һәм күзаллаулар тылсымлы татар экиятләрендә саф хәлендә дә, үзгәргән рәвештә дә киң чагыла һәм алар экиятнең мөһим компонентларын тәшкил итәләр. Ә сыйнфый җәмгыять диннәре, аерым алганда Болгар дәүләтендә X гасырда рәсмиләштерелгән ислам дине, кайбер элементлары очраса да (мәсәлән, хаҗга бару, дога кылу, никах уку һ.б. күренешләр), экиятләрнең нигезенә тәэсир итә алмаган. Моны Г. Бәширов та билгеләп үткән иде[1].

* * *

Моңа кадәр татар фольклористикасында экият тарихына караган махсус хезмәтләр булмаганлыктан, биредә без тылсымлы экиятнең иң мөһим мәсьәләләрен аның генетик чыганакларына мөнәсәбәттә бәян иттек. Генетик нигезне ачыклау – тикшерелә торган жанрның

[1] Бәширов Г. Безнең заман. Казан. 1953. Б. 251.

тарихи-этнографик ягы. Ләкин әкият, тарихи-этнографик күренеш булу белән бергә, сүз сәнгате әсәре дә булганлыктан, аның поэтикасына тукталмый мөмкин түгел.

Иң элек сюжетларның (мотивларның) генетик хасиятләре ягыннан төркемләнеше турында берничә сүз.

Төрле халыкларның әкиятләрен күзәткәндә, алардагы сюжет һәм мотивларның бер-берсенә гаять охшашлыгы игътибарны җәлеп итә. Бу хәл – әкиятнең бер үк тамырдан булуы турында сөйли. Димәк, тылсымлы әкиятнең югарыда бәян ителгән төп генетик чыганаклары (мифлар, йолалар, үлеләр дөньясы турындагы күзаллаулар, шаман легендалары) татар әкиятләре өчен генә түгел, бәлки барлык халыкларның тылсымлы әкиятләре өчен дә уртак икән.

Академик А.Н. Веселовский күрсәткәнчә, кешелек үсешенең беренче чорларында көнкүреш яки психологик шартларның охшашлыгы, бердәмлеге нәтиҗәсендә күп кенә охшаш мотив һәм сюжетлар мөстәкыйль рәвештә барлыкка килә алган[1]. Шуңа күрә хәтта географик яктан бер-берсеннән бик ерак торган халыкларның әкиятләрендә дә охшаш урыннар күп очрый. Болар – типологик характердагы уртаклыклар. Халыкара сюжетлар шул юл белән барлыкка килгән. Мәсәлән, «Камыр батыр», «Чәчәк күлмәк», «Үги кыз» һ.б. бик күп әкиятләрнең сюжеты әнә шундыйлардан.

Димәк, халыкларның уй-теләкләре, хыял-омтылышларында да элек-электән үк уртаклык булган һәм бу аларның поэтик иҗатларында да ачык чагылган. Ләкин әкиятләрдә, типологик охшашлыклардан тыш, тарихи-генетик бәйләнешләр белән аңлатыла торган бердәйлекләр дә шактый зур урын тота. Мәсәлән, аждаһа һәм дию персонажлары төрки халыкларның барысында да диярлек бар. (Гәрчә бу образлар, алда әйткәнебезчә, элек типологик характерда булса да, әлеге халыкларның тарихи үсеше дәверендә аларның генетик характердагы эволюция кичергән булуы да шөбһәсез.)

Билгеле булганча, теге яки бу халыкның формалашуында, бер яктан, төрле кабиләләр катнашса, икенче яктан, бер үк кабилә берничә халык составына керергә мөмкин. Әйтик, татар халкының этногенезында болгар, кыпчак, угыз һ.б. кабиләләр катнашуы мәгълүм. Шул ук вакытта әлеге кабиләләр башка халыкларның оешуына да өлеш керткәннәр. Мәсәлән, кыпчаклар башкорт, каракалпак, казакъ һ.б. халыкларның формалашуында зур роль уйнаган. Шуңа күрә бу халыкларның әкиятләрендә шушы төркемгә генә, ягъни төрки халыкларга гына хас булган уртаклыкларның булуы табигый.

---

[1] Веселовский А.Н. Поэтика сюжетов // Историческая поэтика. Л., 1940. С. 500.

Ләкин әкиятләрдә уртаклык никадәр генә зур булмасын, аларда теге яки бу халыкның үзенә генә хас үзенчәлекләре дә чагылмый калмый. Мондый үзенчәлекләр күбесенчә геройларның характерында, сөйләмендә, табигать күренешләрендә, көнкүреш детальләрендә ачык күренә. Ниһаять, милли үзенчәлекне аерым мотив һәм сюжетлар да тәшкил итә.

Болардан тыш, географик кыса белән чикләнгән һәм шул кыса эчендә яшәүче халыклар иҗаты өчен генә хас региональ үзенчәлекләрнең булуы да мәгълүм.

Тикшеренүләрдә тагын «алынма сюжет» дигән төшенчә дә очрый. Болар – башка халыклар репертуарыннан кергән сюжетлар. Алар арасында халыкара сюжетлар да, халыкларның билгеле бер генетик төркеменә генә хас булганнары да, шулай ук теге яки бу халыкның үз иҗаты чикләрендә туган оригиналь сюжетлар да булырга мөмкин. Шундый күчешләргә төрле халыкларның үзара экономик һәм культура багланышлары сәбәп булган. Татарлар, мәсәлән, элек-электән рус һәм Идел буе халыклары белән генә түгел, Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия халыклары белән дә тыгыз элемтәдә торганнар. Шуңа күрә татар әкият репертуарында рус, фарсы һәм гарәп халыкларыннан кергән сюжетлар очравы бер дә гаҗәп түгел. Алынма сюжетлар, аларны кабул итүче халыкның әкият традицияләренә ярашлы рәвештә үзгәреп, «үз булып», яңа рух белән сугарылып яши башлыйлар. Шунлыктан, мәсәлән, «Елан патшасы Шаһмара» кебек иран фольклорыннан кергән әсәрне дә без татарныкы дип саныйбыз.

Язмалар санына караганда, татар тылсымлы әкиятләре арасында түбәндәге халыкара сюжетлар аеруча киң таралган: «Өч патшалык» (АА 301), «Могҗизалы качу» (АА 313), «Киек сөте» (АА 315), «Патша эте» (АА 449), «Чибәр хатын» (АА 465), «Үги ана һәм үги кыз» (АА 480), «Илтифатлы хайваннар» (АА 554), «Тылсымлы балдак» (АА 560), «Тылсымлы бүләкләр» (АА 563), «Мөгезләр» (АА 566), «Тылсымлы кош» (АА 567), «Гаҗәеп балалар» (АА 707)[1] һ.б.

Күп кенә әкиятләр берничә сюжетка корылган. Мәсәлән, «Ярлы егет белән патша кызы» әкияте АА 560, 315 B, 566 сюжетларыннан тора, ә «Серле балдак» әкиятендә АА 922, 300 A, 400 B һәм 560 сюжетларын табып була. Тылсымлы әкият составындагы эпизод һәм мотивлар, гадәттә, тотрыклы бербөтен хикәя тәшкил итә. Ләкин әкиятләрнең кайберләрендә сюжет тотрыксызлыгы да күзәтелә. Моңа мисал итеп, аңгыра җен (шайтан, пәри, дию) турындагы

[1] Сюжетларның исемнәре һәм тәртип саннары Аарне–Андреев күрсәткече буенча алынды. (Андреев Н.П. Указатель сказочных сюжетов по системе Аарне. Л., 1929.)

әкиятләрне күрсәтергә мөмкин. Алардагы аерым эпизод һәм мотивларның мөстәкыйль әсәр булып формалашканнары булган кебек, кайчак шулар ук башка әкиятләр составында да очрый (мәсәлән, күлне күккә асу белән куркыту һ.б.).

**Контаминация,** ягъни мәгълүм берничә сюжетның яки алардагы аерым мотивларның бергә үрелеп яңа рәвешкә керүе нәтиҗәсендә еш кына әкиятләрнең төрдәшләре барлыкка килә. Бу очракта әкиятнең герое шул ук кала, башка персонажлар өстәлми, бары тик герой катнаша торган эпизодлар гына арта. Мисал итеп «Камыр батыр» әкиятенең вариантларын күрсәтергә мөмкин.

Гомумән тылсымлы әкиятләрдә жанрның башка төрләренә караганда трансформация, ягъни үзгәреш өчен мөмкинлек зуррак. Чөнки, күләмнәре зур булганга күрә, алар кыска әсәрләрне сөйләгәндәге кебек төгәллек белән сөйләнә алмыйлар. Монда импровизациягә, сюжет һәм мотивларның ирекле контаминациясенә юл ачыла.

Барлык әкиятләрнең дә үзәгендә идеаль герой образы тора. Әкият героеның кече туган булу очрагына без тукталган идек инде. Кече туган еш кына таз итеп сурәтләнә, гадәттә башта ана бернинди дә өмет багланмый, олы туганнар тарафыннан «юләр» дип кимсетелә һәм җәберләнә. Шулай да ул олы туганнар кулыннан килмәгән эшләрне башкарып чыга, үзенең максатына ирешә һәм күп очракта патша кызына өйләнеп, үзе дә патша булып кала. Ә олы туганнар хурлыклы рәвештә җиңелүгә дучар булалар, кылган усаллыклары, җинаятьләре өчен хөкем ителәләр.

Тылсымлы әкиятләрдә геройның гаиләдә бердәнбер бала булу очрагы да киң урын алган.

Әкият герое хезмәт халкының социаль, әхлакый һәм эстетик идеалларын чагылдыра.

Тылсымлы әкиятләрнең композициясенә башлам, эпик өлеш (төенләнеш, вакыйгалар үсеше, кульминацион нокта, чишелеш) һәм бетем хас.

Бу төрдәге әкиятләрнең характерлы башламы, алдарак әйткәнебезчә, әсәрнең уйдырмага корылуына ишарә итә. Бер үк вакытта ул тыңлаучыларның игътибарын җәлеп итүгә дә исәпләнгән. Мәсәлән, «Аучы малае» әкияте: «Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, бака плотник, үрдәк үрәтник булган заманда яшәгән, ди, бер аучы»,– дип башланып китә. Ләкин мондый типик башлам һәр әкияттә дә булмый. Киресенчә, тылсымлы әкиятләрнең күбесенә көнкүреш әкиятләрендәге кебек башлам хас: «Борын заманда бер авылда ир белән хатын бер генә ир малай үстергәннәр» («Дию мулла»). Әмма башлам нинди генә булмасын, ул әкиятнең

герое белән таныштыра, аның яшәгән урыны турында мәгълүмат бирә һәм вакыйгалар барган вакытны күрсәтә.

Төенләнеш күп кенә әкиятләрдә герой өйдән чыгып китеп беренче каршылыкка очрагач барлыкка килә. Геройның өйдән китүе төрле сәбәпләр аркасында булырга мөмкин: ул, күбесенчә, кәләш эзләргә, дөнья күрергә, югалган берәр кешене яки әйберне эзләргә юнәлә.

Вакыйгалар үсешендә геройның дошманнары белән очрашу һәм сугышу күренешләре зур урын алып тора; аның антиподларыннан дию, убырлы карчык (җалмавыз) һәм аждаһа (елан) турында алдарак сөйләнгән иде инде. Болардан тыш шундый рольдә тагын Үзе бер карыш, сакалы биш карыш карт. («Камыр батыр», «Турай батыр»), җен патшасы («Унберенче Әхмәт»), Этбаш-сыераяк («Батыр солдат») һ.б. очрый.

Әлбәттә, без биредә мифик затларны гына күрсәттек. Тылсымлы әкиятләрдә геройның антиподлары төрле социаль типлар да (патша, бай һ.б.) булырга мөмкин.

Максатына ирешү юлында геройга күп вакыт ярдәмчеләр булыша. Ярдәмчеләр сыйфатында гади кешеләр (юлаучы карт, асрау кыз һ.б.), шулай ук гадәттән тыш сәләткә ия булган әкият батырлары (зур агачларны йолкып атучы, комга төкереп күл ясаучы, кызуга һәм салкынга түзә алучы, күп ашаучы һәм күп эчүче, бик зур атлаучы, гаять төз атучы һ.б.ш.) катнашкан кебек, хайван, кош затыннан булган төрле персонажлар да (ат, эт, мәче, кәҗә тәкәсе, аю, бүре, куян, төлке, күгәрчен, саескан, сыерчык, мифик сәмруг кош һ.б., һ.б.) зур урын алып тора. Гадәттә ярдәмче хайваннар яисә кошлар, хәбәрләшү чарасы итеп, геройга әгъзаларының бер өлешен (мәсәлән, кош – каурыен, җәнлек – йон бөртеген, ат – кылын, балык – тәңкәсен) биреп калдыра. Кирәк вакытта герой әлеге нәрсәләрне яндыра, һәм шул мизгелдә үк аларның ияләре (ягъни кош, җәнлек, ат, балык һ.б.) пәйда була.

Шулар өстенә герой тылсымлы әйберләрдән дә файдалана. Аларның төрләре гаять күп: эченнән гаскәр чыга торган таяк, төрле ашамлыклар чыга торган тырыс, күпме алсаң да хәзинәсе кимеми торган сумка, кигәч күрсәтми торган бүрек һәм җилән, зур атлата торган итек, ерактан ук дошманны кырып сала торган кылыч һ.б., һ.б. Дошманыннан качып барганда әкият герое күп вакыт тарак, көзге, кайрак кебек тылсымлы әйберләр куллана. Аларны дошман юлына ташлагач, тарак – куе урманга, көзге – киң дәрьяга, ә кайрак – биек тауга әверелә. Сызгыртып ярдәмчеләрне чакыра торган тылсымлы балдак та әкиятләрдә күп очрый.

Гадәттә тылсымлы әйберне герой эпизодик персонаждан (бүләк бирүчедән) ала. Бүләк бирүче вазифасында геройның үлгән әтисе

(«Юләр угыл»), юлда очраган карт яисә карчык («Үги ана белән яшь егет», «Күренмәс чикмән», «Серле балдак», «Алтын алма», «Патша белән солдат», «Унөч»), йә булмаса гадәти «бер кеше» («Ике туган»), төрле җанварлар («Патша малае, аның апасы, юлбарыс һәм башкалар»), кошлар («Өч күгәрчен»), шулай ук мифик затлар (сәмруг кош) булырга мөмкин («Мәче һәм ярлы егет»).

Герой катнашындагы соңгы хәлиткеч вакыйга (ярыш яисә дошман белән соңгы көрәш) әкият сюжетының кульминациясе була.

Тылсымлы әкиятләрдәге чишелешкә, кагыйдә буларак, бәхетле финал хас: герой, патша кызына өйләнеп, туган җиренә кайта яисә, кыз янында калып, патша урынына тәхеткә утыра. Яхшылык, хаклык җиңә, ә явызлыкка җәза бирелә.

Эпик өлештән соң гадәттә бетем килә һәм ул сюжетны тәмамлап куя. Гадәти бетемнәр «яхшы гына гомер итәләр» («Аучы белән асрау кыз»), «һәркем үз юлына китте, шуның белән әкият тә бетте» («Әйгәли батыр») кебек формулалардан гыйбарәт. Ләкин тылсымлы әкиятләрдә такмаза характерындагы бетемнәр дә күп кулланыла. Мондый бетемнең вазифасы – тыңлаучыларны әкият дөньясыннан реаль дөньяга кайтару һәм аларның күңелен күтәреп, көлдереп алу. «Болар бик яхшы торалар. Бүген бардым, кичә кайттым, иләк белән бал эчтем» («Аучы малае») кебек бетемнәрнең максаты шуннан гыйбарәт. Бу бетемдәге бер үзенчәлекне билгеләп үтәргә кирәк: сөйләүче әкият вакытын юри реаль вакытка күчереп, әкият героеның танышы сыйфатында, әсәргә үзен дә кертә. Әкияткә тыңлаучыларның замандашы булган реаль шәхес – сөйләүченең килеп керүе махсус художество алымы булып тора. Бу алым такмаза-бетемне тагын да тәэсирлерәк итә.

Теге яки бу халыкның әкият традициясенә ярашлы рәвештә, бетем тагын башка төрле вазифалар да үтәргә мөмкин. Мәсәлән, русларда элек профессиональ әкиятчеләр булганлыктан, рус әкиятләре бетемендә сөйләүчегә сый яисә бүләк кирәклегенә ишарә очрый: «Вот вам сказка, а мне бубликов связка», яисә «Тут и сказке конец, сказал ее молодец, и нам молодцам по стаканчику пивца, за окончание сказки – по рюмочке винца»[1].

Татар әкиятләрендә мондый бетемнәрнең очраганы юк.

Тылсымлы әкиятләрнең композициясе гади. Ул барлык халыкларда да шулай. Ләкин төрле халыкларның әкият композициясендә аерым үзенчәлекләр булырга мөмкин. Мәсәлән, татарларда кайбер башка халыкларның әкиятләренә (әйтик, русларныкына) хас булган

---

[1] Померанцева Э.В. Русская народная сказка. М., 1963. С. 67.

присказка – башламнан алда килә торган һәм әсәрнең эчтәлеге белән турыдан-туры бәйләнмәгән өлеш – сирәк күренеш. Моңа татарларда профессиональ әкиятчеләрнең мәйданнан бик иртә китүе сәбәп булган, күрәсен. Присказка сакланган әкиятләрдән 1947 елда Татарстанның Апас районы Иске Энәле авылында Сафиулла Габитовтан язып алынган «Алтын кош»ны күрсәтергә мөмкин. Ул болай башлана: «Борын-борын заманда, борыны китек команда, саескан сотник, үрдәк урәтник, песнәк писер булып йөргән заманда, эт дисәтниккә менде, ди, шул заманда начальство күбәеп китте, ди. Бар иде, ди, бер кеше, чыгып китте, ди, ул ике сукмак, бер юл белән. Кәкре китте, җантык китте, чалыш китте, кыек китте, бара-бара барып җитте, ди, бу ике куак, бер талга. Берне кисте кәкрене, берне кисте бөкрене, янә китте, ди, ике сукмак, бер юл белән, барып җитте, ди, бу бер күлгә, утырып торадыр иде, ди, анда ике чүрәки, бер үрдәк. Кәкре атты, тияр-тимәс булды, бөкре атты, тиде, ди. Үрдәкне суйды, пот май чыкты, ди».

Димәк, кайбер җор әкиятчеләр, тыңлаучыларның кәефен күтәрү өчен, әнә шундый такмаза-чуалтмышларны да кулланганнар.

Тылсымлы әкиятләргә хас интернациональ сыйфатларның берсе – вакыйганың, күп мәртәбә (гадәттә өч мәртәбә) кабатлануы. Бу – әкият композициясенең үзенчәлекле законы, һәр кабатлауда каршылык арта, хәл катлаулана бара. Бу бигрәк тә геройның авыр бурычлар башкаруы вакытында ачык күренә. Мәсәлән, «Аучы малае» дигән әсәрдә ак сакаллы карт әкият героен өч төн эшләргә мәҗбүр итә. Беренче төнне урман төпләп, шул җирдә үскән ашлыктан иртәнгә кадәр өч потлы өч коймак пешерергә куша. Икенче йомыш түбәндәгедән гыйбарәт: «Монда безнең бик әшәке сазлык бар, ди, шул сазлыкны киптерергә кирәк, ди. Анда йөзем, груша агачлары утыртырга кирәк. Шул сазлык урынын таш белән әйләндереп алырга кирәк. Сазлыкның суы бер елга аркылы агып торсын, бу суга күпер салынсын, ди. Бөтенесе бер төн эчендә эшләнсен, – ди». Өченче төнне әлеге карт әкият героена өч ат бирә һәм шуларның берсен дә югалтмыйча сакларга куша. Ләкин алар гади атлар түгел. Шуңа күрә бу өченче йомыш арада иң авыры булып чыга.

«Аучы» дигән әкияттә герой иң элек алты башлы аждаһаны үтерсә, икенче мәртәбә – тугыз, ә өченчесендә – унике башлысын үтерә.

«Ак бүре» әкиятендә герой дию белән сугышу өчен билгеләнгән биш йөз пот авырлыктагы шарны өченче тапкыр тотынгач кына күтәрә башлый. «Әйгәли батыр» әкиятендә герой үзенә яраклы атны шулай ук өченче мәртәбә сайлаганда гына таба.

Вакыйгаларның әнә шулай эффекты арта бару юнәлешендә кабатлануы беренче чиратта образны героиклаштыру максатына хезмәт итә.

Әкиятләрнең кайберләрендә башламнан соң пролог килә. Прологта күбесенчә геройның төенләнешкә кадәр булган хәле турында сөйләнә. Мәсәлән, «Ут гармуны» әкиятендә төп сюжет вакыйгалары башланганчы, «Үги кыз» әкияте мотивы кертелә: кыз, үги ананың таләбе буенча, урманга китереп ташлана, «Ике туган» әкиятендә дә зур гына пролог бар.

Сирәк кенә булса да, кайбер әкиятләрдә эпик өлештән соң сюжетның дәвамы (эпилог) очрый. Эпилогта геройның төп вакыйгадан соңгы язмышы яисә аның якыннарының хәле сурәтләнә. Мәсәлән, шул ук «Ике туган» әкиятендә төп вакыйгалар тәмамлангач, туй булгач,ауга чыккан геройны һәм аның җанварларын урманда сихерче карчык ташка әйләндерә. Геройның абзасы бу хәлне сизеп килә дә әлеге сихерчедән мәҗбүри рәвештә аларны терелттерә һәм соңыннан карчыкның үзен утка салып яндыра. Әкиятнең соңгы юлларында абзасының өйләнүе турында әйтелә.

Халык әкиятләрендә «уртак урыннар» («loci communes») шактый күп кулланыла: аерым өлешләрнең һәм эпизодларның кабатлануы, күпләренең туй белән тәмамлануы, геройның кече туган булуы һ.б. Уртак урыннарның зур өлешен төрле тотрыклы тәгъбирләр (традицион формулалар) алып тора. Әкиятчеләр бу стилистик фондтан киң файдаланалар.

Тотрыклы тәгъбирләр әкиятнең башында да (**инициаль формулалар**), уртасында да (**медиаль формулалар**) һәм азагында да (**финал формулалар**) кулланылалар.

Әкиятләрнең башламында бигрәк тә «борын заманда» («борын-борын заманда») дигән тәгъбир күп очрый. Озын башламнар тулаем да мөстәкыйль формула булып санала. Мәсәлән: «Борын-борын заманда, кәҗә команда, песнәк писердә, саескан солдатта вакытта, бер авылда өч егет булган, ди» («Өч дус»).

Әкиятнең бетеме турында да шуны ук әйтергә була. «Бүген бардым, кичә кайттым», «Ун көн уен иттеләр, утыз көн туен иттеләр» кебек тәгъбирләр аерым-аерым кулланылган кебек, аларның яки шуларга охшаш башка тәгъбирләрнең шактый күләмле бетемнәрдә барысы бергә кулланылып, мөстәкыйль финал формула рәвешендә дә йөрергә мөмкин.

Инициаль һәм финал формулаларның әкият белән бәйләнеше шактый йомшак, чөнки алар сюжетның, вакыйгаларның состав өлеше булып тормый.

Медиаль формулаларга килсәк, алар ике төркемгә бүленә: а) **тышкы медиаль формулалар,** б) **эчке медиаль формулалар.**

Тышкы медиаль формулаларга бер эпизодны икенчесе белән бәйли торган күчеш формулалары керә. Мәсәлән: «Болар шулай шатланып торсыннар, без егет янына барыйк әле» («Мәче һәм ярлы егет»). Бу типтагы формулалар үзенчәлекле композицион элемент булып торалар.

Тылсымлы әкиятләрдә очрый торган тотрыклы тәгъбирләрнең иң зур өлеше эчке медиаль формулаларга туры килә. Бу формулалар әкиятнең мөһим элементлары белән органик рәвештә бәйләнгән. Алар персонажларның хәрәкәтен, портретын һ.б. якларын характерлыйлар. Күп кулланыла торган эчке медиаль формулаларның берничәсен күрсәтеп узыйк: «Син – минеке, мин – синеке» («Аучы малае»), «Уң ягыма сук, сул ягымнан кан чыксын» («Корчаңгы тай»), «Көн китәләр, төн китәләр, ай китәләр болар», «Ике каба, бер йота» («Аучы егет»).

Югарыда сөйләнгәннәрдән чыгып, шуны әйтергә була: тылсымлы әкиятнең генетик чыганаклары никадәр борынгы чорга караса да, алар белән бәйле сюжет һәм мотивлар һәрвакыт заман таләпләренә җавап биргән: аларда һәрвакыт кешеләрнең теләк-омтылышлары, киләчәккә юнәлгән өмет-хыяллары чагылган. Идея һәм эстетик кыйммәте булмаса, бу әсәрләр меңнәрчә еллар аша бүгенгә кадәр килеп җитә алмаган булырлар иде. Шуның белән бергә, әлеге әкиятләрдә һәр чор калдырган үзенчәлекле эзләрне дә табарга мөмкин.

Хәзерге әкиятчеләр тылсымлы әкиятләрне дә күпмедер дәрәҗәдә бүгенге көнгә яраклаштырып сөйлиләр, ягъни заманга, бүгенге тыңлаучының психологиясенә ярашлы рәвештә әкияттәге кайбер моментлар көчәйтелә, яңа детальләр кертелә, ә кайчак гомумиләштерүләр ясала, мораль нәтиҗәләр чыгарыла. Шулай итеп, тылсымлы әкият үзенең асылы белән никадәр тотрыклы булмасын, барыбер заман белән бергә билгеле бер дәрәҗәдә үзгәрешләр кичерми калмый.

Фантазиягә, оста әкиятчеләр тарафыннан эшләнгән тел-стиль бизәкләренә искиткеч бай булган бу төр әкиятләр халкыбызның үзенчәлекле рухи хәзинәсе булып тора.

Алдарак тылсымлы әкиятләребезнең күп булуын әйткән идек. Әлбәттә, аларның барысын да дөньяга чыгару мөмкин түгел. Ләкин, иң яхшы үрнәкләр сыйфатында сайлап алынып, бу китапка урнаштырылганнары да укучыларыбызны канәгатьләндерер, әкият сөючеләребезне шатландырыр, дип уйлыйбыз.

## Көнкүреш әкиятләре

Көнкүреш әкиятләре башка төр әкиятләрдән реаль чынбарлыкка гаять якын торулары белән аерылалар. Бу әсәрләрнең күбесе сыйнфый конфликтка корылган, һәм алар башлыча Октябрь революциясенә кадәрге авыл тормышын чагылдыра.

Көнкүреш әкиятләренең шушы сыйфаты фольклористикада көнкүреш әкиятләре тылсымлы әкиятләргә караганда шактый соң барлыкка килгән дигән карашның яшәп килүенә китерде. Ләкин соңгы вакытларда бу караш кыю тәнкыйть ителә. Мәсәлән, Е. Турсунов фикеренчә, көнкүреш әкияте башка төр әкиятләр белән бер чорда ук туган, алар белән янәшә үскән[1]. Без дә шушы фикергә кушылабыз.

Көнкүреш әкиятләре үзләренең тематикасы ягыннан шактый чуар. Алар арасында җитез караклар, хыянәтче һәм тугры хатыннар, зирәк кешеләр, бай һәм хезмәтчеләр, муллалар, хәтта аңгыра җеннәр турындагы әсәрләр дә бар. Бу җәһәттән «көнкүреш» атамасы бик үк кулай да түгел кебек. Шуңа күрә тикшеренүчеләр арасында башка атамалар табарга омтылулар да очрый. Кайберәүләр бу төр әкиятләрне, «новеллистик әкиятләр»[2] яисә «халык новеллалары»[3] дип атыйлар. Фәндә «новеллистик әкият» һәм «көнкүреш әкияте» дигән атамалар белән жанрның мөстәкыйль төрләрен билгеләү дә очрый. Мәсәлән, С.Ф. Баранов тапкыр җаваплар, яхшы һәм начар хатыннар, юлбасар кияү, язмыш һ.б.лар турындагы әсәрләрне новеллистик әкиятләргә кертә. Ә калганнарын (башлыча сатирик характердагыларын) көнкүреш әкиятләре дип саный[4] Соңгыларын ул хәтта «көнкүреш реалистик әкиятләр» («бытовые реалистические сказки») дип тә атый[5]. Бер үк вакытта автор бу ике төркем арасына чик куюның авыр булуын да әйтә[6]. Х. Ярми исә әкиятләрнең әлеге төрен «тормыш-көнкүреш әкиятләре» дип исемли[7]. Сүз уңаенда

---

[1] Турсунов Е.Д. Генезис казахской бытовой сказки. В аспекте связи с первобытным фольклором. Алма-Ата: Наука, 1973. С. 198.

[2] Аникин В.П. Сказки // Русское народное поэтическое творчество: Учебное пособие для филологических факультетов педагогических институтов. Под редакцией проф. Н.И. Кравцова. М.: Просвещение, 1971. С. 120–128.

[3] Глонти А. Грузинская народная новелла // Грузинские народные новеллы. Тбилиси, 1970. С. 5–10.

[4] Баранов С.Ф. Русское народное поэтическое творчество: Пособие для студентов историко-филологических факультетов педагогических институтов. М., 1962. С. 146–147.

[5] Шунда ук. Б. 147.

[6] Шунда ук. Б. 146.

[7] Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967. Б. 101.

шуны да әйтеп узыйк: фольклорны яхшы белгән, аны җыйган һәм өйрәнгән рус язучысы Г.И. Успенский көнкүреш әкиятләрен бөтенләй әкият дип санамаган, аларны ул «халык хикәяләре» дип атаган[1].

Соңгы вакытта чыккан кайбер хезмәтләрдә «новеллистик әкиятләр» дигән төшенчә көнкүреш әкиятләре эчендәге төркемнәрнең берсен билгеләү өчен файдаланыла. Мәсәлән, М. Алиева уйгур халкының көнкүреш әкиятләрен түбәндәге дүрт төркемгә аера: новеллистик, авантюр, юмористик һәм сатирик әкиятләр[2].

Күренә ки, классификацияләрдәге аерма тикшеренүчеләр тарафыннан новелла төшенчәсенә нинди мәгънә бирү һәм төркемләүнең кайсы принцибын куллану белән бәйле. Мәсәлән, көнкүреш әкиятләрен тулаем новелла дип атаучылар карашы буенча, новелла төшенчәсе, көнкүреш әкиятләре төренә кергән һәр әсәрне, шул исәптән сатирик һәм юмористик әкиятләрне дә үз эченә ала, ә соңгы очракта инде бу төшенчә әлеге төрнең бер өлешен генә белдерә.

Мәгълүм булганча, тылсымлы әкиятләр белән көнкүреш әкиятләре арасында тора торган әсәрләр дә бар. Андыйларның кайсында реаль чынбарлыкны сурәтләү өстенлек итсә, шулар көнкүреш әкиятләре рәтендә йөртелә. Әйтик, «Тугры белән Алдар» әкияте, сюжетында чишмә суы белән сукырның күзе ачылу, җеннәр сүзен ишетеп дәвалау ысулын үзләштерү кебек мотивлар булуга карамастан, үзенең асылы белән көнкүреш әкиятләре рәтендә торырга тиеш. «Саран белән Юмарт», «Акыл белән Бәхет», «Кулсыз кыз», «Еланнар» һ.б. әкиятләрдә дә без тылсым элементлары белән очрашабыз. «Хәйләкәр адәм», «Диюләрне җиңгән», «Һөнәрле үлмәс» һ.б. әкиятләрдә хәтта мифик персонажлар хәрәкәт итә. Әмма мондый әкиятләрдәге тылсым элементлары һәм мифик персонажлар, сюжетта никадәр генә мөһим урын тотсалар да, ахыр чиктә барыбер ярдәмче вазифа гына башкаралар. Ә кайбер әкиятләрдә тылсым элементларының сюжет белән бәйләнеше шактый йомшак булырга да мөмкин. Мәсәлән, «Гөлшикәр» әкиятендә тылсымлы гөл бар. Иясенең хәле начар булса, ул гөл шиңәргә тиеш. Ләкин әкияттә геройның хәле начарланмый һәм тылсымлы әйбергә үзенең вазифасын үтәргә дә туры килми. Тылсымлы әкиятләрдә исә тылсым үзенең асыл сыйфатларын бер вакытта да күрсәтми калмый, ул – әкиятнең мөһим компонентларыннан берсе булып тора. Ә «Гөлшикәр» әкияте әлеге гөл хәтта бөтенләй булмаган тәкъдирдә дә үзенең композицион бөтенлеген һәм идея-эстетик кыйммәтен югалтмас иде.

---

[1] Успенский Глеб. Полн. собр. соч. Т. I. М.: Изд-во АН СССР, 1940. С. 529.
[2] Алиева М.М. Уйгурская сказка. Алма-Ата,1975. С. 105.

Татар халкының көнкүреш әкиятләре репертуарында бигрәк тә «Фикерле кыз» (АТ 875), «Өч туган» (АТ 763), «Шамак карак» (АТ 1525 А), «Чибәр кыз Хәдичә» (АТ 883 А), «Кулсыз кыз» (АТ 706), «Тугыз Тукылдык, бер Мимылдык» (АТ 1535, АТ 1537), «Мулла эләкте» (АТ 1730), «Хәйләкәр мылтыкчы» (АТ 1380) әкиятләрендәге сюжетлар зур урын алып тора. Шулар өстенә «Бай һәм хезмәтче», «Аңгыра җен» темаларына караган сюжетлар да (АТ 1000–1199) популярлыкта алда күрсәтелгән сюжетлардан калышмыйлар дип әйтергә мөмкин.

Көнкүреш әкиятләрен төрлечә төркемләргә мөмкин. Бу – нигез итеп нинди принципны алуга бәйле. Мәсәлән, тема берлеге һәм геройларның охшашлыгы буенча аларны түбәндәге төркемнәргә аерып булыр иде: «Тапкыр җаваплар турында», «Караклар һәм юлбасарлар турында», «Байлар һәм муллалар турында», «Ялкаулар һәм тиләләр турында», «Алдакчылар турында» һ.б.

Мондый төркемнәр шактый күпкә җыелганлыктан, сюжетларны тагын да зуррак өлешләргә берләштерү сорала. Безнеңчә, татар көнкүреш әкиятләрендә жанр үзенчәлекләре җәһәтеннән дүрт төркем аерымлана: гыйбрәтле әкиятләр, маҗаралы әкиятләр, юмористик әкиятләр, сатирик әкиятләр. Дөрес, бу классификациянең нигезендә бер генә принцип ятмый: беренче төркемдә әсәрләрнең идея-мораль дәрәҗәсе хәлиткеч булса, икенчесендә сюжетның характеры алга чыга, ә соңгыларында сурәтләү алымына өстенлек бирелә. Шулай да, безнең фикеребезчә, практик яктан әлеге бүленеш үзен аклый.

«Гыйбрәтле» дигән атама биредә сәеррәк яңгырый шикелле. Чөнки гомумән алганда барлык әкиятләр дә гыйбрәтле. Ләкин арада үгет-нәсихәт, мораль «маңгайга бәреп торган» әсәрләр дә бар. Алар, мораль алдан билгеләнеп, сюжетлары шуңа иллюстрация рәвешендә иҗат ителгән әсәрләргә охшыйлар. Гыйбрәтле әкиятләр дип без әнә шундыйларны саныйбыз.

Маҗаралы дигән атама да шартлы рәвештә кулланыла. Бу төркемгә башлыча караклар һәм юлбасарлар, яла ягылган хатын-кызлар, шулай ук тугры хатыннар турындагы әкиятләр керә.

Юмористик әкиятләрдә кешеләргә хас булган гомуми кимчелекләр, начар сыйфатлар тәнкыйть ителә. Көлү җиңелчә, «чеметеп алу» характерында. Шуңа күрә аларда ирония өстенлек итә.

Сатирик әкиятләрдә исә күбесенчә сыйнфый җәмгыятьтәге өстен катлау вәкилләреннән һәм дин әһелләреннән көленә, аларның явызлыгы, комсызлыгы, бозыклыгы фаш ителә. Мондый әсәрләрдә көлү сарказм, хәтта гротеск дәрәҗәсенә күтәрелә.

Бу классификация буенча әсәрләрне теге яки бу төркемгә аеруда шулай ук шартлылыкның шактый урын алуын әйтеп үтәргә кирәк. Чөнки еш кына бер үк әсәрдә төрле төркемнәргә хас сыйфатлар очрый. Бу очракта без әлеге сыйфатларның кайсы өстенлек итсә, әсәрне шул сыйфатка ия булган төркемгә кертү ягында. Мәсәлән, «Чибәр кыз Хәдичә» дигән әкияттә мулла һ.б.лар фаш ителсә дә, әсәрнең сюжеты аны сатирик әкиятләргә түгел, бәлки маҗаралы әкиятләр төркеменә кертергә мәҗбүр итә.

Инде хәзер югарыда әйтелгән төркемнәрнең дүртесенә дә беркадәр киңрәк тукталыйк.

Гыйбрәтле әкиятләрдә халыкның бик күп буыннары тарафыннан тупланган тормыш тәҗрибәсе, акылы һәм зирәклеге чагыла. Алар арасында зирәклек темасына багышланганнары аеруча күп. Мәсәлән, шундыйлардан «Зирәк карт» әкиятенә күз салып узыйк. Патша җитмеш яшькә җиткән кешеләрне, барыбер эшкә ярамыйлар дип, үтертә торган була. Шуңа күрә бер егет үзенең картайган әтисен яшереп тота. Картның тормышта кирәге булган, әмма башка берәү дә белмәгән файдалы мәгълүматлары, тәҗрибәсе барлыгына ышангач, патша үзенең әмереннән баш тарта – картларга тими башлый. Шулай итеп, әкияттә явызлык кире кагыла, яхшылык җиңеп чыга.

Картларның васыятьләре турындагы әкиятләрдә атаның улларына васыятьләре күбесенчә кинаяле формада әйтелә. Мәсәлән, «Васыять» дигән әкияттә аталары үлем алдыннан өч улына авыл саен йорт салырга, тәмле аш кына ашарга, ешрак өйләнергә киңәш бирә. Әмма уллары нәкъ аталары әйткәнчә эшләп, һич бәхеткә ирешә алмыйлар. Ниһаять, бер карт очрап, әлеге васыятьләрнең асылын аңлатып бирә: авыл саен йорт салу – авыл саен дус-иш булдыру, тәмле аш ашау – эшләп ашау, еш өйләнү – эш артыннан йөреп, хатыныңны сагынып кайту икән.

Зирәклек темасына караган әсәрләр арасында зирәк җаваплар турындагы әкиятләр аерым игътибарга лаек. Аларны әкият-табышмак яисә табышмаклы әкиятләр дип атарга да мөмкин. Мондый әкиятләрдәге табышмаклар ике төрле була. Беренчесе – кинаяле сөйләм формасында. «Укымышлы кыз» әкиятендә, мәсәлән, егетнең шундый кинаяле сүзләрен бер кыз шәрехләп бирә. Егет үзенә хатынлыкка нәкъ менә шундый зирәк кызны эзли торган була.

Әкиятләрдәге табышмакларның икенче төре сораулардан гыйбарәт. «Өч килен» әкиятендә карт үзенең өч килененә бер үк сорауларны бирә. Дөрес җавапларны кече килененнән ишетә. Сораулар түбәндәгеләр: «Бу дөньяда нәстәкәй симез?» («Җир»), «Бу дөньяда нәстәкәй тавышы көчле?» («Ипи, тоз авазы»), «Бу дөньяда нәстәкәй якты?» («Кояш»).

Тикшеренүчеләрнең күрсәтүенчә, мондый төрдәге табышмакларның чыганаклары бик борынгы чорларга, өйләнәсе егетнең яисә башлыкның зирәклеген сыный торган борынгы гадәтләргә барып тоташа. Мондый сынаулар аларның кинаяле сөйләмне аңлавын һәм файдалана белүен ачыклау өчен үткәрелгән. Чөнки борынгы кеше ау, сугыш, өйләнү кебек мөһим эшләрне явыз рухлардан яшерергә тырышкан һәм кинаяле сөйләм бу эштә ярдәм итә дип ышанган[1].

«Фикерле кыз» әкиятендә патша картка үзе янына ничек килергә икәнен болай белдерә: «Ач та килмә, тук та килмә; ялангач та килмә, кием белән дә килмә; атланып та килмә, җәяү дә килмә».

Карт, кызының киңәше белән патша янына ятьмәдән тегелгән кием киеп, кәҗә тәкәсенә атланып, көнбагыш чиртә-чиртә бара.

Бу әкиятнең үзенчәлеге шунда: биредә табышмакларны бер як биреп, икенче як чишеп кенә калмый, бәлки бу эш ике якның да бердәй катнашуы белән бара. Патша кызга өч чирек җептән киндер сугып, күлмәк-ыштан тегәргә куша. Кыз үз чиратында, патшага шырпы буе чыбык җибәреп, киндер сугу өчен стан ясап бирүне таләп итә. Патша җиде яшьлек сарык тәкәсен бәрәнләтү бурычын йөкләгәч, кыз патша килгән төшкә әтисен мунчага «бәбәйләргә» җибәрә. Ахыр чиктә патша мондый табышмаклар белән кызны җиңә алмый һәм аңа өйләнә.

Шулай итеп, әкияттә табышмаклар әйтешеп ярышу кинаяле формадагы никах килешүе булып аңлашыла[2]. Ә ярлы кызының зирәклектә патшаны да уздыруы сыйнфый җәмгыять шартларында әлеге сюжетның социаль үткенлеккә ия булганлыгын да күрсәтә. «Зирәк солдат», «Патша белән поп», «Патша, вәзир һәм тегермәнче» әкиятләре дә әнә шул җәһәттән кызыклы.

Зирәклек темасына караган әкиятләр бигрәк тә көнчыгыш халыкларында киң таралган. Татар әкиятләренә охшаш, хәтта тәңгәл килә торган мондый әкиятләрне, мәсәлән, үзбәк, казакъ, уйгур, төрекмән, кыргыз халыклары репертуарыннан күпләп табарга мөмкин.

Гыйбрәтле әкиятләрнең кайберләрендә кешеләрдә очрый торган яхшы һәм начар сыйфатлар капма-каршы куела. Мәсәлән, «Тугры белән Алдар» әкиятендә ике кешенең беренчесе – тугры, гадел, ә икенчесе – ялганчы һәм карак. Аларның һәркайсы үзен хаклы дип саный. Бәхәсне чишү өчен алар, юлга чыгып, бу турыда башкалардан сорыйлар. Боларга очраган өч кешенең өчесе дә Алдар фай-

---

[1] Колесницкая И.М. Загадка в сказке // Уч. зап. ЛГУ. Серия фнлологич. наук. Вып 12. 1941. С. 98–142.

[2] Ведерникова Н.М. Русская народная сказка. М., 1975. С. 96.

дасына сөйли. Ләкин ахыр чиктә, җеннәр сөйләшүеннән серләрне белеп, Тугры өстен чыга.

Бу әкиятнең герое тылсымлы әкият героена охшаган. Ул, сатирик әкиятләр героеннан аермалы буларак, хаклык өчен көрәштә активлык күрсәтми. Аңа көтелмәгән тылсым ярдәм итә. Нәтиҗәдә гаделлек җиңә, ә явызлык хөкем ителә.

Гыйбрәтле әкиятләрнең бер өлешен фәлсәфи гомумиләштерүгә ия булган кечкенә күләмле гыйбрәтле хикәяләр (русча: притча) тәшкил итә. Мондый әсәрләрнең кайберләре – мәкаль яки канатлы сүзнең эчтәлеген ача яисә дөреслеген раслый[1].

Мәсәлән, «Алтын арба» дигән әкияттә бер патша алтын арба ясатып, хезмәткәрләрен әлеге арбага хак куяр өчең ил буйлап йөрергә чыгара. Хезмәткәрләр шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга йөриләр, әмма хак куючы табылмый. Бары тик сәхрәдә бер көтүче генә арбаны бер ипигә алышырга риза була. Тегеләр, әлбәттә, бирмиләр. Көтүче ипинен яртысын ашый да арбаны ярты икмәккә бирүләрен сорый. Хезмәткәрләр кайтып бу турыда патшага сөйлиләр. Патша әйтә: «Килер шундаен бер заман: бирерсең – бер ипигә алучы булмас. Ипине ашап була, алтынны ашап булмый» – ди. Бу әсәр шушы соңгы җөмләдәге фикергә иллюстрация буларак иҗат ителгәнгә охшый.

Татар фольклористикасында притча мөстәкыйль жанр булып аерымланмаган һәм аның атамасы да юк. Әмма фәлсәфи гомумиләштерүгә ия булган мондый җыйнак, тәэсирле әсәрләр бар һәм шуларның бер өлеше нәкъ менә гыйбрәтле әкиятләр рәтендә йөри. Аларны халык телендәгечә гыйбрәтләр дип атарга мөмкин булыр иде. Бу китапка кергән «Алтын алмалар», «Хикмәтле йөзек», «Өч туган», «Җиде баҗаны бер бүре ашаган» һ.б. әсәрләр әнә шундыйлардан.

Маҗаралы әкиятләр идея-тематик яктан гыйбрәтле һәм сатирик әкиятләр арасындагы төркемне тәшкил итә[2]. Шуңа күрә бу әсәрләрдә бер яктан үгет-нәсихәт сизелеп торса, икенче яктан сатирик әсәрләргә хас күп кенә сыйфатларны табып була. Мәсәлән, җитез караклар турындагы әкиятләрдә караклар гадәттә бай малын урлыйлар. Җитмәсә, мондый әкиятләрнең кайберләрендә караклар байга аның таланачагын алдан кисәтеп куялар. Бай бу эшнең мөмкин булмаячагын белдергәч, караклар бай белән бәхәскә керәләр.

---

[1] Притча мәкальнең чыганагы да була ала. Моның мисалларын Н. Исәнбәт тарафыннан җыелган һәм төзелгән «Татар халык мәкальләре» томнарыннан (I т. – 1959. II т. – 1963, III т. – 1967) күпләп табарга мөмкин.

[2] Кайбер тикшеренүчеләр маҗаралы әкиятләрне жанрның мөстәкыйль төре итеп саныйлар. (Кара: Померанцева Э.В. Русская народная сказка. М., 1963. С. 87–93).

«Шамак карак» дигән әкияттә Шамак, бер бай белән бәхәсләшеп, аның кара айгырын, ашый торган савытын, түшәген һәм, ниһаять, хатынын урлый. «Байны «утырткannar» дигән әкияттә дә өч карак байның атларын бәхәсләшеп урлыйлар.

Мондый әкиятләрдә үз-үзенә ышанган тәкәббер бай көлкегә кала. Шушы яктан караганда, әсәр сатирик сыйфат ала.

Гомумән алганда, халык караклыкны гаепли. Ләкин ул бай милкен урлауны гаделсезлек дип санамый. Күрәсең, изүче сыйныф вәкилләренә каршы көрәшнең бер формасын халык әнә шулай күз алдына китергән. Сыйнфый аң уянып та, изүчеләргә каршы көрәш юллары мәгълүм булмаган чорда, сыйнфый көрәшнең примитив чагылышы буларак, әкиятләрдә әнә шундый җитез карак образы киң таралган.

Халык иҗатында җитез карак образы феодализмның таркалуы белән бәйле рәвештә туган[1]. Шуңа күрә, бу геройга багышланган әкиятләрнең сюжеты (АТ 1525), аның аерым мотивлары бик борынгы заманнарга ук барып тоташса да (алар Геродотның «Тарих»ында һәм гарәп әкиятләрендә үк очрый), бер бөтен буларак, XV–XVIII гасырлардан да элек барлыкка килә алмаган. Феодаль җәмгыять тарафыннан кире кагылган кеше – авантюрист герой нәкъ менә Европа халыкларының XV–XVIII йөзләрдәге әдәбиятында урын алган. Әдәбиятка ул, һичшиксез, фольклордан кергән.

Россиядә «Җитез карак» сюжеты XVIII йөздә бик популяр була. Аның әлеге чорда халык телендә йөргәнлеге мәгълүм, кульязмада һәм китапларда теркәлгән вариантлары бар[2].

Татар фольклорына килсәк, җитез караклар турындагы әкиятләр халык репертуарында бүгенге көндә дә еш очрый. Гомумән, караклар темасы маҗаралы әкиятләр төркемендә зур урынны биләп тора. Андый әкиятләрнең сюжетлары гарәпләрнең «Мең дә бер кичә» әкиятләрендә дә бар. Мисал итеп, «Карак белән жулик», «Патша һәм карак» әкиятләрен күрсәтергә мөмкин. Соңгысында иске киемнәр киеп карак кыяфәтенә кергән Петр I, төнлә бер каракны очратып, патша сараен басарга тәкъдим итә. Бу тәкъдим каракка ошамый, һәм ул патшаны күсәк белән кыйный. Шуннан соң карак сенаторны басарга тәкъдим итә. Барып тәрәзәдән тыңласалар, анда сенатор патшаны үтерү турында киңәшләшеп утыра икән. Шулай итеп, карак патшаны үлемнән йолып кала. Соңыннан патша аны үз янына алдыра.

---

[1] Вавилова М.А. Процесс циклизации сказок о ловком воре в XVIII в. // Проблемы реализма в русской и зарубежной литературах. Метод и мастерство. (Тезисы докладов II Межвузовской научной конференции литературоведов. Май, 1969 г.). Вологда, 1969. С. 15.

[2] Шунда ук. Б. 15.

Әкияттә Россия чынбарлыгындагы политик атмосфера да, һәм бер үк вакытта, революциягә кадәрге крестьянның яхшы патша турындагы хыялы да чагыла.

Бу «тарихи» әкиятнең сюжеты рус җирлегенә бәйле рәвештә үзгәреш кичергән: башта ул Иван Грозныйга мөнәсәбәтле рәвештә сөйләнгән, ә соңыннан патша персонажы Петр I гә әверелгән. Татарларга да ул рус репертуарыннан шул вакытларда ук кергән.

Караклар турындагы әкиятләрдә «пешмәгән» карак образы да очрый. «Байдек» дигән әкият герое әнә шундыйлардан. Аны һәр адымда уңышсызлык көтә, урланган нәрсәсе дә аңа бәхет китерми, киресенчә, бәлагә генә дучар итә.

«Кулсыз кияү» әкиятендә исә карак фаҗигагә юлыга: таланган өйдәге кыз аның кулын чабып өзә.

Бу әкиятләрнең икесе ике рухта: беренчесендә юмор күбрәк урын алса, икенчесендә сатира өстенлек итә. Ләкин таланучылар байлар булса да, әкиятләрнең икесендә дә караклык хупланмый, алай гына да түгел, ул гаепләнә, фаш ителә. Ягъни каракның карашлары ул яши торган җәмгыять карашларына каршы килә. Шуңа күрә бу әсәрләрне килеп чыгулары ягыннан борынгырак дип санарга нигез бар. Инде соңрак, халыкның сыйнфый аңы үсә төшкәч, әкиятләрдә бай милкен урлаучы каракларга карата теләктәшлек белдерелә, тасвирланган ситуацияләрдән караклар һәрвакыт җиңүче булып чыга, ә өстен катлау вәкиле мәсхәрә ителә.

Юлбасарлар (качкыннар, кеше үтерүчеләр) турындагы әкиятләрдә исә халыкның андый типларга карашы бер төрле генә – ул аларны явызлар дип саный, һәм мондый әкиятләр әлеге язвызларның фаш ителүе, җиңелүе белән тәмамлана.

Маҗаралы әкиятләр арасында кәләш алу турындагылары да очрый. Мондый әсәрләрдә гадәттә герой – солдат, ә кәләш – патша кызы була. Солдат һәрвакыт җитез, үзенең максатына хәйләкәрлеге һәм зирәклеге белән ирешә.

Маҗаралы әкиятләр төркемендә яла ягылган хатын-кызлар турындагы әсәрләр аерым цикл тәшкил итә. «Кулсыз кыз» әкиятендә, мәсәлән, кызга абыйсының хатыны тарафыннан төрле ялалар ягылуы тәфсилләп сурәтләнә.

«Чибәр кыз Хәдичә» әкиятендә дә нахакка рәнҗетелгән кызның урманда яшәве һәм патша улына кияүгә чыгуы, ире өйдә югында баласын һәлак итүләре, хатынның ирләр киеме киеп хезмәткә керүе һәм соңыннан мәҗлестә үзен кыерсытучыларны фаш итүе сурәтләнә.

Бу әкиятләрдә вакыйгалар шәһәрдә бара. Шуңа күрә аларны шәһәр әкиятләре дип тә атарга мөмкин. Күләмнәре белән зур булган

мондый әсәрләрдә сентименталь мотивларның күплеге игътибарны җәлеп итә. Аларда хатын-кыз геройларга халыкның мәхәббәте аеруча ачык күренә.

Маҗаралы әкиятләрдә хатын-кыз персонажлар тылсымлы әкиятләрдәге кебек пассив түгел, бәлки кыю һәм тәвәккәл кешеләр. Бигрәк тә тугрылык темасына караган әсәрләрдә хатын-кызлар акыллы, батыр һәм зирәк итеп сурәтләнә. «Гөлшикәр» әкиятендә, мәсәлән, Гөлшикәр исемле хатынның ире өйдә юкта аны хыянәткә этәрергә теләгән байны һәм байның энеләрен ничек хурлыкка калдыруы гаять тәэсирле бәян ителә.

Көнкүреш әкиятләренең иң зур өлешен юмористик һәм сатирик әсәрләр тәшкил итә. Кайбер тикшерүчеләр аларны бер төркемгә кертеп өйрәнәләр, дөресрәге, юмористик әкиятләрне аермыйча, сатирик әсәрләр рәтендә карыйлар, ә кайберәүләр аерымлауны мәгъкуль күрәләр. Чыннан да, формасы ягыннан аларны бер-берсеннән аеру мөмкин түгел. Ләкин көлүнең характеры буенча бу әсәрләр икегә бүленә: юмористик әсәрләрдә көлү ироник һәм миһербанлы булса, сатирик әсәрләрдә ул зәһәр һәм һөҗүмчән. Мондый аерма күп очракта персонажларның кайсы сыйныф вәкиле булуына бәйле. Мәсәлән, Алдар бер үк сюжетка корылган ике әкиятнең беренчесендә гади «бер кеше»не, ә икенчесендә бай яисә мулланы «төп башына утыртуы» мөмкин. Бу очракта беренче әкият юмористик булса, икенчесе – һичшиксез, сатирик әкият.

Юмористик әкиятләрдә кешеләргә хас гомуми кимчелекләр тәнкыйть ителгәнлектән, аларның персонажлары да шул кимчелекләргә ия булган шәхесләр: ялкау («Карт белән ялкау егет», «Ялкау карчык»), саран («Ике саран»), куркак («Куркак солдат»), тәкәббер («Хәйләкәр патша»), икейөзле («Әби белән бабай»), мактанчык («Батыр мактанчык»), булдыксыз («Кемгә читенрәк»), ялганчы («Алдакчы белән күпер») һ.б.

Дөрес, сатирик әкиятләрдә дә шул ук кимчелекләр тәнкыйтьләнергә мөмкин. Ләкин анда инде әлеге сыйфатларның иясе күп очракта өстен сыйныф вәкиле була һәм күрсәтелгән кимчелекләр ике капма-каршы сыйныфка караган персонажларның бәрелеше, көрәше фонында ачыла.

Хронологик яктан, әлбәттә, юмористик әкиятләр элегрәк барлыкка килгән. Алдакчылар һәм беркатлы (тиле, җүләр) кешеләр турындагы юмористик әсәрләр әле җәмгыять сыйныфларга бүленмәгән чорда ук туган. Кешелек җәмгыятенең интеллектуаль үсеше белән бәйле рәвештә, борынгы ышанулар, күзаллаулар да көлке объектына әверелә барган. Болар барысы да беренче мәртәбә юмористик

әкиятләрдә чагылган. Әмма сыйнфый җәмгыять шартларында мондый әкиятләрнең күбесе социаль-сатирик әсәрләргә әйләнгән. Шуңа күрә әлеге борынгылык элементларын юмористик әкиятләрдә дә, сатирик әкиятләрдә дә очратырга мөмкин. Бу исә сюжет һәм мотивларның генетик ягын күзәткәндә, фактик материал буларак, һәр ике төркемне бер бөтен итеп карарга мәҗбүр итә. Аннары шуны да әйтергә кирәк: социаль тенденциянең эзлекле рәвештә өстенлек ала баруы, шуның өстенә мәзәкләрнең мөстәкыйль жанр булып аерымлануы сәбәпле, бүгенге көндә юмористик әкиятләр сан ягыннан сатирик әкиятләргә караганда азрак та.

Мәзәкләр турында сүз чыккач, юл уңаенда бер ачыклык та кертеп үтик. Юмористик һәм сатирик әкиятләр белән мәзәкләр арасында охшашлык бик зур. Кайбер тикшеренүчеләр, гомумән, мәзәкләрне көнкүреш әкиятләренең бер төре итеп карыйлар. Чөнки уртак сюжетка корылган әкият һәм мәзәк бер-берсеннән нигездә формасы (күләме) һәм композицион үзенчәлеге белән генә аерыла. Вакыйгага корылган (ягъни сюжетлы) мәзәкләр, кагыйдә буларак, бер эпизодлы була. Беренче тапкыр юмористик (сатирик) әкиятләр шундый бер эпизодлы әсәрләрнең үзара кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Мәсәлән, «Юаш кияү» әкиятен бик җиңел биш мөстәкыйль мәзәккә аерырга һәм аларга мондыйрак исемнәр бирергә мөмкин булыр иде: 1) «Сыптыра», 2) «Балык түгел – мин», 3) «Сорама, тыгын», 4) «Атсыз калуы читен», 5) «Кайтып тормыйм». Әнә шуңа охшашлы аерым мәзәкләрдән барлыкка килгән әсәрләр әкиятләр рәтендә йөри.

Инде юмористик һәм сатирик әкиятләрнең берничә тибын күрсәтеп узыйк.

Әйткәнебезчә, тиләләр турындагы әкиятләр бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Шундый әсәрләр арасында «Шыр тиле» сюжеты (АТ 1696) еш очрый. Анда төп персонаж һәр очракта урынсыз сүз әйтә, тиешсез эш эшли. Мәсәлән, «Кыйныйлар да кыйныйлар» дигән әкияттә герой, янгын чыккач: «Алла куәт бирсен», – дип кычкыра. Кешеләр: «Су сибәргә кирәк», – дип, аны кыйныйлар. Шуннан соң ул, чучка өткән җиргә килеп, чучкага су сибә. Мәет күмүчеләр янына барып: «Сугымыгыз симез булсын», – ди. Яңа төшкән киленгә: «Гүр туфрагың җиңел булсын», – ди һ.б. Тиешсез сүз әйткәнгә күрә, ул һәр урыннан кыйналып китә.

«Аңгыралык бәласе» дигән әкиятнең герое да шуңа охшаш: Таз үзенең абыйсы өйрәткәннәрне төгәл үтәргә тырышса да, аның эше һәм сүзе һәрвакыт урынсыз килеп чыга. Нәтиҗәдә ул кыз сорарга барган йортта көлкегә кала.

Кайбер тикшеренүчеләрнең фикеренчә, мондый әкиятләрнең тамыры борынгы кешеләрнең үлеләр дөньясы турындагы күзаллауларына барып тоташа. Бу күзаллау буенча, үлеләр дөньясында һәр нәрсә тереләр дөньясындагының киресе булырга тиеш. Соңрак мондый күзаллау юкка чыкканнан соң, балигълык йоласын үткәндә «үлеләр дөньясына барып әләккән» үсмернең, шул дөньяда яшәүчеләр булып кыланып, аларны җиңүе яисә нәрсәләрендер урлап кайтуы турындагы көнкүреш хикәяләре барлыкка килә, ә аннан соң шулар нигезендә әнә шундый аңгыра һәм тиләләр турындагы әкиятләр формалаша[1].

Нәкъ менә шушы урында көлдергеч әкиятләр турында да сөйләү сорала. Татар әкиятләре арасында көлдергеч әкиятләр күп түгел. Алар юмористик төркемдә каралырга тиеш. Ләкин, сирәк булса да, арада сатирик сыйфатка ия булганнары да очрый. Мондый әсәрләр әкияткә пародия рәвешендә иҗат ителгән кебек тәэсир калдыра, чөнки анда аек акыл кабул итми торган хәлләр сурәтләнә. Шуңа күрә көлдергеч әкиятләрне кайбер фольклорчылар әкият жанрының мөстәкыйль төре итеп тә карыйлар[2]. Мәсәлән, «Аучы сөйли» дигән әкияттә үрдәкләр гадәти ишек һәм тәрәзәдән сыймыйлар, ә кечкенә тәрәзәдән сыялар, пешкән үрдәкне тумаган балалар ашый. «Урман буры» әкиятендә кисеп идән астына салган агач, үсеп, түшәм-түбәләрне һәм һаваны тишеп чыга, шул агач буйлап менгән кеше һавадан бер чебенгә бер сыер алышып төшә, кибәктән аркан ишә, бүдәнә кешенең башына күкәй сала, бүре үзенең тиресеннән чыгып чаба һ.б., һ.б.

Ялганчылар турындагы әкиятләр дә шушы ук төркемчәгә карый. Мәсәлән, «Ике ялганчы» әкиятендә тавыкларның, тау башына менеп, күктән йолдыз чүпләүләре, әтәчләрнең исә, айны тартып төшереп, урам буенда өстерәп йөрүләре турында сөйләнә.

Теге яки бу көлдергеч әкиятнең конкрет кайсы төркемгә каравы аларда акылга сыймый торган гайре табигый хәлләрне сурәтләүнең нинди максатка хезмәт итүенә бәйле. Бер әкияттә ул шаянлык-шуклык өчен генә булса, икенчесендә социаль мотивлар белән дә бәйләнгән була. Шунлыктан хәтта бер үк сюжетка корылган көлдергеч әкиятләренең икесе ике төркемгә каравы мөмкин. «Ике ялганчы» һәм «Изге ил кешеләре»[3] дигән әсәрләр моның ачык мисалы булып тора. Беренчесендә ялганчылар үзләренең «күргәннәрен» бер караңгы авылда яшьләргә сөйләсәләр, шул ук сюжетка нигезләнгән «Изге ил кешеләре»ндә ялганчыларның капкынына

---

[1] Турсунов Е.Д. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 155.

[2] Зухба С.Л. Абхазская народная сказка. Тбилиси, 1970. С. 60.

[3] Халык әйтсә, хак әйтер. Төзүчеләре Ф. Әхмәтова, Х. Гатина, Ф. Урманчеев. Казан, 1967. Б. 116.

мулла килеп каба, һәм бу әкият дин әһелләреннән көлә торган сатирик әсәргә әверелә.

Көлдергеч әкиятләр генетик яктан борынгы кешеләрнең үлеләр дөньясы турындагы күзаллауларына һәм балигълык йоласына барып тоташа дигән караш бар[1]. Мондый әсәрләрнең барлыкка килүе ыруглык строеның таркалуы белән бәйле. Нәкъ шул чорда аларда сурәтләнгән хәлләр көлке объектына әверелә дә. Аңа кадәр мондый хикәяләр балигълык йоласын үткән үсмернең «үлеләр дөньясында күргәннәре» буларак, җитди кабул ителгән.

Тора-бара көлдергеч әкиятләрнең сюжетлары шактый үзгәреш кичергән, һәм нигездә алар сатиралаша барган. «Тапкыр кыз», «Өч капчык сүз», «Ике ялганчы» һ.б. әкиятләрдә без әнә шундый трансформацияләнгән сюжетларның төрле вариантлары белән очрашабыз. Әкиятнең яңаруы билгеле бер тарихи шартларда яңа идеалларның барлыкка килүе белән бәйләнгән.

Юмористик һәм сатирик әсәрләр арасында хәйләкәрләр турындагы әкиятләр аеруча күп. Аларны төп персонажлары (Алдар, Таз, хезмәтче һ.б.) буенча төрле циклларга аерырга да мөмкин булыр иде. Ләкин бу персонажларның исемнәре шактый шартлы һәм алар мондый әсәрләрдә еш кына бер-берсен алыштырып киләләр.

Хәйләкәрләр турындагы әкиятләр кайсы гына төркемгә карамасын, аларда көлүнең ысулы бердәй: герой үзенең антиподын «төп башына утырта».

Андыйларны без маҗаралы әкиятләрдә дә күреп узган идек. Ләкин анда сурәтләнгән хәйләкәрләр – җитез караклар. Юмористик һәм сатирик әкиятләрдә исә хәйләкәрләр урламыйлар, бәлки күз алдында алдыйлар.

Бу типка аңгыра җен (шайтан, дию, шүрәле, пәри һ.б.) турындагы әкиятләр да керә. Алар генетик яктан бик борынгы чорларга карый торган мотивлар белән бәйләнгән һәм аерым бер цикл тәшкил итә. Бу әсәрләрнең барысында да кеше үзенең хәйләсе белән мифик персонажларны көлкегә калдыра. Мисал итеп, «Хәйләкәр адәм», «Диюләрне җиңгән», «Һөнәрле үлмәс», «Чуен бабай» һ.б. әкиятләрне күрсәтергә мөмкин.

Бу әкиятләрнең генезисы капма-каршы сыйфатларга ия булган ике туганның берсе, икенчесеннән көлеп, аны төрле трюклар ярдәмендә «төп башына утыртуын» күрсәтүгә корылган борынгы дуалистик мифлар традициясе белән бәйле дип санала. Аларда тиле һәм тәҗрибәсез туган образын мифик персонажлар алыштырган. Хәер,

[2] Турсунов Е.Д. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 106–109.

бу циклдагы әкиятләр арасында антипод ролендә кеше сурәтләнгән әсәрләр дә очрый. Мәсәлән, «Батыр тегүче» әкияте шундыйлардан. Бу әкиятнең герое тегүче үзенең антиподы булган батырны урманда очрата. Алар арасында көч сынашу югарыда китерелгән әкиятләрдәгегә охшаш: герой таш кысып су чыгаруда (коймакны кыса), һавага таш чөюдә (кошны чөя һәм кош әйләнеп кайтмый) шулай ук өстенлек ала. Җиңелүче батыр мифик персонажлар кебек үк аңгыра: ул ауган чыршының юан башы җиңелрәк булуга берсүзсез ышана.

Аңгыра җен турындагы әкиятләрнең кайбер сюжетлары (мәсәлән, ташны кысып су чыгару, күлне күккә асу белән куркыту һ.б.) тылсымлы әкиятләрдә дә очрый. Ләкин аңа карап кына әлеге әкиятләрне тылсымлы дип санап булмаган кебек, алар чын мәгънәсендә көнкүреш әкиятләре дә түгел. Шуңа күрә сюжет күрсәткечләрендә бу цикл аерым бүлек итеп бирелә дә. Ләкин мондый әкиятләрдә мифик персонажлар, күргәнебезчә, җиңел генә кеше персонажы белән дә алыштырыла ала. Бу әкиятләрнең төп хасияте шул: герой үзеннән күп мәртәбә көчле булган антиподы белән эш итә, әмма хәйләсе белән аңгыра көндәшен җиңә, аны хурлыкка калдыра. Шуңа күрә бу циклдагы әсәрләр сатирик сыйфатка ия. Геройның көчсез, хәтта куркак кеше итеп бирелүе мондый әкиятләрнең сатирик яңгырашын тагын да көчәйтә төшә.

Юмористик әкиятләрнең сатирик әкиятләргә әверелү процессын бигрәк тә сыйнфый мотивлар килеп керү җәһәтеннән күзәтү кызыклы. Мисалга тылсымлы бүләкләр турындагы сюжетка корылган «Убыр-Таз» һәм «Кыйна, этәч»[1] дигән әкиятләрне алырга мөмкин. Беренче әкияттә сатирик башлангыч бар, әмма ул әле үсеш алырга өлгермәгән. Анда тылсымлы бүләкләрне урлаучылар җәзаланса да (аларны тылсымлы тукмаклар кыйный), персонажлар поляризацияләшмәгән. Полярлашу исә сатирик әсәрләр өчен типик күренеш. Икенче әсәрдә тылсымлы бүләк (этәч) комсыз муллаларны кыйный. Монысы инде чын мәгънәсендәге сатирик әкият.

Е. Турсунов фикеренчә, бу сюжетлар ыру-бабалары турындагы күзаллауларга барып тоташа[2]. Сюжетларның турыдан-туры чыганагы булып, мал алу өчен әлеге бабалар янына үләләр патшалыгына сәяхәт итү турындагы шаман легендасы хезмәт иткән булса кирәк. Соңга таба алар шаман легендасы белән элекке бәйләнешне югалталар һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, өчләтү барлыкка килә (хәзер инде герой бер генә бүләк алмый, ә өчне ала).

[1] Татар халык әкиятләре. Төзүчеләре Г. Бәширов һәм Х. Ярми. Икенче китап. Казан, 1956. Б. 217.

[2] Турсунов Е.Д. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 63.

Бу сюжетның нигезе, күрәсең, тотемның ярдәм итүе турындагы көнкүреш хикәясенең формалашып килүче тылсымлы әкият поэтикасын файдалануы (бүләк бирүче үзен коткаруны үтенә һәм геройның теләсә нинди теләген үтәргә вәгъдә итә, герой аңардан тылсымлы әйберләр ала) нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Чөнки әкиятләрнең икесендә дә бүләк бирүчеләр – хайваннар, төгәлрәк әйтсәк, мифик затлар: шүрәле һәм алтын кош.

Алда китерелгән байтак әкиятләрдән күренгәнчә, борынгы трюкачлык традициясе, комик хәлләрне сурәтләү сыйнфый җәмгыять шартларында әкренләп социаль сатира традициясенә әверелгән. Моның мисалларын янә «Бай һәм хезмәтче» темасына караган бик күп әкиятләрдә очратырга мөмкин.

«Мужик белән алпавыт» әкиятендә хәйләкәр крестьян, алдап, алпавытның ике тройкасын кулга төшерә, ә соңыннан өенә чакырып, аны таяк белән «сыйлый».

«Нужа» дигән әкияттә исә нужа дигән нәрсәне күрәсе килгән акылсыз һәм саран байның ничек хур булуы бәян ителә. Нужа күрсәтергә дип бик ерак җиргә алып киткән хезмәтче, байның ризыгы беткәч, аңа телемләп үз икмәген бирә, ләкин һәр ашаткан саен, телемнең бәясен арттыра бара. Соңыннан ул байны печән ашарга да мәҗбүр итә.

Әкияттә кулыннан бер эш килми торган, хәтта нужаның нәрсә икәнен белмәгән байның яшәве һәм баюы башка кешеләрнең, ярлыларның хезмәте нәтиҗәсендә генә мөмкин икәнлеге аңлашыла. Эш рәтен белмәгәч, аның хезмәтче тарафыннан корылган төрле хәйлә капкыннарына эләгүе дә гаҗәп түгел. Бай тиз ышана, хезмәтченең сүзен тыңларга, ул кушканнарны үтәргә тиеш була һәм нәтиҗәдә бернисез кала. Шулай итеп, эш эшли белмәүнең, әрәм тамак булуның соңгы нәтиҗәсе ахмаклык, хурлык икәне әкияттә ачык күрсәтелә.

Мондый әкиятләр хайваннар турындагы кайбер әкиятләр белән аваздаш. Сатирик әкиятләрдәге өстен катлау вәкиле (бай, алпавыт, мулла) хайваннар турындагы әкиятләрдәге бүре кебек үк комсыз һәм ахмак. Ул уңай герой тарафыннан җиңел алдана һәм көлкегә кала. Шулай итеп, борынгы аллегорик сюжетларның төп образлары сыйнфый җәмгыятьне сурәтләү өчен дә хезмәт итә башлый.

Сатирик әкиятләрнең кайберләрендә сыйнфый көрәш аеручача кискен чагыла. Мәсәлән, «Күке кычкыргач, көтүче хезмәт хакы ала» дигән әкияттә бай көтүче егеткә хезмәт хакын күке кычкыргач түләргә вәгъдә итә. Ләкин байның хатыны агачка кунып кычкырырга теләгән күкеләрне һәр көнне куа икән. Егет, моны күреп, хатынны камчы белән сугып үтерә. Күкеләр кычкыра башлагач, бай, егеттән

котылырга теләп, мунча ташына агу сала. Егет бу эшне сизгәч, юынганда мунча ташларын алыштыра. Чыкканда ул агулы ташларны кире урыннарына куя, һәм бай үзе салган агуга үзе тончыгып үлә.

Әлбәттә, тормышта мондый хәлләр булмый. Әкияттә халыкның хыялы чагыла. Ул, хыялда гына булса да, байны җиңә, аңардан үч ала, тормышта гаделлек урнаштыра. Хәзер бу әкиятләр бары тик кызыклы хикәяләр рәвешендә генә кабул ителә, ә бит сыйнфый җәмгыять шартларында мондый әсәрләрнең социаль вазифасы да бер үк дәрәҗәдә йөргән, ягъни асылда алар сыйнфый көрәш чараларының берсе булган.

Социаль конфликтка корылган әкиятләрдән тыш, сатирик әкиятләр арасында гаилә-көнкүреш конфликтына корылганнары да шактый. Аларда көнче, коткы таратучы, хыянәтче, лыгырдык, диндар, кире беткән, «пешмәгән» һ.б. шундый типлардай юмористик әкиятләрдәгегә караганда көчлерәк, зәһәррәк итеп көленә. Хыянәтче хатыннар турындагы әкиятләрдә икейөзлелек, хаинлек һәм бозыклык фаш ителә. Әхлаксызлык һәм хорафатларга ышануның бергә тәнкыйть ителүе нәтиҗәсендә «Хәйләкәр мылтыкчы» кебек әкиятләр мавыктыргыч, ә андагы образлар бик ачык һәм җанлы. Борынгы һинд әкиятләрендә дә чагылган бу сюжетның бик күп халыкларда популяр булуын шуның белән аңлатырга кирәктер.

Инде көнкүреш әкиятләренең поэтикасына кагылышлы берничә сүз.

Бу төр әкиятләргә, кагыйдә буларак, бик кыска башлам хас. Шулай да кайберләрендә тылсымлы әкиятләргә хас башламны да күрергә мөмкин. «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми» дигән әкиятнең башламы хәтта тылсымлы әкиятләрдә дә сирәк очрый: «Бик борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, карга плотник булганда, атлар диңгездә йөзгәндә, балыклар җирдә йөргәндә, кешеләр аяк белән күктә очканда, яшәгән, ди, бер балта остасы».

«Патша кияве солдат», «Кулсыз кияү» дигән әкиятләрдә, мәсәлән, тылсымлы әкиятләргә хас бетем очрый.

Ләкин көнкүреш әкиятләрендә мондый башлам һәм бетемнәр сирәк күренеш.

Бу төр әкиятләрнең темалары сан ягыннан күп булмаса да, аларның төрлечә вариацияләнүләре нәтиҗәсендә, бер үк темага бик күп сюжетлар барлыкка килгән. Көнкүреш әкиятләренең сюжетлары мавыктыргыч, бигрәк тә сатирик һәм юмористик әкиятләрдә комик ситуацияләр зур урын алып тора.

Комик ситуацияләрне барлыкка китерү ысуллары күп төрле. Шуларның берничәсен күрсәтеп узыйк.

Герой антиподын фаш иткәндә күренешнең табигыйлеге аңлы рәвештә бозыла. Мәсәлән, «Буразнада балык» әкиятендә хатын үзенең диндар ирен көлкегә калдыру өчен, буразнага балыклар салып чыга, ире исә аларны алла бирде дип уйлый.

Табигыйлекнең аңлы рәвештә бозылуы персонажларның көндәлек шөгыльләре рәвешендә дә сурәтләнергә мөмкин. Мәсәлән, «Гакыллы бала» дигән әкияттә тәрәзәсез өйгә тубал белән тыштан якты ташыйлар.

Комизм еш кына сукырларча ышануга нигезләнә. Мәсәлән, «Көтүче Зариф» әкиятендә мулла хәйләкәр Зариф ясаткан тимер фәрештәнең Аллаһы тәгалә җибәргән чын фәрештә булуына ышана һәм, аңа атлангач, алла янына очам дип уйлый.

Урыннарны алыштыру шулай ук комизм чарасы булып хезмәт итә. «Кайгы» дигән әкияттә, мәсәлән, абстракт образ булган Кайгы, ярлы тарафыннан җиңелгәч, байның җилкәсенә атлана. Яисә «Кемгә читенрәк» әкиятендә ир белән хатын, бәхәсләшеп эшләрен алмашкач, ир, йорт эшләрен башкара алмыйча, көлкегә кала.

Комик ситуация сүзнең (тәгъбирнең) күп мәгънәлелегеннән файдалану нәтиҗәсендә дә барлыкка килә. «Тапкыр кыз» әкиятендә шәһәр бае авыл картыннан: «Тулаем сатам», – дип өч мәртәбә әйттереп, утын белән бергә аның үгезен дә, арбасын да алып кала. Бабайның кызы исә әлеге байдан: «Кулым белән бирдем», – дип өч мәртәбә әйттереп, кулын кисеп алырга хокук ала. Бай, әлбәттә, кистерергә теләми һәм кулы бәрабәренә өстәмә рәвештә мең тәңкә акча түләргә мәҗбүр була.

Әкияттә образны ачу чарасы буларак, поэтик ысуллардан аеруча антитеза һәм гипербола күп кулланыла.

Персонажларның социаль хәлен, милек дәрәҗәсен күрсәтү үзе үк инде аларны капма-каршы кую дигән сүз. Ләкин әкияттә бу каршылык әлеге персонажларга хас аерым мөһим сыйфатларны аңлы рәвештә күпертеп күрсәтү (ягъни гипербола куллану) нәтиҗәсендә тагын да көчәйтелә. Мәсәлән, «Алдар һәм мулла» әкиятендә мулла шул дәрәҗәдә комсыз һәм аңгыра итеп сурәтләнә, ул, Алдарның хәйләсенә җиңел генә ышанып, аның «алтын бирә торган» атын, «кар өстендә ит пешерә торган» казанын, «йомышка йөри торган» куянын сатып ала.

Персонажларның тотрыклы характеристикасы образларны типиклаштыруга китерә. Мәсәлән, персонаж бай яисә мулла икән, ул, һичшиксез, явыз, комсыз, мәкерле, аңгыра була, ә хезмәтче, киресенчә, миһербанлы, зирәк, акыллы һәм хәйләкәр. Персонажларның күп очракта исеме булмау яисә булган тәкъдирдә дә Тугры,

Алдар, Саран, Юмарт кебек символик исемнәр белән генә йөртелүе янә дә типиклаштыруның көчлелеге турында сөйли.

Әкиятнең теле шулай ук образны ачу чараларының берсе булып тора. Теге яки бу персонажның теле аның характерына туры килә, хәтта еш кына аның кайсы сыйныф вәкиле булуын да күрсәтә. Мәсәлән, мулланың хезмәтчесенә әйткән сүзләре дорфа, тупас: «Синең ише ялкау хәерче бәхетен йоклап җилгә очыра. Йокламаган булсаң, бүгенге көнне сиңа да бәхет эләгер иде. Менә мин абага чәчәген кабам да, теләсә нинди кибеткә кереп, җаным теләгән малны алып баеп китәм» («Абага чәчәге»). Ә менә монысы азгын мулланың кеше хатынына төчеләнеп әйткән сүзләре: «Тукта, тукта, асыл кош, кая ашыгасың? Бер серләшик кеше югында» («Чибәр кыз Хәдичә»). «Еланнар» дигән әкиятнең герое – ялчы егет исә, иптәшләрен өндәп, болай ди: «Байның байлыгын бүлешеп, илләргә кайтыйк, туганнар».

Гомумән алганда көнкүреш әкиятләре өчен традицион формулалар, күтәренке эпитетлар һәм кабатлаулар хас түгел. Бу әкиятләрдә образлылык тудыруның башка поэтик чаралары зуррак урын тота. Мәсәлән, образлы тәгъбирләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, җырлар һәм табышмаклар көнкүреш әкиятләрендә шактый еш очрый.

Образлы тәгъбир һәм мәкальләрдән «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми» (шул исемдәге әкияттә), «Җаннан татлы, әҗәлдән әче юк» («Әби белән бабай»), «Ырыкныкы шырыкка» («Байдек»), «Тугры сөйләгән котылган, ялганлаган тотылган» (шул исемдәге әкияттә), «Яңгыр яуганда бала җәл, таш яуганда баш җәл» («Кулсыз кыз») һ.б.ларны күрсәтергә мөмкин.

Мәкаль һәм әйтемнәр фикерне анык һәм ышандырырлык итү өчен кулланыла. Бу очракта алар әкият композициясендә оештыру ролен үтәми (мәсәлән, «Кулсыз кыз» әкиятендә). Мәкаль кайвакыт әкиятнең эчтәлегенә йомгак рәвешендә азакта килеп, аны тәмамлап куя. Мәсәлән, «Байдек» әкияте түбәндәгечә тәмамлана: «Шуның өчен әйткәннәр: “Ырыкныкы шырыкка” дип, һәм дөрес: ырыкныкы шырыкка китте».

Әсәрнең башында килгәндә әкият эчтәлеге мәкальнең мәгънәсен ача. Бу очракта ул композицион вазифа үти. Кайвакытта мәкаль әкиятнең исеме булып йөри (мәсәлән, «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми»).

Көнкүреш әкиятләрендә очрый торган кыска җырлар (такмаклар) әкият сюжеты белән тыгыз бәйләнгән була. Аларда башлыча герой үзенең хәйләсен ача, ләкин аның антиподына бу соңыннан гына «барып җитә». Мәсәлән, «Байны утырткannaр» дигән әкияттә каракларның берсе байның атларын урлаган вакытта, калган икесе, ишек тавышы ишетелмәс өчен, мәҗлестә җырлап бии башлыйлар:

Шыгырдый ла, майласана;
Аласы – миңа, коласы – сиңа,
Әрәмәлеккә бәйләсәнә!

«Ике кода» дигән әкияттә дә кодалар бер-берсенә үзләренең хәйләләрен шулай ук такмакка салып әйтәләр (җырлыйлар).

Көнкүреш әкиятләрендә табышмаклар да күп очрый. Без биредә табышмак-әкиятләрне күздә тотабыз. Алар турында югарыда сүз булган иде инде. Кинаяле сөйләмгә мисал итеп, «Патша, вәзир һәм тегермәнче» дигән әкияттән патша белән тегермәнче сөйләшүен күрсәтергә мөмкин.

«Патша, тегермәнчегә кергәч тә әйткән:

– Әллә, мәллә, – дип (Әссәламегаләйкем).

Тегермәнче җавап биргән:

– Кәллә, мәллә, – дип (Вәгаләйкемәссәлам).

Патша әйткән тегермәнчегә:

– Өчнеке тугызга җитәме? – дип (Өч ай эшләгәнең тугыз айга җитәме?).

Тегермәнче җавап биргән:

– Җитә җитүен, утыз икедән артмый, – дип (Җитә җитүен, утыз ике тештән артмый)».

Кинаяле сөйләм формасындагы табышмаклардан тыш, әкиятләрдә башваткыч сораулардан һәм җаваплардан гыйбарәт булган табышмаклар да очрый (мәсәлән, «Өч сорау», «Акыллы килен» әкиятләрендә).

Алдарак та әйткәнебезчә, сыйнфый җәмгыять шартларында мондый сюжетлар социаль юнәлештә үзгәрәләр. Ярышта түбән катлау вәкилләре җиңеп чыга башлый, табышмак җавабын табу аларның өстенлеген дәлилли торган чарага әверелә.

Көнкүреш әкиятләре составында күпчелек әсәрләрнең сатирик әкиятләр рәтенә күчә баруы нәтиҗәсендә сатирик әкиятләр ин зур өлешне тәшкил итә. Бу хәл, әлбәттә, халыкның сыйнфый аңы нык үскән булудан килә. Моңа исә, безнеңчә, татар халкының Октябрь революциясенә кадәр икеләтә-өчләтә сыйнфый изелү астында яшәве һәм аңарда иҗтимагый-политик фикернең иртә уянуы сәбәп булган.

Көнкүреш әкиятләре, әкиятләрнең башка төрләре кебек үк, культурабызның күркәм сәхифәләреннән. Алар татар халкының бетмәс-төкәнмәс иҗат мөмкинлекләрен, юмор хисен, сатира көчен, акылын, зирәклеген һәм тормыш тәҗрибәсен чагылдырган гаять кыйммәтле рухи хәзинәсе булып тора.

# ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

## Татар фольклоры басмалары тарихыннан: халык әкиятләре

Халык әкиятләренең беренче чиратта педагогик һәм эстетик тәрбия чарасы булуы күптәннән мәгълүм. Хәзерге вакытта әкият телдә актив сөйләнмәгәнлектән, әкият китапларының роле аеруча зур. Мондый китап аңа ихтыяҗы төшкән һәркемнең кулында булырга тиеш. Әмма моңа әле без һаман да ирешә алганыбыз юк.

Без быел, 1992 елда, татар милли басма китабының 270 еллыгын бәйрәм иткәндә халкыбызның беренче басма әкиятенең 150 еллыгын да билгеләп үтә алабыз. Моннан нәкъ гасыр ярым элек – 1842 елда Казан шәһәрендә Мартиньян Ивановның «Татарская хрестоматия» дигән китабы дөнья күргән. Хәрби уку йортында татар телен өйрәнү өчен чыгарылган бу уку ярдәмлегендә халык иҗаты әсәрләренә дә зур урын бирелгән. Анда халкыбызның мәкаль, табышмак, җыр кебек киң таралган жанрларына караган әсәрләр белән беррәттән 8 әкият тексты да басылган. Шушы 8 әкиятнең 2 се «Татар халык иҗаты»ның 12 томлык фәнни җыелмасындагы әкият китапларына да кертелде. Алар – «Ак елан» һәм «Өч бәҗхур» дигән әкиятләр. Димәк, гасыр ярым элек мәйданга чыккан бу әкиятләр әле бүгенге укучыга да тугры хезмәт итәләр.

XIX гасырда М. Иванов хрестоматиясеннән тыш, халык әкиятләрен эченә алган тагын берничә уку ярдәмлеге һәм тел белеме галимнәренең фәнни хезмәтләре дөнья күрә. Шулардан С. Күкләшевнең «Диване хикәяте татар» (Казан, 1859), М. Бикчуринның «Начальное руководство к изучению арабского, персидского и татарского языков...» (Казан, 1859, 1869), В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» (СПб., 1872) һәм

венгр галиме Г. Балинтның «Казан татарлары телен өйрәнү» (Balint Gabor. Kazáni-tatár nyelvtanulmányok I. füzet Kazáni-tatár szövegek.– Budapest, 1875) дигән хезмәтләрен атарга мөмкин. Әмма боларның берсе дә киң катлау укучылар өчен түгел. Җитмәсә, В. Радлов һәм Г. Балинт китаплары транскрипция белән басылганнар, ә М. Иванов хрестоматиясенең тиражы тулысынча диярлек янгында юкка чыккан.

Халыкның киң катлавы өчен фольклор җыентыклары чыгара башлау – татарлар арасындагы мәгърифәтчелек хәрәкәте белән бәйле. Эченә экиятләр дә кертелгән шундый җыентык Казан шәһәрендә 1889 елда басылып чыга. Ул Габделгалләм Фәезханов төзегән «Хикәят вә мәкаләт» дигән китап. Кечкенә форматлы һәм 32 генә биттән торган бу җыентыкка 12 экият, 3 бәет, 500 дән артык мәкаль сыйган. Ул 20 ел эчендә биш мәртәбә басыла.

Ниһаять, 1900 елда экиятләрдән генә торган беренче китап пәйда була. Ул – Казанда басылган «Дәфгылькәсәл мин эссаби вә сабият» («Яшь ир балалардан вә һәм яшь кыз балалардан ялкаулыкны җибәрә торган хикәяләр») исемле җыентык. Төзүчесе – мәгълүм мәгърифәтче Таип Яхин. Бу китап заманына күрә зур булып чыккан: 204 биттән тора, анда 99 текст урын алган, һәм ул беренче чиратта, исеменнән үк күренгәнчә, балаларга атап чыгарылган. Дөрес, ул китапта тәрҗемәләр дә шактый. Ләкин шулай да җыентык үзенең күләме, оригиналь экиятләрнең саны һәм сыйфат ягыннан тәкъдир ителергә хаклы.

Күренекле мәгърифәтче галимебез Каюм Насыйри да экиятләр җыю белән шөгыльләнгән. Ул туплаган 11 экият нигезендә урыс галиме П.А. Поляков тарафыннан «Казан татарларының экиятләре һәм аларны башка халыклар экиятләре белән чагыштыру» дигән хезмәт язылып, әлеге экиятләрнең гарәп шрифты белән оригиналь тексты, шулай ук, «академик транскрипция» дип йөртелгән транскрипциясе һәм урыс теленә тәрҗемәсе теркәлгән хәлдә 1900 елда нәшер ителә. Бу – фәнни басма. К. Насыйриның экият текстлары исә шул вакыттан алып бүгенгә кадәр төрле җыентыкларда даими басылып килә.

Бу басмалар барысы да XIX гасырга карый.

XX гасырга чыккач, экиятне бастыру өлкәсендә эш беркадәр сүлпәнләнеп кала, бары тик 1915 елда гына Гали Рәхимнең 4 текстны берләштергән «Халык экиятләре» дигән кечкенә генә җыентыгы басылып чыга. Әлеге китапка 4 әсәр кертелгән: «Алдар Таз», «Йорт тотмас», «Камыр батыр», «Таз – патша кияве».

Дөрес, бу чорда Т. Яхинның «Сабый вә сабыйлар өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗаиб

булган гыйбрәтләр» (1902), Г. Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» китапларының яңа басмалары (1902, 1909) чыга, янә дә аерым әкиятләр төрле җыентыкларда һәм дәреслекләрдә дөнья күрә. (К. Биккулов., «Нәмүнәи тәрәккый» – Казан, 1904; «Фәррахнамә» – Казан, 1906, 1914; Ә. Хәнәфия. «Кыйраәте җәдидә» – Казан, 1908, 1912, 1916; М. Корбангалиев, «Татарча уку» – Казан, 1915 һ.б.), берәм-сәрәм текстлар беренче буржуаз революциядән соң чыга башлаган журналларда да («Аң», «Шура», «Ак юл» һ.б.) басылгалый.

Тагын шуны да әйтергә кирәк, бу чорда, дөресрәге 1907 елда, Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы дөнья күрә. Бу поэма халык иҗаты һәм профессиональ әдәбият чигендә туган һәм шартлы рәвештә әдәби әкият дип атала торган үзенчәлекле күренешнең татар әдәбиятында беренче һәм искиткеч гүзәл үрнәге булып тора. Шуннан соң Г. Тукай үзенең башка әкиятләрен иҗат итә.

Шулай итеп, гасыр башында әкият китапларына кытлык булса да, халык бөтенләй үк әкиятсез калмаган.

Совет чоры башлангач, 1918 елда ике әкияттән торган «Гөлчәчәк» исемле беренче җыентык чыга («Гөлчәчәк» әкияте – Җан Шәрәф язмасы, икенче әкият – Г. Рәхимнең «Камыр батыр»ы). Бу китапчык 1921 елда «Күчмә уку китабы» сериясендә кабат басыла. Шул ук сериядә 1921 елда Г. Рәхимнең «Кырык бер күгәрчен» һәм «Алдар Таз» әкиятләрен берләштергән тагын бер җыентык чыга. Ә 1922 елда «Камыр батыр» «Күчмә уку китабы» сериясендә аерым басма рәвешендә дә дөнья күрә.

1924 елда Казанда «Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды» дигән китап басылып чыга. Аны Казан педагогия институты укытучысы Михаил Андреевич Васильев (1878–1944) төзегән һәм тәрҗемә иткән. Бу китап – урыс телендә татар әкиятләре һәм легендалары тупланган беренче җыентык. Анда 78 текст урын алган.

20 нче елларда татар фольклоры өлкәсендәге эшчәнлек 1920 елда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршында төзелгән Гыйльми Үзәк (Академцентр) эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән. Республикада мәдәният үсеше белән җитәкчелек итү йөкләнгән бу фәнни-практик оешманың җитәкчесе итеп 1925 елда Г. Ибраһимов билгеләнә. Шуннан соң республикада тел һәм әдәбиятны үстерү, төбәкне һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү, халык иҗаты әсәрләрен туплау кебек эшләр шактый җанланып китә.

Халык иҗаты әсәрләрен туплау, тупланган хәтлесен бастырып чыгару һәм фәнни-тикшеренү эшләре белән җитәкчелек итү өчен Гыйльми Үзәк янында М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Г. Рәхим

составында махсус бер комиссия – «Халык әдәбиятын эшләү комиссиясе» төзелә. Әмма эш авыр бара. 1926 елда Г. Ибраһимов үзенең «Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы (татар халык әдәбияты турында)» дигән мәкаләсендә («Безнең юл» журналы, № 5–6) Гыйльми Үзәктә тупланган фольклор материалларының дөньяга чыкмый ятуына көенеч белдерергә мәҗбүр булган. «Соңгы елларда моңарга (халык иҗаты әсәрләрен җыюга. – *Л.Ж.)* әһәмият бирү аеруча төс алды, – дип яза ул.– Ләкин бастырып чыгара алмау мәсьәләсе боларны бөяләп торадыр. Мәсәлән, Бөре кантоныннан Гата Исхакый иптәш тарафыннан татар экиятләре җыелган. Барлыгы 31 дәфтәр, 500 битләр чамасы. Бу безнең кулда 4–5 ел ята. Карар күптән булса да, бастырып чыгаруның юлын таба алганыбыз юк». Күрәбез ки, нәкъ бүгенге хәл.

Мәгълүм булганча, Гыйльми Үзәкнең язмышы бик аяныч төгәлләнә. Җыелган материаллар да кайсы кая таралып бетә, күбесе югала.

1934 елда совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында А.М. Горькийның: «Сүз сәнгатенең башы – фольклорда. Үзегезнең фольклорыгызны җыегыз, аңардан өйрәнегез, аны эшләгез» дигән чакыруына җавап йөзеннән Татарстанда да шактый эш башкарыла. Язучылар республиканың төрле төбәкләренә экспедициягә чыгып китәләр. 1938 елда Татгосиздат «Халык иҗаты» дигән фольклор җыентыгы бастырып чыгара. Анда зур урынны татар халык иҗаты әсәрләре били. Җыентыктагы 24 татар әкияте нигездә моңарчы чыккан төрле җыентыклардан алып басылган. «Халык иҗаты» җыентыгының икенчесендә – тулыландырылган басмасында (1940) татар әкиятләре 31 данәгә җиткерелгән. Биредә урыннардан язып җибәрелгән әкиятләр дә файдаланылган.

30 нчы елларның азагында татар халык әкиятләре өлкәсендә җитди эш башлап җибәрүчеләрнең берсе язучы Гомәр Бәширов була. Ул оста-әкиятчеләрдән үзе язып алган әсәрләрне 1940 елда «Халык әкиятләре» дигән исемдә аерым җыентык итеп бастыра. Кырыкка якын әкият һәм мәзәк тупланган бу җыентык татар халык әкиятләрен җыю, бастырып чыгару һәм өйрәнүдә мөһим өлеш булып тора.

Бу эштә тагын бер этап 1939 ел азагында төзелгән Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих институты (хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты) белән бәйле. Биредә системалы рәвештә фольклор экспедицияләре оештырыла. 1946 һәм 1956 елларда татар халык әкиятләренең ике китаптан торган фәнни басмасы дөньяга чыга (төзүчеләре Г. Бәширов һәм Х. Ярми). 1958 елда беренче китап тулыландырылып басыла. 1951 һәм 1954 елларда «Татар халкы иҗа-

ты» исеме белән нәшер ителгән антология характерындагы фольклор җыентыкларында да әкиятләргә шактый урын бирелгән.

Г. Бәширов һәм Х. Ярми тарафыннан әкиятләрнең бер өлеше балалар өчен сайланып, 1952 елда урыс телендә «Гульчечек» исемендә нәшер ителә. Бу җыентыкны Татарстан китап нәшрияты да ике мәртәбә (1953, 1956) бастырып чыгара. Болардан тыш Х. Ярми «Татарские народные сказки» исемендә Казанда (1957, 1970) һәм Мәскәүдә (1957, 1976), янә дә «Находчивый джигит» исемендә Мәскәүдә (1964) мөстәкыйль биш җыентык чыгара. Бу күрсәтелгән урыс телендәге басмалар күп кенә (әрмән, казакъ, украин, төрекмән, азәрбайҗан, литва, молдован, үзбәк, кытай, болгар, словен, монгол һ.б.) телләргә тәрҗемә ителде.

1962 елда «Абага чәчәге» исеме белән татар халкының сатирик әкиятләре дөнья күрде. Аны Э. Касыймов төзегән иде.

Татарстан китап нәшриятының үз инициативасы белән моңарчы чыккан китаплар нигезендә төзеп бастырган әкият җыентыклары да бар: «Шомбай» (1960), «Татар халык әкиятләре» (1964). Шуның өстенә халык әкиятләре татар һәм урыс телләрендә К. Насыйри китапларында да дөнья күрде (1945, 1954, 1956, 1960, 1974, 1977 елларда).

Соңгы дәвердә әлеге институтта татар халык иҗаты әсәрләренең 12 томлы җыелмасы әзерләнеп, шуның өч томы әкиятләргә багышланды. Алар 1977, 1978, 1981 елларда басылып чыктылар. (Төзүчеләре Х. Ярми, Х. Гатина, Л. Җамалетдинов.) Гомуми күләме 90 табакка якын булган әлеге өч китапта 313 әкият урын алган. Шуларның яртысына якыны беренче мәртәбә басылды. Бу китапларда әкиятләрнең төрле төрләренә караган кереш мәкаләләр бирелде, искәрмәләрдә һәр әкиятнең мәгълүм булган барлык вариантлары күрсәтелде, башка халыклардагы параллельләре китерелде һәм әкият сюжетларының халыкара күрсәткечләре нигезендә эшләнгән типологик анализлар урнаштырылды. Шулай итеп, татар әкиятләренең дөнья күләмендә фәнни әйләнешкә керүе өчен мөмкинлек тудырылды. Мондый зур хезмәтнең татар фольклористикасында һәм китап басу тарихында әлегәчә булганы юк иде. Бу – Татарстан фәненең мөһим казанышы дип бәяләнде.

Шуннан соңгы чорда берничә җыентык Л. Җамалетдинов тарафыннан төзелеп, татар һәм урыс телләрендә басылып чыкты: «Татарские народные сказки» (1986, 1992), «Татар халык әкиятләре» (1989), «Өч каурый» (1992), «Три волшебных перышка» (1992).

Сабыйлар өчен зур форматлы, төсле рәсемнәр белән бизәлеп эшләнгән басмалар турында да берничә сүз әйтеп үтәргә кирәк.

Казандагы нәшриятлар татар һәм урыс телләрендә бер яки берничә әкияттән торган түбәндәге китапларны чыгарды: «Гульчечек» (1987), «Камыр батыр» (1988), «Салам-Торхан» (1989), «Красные штаны» (1991), «Шомбай» (татар һәм урыс телләрендә, 1992). Шундый ук китапларны Мәскәүнең «Малыш» нәшрияты да бастырды: «Гульчечек» (1967), «Камыр батыр» (1985), «Золотая арба» (1987), «Три дочери» (1992).

Сүз уңаеннан шуны да искәртик: сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы чорда кече яшьтәге балалар өчен башлыча Х. Ярми һәм Г. Бәширов тырышлыгы белән бер яки берничә әкияттән торган байтак кына китап һәм китапчыклар дөнья күргән иде. Алар түбәндәгеләр: «Камыр батыр» (1944), «Аю белән бабай» (1944), «Кәҗә белән бүре» (1944), «Ак бүре» (1947), «Гөлчәчәк» (1947), «Әкиятләр» (1947), «Татар халык әкиятләре» (1950), «Тапкыр **егет»** (1956), «Золотой перстень» (1956), «Өч кыз» (1959), «Тапкыр кыз» (1960), «Акыл белән бәхет» (1963). 1974 елда басылган «Татар халык әкиятләре» (төзүчесе Х. Гатина) кече яшьтәге балаларга атап чыгарылган җыентыклар арасында әлегәчә иң күләмлесе (51 текст) булып кала.

Моңарчы сүз башлыча татар халык әкиятләреннән генә торган басмалар турында барды. Әмма аерым татар әкиятләре нигездә мәктәп балаларына адресланып нәшер ителгән төрле халыкларның әкиятләре тупланган татар һәм урыс телләрендәге җыентыкларда да дөнья күрде. Мәсәлән, шуларның кайберләренең исемнәре: «СССР халыкларының әкиятләре» (Казан, 1947, 1953, 1969), «Алтын грамота» (Казан, 1955), «Тылсымлы чишмә» (Казан, 1984), «Сказки народов СССР» (М., 1939; Рига, 1949; Астрахань, 1959), «Сказки народов Советского Союза» (М., 1942; Горький, 1950), «Сказки моей Родины» (Киров, 1948), «Народные сказки» (Саратов, 1950, 1952), «Чудесная мельница» (М., 1951), «Гора самоцветов» (М., 1953, 1957, 1964, 1971, 1973; Ташкент, 1958), «Сказки нашей Родины» (Горький, 1954), «Сказки народов нашей Родины» (Горький, 1962), «Книга о судах и судьях» (М., 1975), «Сказки народов Урала и Поволжья» (Ижевск, 1977), «Волшебный цветок» (Казань, 1983); «Волга родная» (Л., 1986), «Три голубя» (Казань, 1990), «Волшебные яблоки» (Уфа, 1991) һ.б. Шундый ук басмаларның башка телләрдә дә чыккан булуы шик уятмый. Әмма әлегә без аларны белмибез.

Кайбер әкият текстлары балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен чыгарылган хрестоматия рәвешендәге җыентыкларда (мәсәлән: «Нәниләргә бүләк», 1947, 1985, 1988; «Көн артыннан көн», 1948; «Нәниләр китабы», 1960, 1971, 1973; «Гөлбакча», 1990; «Татар-

ская поэзия и фольклор в детском саду», 1982; «Үги кыз» – Чаллы, 1992; «Падчерица» – Набережные Челны, 1992 һ.б.), гомуми белем бирү мәктәпләренең уку программалары буенча төзелгән дәреслек-хрестоматияләрдә (мәсәлән: Нуриева А.Х., Галиева Л.И. Туган тел китабы. Рус мәктәпләренең II–III классларында укучы татар балалары өчен, 1978; Җәләлиева М.Ш., Әдһәмова Г.М. Әдәбият. Дүртенче класс өчен дәреслек-хрестоматия, 1978 һ.б.), класстан тыш уку өчен чыгарылган китапларда (мәсәлән: «Иркен минем туган илем», 1976, 1987 һ.б.), шулай ук төрле тематик фольклор җыентыкларында (мәсәлән: «Дин турында халык», 1963; «Халык әйтсә, хак әйтер», 1907; «Иртешкә сәяхәт», 1989 һ.б.) басылганнар һәм хәзер дә басыла торалар. Әмма аларның күбесендә моңарчы мәгълүм булган бер үк текстлар кабатлана.

Хәзерге вакытта яңа текстлар, кагыйдә буларак, фольклорчылар әзерләгән җыентыкларда дөнья күрә. Аерым очракларда тел белгечләре-диалектологларның хезмәтләренә кушымта рәвешендә бирелә торган материаллар арасында да (мәсәлән, Материалы по татарской диалектологии: I – 1955, II – 1962, III – 1974, IV – 1978, V – 1983, VI – 1988, VII – 1989) әкият текстлары очрап куя. Шундый материаллардан югарыда без В. Радлов һәм Г. Балинт хезмәтләрен искә алган идек инде. Узган гасыр азагында Бөгелмә өязендә татар фольклорын җыйган фин галиме Хейкки Паасоненның китабы да 1953 елда басылып чыккан иде (Mischärtatarische Volksdichtung, gesammelt von H. Paasonen (Übersetzt und herausgegeben von Eino Karahka. – Helsinki, 1953). Анда җырлар белән бергә 21 әкият тексты да урын алган. Инде 1989 елда Венгриядә дөнья күргән китап (Kazantatarische Volksmärchen. Auf Grund der Sammlung von Ignác Kúnos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk und **Im**re Baski (Oriental Studies 8). – Budapest, 1989) тулаем әкиятләрдән генә тора. Аларның беренче бөтендөнья сугышы вакытында (төгәлрәге 1915–1918 елларда) татар әсирләреннән венгр галиме Игнац Кунош язып алган. Бу әкиятләр (14 текст) 70 елдан артык гомер узгач, беренче мәртәбә басылып чыктылар. Аларны 1993 нче ел дәвамында «Мирас» журналыннан укырга мөмкин булачак.

Шулай итеп, беренче басма татар әкияте тел өйрәнү материалы буларак дөнья күрсә, әкият басылган беренче фольклор җыентыгы һәм беренче әкият китабының нәшер ителүе татар мәгърифәтчелек хәрәкәте белән бәйле. Әкият китапларын нәшер итүдә икенче этап М. Горькийның фольклорны өйрәнүгә чакыруы уңаеннан татар әдипләренең эшчәнлегеннән гыйбарәт. Өченче этап исә – Г. Ибраһимов исемендәге институт эшчәнлеге нәтиҗәсе.

## Әкиятләр тарихыннан

Татар халык әкиятләре беренче мәртәбә нинди китапта басылган? Беренче әкиятләр җыентыгы кайчан чыккан? Татар әкиятләре беренче мәртәбә рус һәм чит ил телләренә кайчан тәрҗемә ителгән? Шундый «беренче»ләрне белү халык иҗатын сөючеләр өчен кызыксыз булмас.

Беренче басма әкиятләр белән без Мартиниан Ивановның «Татарская хрестоматия» дигән дәреслегендә очрашабыз. Бу дәреслек Оренбург хәрби училищесында татар теле укытуда файдалану өчен төзелгән һәм 1842 елда Казан университеты типографиясендә басылган. Ләкин типографиядә янгын чыгу сәбәпле, ул берничә данәдә генә сакланып калган. Бу хрестоматиядә 8 әкият урнаштырылган. Шуларның «Ак елан» дигәнен «Әкиятләр»нең икенче китабыннан да (1978 ел) укырга мөмкин.

Халыкның киң катлауларына исәп тотып төзелгән һәм 12 әкият, 3 бәет, 500 дән артык мәкальдән торган беренче махсус фольклор җыентыгы 1889 елда Казан шәһәрендә басыла. Ул «Хикәят вә мәкаләт» дип исемләнгән. Төзүчесе – Габделгаллəм Фәезханов. Кечкенә форматлы һәм 32 биттән генә торган бу җыентык 20 ел эчендә биш мәртәбә басыла. Бер бүренең җиде баҗаны ашавы; уртакка шалкан һәм бодай чәчеп, аюның төлкедән алдануы; «мә» дигәнгә генә күнеккән мулланың суга батканда да аңа кулын сузучыларның «бир» дигәнен ишетмәве; үз-үзенә нык ышанган берәүнең, алданып, кәкре каен терәтеп торуы; бер тегүченең ач бүрене аршыны белән кыйнап һуштан яздыруы; төлке белән торнаның бер-берсен кунакка чакырышуы турындагы әкият һәм мәзәкләр беренче мәртәбә әнә шул җыентыкта дөнья күргән.

Әкиятләрдән генә төзелгән беренче җыентык «Дәфгылькәсәл мин әссаби вә сабият» (Яшь ир балалардан вә һәм яшь кыз балалардан ялкаулыкны җибәрә торган хикәяләр) дип атала. Ул 1900 елда Казанда Таип Яхин тарафыннан дөньяга чыгарыла. Анда 99 текст урын алган. Китапның күләме 204 бит.

К. Насыйри һәм П.А. Поляковның «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» дигән хезмәте татар халык әкиятләре өлкәсендәге беренче фәнни тикшеренү булып тора.

Себер татарларының әкиятләрен беренче булып академик В.В. Радлов җыя. Әлеге әкиятләрне ул «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» дигән хезмәтенең IV томында бастыра. Бу том 1872 елда Петербургта чыга.

В.В. Радлов рус әкиятләрен беренче мәртәбә татар теленә дә тәрҗемә итә. Аның Казанда 1872 елда балаларга атап чыгарган «Белик» дигән китабындагы «Төлке белән бүре» һәм «Аю белән адәм» исемле әкиятләре А.Н. Афанасьев җыентыгыннан алынган.

Ә татар әкиятләрен беренче мәртәбә рус теленә тәрҗемә итеп бастырган кеше – Р.Г. Игнатьев. Аның 1875 елда «Рус география җәмгыятенең Оренбург бүлеге язмалары»нда дөнья күргән «Татарча кульязмаларда һәм Оренбург ягы мөселманнары телендә сакланган хикәятләр, әкиятләр һәм җырлар» дигән хезмәтендә 3 әкиятнең эчтәлеге бәян ителә. Ләкин татарча текстлары бирелмәгән.

Татар әкиятләрен рус телендә оригиналлары белән бергә бастырган беренче кеше В.Н. Витевский дигән укытучы була. Аның тарафыннан 1877 елда тәрҗемә ителгән ике әкият 1891 елда IV Археология съезды материаллары эчендә дөньяга чыга. Кәҗә белән сарык турындагы киң таралган әкият татар һәм рус телләрендә беренче тапкыр әнә шунда басыла.

Татар әкиятләрен беренче булып чит ил теленә тәрҗемә итүче кеше – академик В.В. Радлов. Венгр галиме Габор Балинт исә татарлар арасында үзе язып алган әкиятләрне һәм аларның венгрчага тәрҗемәләрен, фольклорның башка жанрдагы әсәрләре белән бергә, «Казан татарлары телен өйрәнү» дигән исемдә махсус китап итеп, 1875 елда Будапешт шәһәрендә бастырып чыгара.

Совет чорында татар әкиятләренең беренче зур җыентыгы М.А. Васильев тарафыннан рус телендә әзерләнә. Ул «Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды» дигән исемдә 1924 елда Казанда басыла. Бу китап рус телендә татар әкиятләре һәм легендалары тупланган беренче һәм хәзергәчә бердәнбер фәнни чыганак булып кала. Анда 70 тән артык текст урнаштырылган.

Әкият һәм әкиятчеләр турында кереш мәкаләсе булган беренче җыентыкны язучы Г. Бәширов төзи. Әлеге җыентык «Халык әкиятләре» дигән исемдә 1940 елда басыла. Анда 40 ка якын әкият һәм мәзәк кертелгән. Бу китап тагып бер үзенчәлеге белән аерылып тора: төзүче, беренче буларак, үзе язып алган әкиятләрне әкиятчеләр буенча төркемләп урнаштырган.

Татар халык әкиятләренең беренче тапкыр ике томлык фәнни басмасы СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнә. Бу томнар 1946 (I китап) һәм 1956 (II китап) елларда дөньяга чыга. Аларда 140 ка якын текст сайлап басылган. Төзүчеләре: Г. Бәширов һәм Х. Ярми.

Хәзерге вакытта халык әкиятләре татар фольклорының шул ук институтта әзерләнә торган 12 томлык җыйналмасы эчендә беренче тапкыр өч томда нәшер ителә. Бүгенге көнгә шуларның икесе басылып чыкты (I китап – 1977, II китап – 1978). Төзүчеләре – Х. Гатина һәм Х. Ярми.

Басылмаган әкиятләргә килсәк, алар арасында безгә мәгълүм иң борынгы кульязма 1752 елга карый. Аның язмышы шактый гыйбрәтле. Ниндидер вак җинаять өчен Казан төрмәсендә утырганда Вәли Алиев дигән кеше үзе янындагы тоткыннарга Петр I образы булган әкият сөйләгән. Тыңлаучылар арасында солдат акчасын урлаган өчен кулга алынган вахмистр Антон Никифоров та була. Ул: «Патша хәзрәтләренә тел тидерде, патшаны карак дип атады», – дип, Вәли Алиев өстеннән донос яза. Вахмистрдан әкиятне сөйләтеп алалар да башкалага сенат хөкеменә җибәрәләр. Сенат: «Патша турында әшәке сүзләр әйткән өчен, камчы белән аяусыз суктырырга», – дигән карар чыгара. Әлеге кульязманы Мәскәү архивларының берсендә саклана торган суд делосыннан 1974 елда филология фәннәре кандидаты М. Гайнетдинов табып алган.

## Колумб татарского фольклора

В прошлом году исполнилось 110 лет со дня рождения литературоведа, фольклориста, педагога и краеведа М.А. Васильева. Его перу принадлежат многочисленные статьи, очерки по русской литературе и фольклору, книги для классного чтения для татарских и башкирских школ, программы для собирания фольклора, сборник татарских сказок и легенд труды по краеведению, рецензии.

Михаил Андреевич Васильев родился в селе Биляр-Озеро Чистопольского уезда Казанской губернии (ныне Октябрьский район Татарской АССР) в семье крестьянина. Первое зерно любви и интереса к народной поэзии заронила в нем его бабка Алена Трофимовна, первая его «учительница словесности», как он ее впоследствии назвал, и все жалел, что не мог воспользоваться ее знаниями фольклорного материала в годы сознательной жизни.

После окончания сельской школы его повезли учиться в Казанскую учительскую семинарию, где он более основательно ознакомился произведениями русской и зарубежной классики. Окончив семинарию, он работал учителем начальных школ в селе Ново-Шешминское Чистопольского уезда, в селе Покровская Слобода вблизи Саратова (ныне город Энгельс), в Баронске (ныне город Маркс).

В 1906 году М.А. Васильев получил приглашение от директора Казанского учительского института занять место учителя в городском училище при институте, и осенью этого же года он со своей семьей переезжает в Казань. В Казань он стремится давно, так как у него была заветная мечта – поступить в университет. Однако до этого ему надо было получить аттестат зрелости. Подготовка к экзаменам на аттестат зрелости заняла у него два года, а затем экзамены были блестяще сданы при третьей мужской гимназии. А вот поступить в университет оказалось непросто. Дело в том, что он, имея семью, не мог бросить работу и обратился к попечителю Казанского учебного округа с просьбой разрешить поступить в университет, не покидая службы. Получил он решительный отказ: или служба, или университет.

В этот тяжелый момент Михаил Андреевич получил приглашение преподавать литературу в Татарской учительской школе, что помещалась на Екатеринской улице напротив дома Шамиля. Только в 1912 году, не покидая работу, ему удалось поступить в университет. И теперь до сих пор неясно бродивший в нем интерес к народной поэзии всецело овладел им. Все ученики школы были обложены данью: после окончания летних каникул привезти записанную сказку, легенду и прочие произведения татарского народного творчества.

После окончания университетского курса Михаил Андреевич был оставлен там же, на кафедре русской литературы для подготовки к ученому званию.

После революции у М.А. Васильева пробуждается интерес к истории местного края и Казани в частности. Он особенно интересовался творчеством местных литераторов, ученых и вообще культурной жизнью Казани. В результате, например, появляется статья «А.А. Наумова в общественных мотивах ее творчества» (1926). Судьба литераторов, участников восстания 14 декабря 1825 года заинтересовала его еще в студенческие годы, и особенно кумира 30-х годов несчастного А.А. Бестужева-Марлинского. Его переписка с родными и разными лицами, разбросанная по разным изданиям XIX века, была собрана Михаилом Андреевичем, но так и осталась ненапечатанной.

До 1922 года М.А. Васильев читал в университете лекции по истории литературы различных периодов, по фольклору и поэтике. В 1922 году он перешел на работу в Восточный педагогический институт. В этом же году ему было присвоено звание доцента. Годы работы в techинституте были самыми плодотворными.

В 1933 году он перешел на работу старшим научным сотрудником в университетскую библиотеку. Там он работал по разбору рукописей, главным образом, касающихся местного края, Среднего Поволжья вообще. Интерес к краеведению, к любимой Казани находит себе широкое удовлетворение, но большинство его работ остается в рукописи.

Когда защитил он диссертацию на степень кандидата филологических наук, ему шел уже 63-й год.

Мне, как фольклористу, разумеется, ближе сердцу те труды М.А. Васильева, которые связаны с фольклором вообще и татарским фольклором в частности, независимо от того, статья ли это как, например, «Татарские версии Хаджи Насреддина», или «Программа для собирания фольклора», изданная на татарском языке совместно с писателем, литературоведом и фольклористом Г. Рахимом, или отдельная книга. Они одинаково ценны для нашей науки, для истории. И все же наиболее значительным трудом по фольклору является его книга, изданная в Казани в 1924 году под названием «Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды». Она составлена из материалов, записанных из уст народа в предреволюционные годы воспитанниками Татарской учительской школы.

М.А. Васильев был истинным интернационалистом. Он считал своим долгом показать русскому и другим народам духовные сокровища татарского народа, среди которого он родился, вырос, жил и трудился. До этого книг по татарскому фольклору на русском языке не было. «Народное устное творчество татар Волжско-Камского края мало известно не только русскому читателю в его массе, но и ученому фольклористу, – писал он в послесловии к сборнику. – ...Между тем потребность в знакомстве с духовным обликом татарского народа и его культурно-художественными достижениями у русского читателя возрастает с каждым днем. Первый почин в этом деле мы и делаем настоящей книгой, ограничив себя опубликованием небольшого собрания сказок и легенд, нисколько не претендуя на полноту материала».

В этот сборник включены переводы около 80 текстов. После каждого произведения приводятся их паспортные данные. Составитель указал также параллели сказок в различных сборниках, составленных русскими и зарубежными учеными. Эта сторона не осталась незамеченной и общественностью. «Чрезвычайно интересная и нужная книжка, – говорится в рецензии на сборник. – ... Свои сказки, легенды мы скорее сравниваем с немецкими, французскими, индусскими, египетскими, чем с народностями нашей же страны...

Между тем Восток нас должен интересовать: татары, например, в создании русской культурно-бытовой физиономии немало имели значения. Записи же отдельных их произведений появлялись иногда лишь в местной печати, но не для “широкой публики”».

Сборник М.А. Васильева, несмотря на научные принципы его издания, в то же время был предназначен и для широкого круга читателей. «Книга имеет... научный интерес для фольклориста, школьный – для преподавателя, наконец, прекрасное чтение для детей младшего и среднего возраста», – говорится в упомянутой рецензии к сборнику.

Итак, благодари этой книге русский читатель, а через русский язык и другие народы, впервые получили возможность ознакомиться с татарскими сказками и легендами, хотя тираж сборника был сравнительно невелик – всего 3 тысячи экземпляров.

Переводы некоторых текстов татарских сказок и легенд, не вошедших в эту книгу, находятся в хранилище рукописей и редких книг Института языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова. Оригиналы использованных произведений на татарском языке до сих пор не найдены, вероятно, они утеряны совсем, как и утеряна могила самого ученого на Арском кладбище Казани.

Как жизнь и педагогическая деятельность, так и научное наследие М.А. Васильева до сих пор специально не изучено. В этом отношении мы остаемся в большом долгу перед светлой памятью нашего замечательного земляка. Откладывать решение этой задачи мы не вправе.

## Тукай һәм әдәби әкият

Г. Тукайның иҗаты һәм әдәби эшчәнлеге халык иҗаты белән тыгыз бәйләнгән. Бу – күптән мәгълүм һәм танылган хакыйкать.

Г. Тукай һәм халык иҗаты мәсьәләсен төрле аспектта карарга мөмкин: шагыйрьнең иҗатына фольклорның йогынтысы; Г. Тукайның халык иҗатына теоретик карашлары, шулай ук халык иҗаты әсәрләрен җыюы һәм бастырып чыгаруы; ниһаять, фольклор жанрлары үрнәгендә һәм шул жанрларга карый торган әдәби әсәрләр (җыр, бәет, әкият һ. б.) иҗат итүе. Без шушы аспектларның соңгысына тукталып, Г. Тукайның әкиятләре турында сөйләргә җыенабыз.

Язучылар иҗат иткән әкиятләрне шартлы рәвештә әдәби әкиятләр дип йөртәләр. Шуннан да уңышлы атаманың әлегә табылганы

юк. Г. Тукай заманында исә язучы иҗатының бу төрен билгеле торган атама бөтенләй дә булмый. Чөнки ул чорда әле татар әдәбиятында әкиятләр иҗат ителмәгән. Бу эшне беренче булып үзенең мәшһүр «Шүрәле» поэмасы белән Г. Тукай башлап җибәрә. Шулай итеп, татар әдәби әкиятенең тарихы 1907 елда иҗат ителгән «Шүрәле»дән башлана, һәм бу тарихның юл башында олуг Тукаебыз басып тора.

Г. Тукай һәм халык иҗаты өлкәсенә караган махсус хезмәтләрдә[1] генә түгел, бәлки, гомумән, Г. Тукай иҗаты турындагы тикшеренүләрдә, шулай ук фольклор мәсьәләләренә багышланган кайбер хезмәтләрдә[2] дә шагыйрьнең әкиятләренә кагылышлы шактый күп мәгълүмат табарга мөмкин. Ләкин әлеге хезмәтләрнең берсендә дә әдәби әкият халык иҗаты һәм профессиональ иҗат чигендә туган һәм матур әдәбиятның мөстәкыйль бер жанрын тәшкил иткән аерым күренеш буларак каралмый.

Әдәби әкиятнең асылын Г. Тукай яхшы аңлаган. Ул үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясендә болай ди: «...әгәр дә шушындый ук хикәя (сүз халык иҗаты әсәрләре турында бара. – *Л.Ж.*) бер-бер мөхәррир вә шагыйрь тарафыннан бизәкләп вә матурлап язылса, инде ул «халык әдәбияты»лыктан чыга. Бу җөмләдән Пушкинның «Алтын балык» вә «Алтын әтәч» кеби хикәяләрен санарга мөмкин. Мондый хикәяләрнең башта халык авызында сөйләнүе дә вә халык рухынча язылуы да аның «халык әдәбияты»лыктан чыгуына манигъ (киртә. – *Л.Ж.*) була алмый»[3].

Бу өземтәдән күренгәнчә, шагыйрь мисалны рус әдәбиятыннан китерә. Чөнки Г. Тукай өчен прогрессив рус әдәбияты әкиятләр

---

[1] Толымбай Г. Тукай һәм әдәби фольклорыбыз // Безнең юл. 1928. № 6–7. Б. 21–27; Габдрахманов Ф. Тукай һәм фольклор әсәрләре // Совет әдәбияты. 1938. № 4. Б. 39–47; Халит Г. Тукай һәм халык иҗаты // Совет әдәбияты. 1938. № 5. Б. 74–84; Гайнуллин М. Тукай һәм халык иҗаты // Совет әдәбияты. 1945. № 12. Б. 57–63; Ярми Х. Тукай һәм халык иҗаты // Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан, 1948. Б. 93–112; Вәлитова Й. Г. Тукай һәм халык әкиятләре // Совет мәктәбе. 1970. № 10. Б. 37–39.

[2] Әмирхан Ф. Габдулла Тукаев шигырьләре // Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр: ике томда. Казан, 1958. 2 т. Б. 183–186; Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре / төзүче, текстны әзерләүче һәм искәрмәләр бирүче Мансур Хәсәнов. Казан, 1960. Б. 40–42; Нигъмәти Г. Тукай ижаты // Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. Казан, 1958. Б. 228; Фәйзи Ә. Халык шагыйре // Фәйзи Ә. Әдипнең эрудициясе. Казан, 1973. Б. 66–71; Халит Г. Тукай үткән юл. Казан, 1962. Б. 115–150; Нуруллин И. Тукай иҗаты. (Беренче рус революциясе чоры). Казан, 1964. Б. 104–112.

[1] Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. Казан, 1955. Т. II. Б. 260. (Алга таба бу басманың том һәм битләре генә күрсәтеләчәк.)

иҗат итүдә дә абруйлы үрнәк булып торган. «Шүрәле» поэмасы басылган беренче җыентыгында шагыйрь бу турыда ачыктан-ачык: «Мин бу “Шүрәле” хикәясен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуына истинадән (таянып. –Л. Җ.) яздым»[1], – ди.

Г. Тукай рус әдәбиятыннан үрнәк алып кына калмый, бәлки андагы иң яхшы әкиятләрне татар теленә дә тәрҗемә итә. «Алтын әтәч» (Пушкиннан, 1908 ел), «Япон хикәясе» (Буренинnan, 1909 ел), «Өч хакыйкать» (Майковтан, 1912 ел) – әнә шундый әсәрләр.

Әдәби әкиятләр язуда ике төрле ысул бар. Беренчесе – халык иҗаты арсеналындагы сюжетларны эшкәртү; икенчесе – халык иҗатының төп закончалыкларын  саклаган хәлдә, яңа сюжетлар иҗат итү. Г. Тукай, бу өлкәгә тәүге сукмакны салучы буларак, беренче ысул белән эш иткән, ягъни аның әкиятләрендәге сюжетлар турыдан-туры халык иҗаты әсәрләреннән алынган.

Г. Тукай иҗат иткән дистәгә якын әкият арасында «Шүрәле» (1907 ел), «Су анасы» (1908 ел) һәм «Кәҗә белән Сарык хикәясе» (1909 ел) аеруча популярлык казана. Шуларның баштагы икесе турында сөйләгәндә, тикшеренүчеләрнең кайберләре шагыйрь аларны халык әкиятләреннән файдаланып язган, дигән караштa торалар. Ләкин бу карашка төгәллек җитми. Чөнки халыкта киң таралган шүрәле һәм су анасы турындагы кечкенә хикәяләр – чын мәгънәсендәге әкиятләр түгел. Аларда, тасвирлаудан бигрәк, хәбәр итү, белдерү өстенлек ала, һәм кешеләрнең борынгы ышануларын чагылдырган ул нәни хикәя-легендалар әкият белән тиңләрлек эстетик вазифа үтәмиләр. Менә шушы хәл, әлеге легендаларны әкият иҗат итүдә нигез итеп  файдаланганда, язучы фантазиясенә зур мәйдан ача.

Г. Тукай легендаларның халык тормышына иң якын булганнарын сайлаган һәм аларның да үзенең идея-эстетик позициясенә туры килә торган вариантларын гына алган[2]. Бу очракта әлеге вариантның иң популяр булуы мөһим түгел.

Шушы уңайдан Г. Тукайның «Кәҗә белән Сарык хикәясе»нә тукталып үтик. Бу сюжетка корылган халык әкияте ул заманда ни дәрәҗәдә популяр булгандыр – әйтүе кыен. Чөнки безнең кулда бу хакта әлегә бернинди мәгълүмат юк. Ләкин, шулай да бер факт игътибарга лаек. 1877 елда Казанда үткәрелгән IV Археология съездында В.Н. Витевский «Оренбург губернасы Верхнеуральск өязе

[1] Тукай Г. Т. I. Б. 259.

[2] Ф. Габдрахманов, М. Гайнуллин һәм И. Нуруллинның алда күрсәтелгән хезмәтләрендә бу мәсьәлә тәфсилләп бәян ителә.

нугайбәкләренең әкиятләре, табышмаклары һәм җырлары» дигән темага белдерү ясый. Белдерүдә нугайбәкләрнең XVI йөздә чукындырылып, бирегә күчереп утыртылган Казан татарлары булуы әйтелә һәм бу фикерне раслау өчен фольклорның төрле жанрларына караган әсәрләр белән бергә ике әкият тә китерелә. Шуларның берсе – кәҗә белән сарык турындагы әкият[1]. Ләкин аның сюжеты Г. Тукай әкияте сюжетыннан аерыла, ягъни аерым бер вариант тәшкил итә.

Әлбәттә, бу сюжет үзе борынгы, ләкин шунысы игътибарга лаек: әлеге әкият IV Археология съездына хәтле һәм аннан соң басылып чыккан әкият җыентыкларының берсендә дә очрамый. Бу фактка өлкән фольклорчы Х. Ярми дә игътибар иткән[2].

XX йөз башында халык арасында популяр булган әкият, әйтик, Таип Яхин төзегән җыентыкларга, аерым алганда, йөзгә якын әкиятне берләштергән «Дәфгылькәсәл...» (Казан, 1900 ел) җыентыгына керми калыр идеме икән? Бу бер. Икенчедән, Татарстан районнарына оештырылган бер генә экспедициянең дә В.Н. Витевский вариантын алып кайтканы юк. Ә бу әкиятнең Г. Тукай вариантын исә һәр авылда табарга мөмкин.

Моннан түбәндәгечә фараз итәргә мөмкинлек туа: бәлки кәҗә белән сарык турындагы борынгы әкият Г. Тукай заманында инде Казан татарларында популяр булмагандыр (бөтенләй онытылган булган дип әйтергә җыенмыйбыз), һәм шагыйрь үзенең әсәрен В.Н. Витевский тарафыннан теркәлгән әкият нигезендә иҗат иткәндер? Әгәр инде бу әкият ул чакта халыкта сөйләнеп, җыентыкларга очраклы рәвештә генә керми калган булса да, барыбер хәлнең асылы үзгәрми: 1909 елдан соң Г. Тукай әсәре популярлашып, аңа кадәрге вариант соңыннан бөтенләй онытылган булып чыга.

Кыскасы, әлеге әкиятнең бүгенге көндә популяр булган бердәнбер варианты Г. Тукай иҗаты белән бәйле, ягъни шагыйрьнең фольклор нигезендә язылган әсәре, гаять дәрәҗәдә халыклашып китеп, ахыр чиктә үзе фольклор әсәренә әверелгән.

Г. Тукайның әкиятләр язуы, беренче чиратта, балалар әдәбиятына хезмәт итүе белән бәйле. Мәгълүм булганча, Г. Тукай балаларны эстетик тәрбияләүгә ифрат зур игътибар биргән, алар өчен дәреслек һәм уку китаплары төзеп бастырган. Үзенең әкиятләрен дә ул балаларга атап нәшер ителгән «Җуаныч» (1908 ел), «Балалар күңеле» (1910 ел), «Җан азыклары» (1912 ел) дигән җыен-

---

[1] Труды четвертого Археологичесхого съезда в России. Казань, 1891. Т. II. С. 277–278.

[2] Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан. 1967. Б. 21.

тыкларында чыгара, яисә аларны аерым китап итеп бастыра. Әнә шундый аерым китап булып чыккан «Алтын әтәч» әкияте турында драматург Г. Камал «Йолдыз» газетасында (1909 ел, 406 сан) болай дип яза: «Габдулла әфәнде бу әсәрне яшь балалар өчен язмыш вә китабының мәфһүменә (эчтәлегенә. – *Л.Җ.*) Пушкинның «Золотой петушок» нам әсәреннән алынмыштыр. Назымы гаять җиңел булу өстенә, тасвирлары да гаять шагыйранәдер».

Әкият баланың рухи дөньясын баета, фантазиясен үстерә, холкын төзәтергә һәм тормышка карашын ачыкларга ярдәм итә. Чөнки әкияттә өстенлек итүче эстетик вазифага төрле дәрәҗәдә идея вазифасы да (әхлакый, социаль, политик һ.б.) юлдашлык итә. Әкиятнең тәрбияви көче әнә шул вазифалар тәэсиренең суммасыннан гыйбарәт. Г. Тукай моны яхшы аңлаган һәм фольклор әсәрләрен, беренче чиратта, әнә шул сыйфатларына карап сайлап алган.

Әдәби әкиятнең исә зур өстенлеге шунда: автор үзенең идея-эстетик карашларына ярашлы рәвештә әлеге вазифаларның теләсә кайсын игътибар үзәгенә куя, көчәйтә, тагын да тәэсирлерәк итә ала. Әйтик, «Шүрәле» поэмасында эстетик вазифаны тагын да калкурак итү максатында халык әкиятенә бик үк хас булмаган алымнардан файдалану (мәсәлән, пейзаж һәм портретны тәфсилләп сурәтләү) күзгә ташлана. Бу исә әдәби иҗатның асылы белән бәйле: халык иҗатына гомумиләштерү сыйфаты хас булса, «әдәбият конкретлыкка омтыла, гомумиләштерү белән бергә, индивидуальләштерүне таләп итә»[1]. Поэмада вакыйганың билгеле бер урынга – Кырлай авылы тирәсенә беркетелүе дә шуның белән аңлатыла.

Эстетик вазифаны көчәйтү белән бер үк вакытта, Г. Тукай үзенең әсәрендә, бик оста итеп, халыкның җәбер-золым эчендә хокуксыз яшәвен, кешелек дөньясы туплаган сәнгать һәм культура хәзинәләреннән мәхрүм булуын да күрсәткән.

Поэманың урманны сурәтләгән өлешендә шундый юллар бар:

Монда бульварлар, клуб һәм тансавальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.

Ягъни цивилизацияле халыкларның һәммәсендә дә булган культура чараларының барысын да монда бары тик бер урман күренешләре генә алыштыра.

Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! – дисең, – без ник болай соң? Без дә хакның бәндәсе.

---

[1] Нуруллин И. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 107.

Бу юллар әлеге нәтиҗәгә өстәмә ачыклык кертә: әйе, «шагыйрь татар милләтенең шул вакыттагы хәле, хокуксызлыгы һәм артталыгына ачына»[1].

Шулай итеп, Г. Тукай лирик пролог ярдәмендә әсәрнең эстетик вазифасын көчәйтеп кенә калмый, бәлки аңа социаль-политик вазифа да йөкли.

«Кәҗә белән Сарык хикәясе»ндә социаль мотивлар тагын да ачыграк чагыла. Мәсәлән, В.Н. Витевский вариантында карт белән карчык кәҗә тәкәсе белән сарык тәкәсен «бу малларны языклы булып асрамыйк» дип чыгарып җибәрсәләр, Г. Тукай бу хәлне турыдан-туры реаль чынбарлыкка бәйләп сурәтли: ир белән хатынның «тормышлары шактый гына фәкыйрь булган», маллар «берсеннән дә берсе арык», чөнки печән хакы кыйммәт.

Әлбәттә, халык мәнфәгатен яклаган, халык кайгысын кайгыртып яшәгән шагыйрь аның социаль хәлен үзенең әкиятләрендә дә чагылдырмый калмый. Г. Тукайга кадәр фольклор әсәрләренең сыйнфыйлыгы мәсьәләсе бөтенләй диярлек кузгатылмаган булуны искә алсак, шагыйрьнең новаторлыгы тогын да калкурак күренер.

Ә менә «Су анасы» әкиятендә Г. Тукай эстетик вазифа белән беррәттән әхлакый вазифаны күз уңында тота.

Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым.
«Йә иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым.

Шулай итеп, әдәби әкияттә кайбер поэтик чаралар активрак кулланыла, әсәрнең идея юнәлеше автор ихтыяры белән үзгәртелә. Г. Тукай халык иҗатындагы сюжет Һәм мотивларны пассив эшкәртеп кенә калмый, аларны, халык рухын һәм милли колоритны саклаган хәлдә, тарих һәм көнкүреш белән, биографик моментлар белән – кыскасы, реаль чынбарлык белән органик рәвештә бәйләп, халыкның зәвыгына, рухи ихтыяҗына һәм, ниһаять, шул заманның идея-эстетик таләпләренә җавап бирә торган синтетик характердагы әсәрләр иҗат итә.

Халык әдәбияты белән язма әдәбият арасындагы аерма турында Г. Ибраһимов болай дип яза: «Бу икенең берсен табигый урманга, икенчесен оста карауччының дикъкатьле тәрбиясендә эшләнгән бакчага охшатырга мөмкин»[2], һәм «Шүрәле» белән «Су анасы»н ул моның иң гүзәл үрнәкләре итеп саный. «Тукаевның бу шигырьләре шулкадәр ачык вә табигый чыккан ки, – дип яза Г. Ибраһимов

[1] Нуруллин И. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 110.
[2] Ибраһимов Г. Әдәбият дәресләре. Казан, 1916. Б. 62.

“Йолдыз” газетасында (1910 ел, 547, 549 саннар) басылган “Халык мосәннәфаты” (иҗат ителгән әсәр. – Л. Җ.) дигән мәкаләсендә, – чи гавамның авызыннан да шулкадәр генә чыгар иде... Әдип вә шагыйрьләребездән Тукаевның “Су анасы” вә “Шүрәле”се кебек шигырь вә хикәячекләрнең чыгуын теләргә тиешлебез»[1].

Г. Тукай әкиятләренең тагын бер күркәм сыйфаты турында әйтми мөмкин түгел. Ул да булса, аларның теле. Ф. Әмирхан шагыйрьнең «Шүрәле» әсәре урнаштырылган беренче җыентыгы («Габдулла Тукаев шигырьләре. Өченче дәфтәр», 1907 , ел) чыгу уңае белән, «Әльислах» газетасында (1907 ел, 3 декабрь саны) басылган рецензиясендә поэманың теленә махсус туктала. Ул мисал рәвешендә әсәрдән пейзаж һәм шүрәленең портреты сурәтләнгән өзекләрне китерә. Шул ук вакытта әдип җыентыктагы күп кенә шигырьләрнең теле чуар булуын билгеләп үтә («иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, әзербәйҗанча, тагын әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер»[2]).

Күренә ки, Г. Тукай әсәрләре ул чорда әле иске корама телдән арынып җитмәгән була. Инде шагыйрьнең 1903 ел башында дөнья күргән икенче җыентыгына («Г. Тукаев шигырьләре. Дүртенче дәфтәр») язылган рецензиясендә Ф. Әмирхан Г. Тукайның күп шигырьләрен «матур тасвирлы, садә татар телендә язылган» дип бәяли[3]. Ә бу җыентыктагы шигырьләрнең күпчелеген исә «Шүрәле» поэмасыннан соң туган әсәрләр тәшкил итә.

Галимнәр дә шагыйрьнең киң массага аңлаешлы саф татар телендә эзлекле рәвештә яза башлавы «Шүрәле» әсәреннән башланып киткән дип саныйлар[4]. Димәк, Г. Тукайның әкиятләр иҗат итүе, тел җәһәтеннән караганда, аның үз-үзен тәрбияләү чарасы да булган дип әйтергә мөмкин.

Г. Тукайның әкиятләр өлкәсендәге эшчәнлеге балалар әдәбиятына хезмәт итү белән бәйле дидек. Ләкин әлеге мәсьәләнең икенче ягы да бар. Бу урында без Г. Халитның «Тукай үткән юл» дигән китабыннан бер өземтә китерү белән чикләнергә уйлыйбыз: «Искергән мәгънәсендәге дидактик һәм риторик поэзия басымыннан тиз арада котылу юлларын эзләгәндә, – ди ул, – Тукай боларны, бер яктан, рус классик поэзиясе традицияләрендә – аеруча Пушкин һәм Лермонтов мирасында күрсә, икенче яктан, татар халык иҗатында тапты. Соңгысын ул, һичшиксез, милли әдәбиятның үзенчәлекле

---

[1] Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960. Б. 40, 41, 42.
[2] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. Т. II. Б. 184.
[3] Шунда ук. Б. 206.
[4] Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. Б. 54.

**халыкчан җирлеген ныгыту өчен** (ассызык безнеке. – *Л.Җ.*) көрәш коралы дип аңлады»[1].

Шагыйрьнең әкиятләре дә әнә шушы максатка хезмәт иткән.

Чыннан да, Г. Тукай әкиятләренең халыкчанлыгы, поэтик яктан камил эшләнеше аларның гаять популяр булуына ярдәм итте. Бу әсәрләрне яратып укыйлар, яттан сөйлиләр. «Шүрәле» һәм «Су анасы» әкиятләре композиторларны опера һәм балетлар язарга рухландырды. «Шүрәле» поэмасы СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителде. Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты Казанда гына түгел, Мәскәү, Ленинград һәм башка күп кенә шәһәрләрдә, шулай ук чит ил сәхнәләрендә зур уңыш казанды.

Г. Тукай иҗаты безнең өчен торган саен тирәнрәк ачыла бара дибез икән, бу аның әкиятләренә дә кагыла. Төрле яклап һәм тирәнрәк төшенә барган саен, әлеге әкиятләр үзләре турында күбрәк һәм яңачарак сөйли башлыйлар. Ләкин алар әлегә үзләренең тикшеренүчеләрен көтә. Мәсәлән, Г. Тукай әкиятләренең мифологик нигезен билгеләү, бу әсәрләрне тарихи-этнографик яктан тикшерү, яисә шагыйрьнең бу өлкәдеге традициялелеге һәм новаторлыгы мәсьәләсен киңрәк ачыклау кызыклы нәтиҗәләр бирер иде.

Илленче еллар башында ук инде Ә. Фәйзи болай дип язган иде: «Тукай иҗатының һичшиксез өйрәнелергә тиеш иң әһәмиятле якларының берсе – әсәр өстендә эшләү ысуллары, шагыйрьнең осталыгы, аның әсәрләрендәге форманың идея эчтәлегенә органик рәвештә бәйләнгән булуы... Классикларыбызның, беренче чиратта Тукаебызның, иҗатын өйрәнү, алар турында монографияләр язу-булдыру яшь язучыларның игътибарын әдәби осталык ягына юнәлдерер иде[2].

Бу бурыч бүген дә актуаль булып кала. Аерым алганда, Г. Тукайның әкият иҗат итү осталыгын өйрәнү нигезендә барлыкка килгән күләмле хезмәтләр язучыларыбызга, бигрәк тә яшь әдипләргә, зур мәктәп булып хезмәт итә ала.

## О мифологической основе сказки «Шурале»

Связь поэмы «Шурале» с фольклором татарского народа изучена в нашей науке довольно обстоятельно. Еще до Великой Отечественной войны появился ряд исследований, посвященных связи

[1] Халит Г. Тукай үткән юл. Б. 126

[2] Фәйзи Ә. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 71.

творчества Тукая с народным творчеством. В статьях Г. Тулумбая[1], Ф. Габдрахманова[2], Г. Халита[3], наряду с другими вопросами, обращается внимание и на мифологическую основу поэмы «Шурале», которая умело использована Тукаем и великолепно оформлена как поэтическое произведение.

Интересующий нас вопрос широко освещается также в трудах М. Гайнуллина[4], Х. Ярмухаметова[5], И. Нуруллина[6], вышедших в свет уже после войны.

В этот период работа такого характера появляется и за рубежом. Это – исследование Й. Бенцинга о поэме «Шурале», опубликованное в 1947 году в «Бюллетене...», издаваемом при Лондонском университете[7].

Как известно, творчество Тукая нашло путь и к зарубежным читателям, становясь достоянием многих народов. Стихи Тукая и статьи о его творчестве после смерти поэта публиковались в журнале «Турк йурду» (1914, № 16), издаваемом в Стамбуле, а в английском журнале «Рашшиан ревью» (1914, т. 3, № 1) было помещено стихотворение «Пара лошадей», с сопроводительной статьей Вильямсона, где приводятся сведения о поэте. Кроме них, как сообщают библиографы, стихи Тукая печатались в Японии, Румынии, Венгрии, а Луи Арагон в своем труде «Советские литературы» ознакомил с

---

[1] Толымбай Г. Тукай һәм әдәби фольклорыбыз // Безнең юл. 1928. № 6 (7). С. 21–27.

[2] Габдрахманов Ф. Тукай һәм фольклор әсәрләре // Совет әдәбияты. 1938. № 4. С. 39–47.

[3] Халит Г. Тукай һәм халык иҗаты // Совет әдәбияты. 1938. № 5. С. 74–84.'

[4] Гайнуллин М. Тукай һәм халык иҗаты // Совет әдәбияты. 1945. № 12. С. 57–63.

[5] Ярми Х. Тукай һәм халык иҗаты. «Габдулла Тукай» // Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан, 1948. С. 93–112.

[6] Нуруллин И. Тукай иҗаты. (Беренче рус революциясе чоры). Казан, 1964. С. 104–112.

[7] Behzing J. «The Forest-Demon» A Tatar Poem of Gabdulla Tuqay // Bulletin of the School of Oriental and African Studies. University of London, 1947. XII. P. 73–85. Институт востоковедения и африканистики при Лондонском университете занимается также изучением истории, литературы, языкознания, культуры и искусства тюркских народов Советского Союза. В его трудах публикуются статьи о жизни и деятельности выдающихся людей тюркских народов, в том числе и татарского народа. В настоящее время в план работы института включено изучение языка и литературы татарского народа, в связи с чем ведется комплектование фондов произведениями татарских советских писателей и трудами по татарскому языкознанию.

творчеством Тукая французских читателей[1]. Отдельные стихотворения поэта вышли и на немецком языке[2]. А поэма «Шурале» переведена на арабский[3].

Исследование. Й. Бенцинга специально посвящено изучению мифологической основы поэмы «Шурале», а также истории ее создания. Однако в этом труде, наряду со спорными выводами, имеются некоторые ошибочные утверждения. Поэтому на нем следует остановиться подробнее.

Этот труд состоит из небольшого вступления и трех разделов. В разделе «А» помещены татарский текст поэмы, отпечатанный латинским шрифтом, и ее перевод на английский язык. Раздел «В» назван «Фольклористические замечания», а последний раздел «С» – «О литературной истории “Шурале” Тукая».

Автор исследования справедливо пишет, что поэма «может считаться одним из наиболее значительных произведений великого татарского поэта Габдуллы Тукая».

Деление поэмы на 5 частей сохранено, так же как и у Тукая, однако каждая часть озаглавлена, и эти заглавия на английском языке приводятся в скобках под номерами частей татарского текста. Например: «Описание татарской сельской местности и лесов», «Обращение автора к татарскому народу», «Животные и духи леса» и т.д.

В статье I и IV части поэмы разбиты на два раздела, а II и III части объединены (однако начальные две строки II части почему-то добавлены к I). Таким образом, татарский текст и подстрочный перевод перемешаны и идут по частям. И в оригинале, и в переводе через каждые 5 строк проставлены их порядковые номера. Фамилия переводчика не указана[4].

Автор, когда считает нужным, в сносках дает и дополнительные сведения. Например, объясняя понятие «джиен», он приводит обширную цитату из книги Фатиха Карими «Татары».

В исследовании большое место занимает раздел «Фольклористические замечания». Здесь автор предпринимает попытку объяснить этимологию слова «шурале». Исходя из того факта, что это «слово не может быть объяснено в достаточной степени на основе татарского языка», он ищет пути решения на материале чувашско-

---

[1] Кәримуллин Ә. Г. Тукай – төрле телләрдә // Совет мәктәбе. 1966. № 4. С. 12–13.

[2] Кәримуллин Ә. Габдулла Тукай әсәрләре СССР халыклары телендә // Совет әдәбияты. 1961. № 4. С. 86.

[3] Казан утлары. 1970. № 2. С. 190.

[4] Вероятно, перевод сделан И. Бенцингом. – *Л.З.*

го языка. По Бенцингу, слово «шурале» («шүрәле») образовано из двух компонентов – чувашских слов: sĕvĕr «острая», «остроконечная» (в тюркских языках – sivri) и ală «рука» (в древнетюркском языке – älig)[1].

При этом возникает вопрос: поскольку эти компоненты в своей основе тюркские, то почему бы не попытаться объяснить этимологию данного слова в рамках татарского языка. Тем более что в последнем употреблялось слово šär «зло, вред»[2] из древнетюркского, и оно фонетически ближе к первому компоненту слова «шурале» (šür), чем указанное И. Бенцингом süvrä. Слово šär встречается даже в творчестве писателя З. Хади (1863–1933). Слово elig «кисть руки, рука», которое И. Бенцинг считает вторым компонентом, тоже не чуждо татарскому языку. Оно имеется, например, в памятнике XIV века «Нахдж-эль-фарадис». А форму el от того же слова мы можем найти в произведениях поэта Мухамедьяра (XVI в.). Выражение «злая рука» по семантике более соответствует характерной особенности шурале (щекотание), чем выражение «острая рука» (имеются в виду острые пальцы).

Такая трактовка этимологии, по-нашему, была бы вернее, ибо вряд ли могла возникнуть потребность в наименовании мифологического персонажа одного народа термином, образованным на основе другого языка. А в рамках родного языка, как нам кажется, такое возможно, и оно показывает интеллектуальное развитие народа (переосмысление древних представлений, стремление к образности и т.д.). Ведь у татар в отдельных местах сохранились и древние названия этого «лесного черта» («урман пәрие»): «ярымтык» (например, у татар Пермской области) и «пицен» (у западносибирских татар).

Что касается чувашской мифологии, то подобное существо, связанное тоже в основном с лесом, называется «арсюри» или «упăте» (обезьяна). Образ шурале для чувашской мифологии не характерен.

Примечательно, что названия мифических персонажей арсюри и ярымтык в своей основе схожи друг с другом: «арсюри» переводится в значении «полумужчина», «ярымтык» тоже связан с «половиной». Вообще, существа, состоящие только из одной половины тела (однорукие, одноногие и т.д.), характерны для мифологии многих народов. Что касается шурале, то в народном представлении

---

[1] В «Древнетюркском словаре» (Л., 1969) эти формы графически фиксированы соответственно: süvrä и elig (с. 519, 170). В дальнейшем мы будем придерживаться «Словаря».

[2] Указ. словарь. С. 522.

последней эпохи его «половинчатость» почти исчезла (разве только единорогость намекает на прежний облик), т.е. народ, по мере своего интеллектуального развития, переосмысливал древние представления, и «лесной черт» из «половинки» превратился в «целого». В результате и его название «ярымтык» переменилось в šär elig («злая рука»). Допустима и следующая форма образования: šär + el + le («имеющий злую руку»). Такие выражения в течение длительного времени могли превратиться в «шурале». Вполне возможно, что это новое название представляет собой условную (тайную) речь, которая была широко распространена в древности у всех народов и сохранилась вплоть до наших дней. Она возникла в силу убеждения древнего человека в том, что называть вещи и явления своими именами опасно, это может навлечь беду. Важно перехитрить враждебную силу.

Конечно, наши суждения об этимологии слова «шурале» ограничивались рамками того материала, которым пользовался Й. Бенцинг. Возможны и другие толкования. Однако эту задачу мы оставляем лингвистам-этимологам.

По нашему глубокому убеждению, нельзя согласиться с утверждением Й. Бенцинга о том, что происхождение народного мифа о шурале не татарское (даже в том случае, если название лешего заимствовано из другого языка). Говоря словами Г. Халита, «народ вынашивал его (т.е. миф о шурале. – *Л.З.)* в своем воображении в течение многих веков как плод собственного искусства»[1].

В последнем, третьем, разделе исследования Й. Бенцинга мы встречаемся с явно ошибочными положениями, вытекающими, видимо, из его вышеуказанной концепции, связанной с этимологией слова «шурале».

По его мнению получается, что Тукай для того, чтобы создать свою поэму, обязательно должен был пользоваться письменным источником по этой теме. Автор даже указывает на произведение, которое якобы служило поэту таким источником. Это – баллада чувашского поэта М. Федорова «Арсюри», по его предположению, написанная примерно в 1880 году[2].

По убеждению Й. Бенцинга, у чувашей собирание «старых традиций» началось более чем на 50 лет раньше, чем у татар. В качестве довода он приводит работу С. Михайлова «Чувашские разговоры и

---

[1] Халит Г. Указ. соч. С. 79.

[2] Указанная баллада, являющаяся первым оригинальным поэтическим произведением на чувашском языке, написана в 1879 году. – *Л.З.*

сказки», опубликованную в газете «Казанские губернские ведомости» (1853, № 33–37)[1]. О том, что же считает автор изначальным в этой области у татар, в исследовании ясно не говорится. Однако чувствуется намек на известную лекцию Тукая «Народная литература». Во всяком случае, если верить Й. Бенцингу, первые образцы татарского фольклора должны были бы увидеть свет позже 1903 года.

Здесь в качестве ответа автору следует сказать, что если даже принимать во внимание лишь те материалы об этнографии татарского народа, которые публиковались в казанской периодической печати, то и тогда началом этих публикаций пришлось бы считать 1814 год[2]. В той же газете «Казанские губернские ведомости», где печатались этнографические очерки С. Михайлова, увидело свет немало статей, посвященных этнографии и фольклору татарского народа, задолго до 1853 года[3].

Может быть, Й. Бенцинг, говоря о «старых традициях», имеет в виду только фольклорные тексты? В сборнике С. Михайлова, например, наряду с этнографическими очерками, помещены песни, пословицы, сказки и прибаутки. Однако в «Татарской хрестоматии» М. Иванова (Казань, 1842) среди материалов татарского фольклора мы (можем найти произведения почти всех этих жанров. А первые публикации татарских пословиц относятся еще к 1831–1834 годам[4]. Пословицы и поговорки помещены также в «Русско-татарской азбуке» Г. Вагапова, изданной в 1852 году[5].

Здесь мы указали на печатные источники, относящиеся к татарскому фольклору, изданные только до 1853 года. Иначе до границы, обозначенной И. Бенцингом, этот список можно было бы пополнить за счет трудов С. Кукляшева, Г. Вагапова, В.В. Радлова, Г. Балинта, Р.Г. Игнатьева, К. Насыри, Г. Фаезханова, В.И. Витевского, Т. Яхина, Н.Ф. Катанова, Х. Паасонена и др.

Следует отметить и то, что собирание чувашского фольклора началось также не с 1853 года. Как известно, его первые образцы

---

[1] В действительности работа С. Михайлова под таким названием в газете не публиковалась, а вышла отдельной книгой (Казань, 1853). Правда, часть материалов из этой книги увидела свет в газете «Казанские губернские ведомости», однако не в тех номерах, которые указал Й. Бенцинг.

[2] Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967. С. 16.

[3] Фукс К.Ф. Татарская свадьба (1843, № 48–49); Сабантуй – татарский праздник (1845, № 26); Артемьев А.Н. Джиин или Зиин, народный татарский праздник (1848, № 26); Пашино Н. Татарские сказания (1852, № 12); Баганов Г. Татарские сказания (1852, № 43, 45).

[4] Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. С. 17.

[5] Там же. С. 19.

вышли в свет уже в 1840 году («Записки Александры Фукс о чувашах и черемисах Казанской губернии»)[1].

Очевидно, И. Бенцинг не был достаточно осведомлен в этой области.

Что касается мифа о шурале, то он у казанских татар очень популярен. Вообще образ шурале характерен для мифологии только татар и башкир. К тому же в народе распространено несколько вариантов таких рассказов, и в упомянутых нами исследованиях об этом ясно говорится. Ф. Габдрахманов, например, показывает три варианта народных рассказов о шурале[2]. М. Гайнуллин ведет речь о двух вариантах, зафиксированных в трех записях[3]. А И. Нуруллин такие рассказы разделяет на четыре группы, каждая из которых состоит из нескольких вариантов[4].

Таким образом, не остается места предположению, что Тукай нуждался в этой области в каком-нибудь письменном источнике. Более того, поэт имел возможность выбрать наиболее подходящий вариант. В исследованиях Ф. Габдрахманова, М. Гайнуллина и И. Нуруллина речь идет именно об этом. Эти авторы едины в мнении, что в основу поэмы «Шурале» положен вариант, который зафиксирован в работе Каюма Насыри «Поверья и обряды казанских татар»[5], опубликованной в 1880 году, и убедительно доказывают, почему поэт предпочел именно данный вариант (здесь ярче выражены неустрашимость, смышленность и находчивость народа).

В исследованиях Ф. Габдрахманова, М. Гайнуллина и И. Нуруллина работа К. Насыри приводится в сущности для обозначения конкретного варианта из рассказов о шурале (потому что этот вариант впервые зафиксирован К. Насыри). Поэтому из вышеуказанных исследований не должно вытекать категорического мнения о том, что поэма «Шурале» могла быть создана только благодаря работе К. Насыри. Конечно, вполне допустимо и то, что данная работа известного ученого могла воодушевить поэта на творчество. Тем более, что Тукай был хорошо знаком с его трудами вообще и высоко ценил их. Однако в печатных изданиях записи мифа о шурале были и до появления работы К. Насыри, и после нее. Говоря о первой, мы имеем

---

[1] Сироткин М. Очерки дореволюционной чувашской литературы. Чебоксары, 1967. С. 12.

[2] Габдрахманов Ф. Указ. соч. С. 41–42.

[3] Гайнуллин М. Указ. соч. С. 61.

[4] Нуруллин И. Указ. соч. С. 105–106.

[5] Записки Императорского русского географического общества по отделению этнографии. СПб., 1880. Т. VI. С. 247–270.

в виду книгу венгерского ученого Габора Балинта «Изучение языка казанских татар»[1], изданную в 1875 году в Будапеште, в которой помещено описание поверья о шурале. Допустим, что этот научный труд, вышедший в свет за рубежом, относится к редким книгам, и имеющийся в нем материал отличается от сюжета поэмы. Однако сборник сказок «Дәфгылькәсәл...» («Предотвращение лености...»)[2], изданный в 1900 году в Казани и объединяющий около ста текстов, уже невозможно оставить без внимания. Вошедшая в него запись о шурале точно совпадает с сюжетом Тукая. Кстати, надо упомянуть и то, что авторы исследований, касающихся поэмы «Шурале», почему-то этот сборник обходят молчанием.

Итак, даже в случае необходимости пользоваться печатными образцами рассказов о шурале, можно не сомневаться в том, что Тукай мог свободно пользоваться записями К. Насыри и Т. Яхина, которые были под его рукой.

Однако, как указано было выше, Тукай вряд ли нуждался в качестве фактического материала в каком-либо письменном источнике, потому что источником был сам народ. Это лишний раз подтверждает и воспоминание о Тукае видного ученого-фольклориста Х. Бадигова. Как известно, в 1907 году с целью сбора татарского и чувашского фольклора в Казань приезжает венгерский ориенталист Ю. Мессарош. Х. Бадигову поручается его сопровождать. В воспоминаниях Бадигова говорится: «Мы с ним (т.е. с Мессарошем. – *Л.З.*) направились в нынешний Арский район (т.е. в район, где родился и рос Тукай. – *Л.З.)* и среди крестьян начали собирать фольклорные материалы. Мы в том году, пробыв в районе целое лето, накопили значительное количество материалов и осенью вернулись в Казань... Тукай расспрашивал меня о том, в каких краях, в каких деревнях побывали мы с Мессарошем, какие материалы привезли, и рассказывал, что он сам тоже интересуется народной литературой, особенно сказками... Я показывал ему сказки. Среди них он присмотрел мифические сказки о шурале. Они были у меня **в трех вариантах. Он сказал, что один из них очень близок к варианту, который сам слыхал и знал, и очень обрадовался этому»[3]** (подчеркнуто нами. – *Л.З.)*.

Стало быть, Тукаю не приходилось искать материал о шурале. Такой материал был вокруг него, ибо шурале, говоря словами

---

[1] Balint Gabor. Kazani – Tatar nyelvtanulmanyok. Budapest, 1875. )
[2] Яхин Таип. Дәфгылькәсәл мин әссаби вә сабият. Казан, 1900.
[3] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960. С. 118, 120.

самого поэта, – «есть “национальный” шурале, который бывает только в татарских лесах»[1]. Поэтому-то «Тукай очень любил образ шурале и... во многих случаях предпочитал литературный псевдоним «Шурале»[2].

Иное дело, что при создании того или иного произведения писателю, поэту некоторые произведения из литератур других народов могут служить не столько источником фактического материала, сколько образцом вообще. Это – естественное явление. Такие образцы были и у Тукая. Например, в примечании к поэме «Шурале» он писал: «Эту сказку «Шурале» я написал, пользуясь примером поэтов А. Пушкина и М. Лермонтова, обрабатывавших сюжеты народных сказок, рассказываемых народными сказителями в деревнях»[3]. Как видим, здесь не названа фамилия М. Федорова. А ведь Тукай, «будучи глубоко порядочным поэтом, при малейшем подражании, под заголовком каждого своего стихотворения указывал, кому именно он подражал»[4]. К тому же баллада М. Федорова «Арсюри», как признает сам Й. Бенцинг, была опубликована только в 1919 году[5].

Удивляет и то, что Й. Бенцинг, оказывается, еще толком и не знаком с указанным произведением М. Федорова. Он рассуждает только «согласно информации», которую он получил от чувашей, «согласно маленьким фрагментам», лежащим перед ним. Однако, несмотря на это, автор делает довольно смелые выводы. Он пишет: «Мы вряд ли можем отвергать предположение, что Тукай знал каким-то образом об “Арсюри” Федорова, который натолкнул его на мысль о шурале, и Тукай внес его в татарскую литературу, возможно, не сознавая сам того факта, что шурале чувашского происхождения».

Как видим, Й. Бенцинг приступил к такому ответственному делу, как исследование творчества Тукая, без достаточной осведомленности, и это привело его к неверным выводам. В его работе вообще не упоминаются труды татарских советских ученых. На использование именно этих трудов, как на один из важнейших условий в исследовании зарубежными авторами творчества Тукая и дру-

---

[1] Тукай Габдулла. Әсәрләр: 4 томда. Казан, 1976. Т. 2. Б. 297. (Далее указываются только тома и страницы данного издания).

[2] Халит Г. Указ. соч. С. 79.

[3] Тукай Габдулла. Т. I. С. 377.

[4] Хәким С. Тукай [Вводная статья] // Габдулла Тукай. Әсәрләр. 1975. Т. I. С. 12.

[5] Это неправильно. «Арсюри» первый раз увидел свет в книге «Сказки и предания чувашей» (на чувашском языке), изданной в 1908 году в Симбирске (Сироткин М. Указ. соч. С. 85). Поэма «Шурале» Тукая была написана летом 1907 года и в том же году издана.

гих видных писателей, обращается внимание в статье И. Надирова «Тукай на иностранных языках»[1]. При соблюдении Й. Бенцингом этого непременного условия мог бы быть более объективный подход к вопросу о мифологической основе поэмы «Шурале», а также и об истории ее создания.

Безусловно, поэма «Шурале» является яркой страницей в творческой биографии Тукая. Однако не менее интересны и остальные его сказки («Су анасы», «Сказка о козе и баране» и др.), которые также нуждаются в обстоятельном исследовании и с точки зрения их мифологических основ. Такой труд был бы нужным и важным вкладом в изучение связи поэзии Тукая с народным творчеством и оказал бы неоценимую помощь современным писателям, особенно молодым, работающим в области литературной сказки.

## Тукайның истәлекләрендә һәм юлъязмаларында фольклор

«Тукай һәм фольклор» темасына тикшеренүчеләрнең берничә буыны тарафыннан байтак хезмәтләр язылган. Аларның күбесендә Тукай иҗатының фольклор белән бәйләнеше һәм шагыйрьнең халык иҗатына карашы мәсьәләләре тулаем яктыртылганлыктан, табигый, беренче чиратта күзгә бәрелеп торган «эре фактлар» анализлана һәм бу хәл еш кына кабатлануларга да китерә. Шул ук вакытта Тукай мирасында фольклорчылар игътибарыннан читтәрәк калып килгән өлкәләр дә юк түгел. Шагыйрь үзе болай дип язган иде: «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле»[2].

Тукайның киләчәккә булган шушы ышанычын аның васыяте итеп аңлап, төрле өлкәдә эшләүче галимнәр беренче чиратта бөек шагыйребезнең үз иҗатын, кабат-кабат кайтып, җентекләп өйрәнергә тиешләрдер.

Без дә, бу эшкә азмы-күпме өлеш кертү максатыннан, Тукай мирасының зур булмаган бер өлкәсен (1909–1912 елларда язылган истәлекләрен һәм юлъязмаларын) алып, аны фольклорчы күзе белән карап чыгарга ниятледек. Ул әсәрләр ике истәлектән («Исемдә калганнар», 1909; «Мич башы кыйссасы», 1912) һәм өч юлъязмадан

---

[1] Надиров И. Тукай чит телләрдә // Казан утлары. 1966. № 10. С. 145–146.
[2] Тукай Габдулла. Әсәрләр: Биш томда. 4 т. Казан, 1985. 265 б.

(«Кечкенә сәяхәт», 1911; «Казанга кайтыш», 1912; «Мәкаләи махсуса», 1912) гыйбарәт[1]. Аларның нинди уңайдан язылулары турында биредә тукталып тормаска булдык.

Язучы иҗатының фольклор белән бәйләнешен күрсәтә торган билгеләр әсәрләрнең сюжетына, образларына, теленә һәм стиленә карыйлар. Бер очракта язучы фольклор әсәрен ничек бар шул хәлендә файдаланса, ягъни үз әсәренә әзер хәлдә кертеп җибәрсә, икенче очракта ул аны үзенә муафикъ рәвештә үзгәртеп кертә; өченче очракта фольклор әсәренең исемен, сюжетын, мотивын, персона-образын, берәр детален генә кулланырга мөмкин; дүртенче очракта язучы фольклор әсәренең бары идеясен генә ала, яисә аның фольклор белән бәйләнешен әсәрләрнең теленнән һәм стиленнән генә танып була; бишенче очракта язучы фольклор әсәрләре үрнәгендә һәм калыбында бөтенләй яңа берәмлек иҗат итә.

Тукайның истәлекләрендә һәм юлъязмаларында фольклор белән бәйләнешнең нинди билгеләре күренә соң?

Иң элек шуны әйтергә мөмкин: шагыйрьнең әлеге биш әсәрендә фольклорыбызның байтак жанрлары чагылыш тапкан.

Тукайның балачагы сурәтләнгән «Исемдә калганнар» дигән истәлеге белән танышканда, беренче булып, мәкальгә тап булабыз. Нәни Габдулла Кырлайда яшәгәндә Сәгъди абзыйның олы кызы вафат була. Кызының үлемен әнисе Габдулладан күрә: ««Менә, үксез бала асрасаң, авызы-борының кан итәр; үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул; мөгаен шуның шомлыгыннан булды инде бу!» – ди[2].

Шагыйрьнең без күздә тоткан әсәрләрендә мәкальләр берничә урында очрый.

Мәгълүм булганча, Тукай гомере буе авырудан интегә. Авыру аңа Петербургта да тыңгылык бирми. «Никадәр мөмкин була торып, Думага керә алмадым, – ди ул «Мәкаләи махсуса»да. – Финляндиягә чакырдылар, анда бара алмадым. Бер театрга, бер музейгә вә гомумән бер достопримечательный җиргә булсын җөреп булмады: әлеге хәстәлек!» Шушы зарына, ачынуына нәтиҗә рәвешендә ул бер мәкаль китерә: «Алла бүрегә бәхет бирсә, тешен сындырып бирә, имеш!»[3]

Шагыйрьне газаплаган нәрсәләр ятимлек һәм авырулар гына түгел, ул әле җитмәсә үзе яши торган номерда күселәрдән дә җәфа-

---

[1] Тукай Габдулла. Әсәрләр: Биш томда. 5 т. Казан, 1986. Б. 9–64. (Алга табан бу басманың том һәм бит саннары гына күрсәтеләчәк).

[2] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 61.

[3] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 61.

лана. Бу җан ияләрен куркытып, куып изалангач та файдасы булмагач, ул күсегә болай мөрәҗәгать итә: «Әй, карак! Беләм инде, син, бичара, ач үлмәс өчен мондый кыюлыклар илтизам итәсең (өстеңә аласың – *Л.Ж.*); соң әкренрәк ашасаң булмыймы инде? Мин синнән аш кызганмыйм, чөнки мин ашны син җитә алмаслык урынга яшерсәм, ачлык сине минем колагымны вә борынымны кимерү кыюлыгына да мәҗбүр итәчәк», – ди һәм өстәп куя; «Ләкин белә этәч синең хәрфе җәреңне! Ул һаман үз эшендә»[1].

«Әтәч синең хәрфе җәреңне каян белсен» дигән фразеологик әйтелмә (хәрфе җәр – исемнең ахырын «и» белән укырга тиешле итә торган бәйлек. – *Л.Ж.*) – мәзәкчәсен белмәгәннәргә аңлашылмый торган афоризм. Аның мәзәкчәсе төрле вариантларда йөри. Шулардан берсе Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» китабының 1 нче томында китерелә: «Бер авыл мулласы мәчет алдында картлар белән сөйләшеп утыра икән. Бер карт аңа сүз кушып:

– Бу этәчләр үз телләрендә нәрсә дип кычкыралар икән? – дип, сорау биргән.

Мулла аларга гыйлем күрсәтәсе килеп:

– Әтәчнең кычкыруы бушка түгел, алар: “Сөбханаллаһи би хәмдиһү...” дип кычкыралар, – дигән.

Шунда чит мәдрәсәдә укып кайткан бер шәкерт тә тыңлап тора икән. Ул мулланың гарәпчә җөмлә төзи алмавын күреп, урыныннан сикереп торып, аны фаш итмәкче булып әйткән:

– Әтәч ничек “би хәмдиһү” дип кычкырсын ди? “Би” дигәнең хәрфе җәр ич, хәрфе җәр соңындагы сүз «ү» белән бетми, һәрвакыт “и” белән бетә, шулай булгач, этәч “вә би хәмдиһи” дип кычкырырга тиеш, – дигән.

Мулла, надан булса да үткен кеше икән, агайлар алдында шәкерттән җиңелеп калмаган, әйткән:

– Һи ахмак, этәч синең кебек мәдрәсәдә укып ятканмы әллә? Хайван бит ул, синең хәрфе җәреңне каян белсен? – дигән.

Агайлар да:

– Әйе, әйе, анысына этәч үзе гаепле, – дип, муллага кул куйганнар.

Үз наданлыгыңны оста җавап белән башка нәрсәгә япсарып кала белүгә мисал йөзеннән әйтелә»[2].

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 44.

[2] Татар халык мәкальләре: Өч томда / Җыючысы һәм төзүчесе Нәкый Исәнбәт. 1 т. Казан, 1959. Б. 632–633.

Рашат Гайнанов сүзләре белән әйтсәк, «ул чорда бик актив кулланылган шушы афоризмны Тукай, күселәргә карата кулланып, аларга сүз белән аңлатып булмаганлыгын әйтә»[1].

Тукайның истәлекләрендә һәм юлъязмаларында халык мәкальләренә вә әйтемнәренә тәкълид ысулы белән иҗат ителгән берәмлекләрне дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, «Мич башы кыйссасы»нда шагыйрь, бизгәге кузгалып, җылы мич башында ятканда үзенең:

Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырләрдән килер миңа кирәк җылы, –

дигән шигъри юлларын исенә төшереп, кычкырып көлә дә: «Әйе, шигырь башка да, дөньяны әйләндерүче чыгыр башка», – дигән нәтиҗә ясый[2]. Бу соңгы җөмлә мәкаль булып яңгырый һәм үз чиратында «Пәри башка, җен башка» дигән мәгълүм мәкальне искә төшерә.

Шагыйрьнең: «Язам, язам – кая көлкесе; урман, урман – кая төлкесе»[3] («Мәкаләи махсуса»), «авылны күпме мактасаң да, аның калада торып өйрәнгән кешене разый итмәслек урыннары табыла икән»[4] («Казанга кайтыш»), – дигән җөмләләре исә, «Хикмәт кәҗәсендә түгел, мәэәгендә», «Авылны макта, калада тор» дигән мәкальләргә авыздаш.

Икенче бер урында («Казанга кайтыш») мәгълүм тәнкыйтьчегә җавап итеп, шул тәнкыйтьче үзе кулланган «Кул кисеп бәхәсләшү» әйтеменә сатирик тәкълид рәвешендә Тукай «Тырнак кисеп бәхәсләшү» гыйбарәсен иҗат итә[5]. Шунда ук әлеге тәнкыйтьчегә карата кулланылган «Алладан оялмый, бәндәдән кызармый» әйтемен дә шагыйрь үзе уйлап чыгарган булса кирәк, чөнки ул фразеологик сүзлектә «Алладан курыкмый, бәндәдән оялмый» шәкелендә теркәлгән[6].

«Күзләр беткәч, кояш булудан сиңа ни файда?»[7] дигән гыйбарәне дә («Мич башы кыйссасы») шагыйрь җиңел кулдан үзе иҗат иткәнгә охшый, ул зур гомумиләштерү сыйфатына ия түгел, чөнки биредә кояш бары яктылык чыганагы буларак кына телгә алына.

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 269.
[2] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 36.
[3] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 54.
[4] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 37.
[5] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 39.
[6] Исәнбәт Нәкый. Татар теленең фразеологик сүзлеге: Ике томда. 1 т. Казан, 1989. Б. 64.
[7] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 32.

Фольклор әсәрләре ничек бар шул килеш кулланылганда, шулай ук алар үрнәгендә яңа берәмлекләр иҗат ителгәндә язучының әсәрләрендә һәркайсы бик ачык күренеп тора. Әмма еш кына профессиональ әсәрдә фольклор «эрегән» хәлдә, катлаулы синтез тәшкил итеп, әйтергә кирәк, шәкеле яисә мәгънәсе җәһәтеннән үзгәргән хәлдә гәүдәләнә. Бу очракта инде андыйларны тану, табу өчен беркадәр көч куярга туры килә. Мәсәлән, «Мәкаләи махсуса»ның VIII бүлеге болай башлана: «Мин дә Петербургка бардым, дегет чиләге дә!»[1]. Тукай биредә үзен дегет чиләгенә тиңләштерә. Моны ничек аңларга? Мәгълүм булганча, ул, шагыйрь буларак, үзенең дәрәҗәсен бик яхшы белгән. «Җавап» дигән шигырендә: «Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай – өч йолдыз ул»[2], – дисә, Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында: «Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасына тора»[3], – ди. Ә биредә... дегет чиләге. Шәкли яктан бу гыйбарә әдәбият белемендә метонимия дип атала торган күренеш, ягъни предметны үз исеме белән түгел, бәлки аның белән ниндидер бер бәйләнештәге икенче нәрсә исеме белән атаудан гыйбарәт булган метафорик троп.

Шагыйрьнең үз-үзен дегет чиләгенә охшату серен фольклор аша гына ачыкларга мөмкин. Татар фольклорында «Арбага таккач, дегет чиләге дә хаҗга бара» дигән мәкаль бар. Тукай мәркәзгә рәсми вәкил булып түгел, гади бер кеше булып кына килә. Ягъни поездга утыргач, кем дә башкалага бара ала. «Дегет чиләге» дигән тәгъбир бу урында әнә шул мәгънәдә кулланылган.

Тукайның истәлек вә юлъязмаларында бәетләр дә очрый. Шагыйрь үзенең «Халык әдәбияты» дигән мәгълүм лекциясендә бәетләр турында болай дигән иде: «Чү, аз гына бернәрсә «шылт!» иттеме, инде аның тугърысында иртәгә урамга бәетләр чыга»[4].

Биредә сүз, әлбәттә, сатирик-юмористик бәетләр турында бара. Шагыйрь үзе дә шушы принципка тугъры булып калган, үзен борчыган нәрсәләр турында бәетләр язган.

Тукай гомере буена салкыннан интегә. Аның «Мич башы кыйссасы» дигән истәлеге болай башлана: «Мин быел 29 нчы сентябрьдән үк салкынлыктан зарлана башладым. Шуннан бирле икәнлеге язып ташлаган бер бәетемнең түбәндәге тарихтан беленде. Бәет шушы иде:

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 61.
[2] Тукай Габдулла. 1 т., Б. 233.
[3] Тукай Габдулла. 5 т., Б. 109.
[4] Тукай Габдулла. 4 т. Б. 175.

Номер салкын, якмыйлар бит, арка туңа,
Иртә берлән, киям дисәң, яка туңа;
Авыр да соң иртә белән тышка чыгу,
Чыкмый хәл юк, чыгасың шул ката-туңа.
Җәйләр үтте, җиттек инде октябрьгә,
Җылылык юк җирдә һәм күктә бер дә,
Сентябрьдә син дә бер, ди, мин дә бер, ди,
Миһманнарның якмаучыга үпкә бергә.
Хөкем итмим, Ходай кыйлыр үзе судын,
Кайгырмый бит, күтәргән дә ята ботын;
Акчам янга калыр, ди ул, якмый торсам,
Барыбер бит җәһәннәмгә үзе утын!

Туңучы

1911 сәнә, 29 октябрь»[1].

Күрәбез ки, хәтта бәетнең үз эчендә дә фольклорның башка жанрларына караган үрнәкләр күренеп китә. Мәкальгә тиң булган «Сентябрьдә син дә бер, ди, мин дә бер, мартта мин артта» дигән канатлы сүзнең баш өлеше биредә көзге муллыкка түгел, бәлки көзен (сентябрьдә) номерда яшәүче һәркем өчен салкынлыкның уртак бәлагә әверелүенә ишарә итә. Янә шушында ук номерлар хуҗасы – байга карата «бот күтәреп яту» (ягъни берни дә эшләмәү)[2] дигән фразеологик әйтелмә дә кулланыла.

«Казанга кайтыш» язмасында шагыйрь әлеге дә баягы күселәр турында сүз барганда үзенең «Гыйбрәт вә нәсыйхәт» дип исемләнгән бәетен китерә һәм бу юлъязма шуның белән тәмамлана да:

Номерың матур булса, күсе булгай,
Һәр матурда начар якның берсе булгай;
Ансы булып җитмәсә дә, монысы булгай, –
Андин җыртык, мондин җыртык туннарым бар.

Бер адәмнең чын дошманы күсе булгай,
Икенчесен җөдәтүче кеше булгай;
Һәркемнең үзенчә бер эше булгай, –
Андин сүтек, мондин җыртык туннарым бар[3].

«Казанга кайтыш»та бәет дип исемләнгән тагын өч әсәр бирелгән: берсе – ачлык турында, калган икесе мәдрәсә һәм мәктәп турында. Әмма боларында шагыйрь бәет димәктән ике юллы шигырьләрне күздә тоткан булуы аңлашыла. Чөнки аларның эчтәлеге һәм стиле

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 32.
[2] Исәнбәт Нәкый. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 1 т. Б. 190.
[3] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 46.

халык бәетенекенә охшамаган, ягъни бу очракта сатирик-юмористик түгел, яисә, шундый булган тәкъдирдә дә, сатирасы – «җитди» сатира. Соңрак алар, берсе нәкъ шулай «Бәет» дип, икенчесе «Авыл мәдрәсәсендә» дигән яңа исем белән, өченчесе исемсез генә басылып, шигырьләр рәтендә йөртелә башлыйлар[1].

Мәкаль һәм бәетләрдән соң сүзне әкияткә күчерик.

Истәлекләрендә һәм юлъязмаларында Тукайның халык әкиятләреннән яхшы хәбәрдар булуы аңлашыла. Ул берничә урында әкият элементларын уңышлы гына файдалана. «Казанга кайтыш» язмасында, мәсәлән, әлеге дә баягы күселәр турындагы бүлектә, шагыйрь үзенең яшәү урынын алыштырып, яңа номерда ике кич кунуын әйтә дә сүзен болай дәвам иттерә: «Өченче кичне, мин сиңа әйтим, язу эшләрем белән төнлә утырадыр идем, үземне хикәят китапларындагы «кергән кеше сәламәт чыкмый» торган пәриле җортта кеби тойдым. Әллә ниләр кытырдый. Дикъкать итсәм: күселәр! Ах, Алла дошманнары! Ах, бәндә дошманнары!»[2]

Шул ук язмада ачлыкны сурәтләгән урынга игътибар итик: «Быел авылда батканнар да, өшегән-катканнар да хисапсыз булды (ачлык, салкын, ялангачлык – өчесе берьюлы һөҗүм иткәч, адәм түгел, дию дә чыдамас)»[3]. Мәгълүм булганча, дию – әкият персонажы. Ул физик яктан гаять көчле итеп сурәтләнә. Инде авылга дию булып дию дә чыдамаслык бәла килгән икән, адәм баласының хәләхвәлен аңлау авыр түгел.

Дию образын шагыйрь «Мәкаләи махсуса»да да куллана. Петербургның Невский проспектында кешеләрнең транспортка тапталып һәлак булуы Тукайны бик тә куркыта, Ул болай яза: «Курыкмаска, ул урам – дию кеби. Һәркөн үзенә бер-ике корбан алмый калмый. Һәркөн тапталучыларны тикшерсәң, күбесе рабочий була. Чөнки алар да, минем кеби, андый «пәриле» урамнарда йөрергә өйрәнмәгәннәр»[4]. Биредә шагыйрь диюнең кеше ашау гадәтен күздә тота.

«Мәкаләи махсуса»да автор әкиятләрдәге Каф тавы топонимын да файдалана: «Теге, яз көне Иделнең күперен ватып, миллионнарча зарар иткән зур бозны Каф тавы артыннан Дәҗҗал мәлгунь безнең шәһәргә җибәргән имеш», – диелә анда. Шуның өстенә: «Боз әждәһа сурәтендә, ди. Казан городской галавасына хат язган, ди: «Күперне ваттырасың килмәсә, кызыңны бир!» – дигән, ди. Городской галава,

---

[1] Тукай Габдулла. 2 т. Б. 204, 203, 205.
[2] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 43.
[3] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 37.
[4] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 61.

дус-ишләре белән киңәшкәч, әждәһага (бозга) каршы мөселман итчеләреннән иң тазаларын сайлап, балта күтәртеп җибәрмәкче булган, ди»[1].

Язманың бу беренче кисәге сатирик-юмористик характерда, Күренә ки, Тукай күпер җимерелүдә шәһәр галавасын гаепли, аңардан көлә, янәсе аждаһага кызын биргән булса, мондый каза булмас та иде. Әкиятләрдә патша булып патша да аждаһага кызын бирә ич, дөресрәге, бирергә мәҗбүр була, Илне бәладән саклап калу өчен әнә шундый соңгы чарага да бара патша. Ә менә городской галава, янәсе, андый кыюлыкка сәләтле түгел.

Шагыйрь язмасының бу өлеше, өстәвенә стиль җәһәтеннән дә тылсымлы әкиятне хәтерләтә.

«Мәкаләи махсуса»ның шушы ук кисәгендә бирелгән үгез белән бозау диалогы[2] хайваннар турындагы әкиятләр тәэсирендә язылгандыр дип гоман кылырга мөмкинлек бирә.

Бу юлъязманың икенче кисәгендә дә халык әкияте йогынтысы ярылып ята. Тукай Самар шәһәрендәге «ишеге койма кадәрле зур, кыйбатлы пыяладан булган» «Бристоль» номерының мәһабәт бинасы янына килеп туктагач, үзен әкият дөньясында итеп хис итә. Бу кыйммәтле номерга керергә икеләнеп торуын шагыйрь мондый сүзләр белән белдерә: «Тик җүләр балык шикелле торам. Читтән караган кеше Саламторханның патша сарае янында торуын исенә төшергәндер»[3].

Дастан мотивын да табып була бу язмадан. Мәркәзгә барып төшкәч, шагыйрьне иртәге Петербургның тынычлыгы гаҗәпләндерә. Башкала сурәтләнгән VII бүлек болай башлана: «Иртә белән сәгать сигез. Менә сиңа Петербург. Николаевский вокзал. Кечкенә Бәдигыльҗамалны эзләп барган Сәйфелмөлекне укыганда, Сәйфелмөлек барган пәри шәһәре әллә нинди тып-тындыр, җеннәр үз шәһәрләрендә күренеп йөрсәләр дә, безгә күренмәгәндәге кеби, тавышсыз йөри торганнардыр һәм әллә нигә ул шәһәр томанлыдыр, караңгыдыр кеби тоела торган иде. Күккә, баскыч куп, фәрештәләрнең серләрен урларга менә торган җеннәрнең өйләре дә күз җитмәслек биек була торгандыр кеби сизелә иде.

Вокзалдан чыгып, извозчикка утыргач, миндә дә шул хәтирә яңарды. Шәһәрдә бер тавыш, шытырдау, дөбердәү юк; үзе карңгы, томанлы...»[4].

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 48.
[2] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 47.
[3] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 49.
[4] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 57.

Шагыйрьнең «Сәйфелмөлек» дигән дастанны исенә төшерүенә башкаланың әнә шундый тыныч һәм серле күренеше сәбәп була.

Г. Ибраһимов үзенең бер мәкаләсендә Тукайны, иҗат активлыгын киметте дип, тәнкыйть итә һәм Сәгыйть Рәмиев белән икесен сүнгән шәмгә тиңли. «Казанга кайтыш» язмасында Тукай аңа сарказм белән җавап бирә һәм «әлегә шигырь язмый торсам да, җырлаудан тартынмыйм» дип, халык җыры үрнәгендә шуңа пародия дип аталырдай бер строфа өсти:

> Җырласаң да, җегет, ачы җырла,
> Уяу җаткан кызлар җокласын;
> Тәрәзәләр ачтым, гөлләр сачтым,
> Асыл кошлар килеп чүпләсен[1].

«Мәкаләи махсуса»да да халык җыры элементларын табарга мөмкин. Шагыйрь Уфа шәһәре турында болай ди: «Уфаның халкы да айнык вә саф күренә. Чөнки бу шәһәрдә чат саен халык саулыгын химая итә (саклый. – *Л.Җ.*) торган сөт кибетләре. Һәммәсендә халык. Пивнойлар сирәк. Бу шәһәр – «ай-хай, Казанның каласы, аза ишан баласы» түгел»[2].

Шулай итеп, шагыйрь Уфа шәһәренә карата үзенең уңай фикерен халык җыры белән ныгытып куя.

Шушында ук ул «җырларымызда шулкадәр күп җырланган Агыйдел»не дә искә алып уза.

Тукайның «Казанга кайтыш» дигән юлъязмасында сөйләк жанрына карый торган хикәя белән дә очрашабыз. Тукай яшәгән заманда, илдәге ачлык сәбәбеннән, хәзерге кебек үк, караклар күбәеп китә. Шагыйрь авылда көз уздырганда, атна саен: «Чыпчык, Балавыз урманнарында фәлән кешене үтергәннәр, фәлән байны талаганнар» дигән хәбәрләр ишетелеп тора. Автор үзенең язмасында шундый хәбәрләрнең берсен болай бәян итә: «Әлләкеметдин бай Чыпчык урманы аркылы калага кайтып бара икән, каршыларына өч карак чыгып, ат башыннан тотканнар. «Малыңмы, җаныңмы?» – дигәннәр. Ләкин байның кучеры таза җегет булган... әллә кайсы авылда шактый «җибәргән» дә булган, ди. Менә шул кучер, повозкадагы нуктаны алып, каракларны уңлы-суллы яңакка кыйный башлаган. Караклар качканнар. Ләкин повозка кузгалып киткәч, байның артыннан әллә ничә иәртәбә «либарбир»дан атканнар. Ни булса булган, бай сау-сәламәт калага кайтып җиткән»[3].

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 39.
[2] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 54.
[3] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 37–38.

Телдән сөйләнә торган бу хикәя Тукайның юлъязмасына бик урынлы килеп кергән. Чөнки шагыйрь Казанга кайтырга җыена, аның әлеге куркыныч урман аша узасы бар. Ул болай ди: «Мин иртәгә иртүк шәһәргә чыгачак сәфәрем өчен күрше агаемыздан бер алтатар сорарга кичтән ният итеп яттым»[1]. Алга китеп шуны да әйтик, шагыйрь юлга, ни сәбәпледер, коралсыз чыга. «Шактый җир киттек, – ди ул. – Иптәш безнең алтатар алмаганны искә төшерде дә: “Хәер, чана төбенә бәйләгән күсәк бар әле!” – дип гыйлавә итте (өстәде. – *Л.Җ.*). Минем күз алдыма Чыпчык урманы һәм безнең күсәк чишеп алганны сабырлык белән көтүче пычаклы караклар килделәр»[2].

Әмма сүз ул турыда түгел, бәлки шагыйрьнең әле генә телгә алынган сөйләкне иҗтимагый-сәяси максатларында файдалануында. Хикмәт шунда: Тукай салкыннан җәфа чигеп яшәгән дәвердә, 1911–1913 елларда, Кавказда урыс гаскәрләре Сәлим хан җитәкчелегендәге тау халыкларына каршы сугыш алып баралар. Сәлим хан, бүгенге Дудаев кебек үк, урыс хөкүмәтенә буйсынырга теләмәгән, баштанаяк коралланган оккупантларны Дудаев кебек үк утлы табага бастырган. Күпме әзәрлекләсәләр дә, аны кулга төшерә алмый интегәләр икән. Тукай үзенең язмасында утлы коралы булган каракларны нукта белән «сыйлаган» кучер турында мәгълүм иткәннән соң, болай дип өсти: «Бу хикәяне ишеткәч, кучер минем күңелемдә бер Сәет-Баттал кеби булып калды. Кавказ тауларындагы “тотылмас” Залим ханны тотарга да шундый бер кучерны нукта күтәртеп җибәрү тиеш кеби күренде»[3].

Шагыйрьнең Сәлим ханны Залим хан тип атавын аңа тискәре мөнәсәбәтеннән дип аңларга кирәкми, бу каламбур авторның нечкә сатирасына бик ятышып тора. Бирердә Тукай юл уңаенда гына әйтелгән шушы бер җөмләсе белән бик күп халыкларны коллыкка дучар иткән самодержавиене сизелерлек чәнчеп уза.

Күренә ки, шагыйрьнең сүзе, идеалы бүген дә актуаль яңгырый. Безнең бүгенге проблемаларыбыз Тукай заманында да шул ук булган: империянең вәхшилеге, татарның фаҗигасе, мәдрәсәләрнең артталыгы, муллаларның наданлыгы һ.б., һ.б; хәтта Кавказ проблемасы да шул ук.

Тукай истәлекләрендә һәм юлъязмаларында татар фольклорының әле тагын башка жанрларына караган әсәрләрне яисә элементларны да очратырга мөмкин. Әйтик, иярмеш, миф, мәзәк һ.б.[4]

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 38.
[2] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 40.
[3] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 38.
[4] Кара: Тукай Габдулла. 5 т. Б. 19; 47; 48; 53.

Тукай юлъязмаларында татар фольклорыннан тыш, башка халыкларның фольклоры да чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Кечкенә сәяхәт»тә рус фольклорыннан бер куплет частушка китерелә. Аның сәбәбе болай. Әстерханга шагыйрь пароходның 3 нче классында бара. Әмма гапләшеп утырырга кеше булмаганга ул, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «...простой 4 нче класс халкы арасына чыга...». Юлъязма түбәндәгечә дәвам итә; «Әнә анда ике марҗа, бер шешә артыннан икенчесен бушатып, аракы эчеп утыралар; камыр кеби изелгәннәр, аракыдан тамаклары карылган, “Самокат”тагы Петрушка тавышы белән җырлыйлар... Шул арада мәҗлескә яланаяклы бер хулиган килеп утыра. Сорап та тормый, алып куйган аракыны алып каплый. Башына киткәч:

Милая Маруся,
Будешь ли моя?
Куплю пуд картошки,
Лопай, как свинья, –

дип, вәли нигъмәтләре (сыйлаучы. – *Л.Җ.*) исерек марҗага мәдхия җырлый. Халык шаркылдап көлә»[1].

Шулай итеп, шагыйрьнең бу документаль әсәренә урыс фольклоры туп-туры тормыштан килеп кергән.

Шул ук «Кечкенә сәяхәт»тә урыс даирәсендәге «дама бывает узкая, а баба – широкая» дигән юмористик канатлы сүз дә урын алган.

«Мәкаләи махсуса» юлъязмасында Тукай шулай ук урысчадан шигъри юлларга салынган канатлы сүз китерә:

Но иной находит счастье,
Чувство счастья потеряв[2].

Шушы язмада янә дә шагыйрь Самар шәһәрендә озаграк яшәргә теләвен бу шәһәрне яратуыннан түгел, ә Казанның юеш һавасыннан качып чыкканлыгына нисбәтән ике мәкаль китерә. Беренчесе гарәпнеке: «Ля лихөбби Галиин биллибогзый Могавия» («Галине яратудан түгел, бәлки Могавиягә дошманлыктан»), икенчесе төрек мәкале: «Бер көн шаһлык – шаһлыктыр»[3].

Тукай «Казанга кайтыш» дигән юлъязмасында шулай ук төрек фольклорыннан, батырлык символы буларак, «Кыйссаи Сәет-Баттал» дастаны герое Сәет-Баттал исемен телгә ала.

Җыеп әйткәндә, Тукай, олуг фикер иясе һәм чын халыкчан шагыйрь буларак, иҗатында фольклорга еш мөрәҗәгать иткән. Бу хәл

---

[1] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 29.
[2] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 61.
[3] Тукай Габдулла. 5 т. Б. 50.

шагыйрьнең әдәби әсәрләрендә генә түгел, бәлки истәлек һәм юлъязмаларында да ачык чагыла. Аларда автор татар фольклорының мәкаль, бәет, җыр, әкият, миф, сөйләк, иярмеш һ.б. жанрларына караган әсәрләрен үзгәрешсез хәлендә тулаем да, өлешчә дә, кирәк булганда үзгәртеп тә файдаланган. Башка халыкларның иҗат үрнәкләре дә аңа ят булмаган. Таланты ташып торган шагыйрь фольклор әсәрләренең шәклен яисә мәгънәсен саклап, үзе дә аерым берәмлекләр (мәкаль, бәет, җыр) иҗат иткән. Әсәрләрендә кулланган фольклор үрнәкләрен ул еш кына үзенең эстетик һәм иҗтимагый-сәяси максатларына да уңышлы хезмәт иттергән.

## Хәмит Ярми һәм халык әкиятләре

Республикабыз җәмәгатьчелеге танылган фольклорчы, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Хәмит Ярминең тууына 100 ел тулуны билгеләп үтте. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында галимнең истәлегенә багышлап фәнни конференция оештырылды.

Хәмит Ярми – Себердән Татарстанга килеп, фән өлкәсендә зур дәрәҗәләргә ирешкән һәм татар фольклорын өйрәнүдә тирән эз калдырган шәхес. Ул Төмән шәһәре янындагы Кырын Күл авылында 1904 елның 5 маенда Хөснетдин мулла гаиләсендә туа. Хезмәт юлын 1923 елдан башлый: Төмән губерна комитеты органы «Юксыллар чаткысы» газетасында техник сәркәтиб, татар китапханәсендә мөдир, җидееллык мәктәптә укытучы, халык мәгарифенең Төмән округы бүлегендә инструктор, янәдән мәктәп, аннары Төмән медтехникумында тел-әдәбият укыту... 1930–1934 елларда Х. Ярми Казан педагогия институтында белем ала һәм шунда ук аспирантурада кала. 1939 елның азагына кадәр әле ул «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә мәдәният бүлеге мөдире, Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркәтиб, Татарстан китап нәшриятында тәрҗемәче һәм мөхәррир булып эшләргә дә өлгерә.

1939 елның азагында Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты (хәзерге Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) оешкач, ул бирегә эшкә килеп, үзенең калган гомерен татар фольклористикасын үстерүгә багышлый. Х. Ярми – халык иҗаты бүлегенең (ул вакытта -сектор) беренче мөдире, татар фольклоры өлкәсендә беренче фән докторы. Бөек Ватан сугышы чорында берничә ел институтның ди-

ректоры булып та эшли. Бер үк вакытта ул байтак еллар буена Казан дәүләт университетында татар фольклорыннан лекцияләр укый, татар мәктәпләре өчен әдәбият дәреслекләренең фольклорга караган бүлекләрен яза. Хәмит ага 1981 елда вафат булды.

Мин беркадәр аның кул астында эшләгән һәм шул вакытлардан алып бүгенге көнгәчә халык әкиятләре өлкәсендә тикшеренүләр алып баручы кеше буларак, бу олпат галимнең нәкъ менә әкиятләр өлкәсендәге хезмәтләрен күрсәтеп үтәргә уйлыйм.

Тел һәм әдәбият институты оешып, татар фольклористикасын үстерү мөмкинлеге тугач, бу эшкә беренчеләрдән булып керешкән Хәмит Ярмигә, табигый ки, халык авыз иҗатының барлык жанрлары белән дә эш итәргә туры килә. Әйтик, ул 1948 һәм 1952 елларда язучы А. Шамов белән бергә халык җырларының зур булмаган ике җыентыгын бастырып чыгара. Шул ук 1952 елда Х. Ярми төзегән кечерәк кенә «Табышмаклар» дигән китап, янә дә узган гасырның 60–70 елларында мәкаль һәм әйтемнәрнең татар телендә бер, рус телендә ике җыентыгы дөнья күрә. Ә инде 1960 елда ул төзегән шактый калын «Бәетләр» китабы нәшер ителә.

Шулай да Хәмит аганың фольклорга мәхәббәте әкиятләр өлкәсендәге эшчәнлегендә көчлерәк чагыла иде шикелле.

Әле Тел һәм әдәбият институты ачылганчы ук, 1938 елда Х. Ярми һәм язучы А. Әхмәт «Халык иҗаты» дигән фольклор җыентыгы төзеп бастыралар. «Мәктәп сериясе»ндә чыккан бу китапта, заман таләпләренә ярашлы рәвештә юлбашчылар хакындагы материаллар урнаштырылып, ул шактый чуар төс алса да, «Әкиятләр» бүлеге уңышлы гына булып чыккан. Анда халкыбызның 24 әкияте урнаштырылган. Безнең классик әкиятебез «Ак бүре» дә беренче тапкыр шушы китапта дөнья күрә. Мәгълүм булганча, бу әкиятне Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында әсир төшкән татарлардан венгр галиме И. Кунош язып алган һәм үзенең бер китабында кушымта итеп биргән. Аны шул китаптан Г. Толымбай күчереп алган. Әкиятне Татарстанда беренче тапкыр бастырып чыгару исә Х. Ярмигә насыйп булган.

Бу җыентыкка язган «Сүз башы»нда Х. Ярми, фольклорның башка жанрлары белән беррәттән, әкиятләргә дә тукталып уза. Заман шаукымына иярүенә карамастан, автор «әкиятләрдәге патшаларны соңгы заманнардагы абсолют монархлар белән тиңләргә ярамый» дигән фикер дә әйтә.

1940 елда бу китапның тулыландырылган икенче басмасы да нәшер ителә. Мондый өлгерлеккә, күрәсең, татар әлифбасының латиннан кирилл хәрефләренә күчүе сәбәп булгандыр. Икенче

басманың күләме дә зур: беренчесе 168 битле булса, монысы – 270 биттән тора. Әкиятләрнең саны да утызлап.

Инде институтка эшкә күчкәч, Х. Ярми фольклор фонды булдыру эшенә башаягы белән чума. 1940 елның җәендә аның җитәкчелегендә Себер татарлары фольклорын җыйнау, аларның тел үзенчәлекләрен һәм көйләрен язып алу максаты белән экспедиция оештырыла (әгъзалары – С. Әмиров, В. Хаҗиев, М. Садри була). Бу экспедиция Төмән, Тубыл, Тара һәм Новосибирск өлкәләрендә яшәүче татарлардан бик күп фольклор материаллары, шул исәптән шактый гына әкиятләр дә алып кайта. 1940 елның көзендә исә Х. Ярми, Г. Бәширов һәм Ш. Маннур составындагы фольклор экспедициясе Татарстанның Бондюг һәм Красный Бор районнарында эшли.

Шул ук елда 7 кешедән торган авторлар коллективы белән татар халык иҗаты антологиясен төзү эше башлана. Әмма 1941 елгы Бөек Ватан сугышы барлык фәнни уйларны чәлпәрәмә китерә.

Шулай да, тормыш нинди генә авыр булмасын, Х. Ярми 1944 елда «Камыр батыр», «Аю белән бабай», «Кәҗә белән бүре» дигән әкиятләрне аерым-аерым китапчыклар рәвешендә бастырып чыгара. Ике генә төстән торган (яшел-кара, зәңгәр-кара, сары-кара) рәсемнәр белән бизәлеп, гади генә кәгазьдә 15 әр мең данәдә басылган әлеге китапчыклар сугыш чоры балаларына күпме шатлык китергәндер!

Сугыш тәмамлануга ук галим халык әкиятләре өлкәсендәге җитди хезмәтенә керешә. Ул, әкиятләр җыю һәм бастырып чыгаруда шактый тәҗрибә туплаган язучы Г. Бәширов белән берлектә, халык әкиятләренең ике томлык фәнни басмасын әзерли башлый, аның 35 әкияттән торган беренче китабы 1946 елда ук нәшер ителә. Ә ун елдан соң, аның икенче китабы дөнья күрә. Монысында 103 текст урнаштырылган, шуларның 20 дән артыгы – мәзәкләр. Китап Х. Якупов һәм Л. Фәттаховның төсле рәсемнәре белән бизәп чыгарылган. Шуннан соң бу басманың беренче китабын да шул ук бизәлештә кабат нәшер итәргә карар кылына. Ул 1958 елда дөнья күрә. Анда 48 әкият урнаштырыла. Нәтиҗәдә 150 ләп әкият һәм мәзәкләр тупланган, 2 табак күләмендәге кереш мәкалә һәм тәфсилле искәрмәләр белән тәэмин ителгән абруйлы фәнни басма барлыкка килә. Ул озак вакытлар тикшеренүчеләр өчен фактик материал тупланган кыйммәтле һәм дәрәҗәле чыганак булып хезмәт итте.

Бай һәм сыйфатлы материал исә Х. Ярми җитәкчелегендә ел саен берәр ай дәвамында халык арасында эшли торган фольклор экспедицияләре тырышлыгы нәтиҗәсендә туплана. Андый экспедицияләр Татарстанның барлык районнарына, ә соңрак татар

халкы тупланып яши торган башка республика һәм өлкәләргә дә оештырыла.

Татар фольклористикасы өлкәсендә бурычлар шактый күп булып чыга – галим әле тагын әллә ничә юнәлештә эш алып бара. Әйтик, 1951 елда сугышка кадәр үк планлаштырылган бер зур хезмәт пәйда була – Х. Ярми редакциясендә дүрт автор (Г. Бәширов, А. Шамов, Х. Ярми һәм Х. Госман) тарафыннан төзелгән «Татар халык иҗаты» антологиясе басылып чыга (икенче басмасы – 1954). Анда соңгы зур бүлекне халык әкиятләре тәшкил итә. «Татар халык иҗаты» дип аталган зур күләмле кереш мәкаләне, әлбәттә инде, Х. Ярми яза. Өч табак күләмендәге бу мәкаләнең бер өлеше әкиятләргә багышланган. Анда бу жанрдагы әсәрләр өчен хас булган күп вариантлылык, әкиятләрнең төрләре, бу төрләрнең хосусиятләре, геройлары, әкиятләрнең тәрбияви әһәмияте, төрле халыкларның әкиятләрендәге уртак сюжетлар... турында сөйләнә.

Хәмит ага нинди генә җитди проблемалар белән шөгыльләнмәсен, балаларны да онытмый. Бигрәк тә әкиятләрнең балалар күңеленә хуш килүен аңлап, алар өчен ул сугыштан соңгы 1947 елда, 22 язмадан торган рәсемле «Әкиятләр» дигән китап чыгара, ә 1950 елда, Г. Бәширов белән берлектә, балалар өчен шул ук күләмдәге «Татар халык әкиятләре» дигән җыентык бастыра.

Инде Х. Ярминең татар әкиятләрен башка милләт халыкларына җиткерү буенча башкарган эшенә күз салыйк. Бу бурыч беренче чиратта әкиятләрне рус теленә күчерүне таләп итә. Рус теленнән исә башка телләргә тәрҗемә итү мөмкинлеге зуррак, ягъни бу гамәл татар әкиятләренең дөньяга таралуы өчен юл башы булып тора. Галим әлеге мәсьәләдә дә иң элек балаларны кайгырта. Бәлки бу алым аның «хәйләкәрлеге» дә булгандыр. Чөнки ул рус телендә зур мәйданга татар әкиятләренең ике томлык фәнни басмасын да тәкъдим итә алган булыр иде. Әмма бу очракта, башка халыкларның фольклорчылары үзләренең хезмәтләрендә татар материалын рус телендәге басма аша уңышлы файдалансалар да, әкиятләрнең үзләре әлеге халыкларның киң катлавына барып ирешмәс иде. Ә балаларга адресланып, рус телендә чыккан китапны башка милләт балалары өчен дә тәрҗемә итү ихтималы бар. Галим нәкъ менә шушы юлны хуп күрә. Ул Г. Бәширов белән бергә 20 дән артык әкиятне сайлап алып, «Гөлчәчәк» исемле җыентык төзи. Аны рус теленә Алма-Аты шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Гайшә Шәрипова тәрҗемә итә һәм җыентык 1952 елда Мәскәүнең «Детгиз» нәшриятында 100 мең данәле тираж белән басыла. 1967 елда ул кабат Мәскәүнең «Малыш» нәшриятында нәшер ителә. «Гульчечек» исемле бу китап 1956 елда

Казанда да 50 меңданәдә дөнья күрә. 1954–1961 елларда әлеге китап әрмән, кытай, казакъ, украин һәм төрекмән телләрендә дә басыла.

Шуннан соң Хәмит ага, бу китап материалына халык әкиятләренең М. Булатов тәрҗемәсендәге дистә ярымлап текстын өстәп, 1957 елда Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында һәм Казанда «Таткнигоиздат»та «Татарские народные сказки» дигән җыентык чыгара. «Детская литература» нәшрияты аны 1964 һәм 1976 елларда 100 мең һәм 150 мең данәле тиражлар белән (беренчесендә «Находчивый джигит» дигән исемдә) кабат бастыра. Бу җыентыкның да язмышы бәхетле була: ул 1966–1989 еллар арасында литва, молдова, словен, үзбәк, монгол, болгар телләрендә дөнья күрә.

Татар әкиятләренең Х. Ярми әзерләгән рус телендәге иң тулы басмасы – 45 тексттан гыйбарәт «Татарские народные сказки» җыентыгы 150 мең данәле тираж белән галим үзе исән вакытта 1970 елда Казанда нәшер ителде, ә вафатыннан соң, аз гына өстәмә белән, шул ук җыентык «Сказки детям» дигән исемдә 1999 елда «Раннур» нәшриятында дөнья күрде.

Х. Ярми әкиятләр өлкәсендәге эшчәнлеген гомеренең соңгы елларында да туктатмады. Татар халык иҗатының 12 томлык фәнни җыелмасындагы әкият томнарының I һәм II китапларын Х. Гатина белән берлектә ул эшләде. Бу китапларда хайваннар турындагы һәм тылсымлы әкиятләрдән 160 тан артык текст урнаштырылган. Әлеге томнар текстология, төзелеш принциплары һәм фәнни аппараты җәһәтеннән бүгенге фән таләпләренә җавап бирерлек итеп, югары кимәлдә башкарылган. Шушы хезмәтләре өчен Х. Ярми, әлеге җыелманы эшләгән башка авторлар белән бергә, 1989 елда (үлгәннән соң) Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты дәрәҗәсенә лаек булды.

Шулай итеп, Х. Ярми татар халык әкиятләрен җыю, бастырып чыгару һәм фәнни өйрәнү өлкәсендә рус, татар һәм чит ил галимнәре вә мәгърифәтчеләре М. Иванов, В. Радлов, Г. Балинт, К. Насыйри, Т. Яхин, Һ. Паасонен, Х. Бәдигый, А. Бессонов, И. Кунош, Г. Толымбай һәм башкаларның игелекле эшен дәвам иттереп, аны яңа баскычка күтәрде. Халык теленнән язып алынган меңнәрчә әкият текстлары бер урынга тупланды, шуларның иң яхшы үрнәкләре күп мәртәбәләр басылып чыкты, ягъни халыкка кире кайтарылды, әкиятләрне фәнни өйрәнүгә ышанычлы нигез салынды. Татар әкиятләре белән башка халыкларны таныштыру юнәлешендә дә шактый эш башкарылды.

Бүгенге көндә исә Х. Ярминең үзе исән вакытта эшләргә өлгермәгән тагын бер хыялы аның дәвамчылары тарафыннан тормышка

ашырыла: татар халык әкиятләренең рус телендәге фәнни басмасы нәшер ителә. Бу басманың I һәм II томнары инде халыкка барып җитте, тиздән III томы да дөнья күрәчәк.

### Яшәгән, ди, булган, ди

Атаклы язучыбыз Г. Бәшировның фольклорга бәйле эшчәнлеге 1939 елда башлана. Нәкъ менә шул елда ул А. Шамов белән берлектә «Халык җырлары» исемендә 295 биттән торган җыентык чыгара. Бу китаптан тыш, матбугатта аның тагын берничә хезмәте пәйда була. Мәсәлән, «Кызыл Татарстан» гәзитендә (1939, 30 июнь) Г. Разин имзасы белән «Халык әкиятләре һәм әкиятчеләре» дигән мәкалә бастыра, шунда ук иллюстратив материал сыйфатында «Закир бәете» һәм «Мужик белән алпавыт» дигән әкият текстларын китерә. Шул ук елны «Совет әдәбияты» журналының 12 нче санында аның тарафыннан язып алган янә бер әкият дөньяга чыга. Болар – язучының ел башында ук Казан арты районнарына чыгып фольклор материаллары туплау белән бәйле гамәлләр.

Бу чор М. Горькийның күпмиллэтле совет язучыларына мөрәҗәгать итеп: «Сүз сәнгатенең башы – фольклорда. Үзегезнең фольклорыгызны җыегыз, аңардан өйрәнегез», – дигән чакыруыннан соң илдә фольклор җыю буенча башланган игелекле хәрәкәт белән характерлы. Әмма чакыруга кушылыр өчен кешенең күңелендә шушы юнәлештәге омтылыш булырга тиеш. Г. Бәшировта ул булган, күрәсең. Мәдрәсәдә укыган дәвердә үк 12–13 яшьлек шәкерт, әле фольклорның ни икәнен дә белмәгән чагында, дәфтәренә «Сөембикә бәете»н күчереп алган һәм шуны гомере буе саклаган. Димәк, аңарда бу эшкә һәвәслек яшьтән үк борынлаган. Шулай булгач, хәзер ул әлеге авыр, мәшәкатьле шөгыльгә дә күңеле кушуы буенча алынган.

Г. Бәширов алга табан халык иҗаты әсәрләрен җыю эшен киң колач белән дәвам иттерә, әмма төп игътибарын нигездә ике жанрга юнәлтә, алар – язып алу һәм эшкәртү өчен иң авыр булган әкиятләр һәм мәзәкләр. Мәзәкләр белән шөгыльләнүен әдип әле дә туктатканы юк, бүгенгә чаклы ул халык мәзәкләрен туплап дистәгә якын китап бастырды. Әмма биредә без аның әкиятләр белән бәйле эшчәнлегенә генә тукталырбыз.

Г. Бәширов халык әкиятләре өлкәсендәге эшчәнлеген дүрт юнәлештә алып бара.

Беренче юнәлеш – экспедицияләр. Инде искә алганыбызча ул 1939 елда фольклор әсәрләре туплау максаты белән Казан арты районнарына чыга. Шушы вакытта аңа Теләче районының Кибәче

авылында Федор Блинов 2, Александр Варварин 4, Савырыш авылында Сөнгать Сибаев 6 әкият сөйли. Ә шул ук районның Максабаш авылында яшәүче Минһаҗ Хәмидуллин исә берүзе 20(!) әкият сөйләгән. Алга китеп шуны да әйтик: соңыннан шул әкиятләрнең 19 ы басылып чыккан. Алар арасында «Турай батыр», «Дубан батыр», «Тире Такыя», «Тапкыр кыз» һәм «Хәйләкәр мылтыкчы» кебек классик әсәрләр бар.

Саба районының Мамалай авылында яшәүче 64 яшьлек Мөхәммәтша Дәүләтшин да бик оста әкиятче булып чыга. Ул сөйләгән 9 әкият арасында «Аучы», «Алтын алма», «Алтын балдак», «Алтынчәч» кебек мәшһүр әкиятләр бар.

1940 елда Г. Бәширов Әгерҗе, Красный Бор (хәзер Әгерҗе районына керә) һәм Бондюг (хәзерге Менделеев0 районнарында була. Бу сәяхәте вакытында Бондюг районының Турай авылында яшәүче 27 яшьлек Хаҗи Бәхтегәрәев «Күренмәс чикмән», «Алтын канатлы кош» дигән әкиятләрне сөйләгән.

Сугыштан соң Гомәр ага үзенең яраткан шөгылен дәвам иттерә.

1945 елда ул Буа һәм Буденный (аның авыллары хәзер Буа һәм Чүпрәле районнарына карый), 1946 елда Чаллы, 1949 елда Минзәлә районнарына күренекле фольклорчы Х. Ярми белән бергә чыга. Буденный районының Иске Тинчәле авылында яшәүче 41 яшлек Барый Галиевтән «Кулсыз кыз» дигән маҗаралы озын әкиятне алар бер-берсен алыштырып, икәү язып алалар. «Тылсымлы чыбык», «Унөч» дигән мәгълүм әкиятләрне Гомәр агага Минзәлә районының Тауасты Байлар авылында Шәмсемөхәммәт Шәрипов сөйләгән.

Югарыда искә алынган 5 экспедиция чорында Г. Бәширов 22 информанттан 85 әкият язып ала.

«30–40 нчы елларда татар халык әкиятләренә тиешле игътибарны юнәлдерүче һәм аларны халык телендә, халык күңелендә сакланганча язып алуны беренче булып башлап җибәрүче Гомәр Бәширов (Г. Разин) булды», – дип язды соңрак филология фәннәре докторы Х. Ярми.

Икенче юнәлеш – әкият җыентыкларын бастырып чыгару.

Г. Бәширов Теләче һәм Саба районнарында җыелган әкиятләрне бергә туплап, 1940 елда Гомәр Разин имзасы белән «Халык әкиятләре» дигән 168 битлек китап чыгара. Анда М. Хәмидуллин, М. Дәүләтшин, А. Варварин, Ф. Блинов һәм С. Сибаевтан язып алынган 38 әсәр урын алган. Бу китапның татар әдәбияты һәм фольклористикасы тарихында бик әһәмиятле урыны бар. Иң элек төзүче-авторның гаять өлгерлеге күзгә ташлана: 1939 елда халык арасында йөреп җыелган материал 1940 елда инде махсус китап булып чыга.

Мондый оперативлыкка сокланырга гына кала. Әмма иң мөһиме шул: бу китап – совет чорында, әкиятләрдән генә төзелеп, татар телендә нәшер ителгән беренче җыентык. Биредәге әкиятләр барысы да беренче мәртәбә басылган оригиналь әсәрләр; алар турыдан-туры халык авызыннан язып алынганнар; алар, теле үзгәртелмичә, ничек сөйләнсә, нәкъ шулай басылганнар (ә моның әһәмияте тел белгечләре өчен генә түгел, фольклорчылар өчен дә мөһим); җыентыкта һәр әсәрнең паспорты бирелгән, ягъни аларның кайда, кайчан, кемнән һәм кем тарафыннан язып алынганлыгы күрсәтелгән; алай гына да түгел, җыентык үзе әкиятчеләр буенча төзелгән, һәр әкиятченең күңел хәзинәсе бер урында туплап бирелгәнлектән, репертуар үзенчәлекләре дә ап-ачык күренеп тора; шуның өстенә, җыентык әкиятләр һәм әкиятчеләр турында шактый тәфсилле язылган кереш мәкалә («Сүз башы») белән ачыла. Димәк, бу җыентык татар телендә әкият жанрына караган беренче фәнни китап булып та тора.

Шуннан соңгы дәвердә Татарстанда әкият китапларын чыгару Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән бәйле. 1946 елда Г. Бәширов һәм Х. Ярми «Татар халык әкиятләре»нең беренче китабын төзеп бастыралар. Ә 1956 елда әкиятләрнең икенче китабы нәшер ителә. Ул Х. Якупов һәм Л. Фәттахов рәсемнәре белән бизәлеп чыга. Инде беренче китапны да шушы ук сыйфат дәрәҗәсендә яңадан чыгару ихтыяҗы туа, һәм аның тулыландырылган яңа басмасы 1958 елда дөнья күрә.

12 томлык «Татар халык иҗаты» исемле фәнни җыелманың әкиятләрдән төзелгән өч китабы өчен Г. Бәшировның фольклор фондында саклана торган кулъязмаларыннан янә дә 10 текст сайлап алынды.

Шулай итеп, әдип тарафыннан халыктан язып алынган 85 әкиятнең 52 се төрле җыентыкларда басылып чыга. Шуларның 29 ы әлеге 12 томлыкта да урын алды.

Г. Бәширов бер үк вакытта «Татар халык иҗаты» исемле антология характерындагы фольклор җыентыгын әзерләүдә дә катнаша. Бу хезмәт 1951 елда басыла (II басмасы – 1954).

Язучының әкият китаплары нәшер итүгә бәйле эшчәнлеге фәнни басмалар белән генә чикләнми. Ул укучыларның киң катлавына, беренче чиратта мәктәп балаларына, исәпләнгән китаплар да бастыра. Әле 1944 елда ук, авыр сугыш чоры булуга кармастан, аның үзе язып алган «Аю белән бабай», «Камыр батыр» дигән әкиятләре ике төстән торган рәсемнәр белән бизәлеп, аерым китапчыклар итеп чыгарыла. («Камыр батыр» күренекле рәссамыбыз Т. Хаҗиәхмәтов бизәлешендә 1988 елда кабат аерым китап булып дөнья күрде).

Сугыштан соң Г. Бәширов һәм Х. Ярми бергәләп балалар өчен әкиятләрдән торган ике җыентык әзерлиләр. Шулардан беренчесе –22 текстны берләштереп, «Татар халык әкиятләре» дип исемләнгәне – 1950 елда дөнья күрә. Икенче җыентык рус телендә 1952 елда «Гульчечек» исеме белән Мәскәүдә басыла. 23 текстган торган һәм Х. Ярминең сүз башы белән чыккан бу китап соңрак ике тапкыр Казанда да басыла (1953, 1956). «Гөлчәчәк»нең язмышы бик бәхетле була: бу китап күп телләргә – элеккеге СССР халыклары һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителә (әрмән, казакъ, украин, төрекмән, азәрбәйҗан, литва, молдаван, үзбәк, кытай һ.б.). Шулай итеп, «Гөлчәчәк» дигән китап аша җир шарының төрле почмакларында яшәүче бик күп халыкларның балалары беренче тапкыр Татарстан турында белделәр һәм татар дигән халыкның тылсымлы рухи хәзинәсе белән таныштылар.

Соңрак Х. Ярми тарафыннан төзелеп Казанда һәм Мәскәүдә рус телендә басылган ике җыентыкка («Находчивый джигит», 1964; «Татарские народные сказки», 1976) Гомәр ага сүз башы яза.

Өченче юнәлеш – мөхәррирлек эшчәнлеге. Татартан китап нәшриятында эшләгән дәвердә Г. Бәширов балалар өчен әкият китаплары чыгаруга зур әһәмитят бирә. 1947 елда ул халкыбызның «Ак бүре» һәм «Гөлчәчәк» дигән классик әкиятләрен ике төстәге (кара–зәңгәр, кара–сары) рәсемнәр белән һәркайсын аерым китап итеп бастыра. Ул Х. Ярми тарафыннан төзелеп шул ук 1947 елда нәшер ителгән «Әкиятләр» җыентыгының һ.б. фольклор китапларының да мөхәррире була.

Дүртенче юнәлеш – әкиятләрне өйрәнү. Инде алда әйткәнебезчә, Г. Бәширов «Халык әкиятләре» җыентыгына әкиятләр һәм әкиятчеләр турында кереш мәкалә язган иде. Анда әкиятләрнең жанр үзенчәлекләре, оптимистик табигате, эстетик һәм педагогик кыйммәте хакында сүз алып барыла, әкиятчеләргә характеристика бирелә. Әдип соңрак әкиятләр өлкәсендә киңрәк, тирәнрәк уйланып, өстәмә күзәтүләр ясый, аерым алганда, әкиятләрнең тууы, камилләшә баруы һәм киң таралуы, бу процесста оста әкиятчеләрнең роле турында, әкиятләрне телдән язып алу тәртибе, шушы эштә принцип һәм кагыйдәләрне катгый саклау кирәклеге һ.б. турында теоретик фикерләрен бәян итә. Нәтиҗәдә, аның «Халык әкиятләре», «Тылсымнар дөньясында» дигән мавыгып укыла торган мәкаләләре пәйда була.

Кыскасы, татар халык әкиятләрен җыюда, бастырып чыгаруда һәм аларны фәнни өйрәнүдә Г. Бәшировның ихтирамга лаек урыны бар, һәм бу мөхтәрәм затның шушы өлкәдәге олуг хезмәтен

күпсанлы китап укучылар да, фольклорчы галимнәр дә ихлас күңелдән тәкъдир итәләр.

## Әкиятләрнең кайбер поэтик үзенчәлекләре

Төрле халыкларның әкиятләрен күзәткәндә, алардагы сюжет һәм мотивларның бер-берсенә охшашлыгы игътибарны җәлеп итә. Академик А.Н. Веселовский күрсәткәнчә, кешелек үсешенең беренче чорларында көнкүреш яки психологик шартларның охшашлыгы, бердәйлеге нәтиҗәсендә күп кенә охшаш мотив һәм сюжетлар мөстәкыйль рәвештә барлыкка килә алган[1]. Шуңа күрә хәтта географик яктан бер-берсеннән бик ерак торган халыкларның әкиятләрендә дә охшаш урыннар очрый. Болар – типологик характердагы уртаклыклар. Халыкара сюжетлар нигездә шул юл белән барлыкка килгән. Мәсәлән, «Камыр батыр», «Үги кыз» һ.б. бик күп әкиятләрнең сюжеты әнә шундыйлардан.

Типологик охшашлыклардан тыш, тарихи-генетик бәйләнешләр белән аңлатыла торган бердәйлекләр дә шактый зур урын тота. Мәсәлән, аждаһа һәм дию персонажлары төрки халыкларның барысында да диярлек бар. (Гәрчә бу образлар элек типологик характерда булса да, әлеге халыкларның тарихи үсеше дәверендә аларның генетик характердагы эволюция кичергән булуы шөбһәсез).

Ләкин әкиятләрдә уртаклык никадәр зур булмасын, аларда теге яки бу халыкның үзенә генә хас үзенчәлекләре дә чагылмый калмый. Мондый үзенчәлекләр күбесенчә геройларның характерында, сөйләмендә, табигать күренешләрендә, көнкүреш детальләрендә ачык күренә. Ниһаять, милли үзенчәлекне аерым мотив һәм сюжетлар да тәшкил итә.

Болардан тыш географик кыса белән чикләнгән һәм шул кыса эчендә яшәүче халыклар иҗаты өчен генә хас региональ үзенчәлекләрнең булуы да мәгълүм. Мәсәлән, «Мөлтәл» әкиятенең сюжеты Урта Идел буе һәм Урал халыклары иҗатында гына очрый. Берничә сюжетның яки алардагы аерым мотивларның бергә үрелеп яңа рәвешкә керүе (контаминация) нәтиҗәсендә еш кына әкиятләрнең төрдәшләре (вариантлары) барлыкка килә. Бу очракта әкиятнең герое шул ук кала, бары тик герой катнаша торган эпизодлар гына арта. Мисал итеп «Камыр батыр» әкиятенең төрдәшләрен күрсәтергә мөмкин.

[1] Веселовский А.Н. Историческая поэтика. Л.: Худож. лит., 1940. С. 500.

Барлык төр әкиятләргә, кагыйдә буларак, башлам һәм бетем хас. Хайваннар турындагы һәм көнкүреш әкиятләренең башламы, гадәттә, бик кыска була: «Борын заманда», «Бервакытны», «Көннәрдән бер көнне» һ.б.ш. Тылсымлы әкиятләрдә исә башламнар шактый үзенчәлекле. Мәсәлән, «Камыр батыр» әкиятенең бер төрдәше болай башлана: «Борын-борын заманда, кәҗә команда, әби-бабай тумас борын, әти белән икәү генә торган чагында, бар иде бер карт белән карчык»[1]. Мондый башлам әкиятнең уйдырмага корылуына ишарә итә. Бер үк вакытта ул тыңлаучыларның игътибарын җәлеп итүгә дә исәпләнгән.

Үзенчәлекле бетемнәр дә нигездә тылсымлы әкиятләрдә очрый. Бетем ул сюжетны тәмамлап куя. Гадәти бетемнәр «яхшы гына гомер итәләр», «һәркем үз юлына китте, шуның белән әкият тә бетте» кебек тәгъбирләрдән гыйбарәт. Ләкин тылсымлы әкиятләрдә такмаза характерындагы бетемнәр дә күп кулланыла. Мондый бетемнең вазифасы – тыңлаучыларны әкият дөньясыннан реаль дөньяга кайтару һәм аларнын күңелен күтәреп, көлдереп алу. «Туйларында мин дә булдым, аш-суның чиге юк, бәлешләренең төбе юк, мичкә-мичкә бал куйганнар, үзләре чүмеч белән чумыралар, миңа сабы белән генә эләкте»[2] («Камыр батыр») кебек бетемнәрнең максаты шуннан гыйбарәт. Мондый бизәкләр кайчандыр безнең халыкта да профессиональ әкиятчеләрнең булганлыгына ишарә итә.

Әкиятләргә хас интернациональ сыйфатларның берсе – вакыйганың күп мәртәбә (гадәттә өч мәртәбә) кабатлануы. Мәсәлән, тылсымлы әкият герое иң элек алты башлы аждаһаны үтерсә, икенче мәртәбә – тугыз, ә өченчесендә – унике башлысын үтерә. «Ак бүре» әкиятендә герой дию белән сугышу өчен билгеләнгән биш йөз пот авырлыктагы шарны өченче тапкыр тотынгач кына күтәрә башлый. Вакыйгаларның әнә шулай эффекты арта бару юнәлешендә кабатлануы беренче чиратта образны героиклаштыру максатына хезмәт итә.

Хайваннар турындагы әкиятләргә бигрәк тә диалог формасындагы сөйләм хас. Бу алым әсәрне аеруча җанлы һәм мавыктыргыч итә.

Диалог формасы геройларның реаль тормышын, алар яши торган табигый мохитне ныграк тоярга, ачыграк күзалларга ярдәм итә. Әкиятләрдә хайваннар тавышына охшатылган аваз ияртемнәре дә шул ук максатларда файдаланыла.

---

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр (беренче китап) / Томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 305. Алга табан: Әкиятләр (беренче китап).

[2] Шунда ук. Б. 307.

Көнкүреш экиятләрендә (бигрәк тә сатирик һәм юмористик экиятләрдә) комик ситуацияләр зур урын алып тора.

Комик ситуация сүзнең (тәгъбирнең) күп мәгънәлелегеннән файдалану нәтиҗәсендә дә барлыкка килә. «Тапкыр кыз»[1] экиятендә шәһәр бае авыл картыннан: «Тулаем сатам», – дип өч мәртәбә әйттереп, утын белән бергә аның үгезен дә, арбасын да алып кала. Бабайның кызы исә әлеге байдан: «Кулым белән бирдем» – дип өч мәртәбә әйттереп, кулын кисеп алырга хокук ала. Бай, әлбәттә, кистерергә теләми һәм кулы бәрабәренә өстәмә рәвештә мең тәңкә акча түләргә мәҗбүр була.

Әкиятләрнең теле гади һәм образлы. Образлылыкка төрле троплар ярдәмендә ирешелә. Тылсымлы экиятләрдә, мәсәлән, чагыштырулар, эпитетлар шактый еш очрый.

Әкият героена бәйле рәвештә эпитет, беренчедән, күп очракта геройның гаиләдә бердәнбер угыл булуын мәгълүм итә. Моңардан тыш герой кече угыл, төпчек угыл булырга мөмкин.

Геройның (персонажның) яшенә карата кулланылган эпитетлардан тагын түбәндәгеләрне күрсәтергә була: өлкән (угыл, абыстай, абзый), уртанчы (угыл, ага), олы (абзый, ага), яшь (егет) һ.б.

Эпитет шулай ук персонажларның йөз-кыяфәтләрен мәгълүм итә: матур егет, чибәр кыз, матур кыз, сукыр карчык, кәрлә карт һ.б.

Геройларны сурәтләгәндә артыклык дәрәҗәсендә эпитетлар да еш кулланыла. Мәсәлән, шундыйлардан «Ак бүре» экиятендә кулланылганнарын гына күрсәтеп узыйк: бик матур егет; иң өлкән абзый; иң кечкенә эне; бик яхшы ат; бик әйбәт алан; бик зур ерткыч хайван; бик биек тау-таш аралары; бик зур ком тавы, бик зур алтын сарай; бик сылу, матур, кызыл битле, кара кашлы бер кыз.

Күренә ки, гади эпитетлар белән беррәттән, катлаулы эпитетлар да очрый.

Эпитет экият героеның дөньяга килүе гайре табигый булуын да күрсәтә: Аю улы Атыләхмәтгәрәй, Камыр батыр.

Эпитет геройның гаилә хәленә аныклык кертә, геройның әтиэнисе булмаса, эпитет шуны белдерә: ятим бала, үги кыз.

Эпитет ярдәмендә персонажның социаль хәле дә ачыклана: ярлы егет, асрау кыз һ.б.

---

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр (өченче китап) / Томны төзүче, кереш мәкаләне язучы, искәрмәләр әзерләүче Л.Ш. Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. С. 189. Алга табан: Әкиятләр (өченче китап).

Эпитет геройның һөнәрен һәм шөгылен мәгълүм итә: көтүче Зариф, күрәзә карчык, сихерче карчык, сәяхәтче кыз һ.б.

Эпитет геройның холык – фигылен дә күрсәтә: батыр егет, зирәк солдат, акыллы кыз, мәнсез карт, хәйләкәр адәм, алдакчы Тимер, юләр угыл һ.б.

Эпитет әкиятләрдәге хайван персонажларның тышкы кыяфәтен һәм холкын да белдерә: Алтын кош, Ак елан, кызыл Әтәч, җүләр Бүре, шәрә Бүре, кодрәтле Әтәч, хәйләкәр Төлке һ.б.

Геройны сыйфатлый торган эпитетлар әкияттә зур урын алып торганлыктан, күп очракта алар әкиятнең исемендә үк кулланыла. Мәсәлән, көнкүреш әкиятләренең исемнәренә генә күз салыйк: «Акыллы Каюм бабай», «Әләкче вәзир», «Батыр тегүче», «Гакыллы бала», «Зирәк карт», «Кыю Шомбай», «Мактанчык бай», «Тиле Таз», «Уңган егет», «Үткен кыз», «Холыксыз хатын», «Шаян кеше», «Юаш кияү», «Ялкау карчык» һ.б.

Тылсымлы әкиятләрдә герой эш итә торган табигать һәм көнкүреш әйберләре дә гадәти генә түгел, алар: алтын алма, күренмәс чикмән, серле балдак, серле дага, серле сумка, тире такыя, тылсымлы чыбык, тылсымлы шәм һ.б. Әлеге әйберләрнең эпитетлары аларның гадәттән тыш сыйфатларга ия булуларына ишарәли. Бу исә, үз чиратында, шушы әйберләр белән эш итүче геройның образын идеаллаштыруга хезмәт итә.

Чагыштырулар исә сөйләмгә җанлылык өсти, күренешләрне ачык итеп күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә. Мәсәлән, «Ак бүре»[1] әкиятеннән берничә мисал: «бер бите ай, икенче бите кояш кебек бер бик матур кыз», «кызларның күзләре ут шикелле яна», «чуеннан да кара бер зур мыеклы гыйфрит» һ.б.

Әкиятнең теле образны ачу чараларының берсе булып тора. Теге яки бу персонажның теле аның характерына туры килә, хәтта еш кына аның кайсы сыйныф вәкиле булуын да күрсәтә. Мәсәлән, өстен катлау вәкиленең үз хезмәтчесенә әйткән сүзләре дорфа, тупас: «Синеңише ялкау хәерче бәхетен йоклап җилгә очыра. Йокламаган булсаң, бүгенге көнне сиңа да бәхет эләгер иде. Менә мин абага чәчәген кабам да, теләсә нинди кибеткә кереп, җаным теләгән малны алып баеп китәм»[2] («Абага чәчәге»). Ә менә монысы азгын затның кеше хатынына төчеләнеп әйткән сүзләре: «Тукта, тукта, асыл кош, кая ашыгасың? Бер серләшик кеше югында»[3] («Чибәр кыз

[1] Әкиятләр (беренче китап). Б. 185.
[2] Әкиятләр (өченче китап). Б. 224.
[3] Шунда ук. Б. 129.

Хәдичә»). «Еланнар» дигән әкиятнең герое – ялчы егет, иптәшләрен өндәп, болай ди: «Байның байлыгын бүлешеп, илләргә кайтыйк, туганнар»[1].

Персонажларның тотрыклы характеристикасы образларны типиклаштыруга китерә. Мәсәлән, персонаж бай икән, ул, һичшиксез явыз, комсыз, мәкерле, аңгыра була, ә хезмәтче, киресенчә, миһербанлы, зирәк, акыллы һәм хәйләкәр. Персонажларның күп очракта исеме булмау яисә булган тәкъдирдә дә Тугры, Алдар, Саран, Юмарт кебек символик исемнәр белән генә йортелүе шулай ук типиклаштыруның көчлелеге турында сөйли. Гомумән, әкияттә образларны сурәтләүдә ак һәм кара буяулар белән генә эш ителә.

Әкияттә образны ачу чарасы буларак, поэтик ысуллардан аеруча антитеза һәм гипербола күп кулланыла. Персонажларның социаль хәлен, милек дәрәҗәсен күрсәтү үзе үк инде аларны капма-каршы кую дигән сүз. Ләкин әкияттә бу каршылык әлеге персонажларга хас аерым мөһим сыйфатларны аңлы рәвештә күпертеп күрсәтү (ягъни гипербола куллану) нәтиҗәсендә тагын да көчәйтелә. Мәсәлән, «Нужа»[2] дигән әкияттә бай шул дәрәҗәдә аңгыра итеп сурәтләнә, ул, хезмәтчесенең хәйләсенә җиңел генә ышанып, нужаның нәрсә икәнен күрергә ерак сәфәргә чыгып китә, азыгы беткәч, хезмәтче киңәшен тынлап, печән ашый, исән-сау кайтуы бәрабәренә бөтен байлыгын, хәтта кызын да хезмәтчесенә биреп, үзе аңа хезмәтче булып яллана.

Стилистик фигура буларак, гипербола тылсымлы әкиятләрдә аеруча мул һәм тәэсирле. Ул әкият героеның үзенә карата кулланыламы, герой файдалана торган әйберләргәме, әллә аньщ дошманнарына нисбәтлеме – ахыр чиктә бу чара шул ук максатка, ягъни геройны идеаллаштыруга хезмәт итә. Менә «Алтын алма» дигән әкияттән бер өзек: «Миңа унбиш потлы гер ташы койдырып китерт, ди, патша малае... Патша гер ташың койдыртып китерде малайга. Әүвәле башта егет гер ташын, нык микән дип, тез башына сугып карады. Тезенә бернәрсә дә булмады. Аннары сукты ташка, таш тузаннар булды, гер ташына бернәрсә булмады»[3].

Күренә ки, баһадир геройның куллана торган әйберләре дә гадәти генә түгел. Аның ярдәмчеләре дә шундый ук: мәсәлән, алты колачлы ала бия («Алтын алма»), алтмыш колачлы ала айгыр («Ак бүре»). «Камыр батыр» әкиятендәге «ай үсәсен көн үскән, ел үсәсен

---

[1] Әкиятләр (өченче китап). Б. 150.
[2] Шунда ук. Б. 203.
[3] Әкиятләр (беренче китап). Б. 229.

ай үскән» геройның ярдәмчеләрен сурәтләгәндә] дә гипербола мул кулланыла. Мәсәлән, борын тишеген бармагы белән кысып утырган кешедән Камыр батыр аның нишләп шулай итүен сорагач, әлеге кеше болай ди: «Миңа болай да таманга туры килә әле. Югыйса, дөньяда зилзилә куба, бер борын тишеге белән өрдереп тә биш ташлы тегермән әйләндерәм мин»[1].!

«Камыр батыр» экиятенең икенче бер персонажы үзенең эшләпәсен тигез итеп киеп куйса, «күз ачмаслык буран чыга», басып кисә, «җир йөзенә ике илле боз ката». Өченче бер персонаж исә алтмыш чакрымнан атып, каршысындагы тауда кунып торган чебеннең сул күзен атып чыгара ала. Ә аягын тышаулаган егет алтмыш чакрым җиргә бер-ике сикерүдә барып җитә. Шул ук «Камыр батыр» экиятеннән тагын бер мисал: туфрак белән уйнаучы кеше бер яктан сугып җибәрә – утыз кеше күмелә, икенче яктан сугып җибәрә – утыз кеше күмелә. Камыр батыр күсәге белән бер селтәнә – утыз-кырык кеше кырылып бетә»[2]. Әкият кануннары буенча геройның дошманы да гадәттән тыш көчле булырга тиеш. Аны сурәтләүдә шулай ук гипербола ярдәм итә. Мәсәлән, «Таңбатыр» экиятендәге дию берьюлы өч түшкә үгез ите, өч мич ипи ашарга, өч мичкә эче су эчәргә мөмкин»[3].

Халык экиятләрендә стилистик чара буларак кулланыла торган «уртак урыннар» шактый урын били: төрле әсәрләрдә аерым өлешләрнең һәм эпизодларның кабатлануы, күпләренең туй белән тәмамлануы, геройның кече туган булуы һ.б. Уртак урыннарның зур өлешен төрле тотрыклы тәгъбирләр (традицион формулалар) алып тора.

Тотрыклы тәгъбирләр экиятнең башында да (инициаль формулалар), уртасында да (медиаль формулалар) һәм азагында да (финал формулалар) кулланылалар.

Әкиятләрнең башламында бигрәк тә «борын заманда» («борын-борын заманда») дигән тәгъбир күп очрый. Озын башламнар тулаем да мөстәкыйль формула булып санала.

Әкиятнең бетеме турында да шуны ук әйтергә була. «Бүген бардым, кичә кайттым», «Ун көн уен иттеләр, утыз көн туен иттеләр» кебек тәгъбирләр аерым-аерым кулланылган кебек, аларның яки шуларга охшаш башка тәгъбирләрнең шактый күләмле бетемнәрдә барысы бергә кулланылып, мөстәкыйль финал формула рәвешендә дә йөрергә мөмкин.

[1] Әкиятләр (беренче китап). Б. 305.

[2] Шунда ук. Б. 307.

[3] Шунда ук. Б. 244.

Инициаль һәм финал формулаларның әкият белән бәйләнеше шактый йомшак, чөнки алар сюжетның, вакыйгаларның состав өлеше булып тормый.

Медиаль формулаларга килсәк, алар ике төркемгә бүленә: а) тышкы медиаль формулалар; б) эчке медиаль формулалар. Тышкы медиаль формулаларга бер эпизодны икенчесе белән бәйли торган күчеш формулалары керә. Мәсәлән: «Болар шулай шатланып торсыннар, без егет янына барыйк әле». Бу типтагы формулалар үзенчәлекле композицион элемент булып торалар.

Тылсымлы әкиятләрдә очрый торган тотрыклы тәкъбирләрнең иң зур өлеше эчке медиаль формулаларга туры килә. Бу формулалар әкиятнең мөһим элементлары белән органик рәвештә бәйләнгән. Алар персонажларның хәрәкәтен, портретын һ.б. якларын характерлыйлар. Күп кулланыла торган эчке медиаль формулаларның берничәсен күрсәтеп узыйк: «Уң ягыма сук, сул ягымнан кан чыксын», «Көн китәләр, төн китәләр, ай китәләр болар», «Син – минеке, мин – синеке» һ.б.

Көнкүреш әкиятләренә исә, гомумән алганда, традицион формулалар, шулай ук күтәренке эпитетлар һәм кабатланулар хас түгел. Бу әкиятләрдә образлылык тудыруның башка поэтик чаралары зуррак урын тота. Мәсәлән, образлы тәгъбирләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, җырлар һәм табышмаклар еш очрый Образлы тәгъбир һәм мәкальләрдән «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми» (шул исемдәге әкияттә), «Җаннан татлы, әҗәлдән әче юк» («Әби белән бабай»), «Ырыкныкы шырыкка» («Байдек»), «Тугры сөйләгән котылган, ялганлаган тотылган» (шул исемдәге әкияттә), «Яңгыр яуганда бала жәл, таш яуганда баш жәл» («Кулсыз кыз») һ.б.ларны күрсәтергә мөмкин[1]. Мәкаль һәм әйтемнәр фикерне анык һәм ышандырырлык итү өчен кулланыла. Әсәрнең башында килгәндә әкият эчтәлеге мәкальнең мәгънәсен ача. Бу очракта ул композицион вазифа үти (мәсәлән, «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми» дигән әкияттә).

Көнкүреш әкиятләрендә очрый торган кыска җырлар (такмаклар) әкият сюжеты белән тыгыз бәйләнгән булып, аларда, башлыча, герой үзенең хәйләсен ача, ләкин аның антиподына бу соңыннан гына «барып җитә». Мәсәлән, «Байны «утыртканнар»[2] дигән әкияттә каракларның берсе байның атларын урлаган вакытта, калган икесе, ишек тавышы ишетелмәсен өчен, мәҗлестә җырлап бии башлыйлар:

---

[1] Әкиятләр (өченче китап). Б. 150, 260, 71, 133.
[2] Шунда ук. Б. 73.

Шыгырдый ла, майласана;
Аласы – миңа, коласы – сиңа,
Әрәмәлеккә бәйләсәнә!

«Ике кода»[1] дигән әкияттә дә кодалар бер-берсенә үзләренең хәйләләрен шулай ук такмакка салып әйтәләр (җырлыйлар).

Көнкүреш әкиятләрендә табышмаклар да күп очрый. Без биредә табышмак-әкиятләрне күздә тотабыз. Алар турында югарыда сүз булган иде инде. Кинаяле сөйләмгә мисал итеп, «Патша, вәзир һәм тегермәнче» дигән әкияттән патша белән тегермәнче сөйләшүен күрсәтергә мөмкин.

«Патша, тегермәнчегә кергәч тә, әйткән:

– Әллә, мәллә, – дип (ягъни: әссәламегаләйкем).

Тегермәнче җавап биргән:

– Кәллә мәллә, – дип (ягъни: вәгаләйкемәссәлам).

Патша әйткән тегермәнчегә:

– Өчнеке тугызга җитәме? – дип (ягъни: өч ай эшләгәнең тугыз айга җитәме?).

Тегермәнче җавап биргән:

– Җитә җитүен, утыз икедән артмый, – дип (ягъни: җитә җитүен, утыз ике тештән артмый)»[2].

Кинаяле сейләм формасындагы табышмаклардан тыш, әкиятләрдә башваткыч сораулардан һәм җаваплардан гыйбарәт булган табышмаклар да очрый (мәсәлән, «Өч сорау»[3], «Акыллы килен»[4] әкиятләрендә).

Фантазиягә, оста сөйләүчеләр тарафыннан эшләнгән тел-стиль бизәкләренә искиткеч бай булган әкиятләр халкыбызның үзенчәлекле рухи хәзинәсе, мәдәни казанышы булып тора.

Хәзерге вакытта яңа әкиятләр барлыкка килми. Сөйләүчеләр исә әкиятләрне күпмедер дәрәҗәдә бүгенге көнгә яраклаштырып сөйлиләр, ягъни заманга, бүгенге тыңлаучының психологиясенә ярашлы рәвештә әкияттәге кайбер моментлар көчәйтелә, яңа детальләр кертелә, ә кайчак гомумиләштерүләр ясала, мораль нәтиҗәләр чыгарыла. Хәтта тылсымлы әкият тә, үзенең асылы белән никадәр тотрыклы булмасын, барыбер заман белән бергә билгеле бер дәрәҗәдә үзгәрешләр кичерми калмый.

---

[1] Әкиятләр (өченче китап). Б. 274.
[2] Шунда ук. Б. 47.
[3] Шунда ук. Б. 33.
[4] Татар халык әкиятләре / Төзүчесе Х. Гатина. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б. 16.

## Тылсымлы әкиятләрдә Дию образы

Дию – татар әкиятләрендә иң күп очрый торган мифологик образ. Ул – нигездә, тылсымлы әкият персонажы, әмма көнкүреш әкиятләрендә дә беркадәр урын алган. Биредә сүз тылсымлы әкиятләрдәге Дию турында барачак.

Татар фольклорының 12 томлык фәнни җыелмасындагы әкият томнарына[1] кертелгән 116 тылсымлы әкияткә күз салсак,шуларның 34 ендә без Дию персонажы белән очрашырбыз (29%).

Дию, башлыча, кешенең дошманы буларак сурәтләнә, сирәк очракларда гына кешегә ярдәм итә.

Дию персонажы татар фольклорына иран мифологиясеннән кергән. К.Насыйри иранлыларның Диюе татарларга «мөселманлык аркылы» килгән дип саный[2]. Ләкин Дию һ.б. затларның татар мифологиясенә керүендә мөселманлык бердәнбер юл булмаска мөмкин, чөнки төрки кабиләләрнең, шул исәптән татар халкының борынгы бабаларыннан кыпчаклар, утызлар һәм болгарларның иран кабиләләре белән аралашуы аларда әле ислам дине таралмаган чорларга ук карый[3]. (Мөселман булмаган грузиннарда һәм әрмәннәрдә дә Дэв (Дию) заты бар).

Борынгы күчмә иран кабиләләрендә Дәү (Дию), һинд эпосындагы кебек үк, мәҗүси Алла булган. Аның исеме Һинд– Аурупа телләрендәге уртак тамырга кайтып кала (латинча «deus» – Алла, Зевс, Юпитер) һәм «Күк» дигән мәгънәне белдерә. Соңрак иран кабиләләренең утрак тормышка күчкән өлеше Дәүләрне дошманлык һәм нәфрәтне гәүдәләндерүче усал аллалар итеп саный башлаган. Шулай итеп, әлеге затлар күктән җиргә төшерелгәннәр, хәтта җир асты дөньясына ук «сөрелгәннәр».

Әлеге зат («Дәү») күп халыкларда «Дэв», «Див» дип аталса, татарларда ул «Дию» шәкелендә йөри. Башкортларда да бу персонажның исеме татарныкына охшаш: аңа «Дейеү» диләр.

Татар әкиятләренең бер өлешендә ул «Дию» дип кенә йөртелсә (I – 56, 69, 72, 75, 83, 88; II – 20, 22, 45, 46, 54, 56), күбесендә, әлеге

---

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр (беренче китап) / Томны төзүчеләр, искәрмәләрне хәзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977; икенче китап – 1978. Алга табан текстта җәяләр эчендә бу китаплардагы әкиятләрнең тәртип саннары гына күрсәтеләчәк.

[2] Насыйри К. Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр // Сайланма әсәрләр: Ике томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 53.

[3] Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. С. 56.

исем белән беррәттән, «Дию пәрие» дип атала, ягъни Дию образы Пәри образы белән кушылып ук китә, сирәк очракларда хәтта «Пәри» дип кенә дә әйтелә (I – 48, 58, 66, 67, 70, 74, 76, 80, 89, 90; II – 6, 9, 13, 17, 28, 42, 60, 65). «Өч дус» дигән әкияттә Дию пәриенең «статусы» да, ялгызлык исеме дә бар: «бөтен пәриләр башлыгы Гыйфрит дигән Дию пәрие» (I – 67). Кайбер әкиятләрдә «Дию патшасы» («Диюләр патшасы») диелә (I – 49[1], 57[2], 64, 68, 72[3], 76[4]; II – 45[5]). Бер әкияттә Дию үзен «пәри зат патшасы» дип атый (I – 67). Дию персонажы искә генә алынган әкиятләр дә бар (мәсәлән, I – 49). Яисә Диюнең гамәле, «сюжеты» бар, ә үзе юк, ягъни әлеге әкиятләрдә, яисә әкиятләрнең аерым сюжетларында, геройның антиподы буларак, башка затлар сурәтләнә: «җен патшасы» («җеннәр патшасы»), «карт», «мулла» һ.б. (I – 74, II – 8, 9, 20, 21). Бу турыда әле сүз алдарак та булыр.

Диюнең портреты әкиятләрдә ачык күрсәтелми, кайберләрендә генә аерым детальләр очрый, мәсәлән: «Диюнең маңгаенда чиләк төбе хәтле бер күзе бар» (I – 72), «Дию пәриенең түтәе бер генә күзле икән» (I – 89). Шулай да Дию карчыгының портретына штрихлар ешрак күренә. Мәсәлән: «аскы тешләре борын тишегенә җиткән, өске тешләре иягенә җиткән» (I – 58). Ә менә Дию гәүдәсенең зур булуы байтак әкиятләрдә ассызыклана. Әйтик, «Әйгәли батыр» әкиятендә Диюнең беренче тапкыр пәйда булуы түбәндәгечә күрсәтелә. Өч башлы Дию елга буйлап күпергә таба килә. Ул атка атланган, трубка тартып бара. Трубкасыннан чыккан төтенне герой ерактан ук күрә һәм аны пароход төтене дип уйлый. Дию шулкадәр зур – «тау күк булып килә» (I – 66).

Тагын бер мисал: «Дию килеп керә. Ул баш дисәң – дөньяга сыймаган зур баш, гәүдә дисәң – дөньяга сыймаган зур гәүдә моның» (I – 72). Аңлашылганча, Дию кеше кыяфәтендә итеп күзаллана. Гомумән, төрки халыкларда, шулай ук Дагыстан халыкларында ул кешегә охшаган (антропоморфик) зат итеп сурәтләнә. Ә менә гру-

---

[1] «Зөһрә» дигән бу әкияттә Дию персонажы юк, кара елан үзен «Диюләр патшасы» дип атый (паролендә).

[2] «Чүмеч» исемле бу әкияттә геройның антиподы Төрекмән бабайга карата «Диюләр патшасы» диелә. Соңгы исем-гыйбарә вариантлары белән (Дию патшасы, Дию патша) тагын берничә әкияттә очрый (I – 68, 70, 72; II – 56).

[3] Бу әкияттә («Зөлкарнәй батыр») Дию патшасының җире турында сүз барса да, андагы Диюләрнең берсе дә патша буларак сурәтләнми.

[4] «Турай батыр» әкиятендә Дию патшасы (Диюләр патшасы) – «Үзе бер карыш, сакалы биш карыш» дигән кәрлә карт («Кәрлә Дию»),

[5] «Патша малае белән хезмәтче малае» дигән бу әкияттә Диюләр патшасы – адәми заттан булган кыз.

зин мифологиясендә һәм фольклорында Дию (Дэв) хайвани (зооморфик) зат итеп күрсәтелә. Ул мөгезле һәм йонлач[1].

Гәүдәсенең зур булуы өстенә, татар Диюе гаять көчле дә. Әмма әкият герое курыкмый, шундый көчле Дию белән аяусыз көрәшә (сугыша) һәм ахыр чиктә җиңеп чыга.

Дию еш кына күпбашлы итеп сурәтләнә. Ул бер, ике, өч, алты, җиде, тугыз, унике башлы булырга мөмкин. Сирәк кенә булса да егерме дүрт, егерме биш, җитмеш, җитмеш биш башлы Диюләр дә очрый[2]. Әгәр әкияттә Диюләр берничә булса, кайбер очракларда аларның баш саннары төрлечә була. Мәсәлән, 6–9–12 (I – 48), 7–9–12 (I – 64). Баш саны арта барган саен, Диюнең көче дә арта бара.

Дию, кагыйдә буларак, кешеләрдән еракта яши (I – 75, 83, 90; II – 8 һ.б.). Ерак урын кайчак атап та әйтелә: Байкал диңгезенең аръягында (II – 46), диңгез артында (I – 72), җиде диңгез артында (II – 13), Каф тавы артында (I – 64), карурман артында (I – 56). Аерым очракларда Диюнең яшәгән җире гадәти урында итеп сурәтләнә һәм ул еракта булмаска да мөмкин: әйтик, әрәмәлектә (I – 90), тау башында (II – 17), «елганың теге ягында яр буенда» (II – 28), су буенда (I – 88), утрауда (II –13). Болардан тыш әле ул җир астында (I – 68, 70) һәм су астында, аерым алганда, диңгез төбендә (II – 65), күл төбендә (II – 22), кое төбендә (I – 67) дә яши. Диюләр авыл булып та (I – 88), шәһәр булып та (II – 17) яшиләр.

Кайбер әкиятләрдә Дию яшәгән урынның гадәттән тыш булуы искәртелә. Мәсәлән, аның карурман артындагы «икенче дөнья»да (I – 56), яисә диңгез артындагы «адәм аяк басмаган урын»да (I – 72) тереклек итүе әйтелә. Кайда булуына карамастан, ул урыннар – куркыныч җирләр.

Дию яши торган урынга карата «ат килсә тоягы көя, кош килсә канаты көя торган җир» (I – 64) диелә, яисә «анда барганнардан берәү дә кире кайтмый» (II – 46), йә булмаса «аннан кайтмак юк инде» (II – 17) дип раслана.

Җир өстендә, әмма еракта яши торган Диюгә кадәр араның зурлыгы әкиятләрдә төрлечә: ике көнлек юл[3] (II – 46), ун көнлек юл

---

[1] Мифы народов мира. Энциклопедия: В двух томах. Том I. М.: Сов. Энциклопедия, 1991. С. 418. (Алга табан: Мифы).

[2] Карт бабай // Мирас. 1993. № 5; Батман бабай // Мирас. 1993. № 3. Сүз җаенда әйтеп үтик: грузин мифологиясендә һәм фольклорында диюләрнең башлары өчтән алып йөзгә кадәр. Башын киссәң, әлеге баш урынына яңа баш үсеп чыга (Мифы. С. 418).

[3] Герой көн бара, төн бара, диңгезгә җитә; диңгезне кичкәч, ике көнлек юл барасы.

(I – 90), өч айлык җәяүле юл (I – 58), биш ай да ун көнлек юл[1] (I – 88), су астыннан йөри торган кораб белән барганда алты еллык юл ераклыгында (I 69).

«Ак бүре» әкиятендә (I – 64) Диюнең биләмәсенә һәм шул биләмәдәге сараена кадәр булган ара тәңгәл килми: Дию биләмәсе Ак бүре урманыннан өч көн, өч төнлек юл ераклыгында. Әкият героена, шушы өч тәүлеклек араны узгач та, Дию сараена җитәр өчен янә өч ай, егерме бер тәүлек һәм өч сәгатьтән артыграк вакыт кирәк була[2].

Җир астында яшәүче Дию сурәтләнгән «Таңбатыр» әкиятендә дә шул ук хәл: Диюнең биләмәсенә аяк баскач та әле геройга бу зат яши торган сарайга җитәр өчен җиде көн, җиде төн караңгыда барырга, аннары, җиде кат чуен капканы ватканнан соң, тагын җиде тәүлек атларга, ягъни җәмгысе ундүрт тәүлек барырга кирәк була (I – 70).

Димәк, Дию үзе яши торган сарай хуҗасы гына түгел, бәлки зур мәйданның, территориянең хакиме дә.

Дию биләмәсенә керергә беркемнең дә хакы юк. Хәтта кошларның да. Дию үзе дә күршесендәге чит биләмәгә аяк басмый.

Диюнең торагы нинди соң? Дию, гадәттә, үзенең зур һәм зиннәтле сараенда яши (I – 64, 70, 72, 83; II – 13). Сарай һәм ныгытмадан тыш, Дию корабта (II – 54), зур йортта (I – 68), гадәти йортта (I – 88, 90), киез өйдә (II – 6), хәтта зимләнкәдә (I – 75) яшәргә мөмкин. Йокларга подвалга да төшә (I – 64, 69).

Әйтеп узылганча, Дию, башлыча, кешеләргә зарар китерүче буларак сурәтләнә. Ул кешеләрне урлый, үтерә, ашый. Шуңа бәйле рәвештә кеше аның белән каршылыкка керә, көрәшә (сугыша) һәм аны юк итә, дидек. Аерым очракларда кеше төрле ысуллар ярдәмендә Диюдән качып котыла. Әмма әкиятләрдә, сирәк булса да, кешегә ярдәм итүче Дию образы да очрый. Диюнең әнә шундый төрле сыйфатлары, кылган гамәлләре, кешегә мөнәсәбәте аның әкияттәге вазифасына бәйле.

Вазифалары җәһәтеннән тылсымлы әкиятләрдә Дию образының берничә төре аерымлана. Хәзер шуларга аерым-аерым тукталып узыйк.

Тылсымлы әкиятләрдә иң күп очрый торган Дию – **урлаучы Дию.** Ул – Дию образы сурәтләнгән 32 әкиятнең 16 сында бар (I –

---

[1] Әкият герое атка атланып барганлыктан, ун көн дәвамындагы бару тизлеге мәгълүм түгел, ә шуннан соң биш ай дәвамында герой атын атлатып кына бара дип аңлашыла, чөнки юлдашлары моның яныннан җәяү баралар.

[2] Безнең тарафтан исәпләп чыгарылды. – *Л.Ж.*

64, 66, 68, 69, 70, 72, 74, 75, 83, 90; II – 13, 28, 46, 56, 65). Бу Дию башлыча кызларны (I – 67), аеруча патша кызларын (I – 69, 70, 72, 75, 90; II – 13, 28, 65, 83), аерым очракларда патша хатынын (I – 64), патша малаеның хатынын (I – 83), патшаның көтү-көтү малларын (I – 66), яисә алтын алмаларын (I – 68) урлап китә.

Дию патша кызларының берсен (I – 69, II – 13, 28, 54), кайчак әлеге кызның кайсы икәне дә атап әйтелә – мәсәлән, олы кызын (II – 28), яисә берничә кызын – гадәттә өч кызын (I – 70, 75) урлый. Соңгысында (I – 75) өч кызны берьюлы өч Дию урлый (көчләп алып китә)[1]. Аерым очракларда урланган кызларның саны күбрәк тә булырга мөмкин, мәсәлән, унике кыз (II – 65), егерме тугыз кыз (I – 90).

Дию пәриенең герой карамагындагы кыз белән бергә алтын тояклы атын һәм алтын сандугачын урлап китү очрагы да бар (I – 74[2]).

Урлау тәүлекнең теләсә кайсы вакытында булырга мөмкин: төнлә (I – 64), төн уртасында (I – 90), кояш чыкканда (I – 68) һәм көндез (I – 69, 70). Күп очракта урлауның кайчан, кайсы вакытта булганлыгы атап әйтелми.

Урлаучы Дию пәйда булганда табигатьтә үзгәрешләр барлыкка килә: «җил-давыл чыга башлый», «ямь-яшел болыт килә башлый», «күкле-яшелле болыт чыга», «кара болыт чыгып, давыл күтәрелә» (I – 72), «бик каты җил-давыл чыга» (I – 70), «болыт күтәрелә, өермә куба» (II – 46). «Өч дус» дигән экияттән бер мисал: «Күк күкрәтеп, җир тетрәтеп, давыл куптарып, тузан туздырып, агач башларын сызгылдырып-сызгылдырып, Дию пәрие килеп төште...» (I – 67).

Табигатьтәге шундый үзгәрешләрдән һәм бигрәк тә «килеп төште» дигән тәгъбирдән Дию очып килә дип аңлашыла. «Ак бүре» экиятендә Диюнең очып килүе турында ачыграк әйтелә: «Һавадан бер Дию патшасы пәйда булып, моның [патшаның] куенындагы хатынын күтәреп алып китте» (I – 64).

Ләкин шулай да Диюнең очуы турында кистереп әйтү экиятләрдә сирәк очрый, гадәттә аның канатлары булуы да күрсәтелми, бары бер экияттә генә Диюнең бик зур ярым кеше, ярым кош сурәтендә очып

---

[1] «Әйгәли батыр» экиятендә өч башлы Диюнең өч бертуган хатын-кызны урлаганлыгы әйтелә (I – 66).

[2] Ошбу «Унберенче Әхмәт» экияте урлау мотивының чагылышы җәһәтеннән бик үзенчәлекле. Биредәге төп сюжетта бик каты җил чыгып, күктә кара болыт күренүе һәм бу кара болытның, җиргә төшеп, хатын-кызны түгел, ә ир кешене – экият герое Әхмәтне күккә күтәреп китүе сурәтләнә. Анда болай диелә: «Әхмәтне унбер женнең бабасы – җен патшасы күтәреп киткән була. Бу җен патшасы Әхмәтне үзенең сараена, Каф тавы артына алып барып төшерә».

килүе тасвирлана (I – 68) һәм икенче бер әкияттә бу персонажның алынмалы-куелмалы бик авыр канатлары булуы әйтелә (II – 65).

Кайвакыт табигатьтәге үзгәрешләр Диюнең шул күренешләргә әверелүе дип тә аңлашыла. Мәсәлән, «Таңбатыр» әкиятендә сурәтләнгәнчә, патшаның өч кызы болынлыкта йөргән вакытта бик каты җил-давыл чыга да кызларның өчесен дә күтәреп алып китә. Әкият түбәндәгечә дәвам итә: «Озак та үтми, әлеге җил-давыл бер җирдә бөтерелеп, котчыккыч булып өерелеп-өерелеп тора да бер биек тау башына барып туктый. Тау башында бик яман бөтерелеп тора-тора да бик ямьсез бернәрсәгә – Дию пәриенә әверелә» (I – 70).

Димәк, Дию кызларны җил-давылга әверелеп күтәреп киткән дә, соңыннан үз халәтенә кайткан булып чыга. «Нурсылу» дигән әкияттә дә шуңа охшаш хәл тасвирлана: «Баш очларында кара болыт җыела. Җыела, җыела да көтмәгәндә Нурсылуны үзенә суырып ала» (I – 83).

Диюнең башка нәрсәләргә әверелүе дә мөмкин: мәсәлән, геройга ул кайчак кеше (егет кеше, I – 75; карт кеше, 1 – 57, 58, 90) кыяфәтендә күренә, яисә хайванга (айгырга, I – 56), кошка (әтәчкә, II – 13; карчыгага, чебешле тавыкка, II – 22), кеше сыман кошка (I – 68) әверелә.

Диюнең кеше ашавы турында искәртеп узган идек инде. «Ул дөньяда адәм итләре ашап кинәнә»,– диелә «Ак бүре» әкиятендә. Дию кешеләрне тегермәндә тарттырып ашый: «Ул сарай Диюнең тегермәне иде. Ул шул тегермәндә әлегә хәтле ничә меңнәрчә адәмнәрне тарттырып, азык итеп ашады» (I – 64).

Икенче бер әкияттә Диюнең кешеләрне мунчада пешереп ашавы турында әйтелә (I – 58).

Күпчелек әкиятләрдә бу хәл тәфсилләнми, әнә шулай Диюнең кешеләрне ашавы турында хәбәр генә ителә (I – 70 һ.б.). Сирәк очракта гына кеше ашау натуралистик планда күрсәтелә. Мәсәлән, «Зөлкарнәй батыр» әкиятеннән бер өзек: «Дию авызын ачкан иде, ярты адәм гәүдәсе серәеп тора икән.

Менә нәрсә исе килә ул,– дип, Дию авызыннан адәм гәүдәсен тартып ала кыз.–Йот кире, ди, аннан исе килмәс, – ди.

Дию ярты гәүдәне йотып җибәрә» (I – 72).

Гомумән, Дию – бирән тамак. Ул, мәсәлән, берьюлы өч түшкә үгез ите, өч мич ипи ашарга, өч мичкә әче су эчәргә мөмкин (I – 70).

Урланган кызлар менә шундый коточкыч зат әсирлегенә килеп эләгәләр. Дию аларның берсен яки берничәсен үзенең хатыны итеп, ә калганнарын коллар итеп тота.

Патшаның урланган кызларын (хатынын) яисә әйберләрен эзләргә, гадәттә, патшаның уллары (башлыча өч улы[1]) чыгып китә.

Ләкин әсирләрне Дию кулыннан коткару кече угылга гына насыйп була. Патша кызларын эзләргә гади халык вәкилләренең (ул солдат булырга да мөмкин) китүе чагыштырмача сирәк очрый (I – 67, 68, 70; II – 54).

Әкиятләрнең бер өлешендә Дию кулындагы тоткыннарны коткарачак герой өйдән махсус чыгып китсә (I – 64, 66, 68, 69, 70, 83), күбесендә ул әлеге хәлгә юлда вакытта көтмәгәндә (ягъни очраклы рәвештә) килеп эләгә (I – 67, 72, 74, 75, 90; II – 13, 28, 46, 54, 65). Шуңа бәйле рәвештә, соңгы төркемнең кайбер әкиятләрендә Дию эпизодик образ гына булырга да мөмкин (мәсәлән: I – 74).

Герой Дию торагына барып кергәндә хуҗасы күп очракта өйдә булмый: йөрергә чыгып киткән (II – 54), икенче бер Дию пәриенә каршы сугышка киткән (II – 13), яраланып кайтып, «фиршелгә киткән» (I – 68), бер атналык юлга чыгып киткән (I – 48), унике айлык юлга киткән (I – 64), яисә кая киткәне мәгълүм түгел (I – 67, 70, 72, 90).

Өйдә булган тәкъдирдә ул йоклап ята (I – 56, 64, 68, 74, 83; II – 65 һ.б.). Дию сәкедә йоклый (II – 65), караватта ята (I – 56), яисә нәрсәдә йоклаганы әйтелми, әмма түрдә дип аңлашыла. Ул еш кына подвалда да йоклый, каты җирдә (I – 64), хәтта яраланып кайтса да, «башын куеп яткан җире дә таш, кулын куеп яткан җире дә таш» (I – 68).

Әкият герое йоклап яткан Диюне шунда ук үтерә дә алыр иде, әмма намуслы егет алай эшләми, иң элек ул дошманын уята.

Диюнең зур гәүдәле һәм көчле зат булуы турында алдарак әйтелгән иде инде. Әмма геройның көче дә Диюнекенә бәрабәр. Көчләре тигез булганга күрә, герой белән Диюнең көрәше озакка сузыла.

Дию хәйләкәр һәм мәкерле, ул дошманын, тәмле телле булып, алдарга тырыша (I – 64), ә көрәшеп арыгач, ашап алырга тәкъдим итә. Максаты – хәл кертә торган су эчү. Диюнең ике төрле суы алдан ук әзерләп куелган: берсе хәл кертә торган, икенчесе хәл китәрә торган. Соңгысы, әлбәттә, дошманы өчен әзерләнгән. Ләкин герой Дию хатынының, яисә тоткын хатын-кызның, сирәк очракта башка кешенең (I – 69) киңәше белән әлеге төрле су тутырылган савытларның (шешә, кисмәк, казан һ.б.) урыннарын алыштырып куя (I – 64, 69, 72, 83 һ.б.). Нәтиҗәдә хәл кертә торган суны герой эчә, һәм җиңү дә аның ягында була.

[1] «Ак бүре» әкиятендә патшаның хатынын эзләргә дүрт улы китә (I – 64).

Герой Диюнең башын (башларын) алмас кылыч белән кисеп ташлый (I – 64). Яки: «Зөлкарнәй алмас кылычы белән Диюнең башын чабып бетерә» (I – 72). Кайбер әкиятләрдә герой Диюне кылычы белән турап, сандыкка салып бикләп куя (I – 69, II – 28). Диюне (диюләрне) кылыч белән чабу башка әкиятләрдә дә очрый (I – 90, II – 28). Бер әкияттә Диюнең гәүдәсе, балта белән туракланып, зур-зур әрдәнә итеп өеп куела (II – 60).

Тылсымлы әкиятләрнең бер өлешендә Диюне һәлак итү өчен башка ысул да кулланыла: ул – хәйлә белән Диюнең җаны кайда сакланганын белеп, әлеге җанын юкка чыгару (бу очракта әкияттә тылсымлы сулар тасвирланмый).

Борынгы кеше табигатьтәге һәрнәрсәне җанлы итеп күзаллаган (анимизм). Абстракт фикер йөртү сәләте зәгыйфь булган кыргый кеше җанны конкрет матди әйбер итеп күз алдына китергән: аны күрергә, тотып карарга һәм тартмага салып сакларга мөмкин дип уйлаган. Шулай булгач, җан кеше тәнендә генә түгел, аңардан тыш та яшәргә мөмкин, һәм болай итү хәтта зарур да, чөнки кешене тормышта күп төрле куркынычлар сагалап тора. Шәхси иминлеген тәэмин итү максатыннан чыгып, кеше үзенең җанын тәненнән тыш, аерым бер ышанычлы җирдә, мәсәлән, берәр хайван, үсемлек яисә предмет эчендә, саклый ала[1].

Җанны тәннән аерым итеп күз алдына китерү тылсымлы әкиятләрдә байтак очрый. «Утыз ул» әкиятендә Дию пәрие патша кызына үзенең җаны кайда икәнен түбәндәгечә сөйли: «Минем җаным, ди, бик еракта шул, ди. Диңгез аркылы чыккач, өч ботаклы бер зур агач булыр, ди. Шул агачның өстендә өч башлы кара елан булыр, ди, шул кара елан астында, ди, кара мәче булыр, шул кара мәче минем җаным булыр»,– ди (I – 90).

Мисаллардан күренгәнчә, Дию, үзен үлемнән саклау өчен, җанын, тәненнән чыгарып, хәвефсез урынга куя.

Җанның кайда саклануын белү максаты белән патша кызы биргән сорауларга Дию еш кына ялган һәм буталчык җаваплар бирә. Мәсәлән, әлеге «Утыз ул» әкиятендә Дию үзенең җанын башта себеркедә, ә аннан соң кисәү агачында, ди. Бары тик ышаныч казангач кына, кыз аның серен алуга ирешә. Бу очракта Дию шикләнүчән һәм үтә сак эш итүче кыргый кешегә бик охшый. Ләкин серне алу әкияткә кирәк булган өчен генә эшләнә, югыйсә кыргый кеше беркайчан да чит-ят кешегә «җанының кайда саклануын» әйтмәгән, һәм аны бу серен ачарга беркем дә мәҗбүр итә алмаган.

[1] Фрэзер Дж. Золотая ветвь. Вып. I. М.–Л., 1931. С. 193–194.

Әкият герое, ахыр чиктә, Диюнең җанын кулга төшереп, аны юк итә, һәм шул вакыт Дию үзе дә һәлак була.

Дию сурәтләнгән әкиятләрнең бик сирәгендә генә бу заттан котылуның янә бер ысулы – аңардан качып китү бәян ителә. Кайбер әкиятләрдә төрле әйберләр (мәсәлән: тарак, кайрак, көзге) ташлап качу очрый. «Унөч» дигән әкияттә, мәсәлән, герой үзен куып килгән Диюнең юлына көзге ташлагач, бик зур дәрья хасил була. «Дию пәрие бу дәрьядан чыга алмый, теге якта Унөчкә бармак янап кала» (I – 89). «Унберенче Әхмәт» дигән әкияттә исә герой Дию әсирлегендәге кыз белән бергә качып барганда, Дию Әхмәт ташлаган көзгедән хасил булган диңгезгә керә, әмма аннан чыга алмый – батып кала (I – 74).

Шулай итеп, тоткынлыктагы хатын-кызны азат итү өчен герой, гадәттә, Диюне үтерә, сирәк очракларда гына тоткын кыз белән бергә аңардан кача (I – 64, 74; II – 46, 54, 65). Берничә әкияттә (I – 64, II – 54) бер Диюне үтерсә, икенчесеннән кача. Мондый качу мотивы булган сюжет алдарак бәян ителәчәк йолымчы Дию образы белән бәйле сюжетларга аваздаш булып тора (аларда герой белән кыз төрле хайваннарга һәм предметларга әверелеп качалар).

Без бер хезмәтебездә татар тылсымлы әкиятләрендә Диюнең үлеләр дөньясы хакиме буларак чагылуын бәян иткән идек инде[1]. Әмма Дию образын мөмкин кадәр тулырак тасвирлау йөзеннән биредә бу мәсьәләне кабат искә алып узарга булдык.

Диюнең башлыча кешеләрдән еракта яшәве, ул яшәгән урынның кешеләр өчен куркыныч булуы, анда барып эләккәннәрнең кире кайтмавы – тоткынлыкта җәфалануы, үтерелүе, ашалуы турында сүз булды инде. Хәтта Дию биләмәсенә җиткән кош та анда очып керергә базмый, туктап кала. Бу – әлбәттә, үлеләр дөньясының алгы чиге. Моннан соң инде Дию хакимлеге башлана. Анда керү – үлем дигән сүз. «Егет тау башында бик күп ат, адәм сөякләре күреп, хәйран-вәйран булып торганнан соң, ике кулына ике ат сөяге алып, таяк итеп таянып, тауның бер ягына таба төшеп китте»,– диелә «Ак бүре» әкиятендә (1 – 64). «Мәрмәр тавы башында» дигән әкияттә дә герой Дию биләмәсендә тирә-якта аунап яткан кеше сөякләрен күрә (II – 17). «Өч дус» әкиятендә Дию герой килгәнне аның исеннән белә: «Фу, адәм исе килә, кая ул адәм, китерегез аны миңа, хәзер мин аның көлен күккә очырам»,– ди (I – 67). Борынгы кешенең ышануынча, тере кешеләрнең исе үлеләргә үтә җирәнгеч тәэсир итә, имеш[2].

---

[1] Җамалетдинов Л. Тылсымлы әкиятләр // Татар халык иҗаты. Әкиятләр (**икенче** китап). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 10.

[2] Пропп В.Я. Исторические корни волшебнои сказки. Л.: ЛГУЮ, 1986. С. 65.

Бу күренешләрнең барысы да Диюнең үлеләр дөньясы хакиме булуы турында сөйли.

Хәлбуки Дию кайда гына яшәмәсен, нинди генә көчле булмасын, әкият герое – баһадир егет, юлда очраган теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп, аның биләмәсенә керә һәм, әйткәнебезчә, аны үтереп, кызны да, башка тоткыннарны да азат итә.

Шулай итеп, кеше бик борынгы заманнарда ук үлемсезлеккә омтылган, хыялында гына булса да үлеләр дөньясы хакимен тармар итеп, аның кулындагы кешеләрне яңадан тереләр дөньясына кайтарган.

Тылсымлы әкиятләрнең кайберләрендә Дию – бер үк вакытта асыл хәзинәләр хуҗасы да. Гадәттә Диюнең үзе яши торган сарае да затлы әйберләрдән төзелгән була. Мәсәлән, аның алтын, көмеш һәм бакыр сарайлары турында югарыда сүз булган иде. Борынгы фарсыларның ышануларында да Дию нәкъ менә җир асты байлыклары белән бәйләнгән. А.А. Семеновның бер хезмәтендә Диюләр (Дәүләр) турында түбәндәге юллар бар: «Аларның торагы – таулар эчендә, җир карынында һәм күлләр төбендә. Дәүләр анда җир хәзинәләрен (алтын, көмеш һәм кыйммәтле ташларны) саклыйлар. Дәүләр бөтен кешелекне дошман күрәләр һәм кешеләр белән беренче очрашуда аларны үтерәләр яисә үзләренең чирканыч торакларына алып китәләр»[1].

Күренә ки, фарсыларда Дию шулай ук кешеләрнең дошманы һәм ул, беренче чиратта, үлеләр дөньясы белән бәйле булырга тиеш, чөнки җир асты хәзинәләре турындагы төшенчә үлем турындагы күзаллаулардан да элегрәк барлыкка килә алмаган булса кирәк.

Инде урлаучы Дию белән бәйле рәвештә, бер күренешкә мотлак игътибар итү сорала.

Халык аңында дошман зат буларак урын алган Дию персонажы халык әкиятләрендәге дошман персонажлар белән охшашлыкта яшәгән һәм, акрынлап, аларны алыштырып та килә башлаган. Бу бигрәк тә АТ 301 А, В (Җир астындагы өч патшалык) сюжетында[2] ачык гәүдәләнә. Татар әкиятләренең бу типтагы сюжетларында патша кызларын урлаучы зат булып Үзе бер карыш, сакалы биш карыш дигән кәрлә карт сурәтләнә. Күрәсең, Дию шушы кәрләне

---

[1] Семенов А.А. Этнографические очерки Зарафшанских гор, Каратегина и Дарваза. [М.], 1903. С. 73.

[2] The Types of the Folktale. A classification and bibliography Antti Aarne's Verzeichnis der Marchentypen (FF Communications № 3). Translated and englarged byStith Thompson. 2-d rev. Helsinki, 1961 (FFC № 184).

алыштырган. Кайбер сюжетларда ул, аны алыштырмаса да, нинди дә булса йогынты ясаган. Мәсәлән, «Турай батыр» әкиятендә Үзе бер карыш, сакалы биш карыш хәзерге көнгәчә үз вазифасын саклап калган, әмма шулай да ул инде «Диюләр патшасы» дигән өстәмә «титул» алган (I – 76). Шул ук әкияттә ул «Дию», «кәрлә Дию» дип тә атала; бу очракта «Үзе бер карыш, сакалы биш карыш» дигән сүзтезмә әлеге затның ялгызлык исеменә әверелгән сыман була. Бу персонаж (кәрлә карт) катнашкан әкиятләрнең кайберләрендә исә ул «җен», «җен карты», «пәри» дип атала (I – 77), ягъни бирегә әле «Дию» төшенчәсе кереп өлгермәгән.

Кыскасы, АТ 301 А, В сюжеты белән бәйле рәвештә, татар тылсымлы әкиятләрендә урлаучы Дию образы урын алган. Калган вазифадагы Диюләр арасында урлаучы Дию сан ягыннан иң күбе булып тора.

Вазифасы җәһәтеннән икенче төркемне тәшкил итүче диюне **йолымчы Дию** дип атарга мөмкин. Диюнең бу тибы АТ 313 А, С (Тылсымлы качу) сюжетларындагы геройның антиподы ролендә очрый. Ул, башлыча, су астында яши, ятып су эчүче кешенең сакалыннан тота һәм, «дөньяда юк нәрсә»не бирүен таләп итеп, әлеге кешенең вәгъдәсен алганга кадәр, сакалын җибәрми тора. Шулай итеп, Дию үзенең корбанын йолым (выкуп) түләргә мәҗбүр итә. «Дөньяда юк нәрсә» яисә «үзең белмәгән әйбер» дигәне – әлеге бәлагә юлыккан кешенең тумаган яки туып та әлегәчә үзе дә белмәгән улы булып чыга. Таләп үтәлмәгән очракта Дию аны һәлак итәчәк: «Дөньяда юк нәрсәне бирәм дип әйт. Бирәм димәсәң, суга батырам мин сине»,– ди ул (I – 56).

Бала, туып тиешле яшькә җиткәч, Дию янына үз аягы белән бара. Диюнең максаты – егетне үтерү. Ул аңа авыр бурычлар йөкли. Бу бурычларны үтәүдә геройга шундагы тоткын кыз ярдәм итә, һәм алар, төрле нәрсәләргә әверелеп, Диюдән качып китәләр (I – 58). Бер әкияттә артларыннан куа килгән Диюне кыз, әфсен укып, тораташка әверелдерә (I – 56).

Бу сюжетның генетик тамырларына килсәк, ул тикшеренүчеләр тарафыннан шактый өйрәнелгән. Ыруглык чорында балигълык йоласын узган үсмерләр «ирләр союзы»ның тулы хокуклы әгъзаларына әверелгәннәр, һәм аларның күбесе «зур йорт»та коммуна булып яши башлаган. Формаль яктан бу союзга бала хәтта туганчы ук кабул ителгән. Моның өчен әтисе билгеле бер күләмдә түләп тә куйган. Шулай итеп, тумаган бала әлеге союзга алдан ук сатып куелган кебек булган. «Дөньяда юк нәрсә»не таләп итүче зат сурәтләнгән сюжет борынгы община төзелеше чорындагы шушы күренешнең

чагылышы дип санала[1]. Билгеле бер яшькә җиткәч, вәгъдә ителгән үсмер балигълык йоласы башкарыла торган җиргә юнәлгән, һәм бу йола бер үк вакытта союзга кабул итү йоласы да булып торган.

«Алдан сатып кую» мәсьәләсенә кайтып шуны әйтергә мөмкин: кайбер әкиятләрдә ул туры мәгънәсендә дә чагыла. Мәсәлән, «Балыкчы карт» әкиятендә Дию, бабайдан «дөньяда юк нәрсә»не бирергә ризалык алып, аның сакалын җибәргәч, бик күп балык тоттырта.

Ә икенче бер әкияттә сатып алу мәсьәләсе тагын да ачыграк сурәтләнә. Карт кеше кыяфәтендәге Дию пәрие акчага мохтаҗ кешегә «үзең белмәгән әйбер»не вәгъдә иткәне өчен, акчасы бетми торган күн янчык бирә һәм бер үк вакытта әлеге кешенең баласы үзе генә укырга тиешле хат яза: «Син, бала, шушы хатны уку белән, минем тарафка сәфәргә чык. Атаң сине миңа сатты... Бармасаң, атаңны да, анаңны да һәлак итәрмен!» Дию кулындагы кыз да шул ук язмышка дучар ителгән булган: «Ул Дию пәрие мине дә бала чагында ук сатып алган» (I – 58).

АТ 313 сюжетына корылган әкиятләрдә геройның антиподы ролендә башка персонажлар да очрый: Төрекмән бабай (I – 57), җен патшасы (II – 8), ак сакаллы карт (II – 9) һ.б. «Чүмеч» дигән әкияттә, мәсәлән, Төрекмән бабай, елгада ятып су эчүче балыкчының сакалыннан тотып, «дөньяда юк нәрсә»не таләп итә. Төрекмән бабайның халкыбыз тарихындагы бик борынгы чорга караган мифологик зат булуы мәгълүм[2]. Дию әкият сюжетындагы әнә шундый һәм шуларга охшаш персонажларны да алыштырып килә башлаган. Әлеге әкияттә су хуҗасының (Төрекмән бабайның) «Диюләр патшасы» дип аталуы да (I – 57) тикмәгә генә булмаса кирәк. Күрәсең, геройның антиподы булган бу затка, аның вазифасына дәгъва итеп, Дию «басым ясаган», ләкин традициясе нык булган Төрекмән бабай «бирешмәгән». Әмма, аны җиңә алмаса да, бу әкияттә Диюнең «эзе» калган.

Йолымчы Диюгә якын торган, аңа охшаш тагын бер Дию бар, ул да булса – **сихерче (укытучы) Дию.** Бу тип АТ 325 (Хикмәтле гыйлем) сюжетындагы адәми заттан булган сихерчене (гадәттә, «бер карт» яисә мулла) алыштырып килә. Аңа кешеләр үзләренең улларын (әкият героен) укытырга, һөнәргә өйрәтергә бирәләр. Егет анда төрле нәрсәләргә әверелергә өйрәнгәч, өенә кайтып атка әверелә һәм әтисеннән үзен саттыра. Моны юк итү максаты белән, атны сихер-

---

[1] Пропп В.Я. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 86.

[2] Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М.: Наука, 1981. С. 42.

че үзе сатып ала. Берничә мәртәбә әверелүләрдән соң, герой өстен чыга (күп очракта сихерчене үтерә).

Әнә шул сихерче кайбер әкиятләрдә Дию персонажы белән алыштырыла. «Кучер малае» әкиятендәге шундый Дию, малайның әтисе кикергәч, «нигә чакырдыгыз мине?» – дип, күл төбеннән чыга. Ул бер ел мөддәт белән малайны кеше белми торган һөнәр өйрәтергә алып кала. Су астында ике кыз «моңарга төрле-төрле һөнәрләр өйрәтәләр». Бер елдан соң әтисе улын килеп ала. Өенә кайткач, егет атка әверелә дә, әтисе аны базарга алып чыга. Дию, бер карт кыяфәтенә кереп, атны үзе сатып ала (үтерү максаты белән). Егет кача. Качып барганда ул һәм аны куучы карт (Дию), төрле кошларга һәм предметларга әверелеп, бер-берсенә һөҗүм итәләр. Ахыр чиктә егет дошманын үтерә (II – 22).

Сихерче (укытучы) Диюнең йолымчы Диюгә охшашлыгы әкиятләрнең кайбер вариантларында икесенең дә су астында яшәүләрендә генә түгел, бәлки алар хакимлегендә кызлар төркеменең булуында, әкият героеның кызлар ярдәмендә тылсымлы һөнәрләргә өйрәнүендә, шундагы бер кыз ярдәмендә һәм аның белән бергә геройның качып китүендә, Диюнең аны үтерү максаты белән төрле нәрсәләргә әверелеп кууында һәм, ниһаять, бу затның җиңелүендә яки үтерелүендә дә.

Генезис җәһәтеннән караганда, әлеге сюжетларда балигълык йоласын үтәү элементлары һәм «хатын-кызлар йорты» мотивы аралышып килә. «Хатын-кызлар йорты»ның әкиятләрдә чагылышы барлык халыкларда да бертөрле түгел. Урыс әкиятләрендә, мәсәлән, бу темага мәгълүмат бик аз[1], татар әкиятләре исә бу җәһәттән бөтенләй тикшерелмәгән.

Дию персонажы, әйткәнебезчә, әкият героеның антиподы вазифасындагы башка персонажларны алыштырып килә. Хәтта әле генә мисал итеп китерелгән «Кучер малае» дигән әкияттә дә ул, беренче мәртәбә телгә алынганда, җен дип аталган, шуннан соң гына сүз Дию буларак дәвам иттерелә.

Шулай итеп, популярлыгы үсә барган бу персонаж әкият сюжетларында әледән-әле яңа вазифалар яулый барган.

Диюнең янә дә бер вазифасы аның кемнеңдер буйсынуындагы хезмәтче сыйфатында булуы. **Хезмәтче Дию** образы бик күп әкиятләрдә очрый.

Менә «Өч күгәрчен» дигән әкияттән бер өзек:

---

[2] Пропп В.Я. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 124.

«Төн урталары җитеп, бөтен кеше йокыга китү белән, бу егет күгәрченнәрдән алып кайткан камчысын алып чыгып, бер генә селтәп җибәрә. Селтәп җибәрүе була, җир йөзендәге пәриләрнең нибары моның каршысына килеп басып:

– Ни боерасың?– дип сорыйлар моннан.

Егет әйтә:

– Таң атканчы патша сараеннан да яхшырак итеп миңа бер сарай салыгыз, ди. Патша сарае белән безнең сарай арасында алтын күпер булсын, ди. Аның өстеннән алтын буяулар белән буятылган машиналар йөреп торсын, ди...

Патша иртә белән торып чыкса, ни күзе белән күрсен: моның сараена каршы якта бик матур итеп бер сарай салынган. Ике сарай арасында ялт иткән зур күпер төзелгән, күпер өстеннән машиналар ялт-йолт итеп кенә узып торалар» (II – 13).

Менә болар инде – чын мәгънәсендә хезмәтче Диюләр.

Биредә мөһим бер мәгънә булуын да билгеләп узыйк: төзүче Дию образы Диюнең әкиятләрдә мәдәни герой буларак чагылуы дип кабул ителергә тиеш. «Шаһнамә»дә сурәтләнгәнчә, кешеләр өчен беренче торакларны нәкъ менә Диюләр төзегән.

Сүз уңаенда шуны да әйтик: Хорезм оазисы үзбәкләренең мифларында да Диюләр ныгытма һәм шәһәрләрне төзүчеләр буларак сурәтләнә.

Хезмәтче Диюләр (гадәттә алар күпсанлы була) әкият героеның (яисә аның антиподының) әмерен үтәп, тиз арада авыр бурычны башкаралар (төзиләр, шәһәрне камыйлар, кешеләрне бер мизгелдә ерак араларга күчерәләр, качучыны эзәрлеклиләр, сакта торалар, игенче эшен башкаралар, урман кисәләр һ.б., һ.б.). Хезмәтче диюнең үз карашы, үз позициясе юк, хуҗасы нәрсә кушса, шуны үти; явыз көчкә хезмәт итсә, әкияттә ул – тискәре образ, яхшы затка хезмәт итсә – уңай образ була.

Диюнең тагын бер тибы Дию белән кеше арасындагы үзенчәлекле мөнәсәбәттә ачыклана. Бу мөнәсәбәт кешенең Диюне «төп башына утыртуы» белән билгеләнә. Мәсәлән, «Унөч» дигән әкияттә герой, патшаның таләбен үтәү йөзеннән, «Диюнең айгырын урларга бара. «Ят кешене күргәч, айгыр бик яман кешни». Герой печән астына яшеренгәнлектән, Дию пәрие, ике мәртәбә чыгып караса да, берни сизми, «нәрсәгә шулхәтле акырасың, беркем дә юк бит!» – дип, айгырны битәрли. Шуннан соң: «Алдакчы икәнсең син. Моннан соң кешнәсәң дә чыкмам инде», – дип кереп китә. Герой исә, Диюнең айгырына атланып, биредән чыгып кача (I – 89).

Диюнең бу тибын без **аңгыра Дию** дип атыйбыз.

Шул ук «Унөч» дигән әкияттә геройга Дию пәриенең юрганын урлау бурычы да йөкләнә. Егет Диюнең өенә оясы белән кырмыска кертеп ташлый. Йокларга яткан Дию, юрган борчалаган дип, ятагыннан юрганын тибеп төшерә. Геройга шул гына кирәк тә: сиздермичә генә алып, өенә кайтып китә.

Геройның үлүе турында ишеткәч, Дию, шатлыгыннан, табут ясаучыга ярдәм итә башлый. Әлбәттә, ул табут ясаучының шул ук герой икәнен башына да китерми. Табутның ныклыгын сынап карау өчен кертеп яткырылган Дию пәриен герой, табутның капкачын ябып, кадаклап, патшага алып кайтып бирә (I – 89).

Яисә шул ук әкияттән тагын бер эпизод. Бер күзле Дию карчыгының («Дию пәриенең түтәе») ике күзле буласы килә. Геройга (Унөчкә) әйтә: «Миңа тагын бер күз куй алайса»,– ди. «Унөч карчыкның чәчләреннән бик нык итеп баганага бәйләп куя. «Син, түтәй, күз куйганда тапырчынма, күз кую уен түгел ул»,– ди. Тимерне кыздыра да карчыкның сыңар күзенә китереп баса, карчыкның күзе чәчрәп чыга» (I – 89).

Бу сюжет икенче бер яктан да игътибарга лаек: әкияттәге сыңар күзле Дию карчыгы Гомернең «Одиссея» поэмасындагы циклопка охшаш. Әкият герое Унөч әлеге поэма герое кебек үк үзенең дошманыннан хайван ярдәмендә котыла (АТ 1137). Әкият болай дәвам итә: «Карчык чәчләрен умырып баганадан ычкына да, кармаланып, Унөчне эзләргә тотына. Унөч тә бик хәйләкәр егет бит. Ишек алдында карчыкның кәҗә тәкәсе йөри икән, Унөч шуның астына керепябыша. Әлеге карчык ары сугылып, бире сугылып тузынып йөри-йөри дә, Унөчне тапмаган ачудан, кәҗә тәкәсен капка аркылы тотып ыргыта». (Искә төшерик: Гомер поэмасында Одиссей мәгарәдәге Полифемнан озын йонлы сарыкның корсак астына ябышып чыгып котыла). Казакъ галиме Е. Турсунов карашынча, бу сюжет, борынгы төркиләр тарафыннан дуалистик миф шәкелендә сөйләнеп, скифлар аша грекларга күчкән һәм грек авыз иҗатыннан «Одиссея»га килеп кергән[1].

Тылсымлы әкиятләрдә аңгыра Дию тибы урын алса да, бу образ башлыча көнкүреш әкиятләренә хас. Чөнки татар фольклористикасында АТ 1000–1199 типларына кергән әсәрләр (Аңгыра җен турындагы әкиятләр) көнкүреш әкиятләре рәтендә йөри. Мәсәлән, «Диюләрне җиңгән» дигән әкияттә Дию, кешене үтерү максаты белән кайбер хәйләле гамәлләр кыла. Әйтик, кунак кешене йокыга

---

[1] Турсунов Е.Д. Генезис казахской бытовой сказки. В аспекте связи с первобытным фольклором. Алма-Ата: Наука, 1973. С. 167.

яткыргач, моның ятагына өске каттан тегермән ташы төшерә. Моны алдан ук сизенгән әлеге кеше, урыныннан торып, читкәрәк киткән була. Иртән ул: «Киленегезнең орчык башы өстемә төшкән иде дә, мин аны аяк очынарак куеп йокладым», – ди. Икенче төнне кунакның өстенә кайнар су коя. Ләкин кеше, алдан ук сизенеп, урынына чыралар куеп, читтән генә карап тора. Иртән торгач: «Бик тыныч йокладым, тик бераз җылы яңгыр гына сибәләп үтте»,– ди. Диюләр бик нык гаҗәпләнәләр. Герой исә, Диюләрнең берсенә атланып, үзен өенә кадәр илттерә, җитмәсә әле берьюлы юлда очраган ауган чыршы агачын һәм аунап яткан тегермән ташын да күтәртеп кайта. Шуннан соң аның үзен (Диюне), пешереп ашау белән куркытып, качып китәргә мәҗбүр итә[1].

Күргәнебезчә, аңгыра Дию – шулай ук кешегә дошман зат. Кешене ул хәйләләп үтерергә тели. Ләкин кеше аңа караганда да хәйләкәррәк, үткенрәк итеп сурәтләнә. Бу очракта Диюнең җиңелүгә дучар булуы, беренче чиратта, аның аңгыралыгы белән бәйле.

Аңгыра Дию белән бәйле сюжетларның генезисы капма-каршы сыйфатларга ия булган ике туганның берсе, икенчесеннән көлеп, аны төрле трюклар ярдәмендә «төп башына утыртуын» күрсәтүгә корылган борынгы дуалистик мифлар традициясе белән бәйле. Соңрак аларда тиле һәм тәҗрибәсез туган образын мифик персонажлар алыштырган[227].

Инде Дию персонажының алда бәян ителгән төркемнәреннән аерылып торган үзенчәлекле бер тибына тукталыйк. Ул – **ярдәмче Дию.**

Ярдәмче Дию әкият героена юлда очрый. Ул башлыча Диюнең хатыны яисә анасы, яисә геройның җизнәсе тиешле Дию булып чыга. «Җыланчай» дигән әкияттә тугыз башлы Диюнең карчыгы (хатыны) сәфәргә чыккан кызга сүзе, киңәше белән ярдәм итсә, унике башлы Диюнеке аңа тылсымлы әйберләр (камчы, тарак, беләү, көзге) һәм бер ат бирә. Әмма биредә күпбашлы Диюләрнең үзләрен дә ярдәмчеләр дип атарга нигез бар, чөнки алар кызга бернинди дә усаллык эшләмиләр, киресенчә, ярдәм итәргә тырышалар (I – 48).

«Тәмәке янчыгы» дигән әкияттә герой юлыккан карчык исә күпбашлы өч Диюнең анасы булып чыга. Урланган апаларын эзләргә дип юлга чыккан герой урман эчендәге бер зимләнкәгә җитә. «Ул зимләнкәгә керсә, бер карчык яткан: аскы теше белән түбәгә, өске

---

[1] Татар халык әкиятләре / Төзүче, кереш мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче Ленар Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 395–396.

[2] Бу турыда кара: Турсунов Е.Д. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 15, 19, 27.

теше белән идән тактасына терәлеп яткан. «Әйдә, әйдә, кода килгән икән», – дип каршы ала егетне. Бу теге егетләрнең (геройның апаларын көчләп алып китүчеләрнең. – *Л.Ж.)* анасы Дию карчыгы була инде».

Игътибар итик: герой юлыккан затның портреты таныш сыман. Әйе, ул – убырлы карчык портреты. Әмма бу юлы ул безгә Дию карчыгы дип тәкъдим ителә, ягъни убырлы карчык вазифасында – Дию карчыгы. Шулай итеп, биредә дә алыштырылу күренешенә тап булабыз.

Әлеге шул Дию карчыгы әкият героена аның апалары яши торган җиргә юл күрсәтеп җибәрә. Ә җизни тиешле өч Диюнең һәркайсы геройга бирәр тәмәке янчыгы бүләк итә. Янчыкны ачканда өстәлгә төрле ризыклар чыгып тезелә, япканда бары да кире кереп бетә. Киләчәктә геройга мондый бүләкләр бик ярап куя (I – 75).

Кайбер әкиятләрдә Дию карчыгы геройның иминлеген тәэмин итү чарасын күрә: аны Дию ашамасын өчен, үзенең танышына хат язып җибәрә. Хатта: «Син бу баланы исән-сау калдырырга тырыш. Ничек булса да Диюгә ашатма!» – диелә (I – 58).

«Дутан батыр» әкиятендә исә ак Дию персонажы бар, ул – Дию-чал. Бу Дию чал сакаллы карт кеше кыяфәтендә. Әкият герое һәм аның юлдашлары бу картка: «Бабай, нишләп йөрисең болай?» – дип дәшәләр. Дию карты бик көчле булса да, гәүдәсе кешенекеннән зур түгел. Ул ун-унбиш йортлы гына Диюләр авылында су буендагы өендә яши. Бала-чагалары бар. Һөнәре дә изге: тегермәнче икән. «Балалар бар барын да, яшьрәкләр әле»,– ди әлеге Дию, янәсе аларга әле зур эшләр тапшырып булмый, шуңа күрә барлык хуҗалык эшләрен үзенә башкарырга туры килә. Ул юлаучыларны өенә алып кереп сыйлый, хәлләрен сораша. Соңыннан аларга ияреп сәфәргә чыга, геройга ярдәм итә (патшаның батыры белән көрәшеп, аны җиңә һ.б.).

Бу да – ярдәмче Дию. Күренә ки, аның тышкы яктан кешедән аермасы юк, «диюлеге» дә физик яктан бик көчле булуында гына («Бер озын имәнне бөтен буе белән бер җилкәсенә күтәргән, икенче кулына зур бер тегермән ташын алган», I – 88).

Дию-чал болай ди: «Ташу вакытында шәп ташу килеп, тегермәннең ташын ваттырды, орчыгын сындырды. Ун көннән бирле бер тауда тегермән ташы ясадым».

Әкияттән күренгәнчә, бу Диюнең бернинди кодрәте дә юк, яшен яшьнәтеп, күк күкрәтеп, давыл чыгара алмый, хәтта тегермән ташын ясарга да аңа ун көн вакыт кирәк булган. Ягъни ул гади кешедән берни белән дә аерылып тормый.

Бу ни өчен шулай? Шушы урында борынгы чорга күз ташлап алыйк.

Зәрдөштлекнең (зороастризмның) изге китабы Авестаны (III–VII йөз) тикшереп, Дармстетер дигән автор өч томлы хезмәт язган һәм аны 1892–1893 елларда Парижда бастырып чыгарган. Менә шул автор әйтә: Авестадагы Мазан диюләре – алар Мазандерандагы (Мазан ул вакытта шулай аталган) аборигеннар, ягъни иранлы булмаган ярымкыргый кабиләләр, ди[1].

Фирдәүсинең «Шаһнамә»сендә дә (XI йөз) Диюләр шулай ук чит ил кешеләре һәм хәтта потларга табынучылар буларак сурәтләнә.

Диюләрнең әнә шулай кеше буларак күзаллануы әкиятләрдә дә чагылмый калмаган.

Татар әкиятендәге ак Диюгә, ягъни чал Диюгә килсәк, ул, әйткәнебезчә, нәкъ кеше итеп сурәтләнә. Ул бәлки кешедер дә, әйтик, Дию исемле «бер карт»!? Ни өчен Дию? Тагын тарихка күз салыйк.

Борынгы һиндләрдә брахманчылык җәелгән чорда чын аскет Алла сыйфатларына ия була ала, дигән караш яшәгән. Бу дәвердә «Дию» атамасы брахманнарның исемнәренә дә кушылып йөртелгән. Патшаларга бигрәк тә. Чөнки алар җирдәге Алла дип игълан ителгән. Шуннан соң күктәге Аллаларның әһәмияте кими.

«Дутан батыр» әкиятендәге Дию-чал образы әнә шул борынгы чор күренешенең үзенчәлекле чагылышы дип фараз кылырга да нигез бар. (Сүз уңаенда әйтеп узыйк, нугайларда, мәсәлән, Дию исемле бер батыр морза булган). Әмма әкияттә дошман Диюдән аеру өчен бу очракта «ак» эпитеты кулланыла (дөресе: чал). Чөнки бу – яхшы Дию, рәхимле Дию, эшләп көн күрә, кешегә ярдәм итә. «Ак» дигән сүз татарда пакьлек, чисталык, керсезлек, намуслылык символы булып йөри. Ф. Урманче бу образны нәкъ шулай тикшерә дә[2].

Ак Дию – сирәк очрый торган зат. Ул Дию персонажының да, елан һ.б. кайбер персонажлар кебек үк, дуалистик хасиятен, ягъни аның борынгы дәвердә уңай образ булганлыгын, алай гына да түгел, ак (чал) эпитетына бәйләп хөкем йөрткәндә, аның изге, илаһи зат булганлыгын абайларга мөмкин.

Таҗик мифологиясендә һәм Төрекмән дастаннарында да рәхимле Диюләрнең төсе ак. Таҗикларда ул Дэви Сафед дип атала («Ак Дию» яисә «Ак Алиһә»). Күренә ки, Ак Дию Алла мәгънәсендә йөри. Ул җеп эрләүчеләрне канат астына алучы Дию, шуңа күрә хатын-кызлар аңа җомга көнне кадер-хөрмәт күрсәтәләр, ул көнне

---

[1] Короглы Х.Г. Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983. С. 35–36.

[2] Урманчеев Ф.И. По следам Белого волка. Казань: ИЯЛИ, 1994. С. 76–89.

ял итәләр һәм аның хөрмәтенә камыр аш пешерәләр[1]. Бу, күрәсең, Диюнең соңгы көнгәчә сакланып калган иң борынгы чордагы дәрәҗәсенең чагылышыдыр, бәлки әле бердәнбер очрагыдыр.

Әрмән мифологиясендә һәм эпосында да ярдәмче диюләр очрый[2].

Сүз уңаенда шуны да әйтик, «Шаһнамә»дә дә Ак Дию һәм Кара Дию бар. Әмма анда «ак» эпитеты бездәге мәгънәдә йөрми. Рөстәм Кара Дию белән дә, Ак Дию белән дә сугышып, аларны җиңә.

Диюләрне бер үк халыкның рухи иҗатында һәм уңай, һәм тискәре итеп сурәтләү аларга карата төрле дәвердәге карашларның чагылуы нәтиҗәсе. Бу – халыкның телдән-телгә тапшырылып килә торган рухани иҗаты. Диюнең мифологик сыйфатлары да шул юл белән таралган. Инде аны кешеләш– терү (антропоморфизм) язма чыганаклардан килә. Филология фәннәре докторы Рифгать Әхмәтҗанов карашынча, татардагы «Дию» дигән исем-сүз шулай ук язма традиция белән бәйле[3].

Диюләрнең рәхимлелеге турындагы күзаллаулар бигрәк тә Урта Азия халыкларының мифларында сакланып калган. Мәсәлән, Хорезм үзбәкләренең мифларында Диюләр – ныгытма һәм шәһәрләрне төзүче затлар. Үзбәк, казакъ, кыргыз шаманнарының мифларында Диюләр – яхшы рухлар, шаман ярдәмчеләре[4].

Шунысын да әйтик, Дию халык хәтерендә, мифологик персонаж буларак, үзбәкләрдә генә киң таралган. Ә калган төрки халыкларда ул, нигездә, әкият образы буларак билгеле. Безнең карашыбызча, К.Насыйри да Дию пәрие турындагы күзәтүләрен[5] әкият материалы буенча язган.

Җыеп әйткәндә, татар әкиятләрендәге Дию образы – катлаулы образ. Ул берничә катламнан тора. Әлеге катламнар Дию персонажының вазифаларына нисбәтле. Шушы вазифалар җәһәтеннән тылсымлы әкиятләрдә Дию образы алты төркемгә аерымлана. Алар түбәндәгеләр:

1. **Урлаучы Дию.** Ул Диюләрне явыз көч итеп сурәтләүче борынгы фарсы мифологиясенә аваздаш. Күләме белән иң зур катлам.

2. Физик яктан какшап та, кешегә каршы көрәштән баш тартмаган, әмма көрәшнең бүтән, «дәрәҗәсез» ысулын сайлаган **йолымчы Дию.**

---

[1] Мифы. С. 418.
[2] Шунда ук.
[3] Ахметьянов Р.Г. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 23.
[4] Мифы. С. 418.
[5] Насыйри К. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 54–56.

3. Шундый ук халәттәге һәм кешегә каршы көрәштә шундый ук «дәрәҗәсез», әмма икенче бер ысулны хуп күргән **сихерче (укытучы) Дию.**

4. Кодрәте беткән, бары тик астыртын, хәйлә ысулы белән уңышсыз, пассив көрәш кенә алып баручы куркак һәм буйсынучан **аңгыра Дию.**

5. Мөстәкыйльлеген югалтканлыктан, ихтыяры калмаган, хуҗасы нәрсә кушса, шуны үтәүче **хезмәтче Дию.**

6. Борынгы һинд мифологиясе һәм һинд тормышы белән аваздашлыкның чагылышы буларак **ярдәмче Дию.** Әкияттә бу образның пәйда булуын күктәге Диюләргә һөҗүмнең беренче этабы дип күзалларга мөмкин. Әмма һөҗүм башланса да (Дию инде күктән җиргә төшерелгән), сюжетта әле Дию белән конфликт чагылмый.

Үлеләр дөньясы турындагы күзаллаулар белән бәйле урлаучы, йолымчы һәм сихерче Диюләрнең гамәлләреннән, беренчесенең исә күп кенә әкиятләрдә үлеләр дөньясы хакиме буларак сурәтләнүеннән бу Диюләрнең (шулай ук калган башка вазифалардагы Диюләрнең дә) тылсымлы әкият сюжетларындагы шундый ук вазифаларны башкарган элгәреге персонажларны алыштырып, алар урынында килгәнлекләре аңлашыла. Чөнки әлеге сюжетларның кайберләрендә Дию ролендә башка затларны да очратырга мөмкин.

Дию вазифаларының күпчелеге кешегә каршы юнәлтелгән гамәлләр булганлыктан, Дию татар фольклорында, гомумән, явызлык символына әверелгән, ә ярдәмче Дию образы исә кешенең рухани иҗатында бу зат белән бәйле иң борынгы катламның бүгенге көнгәчә килеп җиткән кечкенә генә бер реликты булып саклана.

## Образы змея и подобных ему персонажей в татарских сказках

В татарских волшебных сказках видное место занимают мифологические образы змея (елан) и связанных с ним аждахи (аждаhа) и юхи (юха). Мы попытаемся выяснить функции и особенности этих образов. Фактическим материалом служат 116 волшебных сказок, опубликованных в I и II книгах многотомного свода татарского фольклора[1].

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр (беренче китап) / томны төзүчеләр, искәрмәләрне хәзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан, 1977; Татар халык иҗаты. Әкиятләр (икенче китап) / томны төзүчеләр, искәрмәләрне хәзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан, 1978.

**Змей.** Древнейший персонаж мифологии змей характерен для сказок разных народов мира. Среди фантастических персонажей татарских сказок он уступает в популярности только дэву (дию). Образ этот имеется в 15-ти сказках из 116 (13%).

По функциям В.Я. Пропп разделяет русских сказочных змеев на четыре разряда: 1) Змей-похититель; 2) Змей, занимающийся поборами («поборы змея»); 3) Змей-охранитель границ; 4) Змей-поглотитель[1]. Данная классификация мало соответствует татарскому сказочному материалу. В роли змея-похитителя в татарских сказках чаще всего выступает дэв (реже аждаха; гигантская птица). Змей, занимающийся поборами, встречается очень редко[2], Эту функцию, как правило, выполняет аждаха. Что касается змея-охранителя и особенно нарушителя границ[3], то в такой роли опять выступает дэв. А змей-поглотитель героя в татарских сказках не встречается. Н.В. Новиков предложил дополнить классификацию В.Я. Проппа пятым разрядом сказочных змеев – змей-соблазнитель[4]. Но в татарских сказках функцию соблазнителя выполняет юха.

В татарских волшебных сказках образы змеев по функциям можно разделить только на три типа: 1) Змей-помощник; 2) Змей-охранитель; 3) Змей, требующий девушку.

Прежде чем рассмотреть в отдельности эти типы, отметим примечательные черты облика, особенности повадок, характер чудесных способностей татарских сказочных змеев. Встречаются белые змеи (в 5-ти случаях), черные (3), красные (1), зеленые (1), а также огненные (ут еланы). В большинстве же случаев о цвете змеев не упоминается. В отличие от русских сказок, для которых характерны многоголовые змеи[5], в татарских сказках чаще всего действуют одноголовые. Герой татарской волшебной сказки сталкивается со змеем на берегу Вера или реки (4), в лесу (3), под деревом или на дереве (1), н яблоневом саду (1), близ города (1), в подземном мире (1), – находясь в пути (2) или только что родившись (1). Когда имей является эпизодическим персонажем, о месте его обитания обычно не сообщается. При появлении водяного змея становится темно, начинается буря, поднимаются огромные полны. Змей иногда

[1] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. Л., 1946. С. 199–201.

[2] Змей, требующий девушку для съедения, встречается только в одной опубликованной татарской сказке. А змей, требующий себе девушку для супружества, почти в каждом случае впоследствии превращается в прекрасного джигита.

[3] См.: Новиков Н.В. Образы восточнославянской волшебной сказки. Л., 1974. С. 185.

[4] Новиков Н. В. Указ. соч. С. 189.

[5] Пропп В.Я. Указ. соч. С. 197.

рождается в человеческом облике, он способен летать, катиться, свернувшись клубком, обвиться вокруг человека или какого-нибудь предмета. Может превращаться в красивую девушку или красивого юношу. Может быть любовником или мужем женщины. Из сказок также видно, что у змеев есть свои падишахи.

**Змей-помощник.** Помогает попавшему в беду герою силой волшебства (благодаря змею, герой добивается желаемого), чудесными дарами (дарит чудесную рубашку, шапку, саблю, платок, коня и т.п.) и даже приносит себя в жертву ради его исцеления (в сказках мясо змея, вода, в которой он варился и пепел сожженного змея наделены целебными свойствами).

Образ змея-помощника, дарителя характерен для сказок народов Востока[1]. Это связано с тем, что в древности бытовал культ змея как родо-племенного тотема. Часто в роли сказочного помощника, дарителя выступает белый змей. Согласно фольклорной традиции эпитет «белый» символически подчеркивает светлое, положительное в характере персонажа.

**Змей-хранитель.** Встречается в сказках редко. Это – персонаж эпизодический: охраняет владения дэва или его душу. Он представляет опасность для героя как слуга враждебного ему дэва.

**Змей, требующий девушку,** обычно для супружества. (Для съедения – крайне редко; в этом случае змей ярый враг человека; герой сказки, спасая девушку, вступает с ним в бой и уничтожает его). Змей, требующий девушку для супружества (в трех сказках), женится на ней, и после этого выясняется, что он был заколдованным в змея джигитом. Снова становится он человеком, живет мирно.

Как видим, в сказках образ змея может быть и положительным и отрицательным. Двойственность его изображения объясняется не одинаковым отношением к змею на различных исторических этапах. В первобытном обществе змей был почитаем как тотемное животное, позднее он получил в фольклоре трактовку как образ, олицетворяющий темные, грозные силы природы, а затем угнетателя, насильника, врага народа[2].

На основании еще недавно бытовавших поверий можно предположить, что культ змея существовал и у татар. Примечательно в данном отношении поверье о йорт еланы (домашнем змее), который не вредил людям, а наоборот, покровительствовал данной семье, заботился о ее благополучии[3], а также поверье, что змей выгоняет

---

[1] Каскабасов С.А. Казахская волшебная сказка. Алма-Ата, 1972. С. 154.

[2] Сакали М. А. Туркменский сказочный эпос. Ашхабад, 1956. С. 54.

[3] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967. С. 354.

лихорадку[1]. К тому же примечательно, что предки татар – волжские булгары – доброжелательно относились к змеям, их не убивали[2]. А источники более позднего времени, относящиеся к периоду Казанского ханства, уже свидетельствуют о том, что уничтожение змеев считалось богоугодным делом[3]. Превращение в процессе развития фольклорного творчества образа змея «из покровительственного и охранительного... в олицетворение враждебного начала» обуславливалось ростом монотеистических тенденций в религиях[4], в данном случае укреплением роли ислама. Поэтому неслучайно, что мотивы змееборства особенно распространены в татарских исторических преданиях об основании города Казани[5].

Итак, змей как положительный тип в татарских волшебных сказках встречается относительно часто и выполняет в основном функции помощника, дарителя. Как отрицательный тип змей (в большинстве случаев это персонаж эпизодический) имеет функцию охранителя и весьма редко является пожирателем девушек. Пожиратель девушек в татарских сказках – это прежде всего аждаха, и с ним, а не со змеем вступает обычно в единоборство герой, хотя ему приходится иногда сталкиваться со змеем-охранителем и змеем-людоедом.

**Аждаха** – одноголовый или многоголовый дракон (ажи – по-персидски дракон), огромное ящероподобное или змееподобное крылатое чудовище. Персонаж этот встречается в 11 из 116 опубликованных в своде татарского фольклора волшебных сказок. Восходит к мифологии древнего Востока и известен по «Авесте», где изображается борьба с трехглавым Ажи-Дахакой витязя Траэтаона[6].

---

[1] Насыров Каюм. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки императорского русского географического общества по отделению этнографии. Т. VI, 1880. С. 245.

[2] Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу / перевод и комментарий под редакцией академика И.Ю. Крачковского. М.–Л., 1939, с. 72.

[3] Мөхәммәдъяр. Төхфәи Мәрдән. Нуры содур / төзүчесе Ш. Абилов. Казан, 1966. С. 100 (на татарском языке).

[4] См.: Валеева Д.К. Искусство волжских булгар (Х – начало XIII вв.). Казань, 1983. С. 41.

[5] В сборнике М.А. Васильева «Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды» (Казань, 1924) сюжет о змееборстве встречается довольно часто. Это, вероятно, объясняется неточностью перевода с татарского языка на русский: смешением змея с аждахой. Ни в одной из 43-х волшебных сказок сборника Васильева нет даже упоминания об аждахе. Между тем оригиналы этих сказок на татарском языке, которые могли бы подтвердить смешение переводчиком понятия об аждахе с понятием о змее, не найдены.

[6] Литература древнего Востока. М., 1971. С. 118.

В фольклорной традиции; татарского и ряда других тюркоязычных народов образ аждахи отчасти слился с образом змея, иногда даже именуется аждахой-змеем (аждаһа-елан). В сказках сибирских татар в роли аждахи действует чудовищный йельбегэн (йельбегән). У тюркоязычных народов бытовало поверье, что змей, проживший сто лет, обретает способность превратиться в аждаху, а тот, достигнув тысячелетнего возраста, превращается в юху-оборотня[1]. По сведениям А.Г. Бессонова, относящимся к башкирским сказкам, способны к таким чудесным превращениям лишь змей и аждаха ни разу не видевшие человека[2].

**Аждаха, требующий девушку.** В сказках типа «Шесть чудесных товарищей» (АТ 513 А) он охватывает своим извивающимся длинным туловищем путников, которые остановились на ночлег у реки. Соглашается освободить их с условием, что герой приведет к нему дочь падишаха. Но она не достается аждахе, а становится женой героя.

**Аждаха-поглотитель.** В сказках типа «Освободитель царевны» (АТ 300) и «Два брата» (АТ 303) нередко аждаха лишает людей их водного источника, вынуждает падишаха согласиться ежедневно отдавать ему на съедение по девушке[3]. Очередь доходит и до дочери падишаха. Он обещает ее руку и половину царства тому, кто победит чудовище. Аждаха появляется с шумом, иногда прилетает. Из его пасти пышет пламя, он может втянуть свою жертву в пасть с расстояния трех верст. Увидев вместе с дочерью падишаха героя, радуется, что съест двух человек, вместо одного. Герой одолевает и убивает аждаху, освобождает царевну. В сказке «Сын падишаха, его сестра, тигр и другие» из второй книги сказок «Татар халык иҗаты» (текст № 27. АТ 315+отчасти АТ 300) джигит после удара двухголового аждахи увязает по колени в землю, а после удара четырехголового – по шею. Победить аждаху в этой сказке герою помогает тигр; в сказках АТ 303 – другие благородные звери.

В фольклоре некоторых народов аждаха иногда выступает на стороне положительного героя[4]. Однако в татарских и башкирских сказках этого нет.

---

[1] Насыров К. Указ. соч. С. 245–246.

[2] Башкирские народные сказки / запись и перевод А.Г. Бессонова, под редакцией Н.К. Дмитриева. Уфа, 1941. С. 192.

[3] Переговоры аждахи с падишахом о принесении ему в жертву девушек остаются за пределами сказки, т.е. воспринимаются как происходившее ранее.

[4] Короглы Х.Г. Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М., 1983. С. 49.

В волшебных сказках татар и других тюркоязычных народов есть еще один змееподобный персонаж – **юха.** Об этом образе мы судим по трем опубликованным сказкам, где он встречается. Обычно он называется юха-змей (юха-елан).

В сказках отразилось поверье о происхождении юхи от аждахи. Например, в сказке «Рубашка, сплетенная из цветов» повествуется о том, как аждаха превратился в красивого юношу. Юха, злобный враг человека, действует не так открыто, как аждаха. Превратившись в красивую девушку (иногда в красивого юношу), вступает в брачную связь с человеком, и тот чахнет. По поверьям, человек, сожительствующий с юхой, чахнет от того, что юха сосет кровь. Сказки это прямо не подтверждают и не отрицают. Согласно же поверьям и сказкам, юха не может жить без воды. Если нет воды, юха, находясь в постели человека, своим длинным языком облизывает окна. То, что юха встречается с людьми обычно у реки и проруби, говорит о том, что он связан с водной стихией. К. Насыров относит его к существам, обитающим в воде[1]. Особой приметой юхи является отсутствие на теле пупка. Как отметил К. Насыров, конечная цель брака юхи-девицы с человеком состоит в том, чтобы съесть последнего[2]. В исследованных нами татарских сказках это свойство юхи-девицы незаметно. Но характерно проявляется в сказках стремление уничтожить человека (мужчину) юхой-джигитом. Ему в этом помогает женщина, с которой тот входит в близкие отношения. Именно такое выражение получает функция юхи как соблазнителя. В названной выше сказке «Рубашка, сплетенная из цветов» юха-джигит подстрекает соблазненную женщину, чтобы она тайно принесла ему чудесную рубашку мужа. Добившись своей цели, пожирает обессилевшего мужа, начинает жить с его женой. Юха – существо коварное и лицемерное. Юха-девица выходит замуж, утаив свою сущность. Нередко притворяется сироткой. Поэтому подлизу и лицемера у татар называют юхой. Герой сказки не может бороться против своей жены-юхи. Юха-жена явно сильнее его. От нее можно избавиться, только заперев ее в чугунной бане и обварив горячим паром. Умирая, юха обретает свою исконную сущность – превращается в змею.

Если превращение змея в человека в сказках означает его внутреннее обновление, то превращение аждахи в юху, имеющего облик человека, является лишь маскировкой античеловечности, служит во вред людям.

---

[1] Насыров К. Указ. соч. С. 244.
[2] Насыров К. Указ. соч. С. 246.

Итак, в татарских волшебных сказках змей в большинстве случаев изображается как помощник человека, даритель, а аждаха и юха – только как его чудовищные враги.

## Алтын медальле экиятләр

Ленинградтагы Рус география җәмгыяте архивында моңарчы безгә мәгълүм булмаган татар фольклоры материаллары табылды. Нәтиҗәдә халык җәүһәрләре хәзинәсенә 61 экият һәм 22 мәзәк өстәлде. Аларны моннан 100 еллар элек татарлар яши торган төрле төбәкләрдә А.Г. Бессонов язып алган.

Мәгълүм булганча, татар фольклорын җыю һәм өйрәнә башлау чорында рус һәм чит ил галимнәре зур эшчәнлек күрсәткәннәр. XIX гасырда эшләгән әнә шундый галимнәрдән М.И. Иванов, В.В. Радлов, В.Н. Витевский, Н.Ф. Катанов, П.А. Поляков, Г. Балинт, Һ. Паасонен исемнәре безгә яхшы таныш. Һәм менә шулар рәтенә А.Г. Бессонов исеме дә өстәлде.

Александр Григорьевич Бессонов 1848 елда Вятка (хәзерге Киров) шәһәрендә рухани гаиләсендә туа. 1877 елда Казанда духовная академия тәмамлый. Үсмер чагында ук татар һәм удмурт телләрендә иркен сөйләшә.

Укуны тәмамлагач, ул төрле өязләрдәге шәһәрләрдә (Уржум, Оренбург, Красноуфимск, Орск, Верхнеуральск һ.б.) башта укытучы, аннан соң мәктәпләр, училищелар буенча инспектор булып эшли. Шул чорда ул башкорт һәм казакъ телләрен дә өйрәнеп, халыктан татар, башкорт һәм казакъ фольклоры әсәрләрен язып ала башлый. Аның игътибарын бигрәк тә экиятләр җәлеп итә. Аларны ул кайсы телдә сөйләнсә, шул телдә рус транскрипциясе белән яза, ә соңыннан рус теленә тәрҗемә итә.

А.Г. Бессонов – һәвәскәр фольклорчы. Аның юридик һәм материаль таянычы булмаган. Ул нинди дә булса фәнни оешманың вәкиле булмаганлыктан, үз хисабына йөри. Өстәвенә А.Г. Бессоновның авылдан-авылга йөреп «кара» халык белән эш итүе полиция властьларына аңлашылмый, аны кайвакыт тоткарлап, шәхесен ачыклау очраклары да була.

А.Г. Бессонов экиятләрне үзе эшләгән төбәкләрдә 30 елдан артык вакыт эчендә туплый. Ләкин, күпме генә тырышмасын, үз гомерендә бер экиятен дә бастыра алмый. Шулай да игелекле эшен дәвам иттерә.

1909 елдан А.Г. Бессонов Вятка губернасының Яранск өязе Кукарка бистәсендә (хәзерге Советск шәһәре) урнашкан укыту-

чылар семинариясе директоры булып эшли башлый. Шул елны ул үзе җыйган фольклор материалларын Петербургка Рус география җәмгыятенә илтеп таптыра.

Күренекле тюрколог А.Н. Самойлович А.Г. Бессонов җыйган әкиятләргә югары бәя биргән. Ул шулай ук русча тәрҗемәләрнең ни дәрәҗәдә дөрес, төгәл булуын да тикшергән һәм канәгатьлек белдергән. Аның бәяләмәсе нигезендә А.Г. Бессоновка әлеге әкиятләр җыелмасы өчен Рус география җәмгыятенең кече алтын медале тапшырыла.

Кызганычка каршы, бу әкиятләрнең милли телләрдә язылган нөсхәләре (барысы 1087 бит) югалган һәм әлегә кадәр аларның табылганы юк.

А.Г. Бессонов җыелмасындагы татар фольклоры материаллары 83 берәмлек тәшкил итә. 61 әкиятнең 15 е хайванн ар турындагы әкиятләр, 28 е – тылсымлы, 18 е –көнкүреш әкиятләре. Аларда яңа сюжетлар һәм яңа мотивлар шактый күп очрый. Әлеге җыелмада бигрәк тә зур күләмле әкиятләр – 28 биттән торган «Кызылча патша һәм Гөлҗан», 23 битле «Гали белән Пәрибану» дигән әсәрләр үзләренең мавыктыргыч эчтәлеге белән әсир итә. Әкиятләрдә моңарчы очрамаган яисә бик сирәк |очрый торган кыр тавыгы, каз, керпе, җир астындагы кызлар патшасы Пәрибану, Сыер башлы, тасма телле нәрсә, башы күккә тигән Кырым карак, җиде башлы Жалмавыз, сиксән башлы дию, Сакалы сиксән аршин, үзе туксан аршин карт һ.б. персонажлар бар. Әкиятләрдә еш кына кызыклы башламнар, бетемнәр, эпик формулалар, мәкаль һәм әйтемнәр кулланыла. Күп кенә сүзләргә җыючы тарафыннан лингвистик һәм этнографик аңлатмалар бирелгән.

Кыскасы, моннан бер гасыр элек әкиятләребезнең нинди булганын күрсәтә торган А.Г. Бессонов җыелмасы – фольклорыбыз өчен кыйммәтле хәзинә.

### Академик Радлов архивындагы татар әкиятләре

Мәгълүм тарихи сәбәпләр аркасында татар фольклоры соң җыела башлаган. Халык авыз иҗаты әсәрләре тупланган махсус җыентыклар Казанда XIX гасырның соңгы чирегендә генә нәшер ителә[1].

Вакыт узган саен, телдә йөргән фольклор әсәрләре үзгәреш кичергәнлектән, үткән гасырларга карый торган материаллар фән

[1] Фәезханов Г. Хикәят вә мәкаләт. Казан, 1890; Яхин Таип. Сабый вә сабыяләр өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗаиб булган гыйбрәтләр. Казан, 1897; Яхин Таип. Дәфгылькәсәл мин әссаби вә сабият. Казан, 1900. 204 б.

өчен аеруча кыйммәтле санала. Бәхеткә, кульязма хәлендәге андый материаллар, сирәк булса да, табыла тора. Шундыйларның шактые төрки телләр белгече академик В.В. Радлов (1837–1918) архивында сакланган булып чыкты. Бу кульязмалар, Шәркыятьчеләр архивыннан алынып, Россия Фәннәр академиясе Шәрекъне өйрәнү институтының С.-Петербург филиалындагы кульязмалар бүлегенә тапшырылгач, С.Н. Муратов тарафыннан тасвирлана. Тасвирлау барышында түбәндәгеләр ачыклана: бирегә тапшырылган шәркый кульязмалардан гыйбарәт 43 дәфтәрнең күп өлешен (34 дәфтәр) төрки халыкларның фольклор әсәрләре тәшкил итә. Шуларның 28 е татар телендә. Татар фольклоры әсәрләре исә 24 дәфтәрдә тупланган. Бу дәфтәрләр, 1875 елда төрле кешеләр тарафыннан язылып, В. Радлов кулына шул ук елда кергән булырга тиеш.

В.В. Радлов (Friedrich Wilhelm Radloff), Берлин университетын тәмамлап, 1858 елда Россиягә күчеп килә һәм, бер ел дәвамында рус телен ныклап үзләштергәннән соң, җиң сызганып эшкә керешә. Радловның фәнни-тикшеренү эшчәнлеге башлану Россиядә шәрекъны өйрәнү өлкәсендә күренекле вакыйга итеп бәяләнә. Аның иҗат биографиясендә өч этап аерымланып тора: Алтай чоры (1859–1871), Казан чоры (1871–1884), Петербург-Петроград чоры (1884–1918).

Радлов 12 ел дәвамында Алтайда яшәп, Алтай һәм Көнбатыш Себер регионындагы төрки халыкларның телен, фольклорын, этнографиясен һәм археологиясен өйрәнә. Аның «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» дигән күп томлык хезмәте дә – шушы чордагы эшчәнлек нәтиҗәсе. Мәгълүм булганча, бу басманың IV томы Себер татарлары фольклорына багышланган[1].

Петербург-Петроград чоры да иҗат тематикасының киңлеге һәм басылып чыккан хезмәтләренең саны буенча, һичшиксез, уңышлы була.

Радловның Казандагы иҗатына килсәк, ул, әлбәттә, әле генә телгә алынган чордагыга караганда ярлырак күренә. Галимнең бу дәвердәге эшчәнлеген академик А.Н. Кононов «чагыштырмача аз продуктлы булган»[2] дип саный. Әмма биредә бер нәрсәне исәпкә алырга кирәктер: яшь галим өчен Казан – яңа урын, яңа мохит, яңа вазыйфа (биредә Радлов Казан уку-укыту округының татар, баш-

[1] Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи / собраны В.В. Радловым. Ч. IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. СПб.: Тип. Имп. АН, 1872. 411 с.

[2] Кононов А.Н. В.В. Радлов и отечественная тюркология // Тюркологический сборник, 1971. М.: Наука, 1972. С. 9.

корт һәм кыргыз (казакъ) мәктәпләре инспекторы итеп билгеләнә) – һәркайсына ияләшергә, күнегергә, җайлашырга кирәк ич. Шулай да галим татар мәктәпләре өчен берничә дәреслек төзеп бастыра. Фольклор әсәрләре дә файдаланылып, уку ярдәмлеге сыйфатында дөнья күргән «Белек»[1] дигән җыентык та аңа нисбәт ителә. Янә дә галимнең берничә зур хезмәте алман телендә басылып чыга. Болардан тыш, 1884 елда гомуми күләме мең биттән артып киткән 2 томлык «Aus Sibirien» («Из Сибири») дигән хезмәте нәшер ителә. Күрәсең, Кононов шушы күләмдәге хезмәтләрне дә Радлов кебек зур галимнең талантына бәрабәр түгел дип санаган. Язучы һәм галим Н. Исәнбәт исә Радловны казан татарлары теленә әһәмият бирмәгәнлеге өчен тәнкыйть итә. Ул болай ди:

«Әле Россиядә Себер тимер юллары юк чакта, Радловның ерак Себер, Алтай чикләренә китеп, авыр шартларда аерым кабиләләр сөйләшен өйрәнүе гыйлем дөньясына, әлбәттә, зур табышлар китерде. Ләкин шул ук вакытта үзенең төп яшәгән урыны Казан булып та, шундагы җирле татар халкының элекке һәм хәзерге әдәби телен, сөйләм телен танымавы, аны читләтеп, керәшен сөйләшен генә нигезгә алуы бу зур галимнең җирле халыкка гаҗәп тар, дини бер тәгассеп (фанатизм) күзлегеннән карап эш итүен күрсәтә... Төрки телләрне өйрәнүдә зур көч куйган һәм шул халыкларның авыз иҗатыннан зур-зур 8 томлык[2] материал җыеп бастырган Радлов шул китабына Идел буе татарлары фольклорыннан бер авыз сүз дә кертми һәм шул китабының сүз башында Казан татарларында авыз иҗаты беткән, аны ислам дине үтергән дип, үзенең бу кырын күз белән карауларына аклану эзли. Билгеле, бу зур академикның[3], үзе Казанда яшәп тә, керәшеннән башка татар халкының дөньяда булуын күрмәмешкә салынуы татар тел-фольклор гыйлеменең үсүенә зур комачау булып төшә һәм аның Каюм Насыйри белән кычкырышып яшәве дә шул җирлектә була[4].

Н. Исәнбәт сүзләрендә хаклык бардыр, әмма без сүз алып барачак архив материаллары Радловның татар мәдәниятенә, аерым алганда татар фольклорына, битараф булмаганлыгына ишарә итә.

Шәркыятьчеләр архивында сакланган һәм моңарчы тикшеренүчеләрнең кулы тимәгән әлеге хәзинәнең әһәмиятен күрсәтү өчен

---

[1] Белек. Балалар укыр өчен чыгарылган китап. Казан, 1872.

[2] Дөресе: 10 томлык. Әгәр В. Радловның үзе җыйган материаллардан төзелгәннәре генә күздә тотылса – 7 томлык. *Л.Җ.*

[3] Дөресе: булачак академикның. *Л.Җ.*

[4] Татар халык мәкальләре: өч томда / җыючысы һәм төзүчесе Нәкый Исәнбәт. 1 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Б. 232–234.

берничә сан китерү дә җитсә кирәк: бу дәфтәрләрдә 54 әкият (300 бит), 44 бәет (3 мең юл), 400 дән артык кыска җыр, берничә кыйсса (235 бит), мәзәкләр һәм шигырьләр тупланган. Аларның гомуми күләме якынча исәп белән 750 бит тәшкил итә.

Бәетләр арасында 1812 елгы Ватан сугышы турында, солдат хезмәте, рекрутлар, авыл мужигының авыр хәле турында һ.б. шундый иҗтимагый яңгырашка ия булган әсәрләр бар.

Инде темага якынрак килеп, В. Радлов тупламындагы әкиятләрне күздән кичерик. Татар халык әкиятләре әлеге 24 дәфтәрнең 19 ында очрый. Алар башлыча «хикәят» дип исемләнгәннәр, «әкият» дип аталганнары 4 әү генә, әмма аларның да берсе әкият түгел (шифры: В 4593). Бүгенге таләпләрдән чыгып караганда без күзәтергә алынган бу тупламда җәмгысе 54 текст урын алган. Кайбер кулъязмаларның почеркы бик начар булганлыктан, текстларның 3 есен тулаем уку мөмкин булмады (В 4579, I, II; В 4589а, II). Янә дә 2 әкият тәмамланмый өзелеп калган (В 4587, II; В 4595, I) һәм бер әкиятнең фрагменты гына теркәлгән (В 4592, IX). Шулай итеп, файдаланырлык әкият текстлары 48 данә тәшкил итә.

Биредә әкият жанрының барлык төрләре дә чагылыш тапкан. Текстларның 9 ы – мифологик әкият, 6 сы – хайваннар турындагы әкият, 10 ысы – тылсымлы һәм 23 е – көнкүреш әкияте. Соңгысының составы, берничә гыйбрәтле әкияттән тыш, башлыча, сатирик һәм юмористик әсәрләрдән гыйбарәт.

Нинди әкиятләр соң болар? Сюжетларын мәгълүм итү өчен, аларны татар фольклорының 13 томлык фәнни җыелмасындагы әкият томнарында[1] урын алган әсәрләрнең исемнәре белән атыйк (кулъязмадагы текстларның күбесе шул китаплардагы әкиятләрнең вариантлары булып тора).

Хайваннар турындагы текстлар «Торна белән Төлке» (В 4596, X), «Төлке белән Бүре» (В 4597, I; В 4592, II), «Аю белән Төлке» (В 4597,1), «Аю, бабай, Төлке» (В 4597, II), «Кәтән Иваныч» (В 4595, III), «Син көчлеме, мин көчлеме?»[2] (В 4589, IV; В 4589, VIIа) кебек әкиятләрнең вариантларын тәшкил итә. Ә мифоло-

---

[1] Татар халык иҗаты: Әкиятләр (беренче китап) / томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977; Татар халык иҗаты: Әкиятләр (икенче китап) / томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978; Татар халык иҗаты: Әкиятләр (өченче китап) / томны төзүче, кереш мәкаләне язучы, искәрмәләр әзерләүче Л.Ш. Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.

[2] Татар халык иҗаты: Балалар фольклоры / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Р.Ф. Ягъфәров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 147.

гик әкиятләрнең күбесе «Үги кыз» әкиятенең вариантлары. Алар өчәү (В 4589, IVa; В 4589, VII; В 4589, VIII). Берәр әкият «Әйдә, кызым, безгә» (В 4579, IX) һәм «Мөлтәл» (В 4589, V) вариантлары, «Һөнәрле үлмәс» яисә «Диюләрне җиңгән» әкиятләренең вариантлары икәү (В 4588а, I; В 4592, I). Әмма мифологик әкиятләр арасында безгә моңарчы таныш булмаган әсәрләр дә бар (В 4581, V; В 4585, II). Шуларның берсен биредә күрсәтеп узыйк. Без аны, эчтәлегеннән чыгып, «Кәккүк» (В 4581, V) дип атадык һәм телен беркадәр җиңеләйттек. (Шуннан соң әкиятнең тексты китерелә. Фән һәм Тел. 2007. № 1. Б. 30.)

В. Радлов тупламындагы тылсымлы әкиятләр исә түбәндәге әкиятләрнең вариантлары булып тора: «Балыкчы карт» (В 4589, I), «Камыр батыр» (В 4590, XXV), «Незнай» (В 4576), «Таз – патша кияве» (В 4581, I (өлешчә), В 4579, V), «Хезмәтче һәм кошлар патшасы» яисә «Мәрмәр тавы башында» (В 4579, VIII; В 4590, XXII), «Мөгезле патша» (В 4590а, II), «Мәче һәм ярлы егет» (В 4591, П; В 4592, IX), «Ярлы егет белән патша кызы» (В 4591,11).

Көнкүреш әкиятләренә килсәк, алар шактый: «Васыять» (В 4590а, III), «Патша, вәзир һәм тегермәнче» (В 4580, IX), «Шомбай» (В 4586, II; В 4589а, I), «Тугыз Тукылдык, бер Мимылдык» (В 4592, III; В 4595, II), «Алдар һәм мулла» (В 4584, II; В 4589, III), «Нужа» (В 4585, I; В 4591, X), «Алдар» (В 4584,1; В 4592, V), «Гакыллы бала» (В 4592, IV), «Мәнсез карт» (В 4586,1; В 4590, XXIII).

Димәк, В. Радлов тупламындагы 48 әкиятнең 40 ы – моңарчы басылып чыккан 27 әкиятнең вариантлары. Калган 8 әкиятне типологик планда өйрәнәсе бар.

Бу тупламдагы дәфтәрләргә күз салу белән, аларның төрле кешеләр тарафыннан язылганлыгы ачыклана. Алда искәрткәнебезчә, кайбер дәфтәрләрне уку ифрат авыр, хәтта мөмкин дә түгел. Безнеңчә, бу дәфтәрләр заказ буенча чагыштырмача кыска вакыт эчендә язылганнар. Кайберләрендә язылу датасы да куелган: 1875 елның апрель ае. Ышануыбызча, дәфтәрләр шәкертләр тарафыннан язылган. Чөнки бу дәвердә Радлов татар, башкорт, казакъ мәктәпләре инспекторы булып эшләгән. Биредә теркәлгән фольклор әсәрләренең сыйфаты да әлеге фаразны куәтли. Язмаларда тормыш тәҗрибәсе җитмәү сизелә, мантыйк-фәһем ягы аксау һәм тел кытыршылыклары күренеп тора; тел-стиль бизәкләре, традицион формулалар, характерлы башлам-бетемнәр юк дәрәҗәсендә. Әлбәттә, әкиятне кәгазьгә төшерүнең үтә җайсыз булуын искә алырга кирәк. Гомумән, халыкта әкиятләр кәгазьгә төшерелми. Кайбер затларда җыр, бәет-мөнәҗәт дәфтәрләре була, ә әкиятләрнең дәфтәргә

язылуы – үтә сирәк күренеш. Кәгазьгә теркәлгән тәкъдирдә дә ул сөйләнгәнчә үк язылмый, кыскартыла, гадиләштерелә, еш кына аерым эпизодлар төшеп кала, сюжет схематик рәвештә бәян ителә һ.б. Без күзәтә торган шәкерт язмаларының кайберләрендә исә теге яки бу хәрәкәтне мотивлаштыру, хәтта кайчак әкияттәге конфликтны күрсәтү дә төшеп калган. Әнә шундый чатаклыклар аркасында әсәрләрнең тәэсир көче кими, сыйфаты түбәнәя, кызыгы бетә һәм кыйммәте дә төшә. Әкиятләрнең олы кешеләр авызыннан язып алынмавы һәм бу процесста белгечнең (бу очракта В. Радловның) катнашмавы кулъязмаларның сыйфатында чагылыш тапмый калмаган, әлбәттә. Кагыйдә шундый: әкиятләр олылардан һәм бары тик телдән генә язып алынырга тиеш! Югыйсә аның сыйфатына хилафлык килә. Шуңа күрә, шәкерт дәфтәрләрендә теркәлгән язмаларның кимчелекләренә гаҗәпләнергә туры килми. Әмма сыйфатлары нинди генә булмасын, фән өчен В. Радлов тупламындагы әкиятләрнең җитди әһәмияте бар. Алар ярдәмендә без татар әкият репертуарының моннан 130 еллар элек нинди булганын күзаллыйбыз, моңарчы безгә билгеле булмаган әкиятләр исәбенә бу өлкәдәге бүгенге байлыгыбызны ишәйтәбез һәм, ниһаять, әкиятләребезнең сюжет составын ачыклыйбыз, бу исә татар халык әкиятләренең якын киләчәктә төзеләчәк сюжет күрсәткеченең билгеле бер күләмдә тулылыгын тәэмин итәчәк? АТ[1] һәм СУС[2] күрсәткечләре белән эш итеп, бу тупламдагы әкиятләрдә түбәндәге сюжет типлары ачыкланды[3]. **АТ 1** РО СПбФ ИВ РАН[4], В 4592Т тат (тетр. 30), л. 4; В 4597Т тат (тетр. 35), л. 1–6. **АТ 2** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 4; В 4597Т тат (тетр. 35), л. 1–6. **АТ 15** В 4597Т тат (тетр. 35), л. 1–6. **АТ 36** В 4597Т тат (тетр. 35), л. 6–7. **АТ 60** В 4596Т тат (тетр. 34), л. 15. **АТ 103** В 4595Т тат (тетр. 33), л. 4–5. **АТ 313** А В 4589Т тат (тетр. 2), л. 1–4. **АТ 327** А В 4589Т тат (тетр. 22), л. 7–9; В 4589Т тат (тетр. 22), л. 27–28. **АТ 400]** В 4579Т тат (тетр. 4), л. 17–23; В 4590Т тат (тетр. 23), л. 60–65. **(АТ 451)** В 4589Т тат (тетр. 22),

---

[1] АТ – The Types of the Folktale. A Classification and Bibliography Antti Aarne's Verzeichnis der Märchentypen (FF Communications № 3). Translated and Enlarged by Stith Thompson. 2-d rev. – Helsinki, 1961 (FFG № 184).

[2] СУС – Сравнительный указатель сюжетов. Восточно-славянская сказка / Составители: Л.Г. Бараг, И.П. Березовский, К.П. Кабашников, Н.В. Новиков. Л.: Наука, 1979.

[3] Тупламдагы сюжет типлары, тиешле таләпләрне искә алып, татар халык әкиятләренең сюжет күрсәткече өчен әзерләнде. Биредә без аларны шул хәлендә тәкъдим итәбез.

[4] СПбФ ИВ РАН – Рукописный отдел С.-Петербургского филиала Института востоковедения Российской Академии наук.

л. 9–14. **АТ 480** В 4589Т тат (тетр. 22), л. 7–9; В 4589Т тат (тетр. 22), л. 27–28; В 4589Т тат (тетр. 22), л. 28–30. **СУС-480 C**** В 4579Т тат (тетр. 4), л. 23-25. **АТ 513** В 4590Т тат (тетр. 23), л. 69–73. **АТ 530** А В 4579Т тат (тетр. 4), л. 10–16. **АТ 532** В 4576Т тат (тетр. 1), л. 1–9. **АТ 533** В 4589Т тат (тетр. 22), л. 9–14. **АТ 560** В 459IТ тат (тетр. 24), л. 5–7. **АТ 566** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 8–9. **АТ 650** А В 4590Т тат (тетр. 23), л. 69–73. **АТ 782** В 4590аТ тат (тетр. 28), л. 2–4. **АТ 915 А** В 4590аТ тат (тетр. 28), л. 5. **АТ 921 F*** В 4580Т тат (тетр. 5), л. 17–18. **АТ 936*** В 4579Т тат (тетр. 4), л. 17–23; В 4590Т тат (тетр. 23), л. 60–65. **АТ 1030** В 4597Т тат (тетр. 35), л. 8. **АТ 1045** В 4588аТ тат (тетр. 26), л. 2–6; В 4592Т тат (тетр. 30), л. 1–3. **АТ 1063** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 1–3. **АТ 1071** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 1–3. **АТ 1072** В 4588аТ тат (тетр. 26), л. 2–6; В 4592Т тат (тетр. 30), л. 1–3. **АТ 1082** В 4588аТ тат (тетр. 26), л. 2–6; В 4592Т тат (тетр. 30), л. 1–3. **АТ ИЗО** В 4588аТ тат (тетр. 26), л. 2–6; В 4592Т тат (тетр. 30), л. 1–3. **АТ 1132** В 458IТ тат (тетр. 9), л. 1–9. **АТ 1149** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 1–3. **АТ 1384** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 5–6. **АТ 1425** В 4588аТ тат (тетр. 26), л. 7–9. **СУС-1525 В*** В 4591Т тат (тетр. 24), л. 35–39. **АТ 1528** В 4584Т тат (тетр. 9), л. 1–6. **АТ 1528 В** В 4585Т тат (тетр. 16), л. 2–4. **АТ 1535** В 4595Т тат (тетр. 33), л. 2–3. **АТ 1537** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 4; В 4595Т тат (тетр. 33), л. 2–3. **АТ 1539** В 4584Т тат (тетр. 9), л. 6–9. **АТ 1540** В 4592Т тат (тетр. 30), л. 5–6. **АТ 1542** II В 4584Т тат (тетр. 9), л. 1–6. **АТ 1542** II В 4592Т тат (тетр. 30), л. 6–7. **АТ 1650** В 4588аТ тат (тетр. 26), л. 2–6. **АТ 1654** В 4588аТ тат (тетр. 26), л. 2–6. **АТ 1681 А** В 4586Т тат (тетр. 17), л. 1–2; В 4590Т тат (тетр. 23), л. 65–68.

## «Ак бүре»нең илгә кайтуы

Татар халык әкиятләре арасында безне кечкенәдән үк үзенә әсир иткән «Ак бүре» исемле гаҗәеп матур әкият бар. Озын, мажаралы бу әсәрне повесть дип атарга да мөмкин. Күләме ягыннан моңарчы басылып чыккан әкиятләр арасында аңа тиңнәр юк. Машинкада 31 бит тәшкил иткән бу тылсымлы әкият эчтәлеге белән дә башкалардан нык аерылып тора. Аны ниндидер бүтән әкият белән бутау мөмкин түгел. Сюжет һәм тел-стиль җәһәтеннән искиткеч төзеклек, камиллек күзгә ташлана.

Әдәби-сәнгати кыйммәте белән беррәттән, әлеге әкиятнең фәнни әһәмияте дә гаять зур. Бу беренче чиратта Ак бүре образы белән бәйле. Халкыбызның бик борынгы заманнардагы тотемистик

карашларын чагылдырган бу образга тикшеренүчеләр еш мөрәҗәгать итәләр. Хәтта аңа багышланган махсус мәкалә дә дөнья күрде[1].

Бу экияткә әнә шулай фәнни игътибарның көчәюе аның чыганагын аныклау зарурлыгын алга куйды. Чөнки «Ак бүре»нең экиятләребез арсеналына килү юлы тәмам исбатланмаган иде. Төп чыганагы билгесез яисә шикле булган теге яки бу материал, факт фәнни тикшеренүләр өчен абруйсыз гына түгел, бәлки хәтәр дә.

Дөрес, «Ак бүре» экиятенең теле ачык әйтеп тора кебек: экият безнеке, татарныкы. Ләкин шунысы бар: ул халык арасында таралмаган. Аның бердәнбер шактый ярлы һәм схематик вариантын 1947 елда Х. Ярми Апас районының Танай-Турай авылында Кәлимулла Әхмәдишиннан язып алган. Шуннан соңгы 40 ел вакыт эчендә бу экият беркайда да очрамаган. Шик туарга җирлек бар: бәлки «Ак бүре» – ят сюжетка корылган ясалма экияттер. Тарихта андый хәлләр булмаган түгел ич. Экиятнең теленә, стиленә сокланабыз соклануын, әмма моның да икенче ягы бар: ярый ла экиятче нәкъ шулай сөйләгән булса, кем белә, бәлки анда бер укымышлының кулы уйнагандыр? Тарихта андый хәлләр дә булган һәм шактый булган. Мәсәлән, моның классик үрнәге итеп, мәшһүр бертуган Гриммнар нәшер иткән немец халык экиятләрен күрсәтү дә җитә.

«Ак бүре» экияте беренче мәртәбә 1938 елда «Халык иҗаты» (Казан, 1938, 109–130 б.) исемле фольклор җыентыгында дөнья күрә. Шуннан соң ул бүгенгә кадәр төрле җыентыкларда күп басылды. Популяр, шулай ук балаларга адресланган басмаларда аның чыганагы күрсәтелмәгән һәм ул таләп ителми дә. Халык экиятләренең беренче фәнни басмасында «Ак бүре» экиятенә «СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Татарстан тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор архивыннан»[2] дигән искәрмә бирелгән. Экиятнең паспорты һәм шифры күрсәтелмәгәнлектән, табигый, бу мәгълүмат сорауларга урын калдыра, кызыксыну уята. 1951 елда чыккан антология характерындагы «Татар халык иҗаты» җыентыгында исә искәрмә тулылана һәм конкретлаша төшкән: «СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында булган материалларга караганда, бу экиятне Венгрия галиме И. Кунош язып алган. Кемнән язып алуы хәзергә билгеле түгел. Әмма теленә һәм сөйләү алымына карап фикер йөрткәндә, бу экият-

[1] Урманчеев Ф. По следам Белого Волка // Советская тюркология. 1978. № 6. Б. 12–23.

[2] Татар халык экиятләре / төзүчеләре Г. Разин (Г. Бәширов] һәм Х. Ярми. Казан, 1946. Б.60.

не әдәбият белән яхшы ук таныш булган, заманына күрә укымышлы кеше сөйләгән булса кирәк дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин»[1].

Шулай итеп, укучыларга беренче тапкыр Кунош исеме мәгълүм була. Әмма бары тик исеме генә. Ни өчен татар әкиятен венгр галиме язып алган? Кайда, кайчан, кемнән? Бу сораулар әле җавапсыз кала.

Соңрак ачыкланды: Кунош язып алган «Ак бүре» әкиятенең безнең китапларда басылуына язучы һәм галим Г. Толымбай «гаепле» икән.

Мәгълүм булганча, 30 нче елларда Г. Толымбай әкиятләр җыентыгы чыгарырга әзерләнә. Шушы максат белән ул 1930–1940 елларда Татарстанның Буа, Апас, Кукмара, Әлки районнарында байтак кына әкиятләр язып ала. Бу материалларның асыл нөсхәләре СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында саклана (21 коллекция, 1 папка, 1–34, 46–49 сак. бер.; 2 п., 51–76 сак бер.). Үзенең ниятен ул 1936 елның башында танылган тюрколог А.Н. Самойловичка да хәбәр итә[2]. Г. Толымбайның архив материаллары арасында үзе язып алган әкият текстларыннан тыш Г. Балинт китабындагы[3] әкиятләренең күчермәләре дә бар (Фольклор фонды, 21 колл., 1 п., 35–45 сак. бер.). Җыентыгына кереш сүз буларак әзерләнгән бер язмасында ул «Ак бүре» әкиятенең хәрби әсирләрдән венгр галиме Игнац Кунош тарафыннан язып алынганлыгын һәм аның 1925 елда Төркиядә чыккан «Төрек халык әдәбияты» дигән китапта кушымта итеп басылганлыгын әйтә (Фольклор фонды, 1 п., 46 сак. бер.). Шулай итеп, татар фольклоры өлкәсендә Кунош эшчәнлеге турындагы байтактан бирле телдә йөргән хәбәрнең Г. Толымбай аша мәгълүм булганлыгы ачыкланды.

Ләкин язучының «Ак бүре» әкиятенә бәйле әлеге сүзләре кәгазьдә танымаслык итеп бозылган. Аларны оптик прибор ярдәмендә генә тулысынча уку мөмкин булды. Әмма бу сүзләрнең кем кулы белән бозылганлыгын белмәү мәсьәләне ачыклау юлында өстәмә кыенлык тудыра иде. Кем белә, бәлки бу мәгълүмат «Ак бүре» әкиятенә мөнәсәбәтсез һәм ялгыш басылган очраклы хата булып, Г. Толымбай аны үзе шулай тырышып бозгандыр. Шигебез торган

---

[1] Татар халык иҗаты / төзүчеләре Г. Бәширов, А. Шамов, Х. Ярми һәм Х. Усманов. Казан, 1951. Б. 517.

[2] Ленинград шәһәрендәге Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәнең кульязмалар бүлеге. 671 ф., 294 эш.

[3] Balint Gabor. Kazani-talar nyelvtanulmanyok. I. Füzet. Kazani-tatar szövegek. Budapest, 1875. (Икенче басмасы: 1877).

саен арта төште, чөнки 1925 елда чыккан «Төрек халык әдәбияты» дигән китап Казан китапханәләрендә дә, Мәскәүдә дә, Ленинградта да табылмады.

1963 елда Будапештта чыга торган «Акта Ориенталиа» журналында венгр галимәсе Жужа Кәкүкнең Кунош тарафыннан җыелган татар фольклоры материаллары турындагы мәкаләсе[1] басылды, һәм ул безгә әлегәчә билгеле булмаган күп кенә яңалыклар алып килде. Аерым алганда, безгә түбәндәгеләр мәгълүм булды.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында, төгәлрәк әйткәндә, 1916–1917 елларда, Кунош чех шәһәре Эгер һәм венгр поселогы Кеньермезье тирәсендәге хәрби әсирләр тотылган лагерьларда казан татарларыннан 212 бит җыр (дүртьюллыклар)[2], 231 бит әкият (14 текст), ә 1918 елда мишәр-татарлардан 161 биттән торган әкиятләр һәм җырлар язып ала, казан татарларының җырларын венгр һәм төрек телләренә, ә мишәр әкиятләрен (барысы 7 данә) венгр теленә тәрҗемә итә. Ләкин җыелган әсәрләрне ул үз вакытында бастыра алмаган. Хәзерге вакытта Кунош материаллары венгр галимнәре тарафыннан эшкәртелә һәм дөньяга чыгару өчен әзерләнә.

Без әнә шуларны белдек.

Кәкүк үзенең публикациясендә Кунош фондындагы ике әкияттән өзекләр дә тәкъдим иткән («Таз әкияте», «Юсыф Минуллин әкияте») һәм «тәртә башы белән» генә «Ак бүре»гә дә кагылып узган, ягъни бу әкиятнең «Төрек халык әдәбияты» дигән китапта басылганлыгын әйткән.

Бу хәбәр безне шатландырды, «Ак бүре»нең чыннан да Кунош тарафыннан язып алынган һәм бастырылган булуында шик калмады. Димәк, Г. Толымбай хаклы булган. Аның әлеге язмасы җентекләп тикшерелгәнгә кадәр файдаланылганлыктан, «Әкиятләр»нең беренче китабында «Ак бүре» әкиятенә бирелгән искәрмәдә (395 б.) төгәлсезлекләр киткән. Искәрмә түбәндәгечә укылырга тиеш: «Игнац Куношның 1925 елда Төркиядә басылган «Төрек халык әдәбияты» исемле китабыннан. Кунош бу әкиятне Венгриядә Беренче бөтендөнья сугышы вакытында әсир төшкән татар солдатларын-

---

[1] Suzanne Kakuk, Poésie populaire tatare recueillie, par I. Kunos – Acta Orientalia Academiae scienliarum Hungaricae. Tomus XVI, fasciculus 1. Budapest, 1963. Pp. 83–97.

[2] Бу җырлар (барысы 634 строфа) 1980 елда Будапештта «Казан татарларының халык җырлары» исемендә аерым җыентык булып басылып чыкты (Kasantatarische Volkslieder. Auf Grund der Sammlung von Ignás Kunos, herausgegeben von Zsuzsa Kakuk. Budapest, 1980).

нан язып алган һәм әлеге китабына кушымта итеп урнаштырган. Күчереп алучы Г. Толымбай».

Ләкин Куношның әлеге серле китабын кайдан табарга? Хәер, безнең өчен генә түгел, чит ил тикшеренүчеләре өчен дә ул «буй җитмәс» нәрсә булган. Ж. Кәкүкнең язуына караганда, «белгечләр әле һаман да Кунош җыентыгының булуын инкарь итәләр, андагы материалларны беркем дә төгәл генә белми». Г. Толымбай исә шул китап белән эш иткән! Менә ул – буыннар арасындагы бәйләнеш өзелүнең аяныч нәтиҗәсе!

Дөрес, «Ак бүре» үзе безнең кулыбызда, күңелебездә, җаныбызда. Ләкин, фәннең катгый таләбе буенча, гамәлдәге текст төп чыганак белән чагыштырылырга тиеш.

Куношның китабы табылмаса да, күңелдә бер юаныч яшәде: шөкер, галимнең архивы исән ләбаса. «Ак бүре» кулъязмасының шунда саклануына иманыбыз камил иде.

Кунош архивы гел ымсындырып, өметләндереп торды. Шундагы әкиятләрне үз күзең белән күрсәң иде, дигән теләк һич күңелдән китмәде. Халкыбызның нинди җәүһәрләре саклана икән анда? Безнең өчен яңа сюжетлар бармы икән? Мәгълүм сюжетларның вариантлары нинди икән? Без иске кулъязмаларда сирәк-мирәк кенә очрап куйган һәрбер өзек-төтек әкият текстына да чын күңелдән шатланабыз, ә биредә – тулы бер коллекция! Җитмәсә бу әкиятләр турыдан-туры халык авызыннан язып алынганнар. Алар менә инде 70 еллап кулъязма хәлендә саклана. Хәтәр чорларда да исән калганнар. Ләкин аларны әле бер генә татар тикшеренүчесенең дә күргәне юк.

Кунош коллекциясе саклана торган Венгрия Фәннәр академиясе архивы турында уйлыйм. Ул Казан университетының Н.А. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендәге сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге кебегрәк булып күз алдына килә. Телдә бу бүлекне «мәгарә» дип йөртәләр. Анда тиешле имзалар куелган махсус рөхсәт кәгазе белән генә керәсең, сигнал төймәсенә басып, беркадәр көткәч, ерактан аяк тавышлары ишетелә, аннары авыр тимер ишекләр акрын гына ачыла да синең артыңнан ук шалтырап бикләнә, һәм син дулкынландыргыч мәгарә тынлыгына чумасың...

Венгриядәге архив та минем күз алдында әнә шулай гәүдәләнә. Имеш, мин анда Кунош коллекциясе белән танышу өчен фәнни командировкага барганмын. Менә өлкән яшьтәге архивариус авыр иске имән өстәлгә сак кына татар әкиятләре кулъязмаларын китереп куя. Мин, гаять тәэсирләнеп, бармак очлары белән генә беренче битне

ачам... Менә ул Кунош почеркы, менә ул халкыбызның әлегәчә үз кулына керә алмый интеккән асыл хәзинәләре, әсирлектә җәфаланган якташ бабаларыбызның күңел юаткычлары... Кадерлеләрем! Менә мин, халкыбызның бер вәкиле булып, сезнең белән күрешергә килдем, сезне туган илгә алып китәргә дип килдем...

Ләкин бу – татлы хыял гына иде. Дөрес, талпынып караулар булмады түгел, әмма минем адымнарым ахыр чиктә бернинди нәтиҗәгә дә китермәде.

Шулай да, вакытлар узу белән, минем хыялым тормышка ашты. Ниһаять, без – татар фольклорчылары – Кунош материалларын үз күзебез белән күрү бәхетенә ирештек. Ләкин чит илдә түгел, бәлки Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, хәтта үзебез эшли торган бүлмәдә!

Кунош әкиятләрен Будапешт университетының яшь галиме Имре Башки алып килгән иде. Үз күзләребезгә ышанмый торабыз: бу чыннан да Куношның без күрергә хыялланган татар әкиятләреме? Әйе, нәкъ шулар. Архив материалы белән мондый шартларда очрашу, әлбәттә, гайре табигый хәл, һәм ул бер үк вакытта безнең өчен гаять шатлыклы вакыйга иде.

Фольклорчыларыбызның барысы да бу легендар коллекцияне үз кулына тотып карады: менә нинди икән ул без әлегәчә ишетеп кенә белгән асыл хәзинә! Мин дә, вакытлар узу белән, саргаеп беткән кәгазьләрне нәкъ хыялымдагыча бармак битен тидерер-тидермәс кенә ачып, үтә саклык белән карарга тотындым. Шул ук вакытта бу кулъязмалар белән эшләүнең җиңел түгеллеге дә аңлашылды. Шуңа күрә дә И. Башки, иркенләп, өч айлык командировкага килгән иде. Килүенең сәбәбе шул: Куношның транскрипциясе камил булмаганлыктан, текстларны матбугат өчен әзерләгәндә, кыенлыклар килеп чыккан. Казан университеты доценты А. Нуриевага һәм миңа бу эштә коллегабызга ярдәм итәргә туры килде.

Кунош коллекциясе турында, әлбәттә, күп сөйләргә мөмкин. Бу – аерым, үзенә бер тема. Әлегә безне бары тик бер әкият – «Ак бүре» әкияте генә кызыксындыра. Дулкынланып, шуны эзлим. Ниһаять, кулъязмалар каралып бетте, ләкин... әкиятләр арасында «Ак бүре» очрамады. Тагын билгесезлек, серлелек, борчылулар... Ярдәм сорап, И. Башкига мөрәҗәгать итүдән башка чара калмады. Коллегабыз хәлдән килгәнчә тырышып карарга булды.

Командировка вакыты беткәч, И. Башки үз иленә кайтып китте.

Байтак кына вакытлар узгач, Венгриядән шатлыклы хәбәр килде: И. Башки Куношның «Төрек халык әдәбияты» дигән китабын тапкан, һәм анда «Ак бүре» чыннан да бар икән. Әкият, кушымта итеп,

гарәп хәрефләре белән татарча басылган, ә китапның исеме... француз телендә, имеш[1]. Менә эзлә син аны төрек китаплары арасыннан!

Әкиятнең ксерокопиясен сорап, венгр коллегабызга кабат мөрәҗәгать итәргә туры килде.

Менә, ниһаять, ксерокопия безнең кулыбызда. Аны хәзер Г. Толымбай нөсхәсе белән дә, төрле җыентыкларда басылган текстлар белән дә чагыштырырга мөмкин. Г. Толымбай нөсхәсе дип әйтү дөрес үк булмас, әлбәттә, чөнки аның тарафыннан күчереп алынган текст сакланмаган. Шуңа күрә безгә Кунош текстын Г. Толымбай нөсхәсе буенча басылган 1938 елгы текст белән чагыштырырга гына кала. Чагыштыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләр ачыкланды. Бу басмада текстка үзен аклый торган шактый гына редакцион төзәтүләр кертелгән: кирәкмәгән артык сүзләр төшереп калдырылган, очраклы грамматик һәм хәреф хаталары төзәтелгән (аерым алганда, кайбер фигыльләр грамматик заманга туры китереп үзгәртелгән, мәгънә аныграк булсын өчен, җөмләдә кайбер сүзләрнең урыннары алыштырылган), кайбер сүзләр иске формадан яңа формага күчерелгән (илә – белән, углы – улы, кечек эне – кечкенә эне һ.б.), фонетик үзенчәлекләр, бигрәк тә «җ»ләштерү (җегет, җырак, жугары, җылан һ.б.) хәзерге орфография нормаларына яраклаштырып бирелгән, текстта кабатланган кирәксез урыннар хаклы рәвештә төшереп калдырылган һ.б.

Әмма шул ук вакытта яңа текстта яңа хаталар да шактый. Алар арасында үкенечлеләре дә бар: байтак урында сүзләр, тәгъбирләр, җөмләләр төшеп калган. Арада мәгънәгә зарар китерә торганнары да очрый. Кайбер сүзләр урынсыз үзгәртелгән (сүзең тәмле – сүзең ямьле, рас түгел – дөрес түгел, күкне күккә орып – күкне күккә очырып, сарайның турысына – сарайның уртасына, төйгән итләр – төялгән итләр һ.б.).

«Ак бүре»нең шуннан соңгы басмаларында исә кайбер күзгә күренеп торган хаталар төзәтелсә дә, гомумән алганда, текст яхшырган дип әйтергә нигез юк, киресенчә, һәр басмада яңадан-яңа хаталар өстәлеп, әкият үзенең төп текстыннан ерагая гына барган. Мәсәлән, халыкта мифологик дию персонажының Каф тавы артында яшәве турындагы фикер киң таралган. Ләкин, «Татар халык иҗаты» җыелмасындагы әкият томнарының I һәм II китапларыннан дию образы булган 30 дан артык әкиятне күздән кичереп, моңа бер

[1] Dr. Jgnace Kunos. De la Poesie populaire Turgue. Ouvrage contenant les conferences fenues a ce sujet a Г Uni- versite de Constantinople. Stamboul, 1925.

генә дәлил дә таба алмаячакбыз. Чынлыкта исә Каф тавы артындагы дию нәкъ менә «Ак бүре» әкиятендә бар икән, тик текстта ул урын төшеп калган. Әкиятнең соңгы басмасында болай диелә: «Ул ком тавының аръягында яман диюләр... яталар». Ә Куноштa түбәндәгечә: «Ул ком тавының артында Каф тавы. Каф тавының аръягында яман диюләр... яталар».

Тагын бер мисал китерик. Безнең китапларда болай: «Алтмыш колачлы ала айгыр егеткә янә:

– И егет, инде кулыңны миннән ычкындыр, – диде.

Шулай итеп низаглашып, болар бер диңгезгә барып җиттеләр».

Ләкин бу өзектә бернинди дә низаг күренми. Низаг булыр өчен, ала айгырның сүзләренә егетнең җавабы булырга тиеш, һәм, җитмәсә, ул җавап әлеге сүзләргә каршы килә торган булырга тиеш. Куношта нәкъ менә без фараз иткән җавап бар: «Егет:

– Юк, минем синнән ычкындыра торган кулым юк, теләсә кая бар, мин дә шунда барам, – диде» (текстның бу өлеше 1938 елгы басмада ук төшеп калган).

Бүген инде без әкиятне, беренче чыганактан файдаланып, камил рәвешкә китерә алабыз. Моның өчен аның соңгы басмасына төрле характердагы йөздән артык төзәтмә кертү сорала.

Кунош үзенең хәрби әсирләр арасындагы фәнни эшчәнлеге турында үз вакытында хезмәтләр дә язган булып чыкты. Аның «Татар хәрби әсирләре лагерында. Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы тикшеренүләр турында хисап» дип исемләнгән мәкаләсе 1916 елда «Будапешт күзәтүчесе» дигән журналда басылган. Галимнең бу хезмәтендә «Ак бүре» әкияте турында да мәгълүмат бар. «Зур осталык белән диярлек «Ак бүре» әкиятен язып алу насыйп булды. Анда мифик эчтәлек халык теленең бик шәп стиле белән бергә кушылган», – диелә мәкаләдә (14 б.). Шунда ук Кунош фольклор материалларын җыюда аңа казанлы Шәһит Вәлиевнең зур ярдәм иткәнен билгеләп уза.

Куношның әсирләр арасындагы эшчәнлеген яктырткан икенче бер хезмәте без сүз алып барган «Төрек халык әдәбияты» китабында аерым бүлек итеп урнаштырылган (7 бүлек, 156–206 битләр). «Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы эш турында» дигән бу бүлектә без авторның 1916 елгы мәкаләсендә булмаган башка фактлар белән дә очрашабыз. Әмма бу – махсус тема.

«Ак бүре» әкиятенең гарәп шрифты белән бирелгән тексты әлеге китапның 176–206 битләрен биләп тора. Нәтиҗәдә төрек фольклорына багышланган 206 битлек китапның 51 бите, ягъни дүрттән бере татар фольклорына мөнәсәбәтле булып чыккан.

Венгрия Фәннәр академиясендәге Кунош архивы тулы түгел. Аның бер өлеше әле табылмаган. Бәлки «Ак бүре»нең кулъязмасы да шундадыр. Күрәсең, Кунош әлеге кулъязманы алда әйтелгән китапка кертү өчен алган да, соңыннан, ниндидер сәбәпләр аркасында, аны кире үз урынына (коллекциягә) куя алмый калган. Безгә калса, Г. Толымбай нөсхәсе дә шундый ук язмышка дучар булган.

Шулай итеп, венгр коллегабызның ярдәме белән мәшһүр «Ак бүре» әкиятенең төп тексты кулыбызга керде, Кунош эшчәнлегенең детальләре ачыкланды, галимгә ярдәм иткән якташыбызның исем-фамилиясе мәгълүм булды һәм, гомумән, татар солдатларының әсирлектәге тормышын күзалларга мөмкинлек туды.

## Әсирлектән кайткан әкиятләр

Беренче бөтендөнья сугышы чорында татар хәрби әсирләреннән фольклор әсәрләре язып алган венгр галиме Игнац Кунош (1860–1945) турында студент елларыбызда ук инде ишеткәнебез бар иде. Белүебезчә, бу мәгълүмат җәмәгатьчелеккә Гомәр Толымбайның архив материаллары буенча ирешкән. Безнең классик «Ак бүре» әкиятен нәкъ менә Кунош язып алган булып чыкты. Г. Толымбай аны Куношның 1925 елда Истанбулда басылып чыккан «Төрек халык әдәбияты» дигән китабыннан күчереп алган икән. Өлкән буын галимнәргә бу кадәресе мәгълүм булса да, Г. Толымбайны телгә алырга ярамаган, ә Төркия белән хәбәрләшү иң зур җинаять саналган заманда әлеге мәсьәләгә өстәмә ачыклык кертергә җөрьәт итүче булмаган, һәм моңа гаҗәпләнергә дә туры килми.

Ниһаять, 1963 елда «Акта Ориенталиа» журналында Будапешт университеты галимәсе төркиче Жужа Кәкүкнең И. Кунош архивы турындагы мәкаләсе басылып чыга. Будапештта нәшер ителә торган бу журналны безнең галимнәр белмәгәннәрдер, дип әйтә алмыйм, әмма әлеге мәкаләнең телгә керүе ун елга соңрак булды шикелле. Аннан соң да әле, тел барьеры сәбәпче булдымы (мәкалә француз телендә басылган), әллә рус телендә кыска гына тасвирламасы (аннотация-резюме) канәгатьләндердеме бу фактка тиешенчә әһәмият бирүче булмады.

Вакыт сизелмичә генә уза торды, мин фәкыйрегезнең Кунош архивы белән танышу омтылышы да барып чыкмады, әмма, Ходайның рәхмәте белән, хыялларымның тормышка ашуына көтелмәгәндә яңа юл ачылды. 1982 елның көзендә Казанга Будапешт университетының яшь галиме Имре Башки килде. Ул әкиятләрнең Кунош кулы белән

язылган асыл нөсхәләрен алып килгән иде. Мин бу әкиятләрне басмага әзерләүдә Башкига ярдәм иттем. Соңрак бу галим «Төрек халык әдәбияты» дигән китапны табып, андагы «Ак бүре» әкиятенең ксерокопиясен җибәрде. Болар турында мин «Ак бүре»нең илгә кайтуы» дигән мәкаләмдә (Казан утлары, 1987, № 8) язган идем инде. Бу әкиятнең төп нөсхә белән чагыштырып төзәтелгән яңа текстын 1989 елда «Татар халык әкиятләре» җыентыгында бастырып чыгару насыйп булды.

Шул ук «Төрек халык әдәбияты» дигән китапта Куношның хәрби әсирләр арасындагы эшчәнлеге бәян ителгән бер хезмәте дә басылган булып чыкты. Аның белән танышкач, бу турыда мин җәмәгатьчелеккә «Венгр галиме татарлар арасында» дигән мәкалә белән (Казан утлары, 1990 № 2) мәгълүм иттем. Ә Куношның үз мәкаләсе соңрак «Мирас» (1992, № 5) журналында дөнья күрде. Дөрес, аның 1916 елда ук, ягъни татар әсирләре тотылган лагерьларда бер ел эшләгәч тә дөньяга чыккан мәкаләсе булганлыгын да беләбез. Әмма әлеге мәкалә басылган «Будапешт күзәтүчесе» дигән журнал Казан һәм Мәскәү китапханәләрендә табылмады. Венгриядән алдыру насыйп булса, укучыларыбызны ул хезмәт белән дә таныштырырбыз дип уйлыйм.

Ә хәзер И. Куношның архивы турында берничә сүз. И. Кунош татар хәрби әсирләреннән авыз иҗаты әсәрләрен язып алуга Венгрия Фәннәр академиясе үтенече буенча керешә. Аның кулъязмалары да шушы академиянең Шәрекъ китапханәсендә саклана. Туплама 1200 гә якын кулъязма-берәмлекне тәшкил итә. Ул биш төргәктән тора.

Беренче төргәк Казан татарларының әкиятләреннән (231 бит) гыйбарәт. Анда барысы төрле күләмдәге 14 әкият тупланган (дөрес, соңгысы тулы түгел). Бу әкиятләр 1916–1917 елларда Эгер шәһәрендәге лагерьда җыелганнар. Текстларның тәрҗемәләре юк, кайбер сүзләрне аңлату йөзеннән җәяләр эчендә төрек яисә венгр сүзләре куелган. Җай чыкканда шуны да әйтик: бу коллекциядә «Ак бүре» әкияте юк. Галим аны бастыру өчен алгач, кулъязмасын кире үз урынына куймаган булса кирәк.

Икенче төргәктә – Кырым татарларының әкиятләре (444 бит). Барысы 38 текст, һәр текстның венгр теленә тәрҗемәсе бар. Бу әкиятләр 1915 елда Кеньермезье лагеренда язып алынган. Кызганычка каршы, Кырым татарларының җырлары, ни сәбәптәндер, биредә юк икән.

Өченче төргәктә мишәр-татарларның җырлары һәм әкиятләре (161 бит) урнашкан. Анда 263 дүртьюллык бар. Шуларның 231 е төрек һәм венгр телләренә тәрҗемә ителгән, калган 32 се – тәрҗе-

мәсез. 7 әкиятнең 6 сы шулай ук венгр теленә тәрҗемә ителгән, берсе – тәрҗемәсез. Бу материаллар 1918 елда Эгер лагеренда җыелган.

Дүртенче төргәк Казан татарларының җырларыннан (108 бит) тора. Биредә 635 дүртьюллык булып, алар төрек һәм венгр телләренә тәрҗемә ителгән. 1915 –1918 елларда Эгер лагеренда җыелган.

Бишенче төргәктә төрле характердагы материаллар (108) тупланган (Дунай татарлары, Кырым татарлары, Кырымнан чыккан караимнар һәм нугайларга бәйле язмалар, мишәр сүзлеге һ.б.). Бу материаллар арасында Дунай татарларына караганнары 1912 елда, ә караимнарга караганнары 20 нче елларның азагында язылганнар. Калганнары шул ук Эгер лагере белән бәйле.

Галимнең үз сүзләренә караганда, ул мөселман хәрби әсирләре тотылган лагерьларда эшләүгә өч елның өчәр аен багышлаган. Бу – 1916–1918 елларга карый булса кирәк. Чөнки Ж. Кәкүкнең язуынча, галим 1915 елда үзенең эшен башлап җибәргән Кеньермезье лагеренда алты атна гына булган. Монда Кунош башлыча Кырым татарларының фольклорын туплаган. Шул ук елда ул Эгер лагерена күчә һәм биредә Казан татарларының, шулай ук мишәрләрнең җырларын һәм әкиятләрен язып ала. Галим Казан татарларының халык иҗаты байлыгына хәйран кала, бигрәк тә әкиятләренә югары бәя бирә.

Кунош туплаган җырларны Будапешт университеты профессоры Ж. Кәкүк «Казан татарларының халык җырлары» дигән исем белән 1980 елда ук инде аерым китап итеп чыгарды. Татар һәм немец телләрендә басылган бу китап турында үз вакытында матбугатта хәбәрләр булган иде. Инде менә Кунош архивындагы әкиятләребез дә дөнья күрде. Бу китап та татар һәм немец телләрендә чыккан: сул як бите – татарча, уңы – немецчә. Басмага әзерләүчеләр Жужа Кәкүк һәм Имре Башки.

Тиешле рәсми элемтәләр булмау сәбәпле, бу китап безнең кулыбызга бик соң килеп ирешә. Мин аны Казан университетының тел белеме галимәсе доцент Ф. Хисамовадан алдым. 1989 елда нәшер ителгән бу китап аңа да күптән түгел генә килеп кергән икән.

И. Кунош телче галим булган, әкиятләрне дә ул тел өйрәнү материалы итеп җыйган, һәм китап та телчеләр өчен, транскрипция белән басылган. Әмма әкият сөюче меңнәрчә укучылар өчен ул – фольклор китабы, әкиятләр җыентыгы. Шуңа күрә аны, транскрипциядән гамәлдәге язуга күчереп, тизрәк халыкка җиткерәсе килде. Бу теләгемне «Мирас» журналы хуплагач, мин, җиң сызганып дигәндәй, эшкә керештем.

Китап кыска гына кереш мәкалә белән ачыла. Мәкалә немец телендә язылган. Анда шушы китапка кергән 14 әкиятнең 2 се озын,

12 се кыска, шулардан берсенең тәмамланмаганлыгы белдерелә һәм аларның 1916–1917 еллардагы Эгер лагеренда язылган булуы раслана. Шулай ук татар хәрби әсирләре арасында зыялы шәхесләрнең дә булганлыгы һәм Куношның алар белән аралашканлыгы хәбәр ителә. Янә дә татар экиятләрендә мифологик пресонажлар белән бергә гадәти карт һәм карчыкларның да катнашуы, шулай ук бу әсәрләрдә халыкның тормышы һәм гореф-гадәтләренең чагылуы турында да сүз бар. Әкиятләрнең 231 бит тәшкил итүе, әмма 223 нче битнең югалганлыгы да теркәп куелган (бу югарыда искә алынган тәмамланмаган 14 нче экияткә туры килә). Мәкаләнең азагында Кунош транскрипциясенең камил булмавы, акка күчергәндә кайбер сүзләрнең төшеп калганлыгы, әмма китапта әлеге хаталарның төзәтелгәнлеге һәм бу фактларнын искәрмәләр бүлегендә чагылганлыгы турында да бәян ителә. Шунысы да мәгълүм булсын: «Патшаның өч улы», «Кол малай» дигән экиятләрнең исемнәре китапны басмага әзерләүчеләр тарафыннан бирелгән.

Әкиятләрнең үзләре турында мин биредә сөйләп тормаска булдым – укучылар үзләре күрерләр. Текстларга бары орфографик төзәтмәләр генә кертелде. Әлбәттә, тыныш билгеләре дә бүгенгечә куелды. Әмма лексикасы һәм стиле нәкъ оригиналдагыча калды. «Бу сүз бик урынлы түгел», яисә «Болай сөйләмиләр бит хәзер», – дип, текстларга үземчә төзәтүләр кертсәм, ул бит инде ахыр чиктә минем тел, минем стиль булып китә. Мираска сак карарга кирәк. Аннан соң бит әле бу – гади мирас кына да түгел, бәлки тоткынлыкта интегеп яшәгән бабаларыбызның күңел юаткычлары да. Теләсә ничек тыгылып, аларның рухларын рәнжетүебез мөмкин. Без бу ядкярләрне аларның хәтере, хәтта васыяте итеп кабул итик. Тик кызганыч, ул вакыттагы гадәт буенча, язып алучы бу экиятләрнең кем тарафыннан сөйләнгәнлеген теркәп калдырмаган.

## Мажаралар дөньясында

*Әкият китапларына күзәтү*

Фольклорның аеруча киң таралган, кызык һәм мавыктыргыч жанрларыннан берсе – экият. Әкиятләр баланың рухи дөньясын баета, фантазиясен үстерә. Аларны тыңлаганда яки укыганда бала үзен экият герое итеп сизә, әлеге геройның шатлыгын да, кайгысын да үзенеке шикелле кабул итә. Явыз көчләр вакытлыча уңышка ирешкәндә, сабый ихлас күңелдән борчыла, ә экиятнең азагында, яхшылыкның җиңүен белгәч, аның шатлыгы эченә сыймый. Шу-

лай итеп, әкият бала психикасын бай һәм гуманлы итүдә тәэсирле чараларның берсе булып тора.

Әкиятләр халык педагогикасында бик күптәннән кулланылган. Бу сихри хикәяләр тәэсирендә кешелекнең ничәмә-ничә буыны тәрбияләнгән.

Әкиятләр тәрбиянең кайсы төрләренә хезмәт итә соң? Шушы җәһәттән аларның әһәмиятен укучылар кулына соңгы вакытта кергән әкият китаплары мисалында күрсәтү, безнеңчә, отышлырак булыр шикелле. Бу максатта файдаланылачак китаплар түбәндәгеләр: «Татар халык әкиятләре» (төзүчесе Х. Гатина, Казак, 1974), «Украин халык әкиятләре» (тәрҗемәчесе Р. Гарипов. Казан, 1973), Г. Тукай, «Шүрәле» (рус телендә, С. Липкин тәрҗемәсе. Мәскәү, 1974), Р. Батуллин, «Алтын куллы Гөлчәһрә» (Әкиятләр, Казан, 1974).

Дүрт китап, дүртесе дүрт төрле: беренчесе – татар халык иҗаты җәүһәрләре, икенчесе – башка халыкның рухи хәзинәсе, өченчесе – классик шагыйрь әсәре, дүртенчесе – бүгенге язучының иҗат җимеше. Дүрт төрле, ләкин барысының да табигате бер: болар – әкиятләр.

Әлеге китаплар, гомумән алганда, бер үк максатка – яшь буынны тәрбияләү эшенә хезмәт итсәләр дә, тәрбиянең аерым төрләренә мөнәсәбәттә караганда, аларның һәркайсының өстенлек итә торган вазифасы бар.

Кече яшьтәге балалар өчен әкиятләр бигрәк тә әхлакый тәрбия чарасы буларак зур роль уйный. Мәрхәмәтле, тугры һәм итагатьле булу, олыларга, аеруча ата-анага хөрмәт хисе балада бик иртә тәрбияләнергә тиеш. Бу идеяләрне үткәрүче әкиятләрне күпләп күрсәтергә мөмкин. Менә беренче җыентыкка кергән «Өч кыз туган» әкияте. Әниләре авырып киткәч, өч кызның икесе аның хәлен белергә бармый. Олысы: «Җиз ләгәннәрне тазартып бетерәсем бар иде», – дигән. Уртанчысы: «Ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул», – дигән. Шуның өчен әниләренең дусты тиен аларның беренчесен ташбакага, ә икенчесен үрмәкүчкә әверелдерә. Кече кыз исә, әнисенең авыру хәбәрен ишетүгә, камырлы кулларын да сөртеп тормыйча, аның янына йөгергән. Тиен аңа изге теләк теләгән. Әкият болай тәмамлана: «Кече кыз чыннан да бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди».

«Күке кычкыргач, көтүче хезмәт хакы ала» дигән әкияттә ярлы, ләкин зирәк көтүченең комсыз байны җиңүгә ирешүе яшь укучыны шатландыра. Бу инде социаль тәрбия дигән сүз.

Хайваннар турындагы әкиятләр бала күңеленә аеруча хуш килә. Беренче җыентыкта алар шактый күп. Мондый әкиятләрнең

бер өлеше этик тәрбия өчен бик кулай. Мәсәлән, «Әтәч патша» исемлесендә түшен кабартып кукраеп йөргән мактанчык әтәчнең ничек көлкегә калуы сурәтләнә. Әтәч үзенең тавыкларына сорау бирә: «Арыслан тавышыннан да көчлерәк тавыш кемдә бар? Кемнең аягы куәтлерәк тә, кемнең киеме зиннәтлерәк?» Тавыклар, түбәнчелек күрсәтеп, болай дип җавап бирәләр: «Кемнең булсын, синең киемең зиннәтлерәк, падишаһыбыз, синең аякларың тимердән дә ныграк, солтаныбыз, синең тавышың арыслан тавышыннан да гайрәтлерәк, куәтле ханыбыз». Шушы характердагы сорау-җаваплар тагын берничә мәртәбә кабатлана. Ләкин әтәчнең язмышы фаҗигале тәмамлана: пешекче аны тотып суя да тәмле шулпа пешерә. «Ә кешеләр ашыйлар-ашыйлар икән дә, ашны мактап: «Ай-яй, тәмле икән бу әтәч! Ай-яй, симез икән бу әтәч! – дип әйтәләр икән, ди».

Шулай итеп, бу әкияттә кәпрәю, нигезсез масаю, шапырыну гаять тәэсирле рәвештә тәнкыйть ителә. Мактану өчен сыйфатлар чынлыкта аларның иясенә бернинди дә файда китерә алмый, нигезсез мин-минлек бик тиз көлке объектына әверелә. Әкияттә бер үк вакытта тәлинкә тотучылар да мәсхәрәгә кала.

Хайваннар турындагы әкиятләрдә кешеләрдә очрый торган башка кимчелекләр дә тәнкыйтьләнә. «Песәй» дигән әкияттә, мәсәлән, ялкаулык, эш сөймәү көчле ирония белән сурәтләнсә, «Кәҗә белән сарык» исемлесендә яхшылыкның кадерен белмәү, игелекне оныту кебек сыйфатлар кискен гаепләнә.

Үз халкының әкиятләре тәэсирендә тәрбияләнгән бала башка халыкларның иҗаты белән дә кызыксыначак һәм аны хөрмәт итәчәк. Мәктәп программаларында төрле халыкларның әкиятәрен чагыштырып өйрәнү каралмаган. Ләкин укучылар моңа мөстәкыйль рәвештә дә ирешә алалар. Мәсәлән, украин халкының «Мыраужан пан», «Бүре, эт һәм мәче», «Кәҗә-ристан», «Төлке-кодача», «Кәҗә белән сарык», «Мескен бүре», «Тапкыр кыз» һ.б. әкиятләрен укыганда алардагы сюжетларның бик таныш булуына игътибар итми мөмкин түгел, чөнки укучы аларны татар халык әкиятләрендә очраткан була инде. Барлык халыклар да бердәй диярлек тарихи этаплар үткәнлектән, хәтта географик яктан бер-берсеннән бик ерак торганнарында да бердәй сюжет һәм мотивлар барлыкка килә алган. Димәк, халыкларның уй-теләкләре, хыял-омтылышлары да элек-электән үк бердәй булган, һәм бу аларның поэтик иҗатларында да ачык чагылган. Әкиятләрне  тикмәгә генә иң интернациональ жанр дип атамыйлар. Интернациональ тәрбия максатларында төрле халыкларның әкиятләрен файдалану гаять зур нәтиҗә бирә.

Г. Тукайның халык легендасына нигезләнеп язган «Шүрәле» поэмасын балалар аеруча ярата. Бу әкиятнең аерым китап булып Мәскәүдә рус телендә 150 мең данә басылып чыгуы шулай ук интернациональ тәрбия эшенә кертелгән мөһим өлеш. «Шүрәле» әкияте аша төрле милләт балалары татар халкының рухи хәзинәсе белән, бер үк вакытта Г. Тукай һәм әлеге китапны бизәгән рәссам Ф. Әминов иҗаты белән да танышачаклар. Эстетик һәм патриотик тәрбия өчен бу классик әсәрнең әһәмияте зур.

Татар совет язучылары да әкиятләрне шактый күп иҗат итәләр. Хәзерге көндә бу өлкәдә Р. Батуллин нәтиҗәле генә эшләп килә. «Алтын куллы Гөлчәһрә» дигән соңгы китабын аның яңа иҗади уңышы дип санарга кирәк. Бу китапка авторның өч әкияте кергән. Арада «Алтын куллы Гөлчәһрә» дигәне башкалардан үзенең формасы белән аерылып тора: ул берничә мөстәкыйль хикәя арасына үреп калдырылган сыман, һәм аның сюжетындагы фантастик күренешләр реаль тормыш вакыйгаларына бәйләп сурәтләнә. Төгәлрәк әйтсәк, автор гражданнар сугышы чорындагы вакыйгаларны мәгълүм поэтик чаралар ярдәмендә тылсымлы әкияткә әверелдергән. Бу әсәр хәрби һәм патриотик тәрбия вазифаларын үти.

Әлеге китапка кергән «Йолдызлар турында әкият» һәм «Курай уйный бер малай» дигән әсәрләр мораль һәм эстетик тәрбия максатларын күздә тотып язылган.

Танылган совет рәссамы Т.А. Маврина, әкиятләрнең эстетик тәрбия бирүдәге ролен күрсәтеп, «Правда» газетасында: «Әкият һәр йортта да булырга тиеш», – дип язды. Татарстан китап нәшрияты һәр йортта да күңелле әкият китаплары булдыру юлында әйбәт эш эшләгән.

## Халык әкиятләрен туплауда һәвәскәрләрнең роле

Фольклор фәне өч зур бүлектән (блоктан, катламнан, юнәлештән) гыйбарәт. Алар: 1) фольклор әсәрләрен халыктан җыю, 2) җыелган хәзинәне бастырып чыгару, 3) фольклор әсәрләрен фәнни өйрәнү.

Әйе, фольклористиканың, ягъни фольклор фәненең фактик материалы – халык авыз иҗаты әсәрләре. Бу әсәрләр, әлбәттә, төрле жанрларга карый, һәр жанрның үзенең хассиятләре бар. Фольклорны жанрларга халык үзе бүлгән: әкият, бәет, җыр, табышмак, мәкаль дигән атамаларны халыкка галимнәр табып бирмәгән. Бу атамалар

халыкның үзенеке, һәр жанрның үзенчәлекләрен тирәнрәк ачып бирү исә фәнгә йөкләнгән.

Фәнни эш материал җыюдан башлана. Фольклор фәненең материалы – фольклор әсәрләре. Бу материал исә халык телендә. Халыкны сөйләтеп, әлеге материал төрле ысуллар белән язып алына. Дөрес, җыр, бәет, мөнәҗәт кебек әсәрләрне халык үзе дә кәгазьгә төшерә. Бу исә фольклорчыларның экспедициядәге эшен шактый җиңеләйтә: әлеге әсәрләрне дәфтәрдән күчереп кенә аласы, фотога төшерергә дә мөмкин. Кайбер информантлар әлеге дәфтәрләрен экспедиция әгъзаларына бүләк тә итәләр. Мәкаль һәм әйтемнәрне исә халык сөйләменнән «чүпләргә» туры килә.

Ә менә әкиятләрне туплау – иң авыры. Беренчедән, хәзерге вакытта әкият халык телендә сөйләнмәү сәбәпле, әкиятчеләр юк. Шуңа күрә, яшь чагында ишеткән әкиятен күңелендә саклаган олы яшьтәге берәр кешене табу – үзе зур проблема. Икенчедән, андый кеше табылса да, иң элек эле аның «телен ачарга» кирәк була: үзеңне аның белән бер дәрәҗәгә куя белергә, аныңча «авыл телендә» аңлашырга һәм аңлатырга, ниһаять, хәтерендә сакланып, «сыекланып» калган әкиятен ачыграк искә төшерү өчен беркадәр вакыт, миһләт бирергә. Өченчедән, әкият телдән сөйләнү сәбәпле, аны гади ысул белән язып өлгерү – гаять авыр шөгыль.

Узган гасыр башында яшәгән фольклорчылар авыз иҗаты әсәрләрен телдән гарәп хәрефләре белән язып алганнар. Без күреп белгән галимнәр дә – Н. Исәнбәт булсын, Х. Ярми булсын, әдип Г. Бәширов булсын, алар фольклор экспедицияләрендә гарәп графикасын кулланып эш иткәннәр. Бу ысул белән язганда сөйләүче артыннан өлгереп бару мөмкинлеге булган. Ягъни бу графика үз чорының стенографиясе ролен дә үтәгән.

Узган гасырның 40–50 нче елларында исә Х. Гатина әкиятләрне халык теленнән нәкъ менә стенография ысулы белән язып алган.

50 нче елларда инде фольклорчылар кулына биниһая авыр магнитофоннар керә башлый. 60 нчы еллар уртасында экспедициядә портатив магнитофоннардан файдалана башладылар. Бүгенге без белгән диктофоннарны куллану татар фольклорчыларына XXI гасыр башында гына насыйп булды.

Әмма инде бу вакытта һәм бүгенге көндә авылларда әкиятчеләрне табу комбайннан төшкән салам өеме эченнән исән калган башак эзләнүгә тиң гамәл булып калды. Фольклор экспедицияләре сәяхәттән гадәттә бер әкият алып кайта, яисә хисапларындагы әкият графасында «0» саны мескенләнеп тора.

Ярый, монысы бер лирик чигенеш булды. Инде төп темага күчик.

Халык әкиятләрен туплаган безгә мәгълүм һәвәскәрләрнең иң өлкәне – Зариф Мөэминев (1893–1966). Аның яшәгән урыны Татарстанның Мөслим районындагы Теләнче (хәзерге исеме Октябрь) авылы. Ул үзенә мәгълүм әкиятләрне кәгазьгә төшереп, 1939 елда Казанга Тел һәм әдәбият институтына (хәзер: Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты – ТӘһСИ) җибәрә. Бу әкиятләрнең берничәсе («Адәм егет һәм җен егет», «Үксез кыз», «Бүре белән Тәкә», «Бүдәнә белән Төлке», «Кәҗә белән Бүре», «Аучы сөйли», «Кулсыз кияү») 1940 елда ук «Халык иҗаты» дигән җыентыкта басылып чыга (информанты күрсәтелмәгән).

Зариф Мөэминевнең әкиятләр белән кызыксынуы, аларны туплавы яшьлек елларында ук башлана. Аның язмаларында, информантлар буларак, Исмәгыйль карт, Латыйп бабай, Габдрахман агай, Габделҗәлил карт, Юсуп карт Хәлилов, Шакир Закиров исемнәре теркәлгән. Болар Зариф Мөэминевнең авылдашлары булса кирәк.

Беренче бөтендөнья сугышы чорында бу яшь солдат әсирлеккә дучар була, әмма тоткын хәлендә дә ул әлеге эшен туктатмый, әсирләрдән әкиятләрне 1915 елда ук язып ала башлаган. (Мәгълүм булганча, венгр галиме Игнац Кунош та шушы чорда татар әсирләреннән әкиятләр һәм җырлар язып алган.) Әмма мәхбүсләрне Босния өлкәсендәге Фрауник шәһәреннән Сараево шәһәренә күчергәндә Зариф солдатның әкиятләр язылган дәфтәрләрен конфискациялиләр (кем белә, гарәп хәрефләре белән язылган бу дәфтәрләр бәлки кайдадыр бер архивта саклана да torгандыр). Аның соңгы язмалары арасында Фәтхетдин Хәйретдинов дигән әсирнең генә исеме ничектер теркәлеп калган.

Ләкин бу энтузиастның күңеле сүрелми, ул чирек гасырга якын вакыт узгач, югалган материалны хәтер көче белән кабат торгыза һәм әлеге әкиятләрне китап итеп чыгару артыннан йөри. Казанда эш барып чыкмагач, ул, бастырып чыгару өмете белән Уфага Тарих, тел һәм әдәбият институтына юнәлә. Зариф аганың улы Сәгыйть Мөэминев сүзләренә караганда, аның әтисен институтның бүлек мөдире язучы Гайнан Әмири кабул итә һәм аның кулъязмаларын алып кала. Коллекциянең язмышын белү өчен кабат барганда инде мөдир: «Таба алмыйбыз, югалды» дип җавап бирә.

Шуннан соң 60 яшьлек Зариф картка үзенең әкиятләрен авыл яшьләренә сөйләү мөмкинлеге генә кала. «Зариф абыйның кышкы озын төннәрдә, куырган борчак ашый-ашый, яшьләргә әкиятләр сөйләве әле дә күз алдында тора», – ди әкиятченең авылдашы Га-

фият ага Сәхиуллин, – һәм ул 1981 елда безгә аның авызыннан ишеткән өч әкиятне[1] сөйләп бирде.

Г. Ибраһимов исемендәге институт мирасханәсендә З. Мөэминевнең 52 әкият язмасы саклана[2]. Шуларның 14 е фәнни басмаларда дөнья күргән.

Халык әкиятләрен җыю белән шөгыльләнгән һәм зур күләмле җитди коллекция булдырган тагын бер энтузиастны телгә алып узыйк. Ул – Кукмара районының Байлангар авылы кешесе Миңлемулла Кәримуллин. ТӘҺСИ мирасханәсендә аның Байлангар һәм Каенсар авылларында төрле елларда язып алынган 30 әкияте саклана[3]. Аларның бер өлеше Бөек Ватан сугышына кадәр үк, 1939–1941 елларда кәгазьгә төшерелгән һәм Казанга Тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәрелгән.

Миңлемулла Кәримуллин Байлангар авылында 1913 елда туган. Авыл башлангыч мәктәбен тәмамлаганнан соң, курсларда укып, 1932 елда Кукмара МТСында тракторчы булып эшли башлый. Дүрт елдан соң, эш вакытында бәхетсезлеккә юлыгып, 23 яшьлек егет бер аяксыз кала. Шулай да тракторын ташламый, сыңар аяклы килеш, эшләвен дәвам иттерә.

Шушы дәвердә ул күп укый, үзе дә иҗат белән шөгыльләнә башлый, пьесалар язып карый, авылдашларыннан халык әкиятләрен язып алып, Казанга фольклорчы Хәмит Ярмигә җибәрә, аның фикерен сорый.

Сугыштан соңгы чорда да бу энтузиаст халык әкиятләре белән кызыксынуын дәвам итә. 1948 елда Х. Ярмигә юллаган хатында ул, моңа кадәр җибәргән әкиятләренә дә җавап алмавы турында әйтеп, «киләчәктә фольклор материаллары җыю кагыйдәләрен өйрәнүдә ярдәм итүегезне үтенәм», – дип яза.

Күренә ки, авылның гади тракторчысы Миңлемулла Кәримуллин фольклор җыю, төгәлрәк әйткәндә, халык телендәге әкиятләрне туплау эшенә җитди карап, бу шөгыльнең методикасын үзләштерү зарурлыгын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә. Әмма җавап, ни өчендер, һаман да язылмый. 1949 елда ул Х. Ярмигә янә әкият текстлары һәм берничә иске китап сала, киләчәктә тагын әкиятләр җибәрергә вәгъдә итә.

Сугыштан соңгы ул хатларын М. Кәримуллин инде Каенсар авылыннан яза. Бәлки ул шунда яшәгәндер дә.

---

[1] ТӘһСИ, мирасханэ, колл. 93, п. 1, сак. бер. 2.
[2] Колл. 10, п. 1, сак. бер. 1, 2, 3, 4; п. 2, сак. бер. 8, 9.
[3] Колл. 2, п. 1, сак. бер. 1, 2, 3, 5–11

Бәла ялгыз йөрми, диләр. Миңлемуллага тагын бер бәхетсезлек килә: ул, тракторда эшләгәндә тимер чәчрәп, бер күзсез кала, икенчесенә дә зарары тия. Бу хәл 1954 елда була. Нәтиҗәдә 41 яшьлек ир бөтенләй эшли алмас хәлгә төшә һәм зур булмаган пенсия хисабына яшәргә мәҗбүр була. Әмма әкиятләргә булган мәхәббәте барыбер кимеми.

М. Кәримуллинның 1959–1960 елларда язылган хатлары Свердловск өлкәсендәге Вангранская станциясеннән килә. Нинди язмыш аны ул якларга илтеп ташлагандыр, анысы безгә мәгълүм түгел. Әмма биредә дә ул үзенең мавыгуын ташламый – Институтка Х. Ярми исеменә тагын унлап әкият тексты җибәрә. Бу әкиятләрне ул, элек ишеткән булып, шунда исенә төшереп язган булса кирәк. Чөнки кайберләрендә «1954 елны Сабир Мусабаевтан», «Сәетгалиев Сәетгәрәйдән» дигән искәрмәләр бар. Шуның өстенә үзенең хатында ул: «Биредәге кешеләрдән дә әкиятләр язып алырга уйлаган идем, андый кешеләрне таба алмадым», – дип яза. Димәк, фаразыбыз дөрес булырга тиеш.

М. Кәримуллинга җавап хаты үз вакытында язылмаган, күрәсең. Чөнки Миңлемулла биредән (Свердловск өлкәсеннән) язган хатында да методик ярдәм соравын дәвам итә. «Бәлки мин бик күп вакытымны бер дә кирәксезгә, бушка уздыра торганмындыр, минем җибәргән әкиятләрем турында дөрес җавап бирүегезне үтенәм. Әкиятләрнең теленә килсәк, үзем ничек сөйлим, шулай язам. Башкача яза алмыйм», – дип хәбәр итә ул Х. Ярмигә 1960 ел башында.

Ниһаять 1960 елның 10 гыйнварында аңа җавап хаты җибәрелә. Хат текстының күчермәсе теркәлмәгән, бәлки анда бу тынгысыз затка тиешле киңәшләр бирелгәндер.

М. Кәримуллин әкиятләре белән беренче тапкыр фольклорчы һәм язучы Э. Касыймов кызыксына. Ул үзе төзегән «Абага чәчәге» исемле сатирик әкиятләр җыентыгына (Казан, 1962) Миңлемулланың өч әкиятен кертә. Ә татар фольклорының 12 томлы фәнни җыелмасындагы әкият томнарының 3 нче китабына (Казан, 1981) мин үзем М. Кәримуллинның тагын ике әкиятен тәкъдим иттем. Аның басылган әкиятләреннән «Алдакчы Тимер», «Кол һәм алпавыт», «Абага чәчәге» дигәннәре аеруча кызыклы.

Димәк, М. Кәримуллин җибәргән 30 әкиятнең бишесе абруйлы фәнни җыентыкларда дөнья күргән. Янә дә шул ук күптомлы фәнни җыелманың Х. Ярми һәм Х. Гатина тарафыннан төзелгән «Тылсымлы әкиятләр» томында (2 нче китап. – Казан, 1978) М. Кәримуллинның тагын дүрт әкияте телгә алына (алар алда искә алган китапта басылган әкиятләрнең вариантлары буларак күрсәтелә).

Шулай итеп, мирасханәдә саклана торган (ФФ, колл. 2, папка 1) 30 әкиятнең 9 ы фәнни әйләнешкә кергән дигән сүз. Басылырга лаеклы әкиятләр әле тагын бар.

М. Кәримуллинның шуннан соңгы язмышы безгә мәгълүм түгел. Әгәр аның якташларыннан берәр кеше, эзтабарлык эшенә алынып, бу мәсьәләгә ачыклык кертә алса, бу бик игелекле гамәл булыр иде.

Без биредә халык әкиятләрен туплау өлкәсендә зур хезмәт куйган һәвәскәрләрнең икесе турында гына сүз алып бардык. Бәлки әле киләчәктә шундый ук эш белән танылган башка һәвәскәр фольклорчылар турында да сөйләү мөмкинлеге булыр. Мәсәлән, Хәдим Канзафаров (Башкортостанның Чакмагыш районыннан, 1939–1940 елларда 36 әкият тексты җибәргән), С. Миңлекәев (Татарстанның Ютазы районыннан, 1952–1953 еллар, 18 текст), Зәкәрия Әхмәров (Оренбург өлкәсе, 1953 ел, 11 текст), Гариф Вафин (Столбище, хәзерге Лаеш районы Хәерби авылыннан, 1959 ел, 35 текст), Усман Вәлиев (Баулы, 1959 ел, 11 текст) һ.б.

## Татар әкиятләре дөнья әкиятләре каталогында

Фәннең кайсы гына өлкәсендә, кайсы гына тармагында булмасын, җитди тикшеренүләр алып барганда, төпле нәтиҗәгә ирешү өчен, беренче чиратта әлеге өлкәне **тулаем күзаллау** зарур. Бу шарт фольклорны, аның төрле жанрларын өйрәнүдә дә мөһим таләп булып тора. Шуңа күрә дә эш, гадәттә, нәкъ менә тикшерү объектын тулаем күзаллауга ярдәм итә торган хезмәтләр белән танышудан башлана. Инде фольклорның әкият жанрына килсәк, бу өлкәдә эшләүчеләрнең күз күремен киңәйтә торган, аның эшендә зур уңайлык тудыра торган, бигрәк тә чагыштырма-тарихи һәм тарихи-типологик юнәлештә тикшеренүләр алып баручыларның «өстәл китабы»на әверелгән бер олуг хезмәт бар. Ул – дөнья халыклары әкиятләренең каталогы. Аны, гадәттә, әкиятләрнең сюжет күрсәткече дип атыйлар.

Мәгълүм ки, фольклорның кайсы гына жанрын тикшерә башлама, иң элек бу жанрдагы әсәрләрнең сюжетларын типлаштыру, системага салу, ягъни классификация таләп ителәә. Бу бурычны тормышка ашыруда әкият жанры,фольклорның башка жанрлары белән чагыштырганда, уңайлырак хәлдә булып чыкты, чөнки әкиятләрнең халыкара сюжет күрсәткече XX йөзнең башында ук пәйда була.

Әкият сюжетларының әлеге беренче халыкара күрсәткече фин галиме Антти Аарне (1867–1925) тарафыннан эшләнеп, 1910 елда Хельсинки шәһәрендә немец телендә басылып чыга [1]. Бу күрсәткеч Аурупа халыкларының әкиятләре нигезендә төзелгән. Шушы тәҗрибә үрнәгендә рус галиме – әдәбият белгече һәм фольклорчы Николай Петрович Андреев (1892–1942), Аарне системасын файдаланып, рус халык әкиятләренең сюжет күрсәткечен эшли, һәм бу күрсәткеч (АА) 1929 елда Ленинградта нәшер ителә [2]. Ә инде дөнья халыклары әкиятләрен колачлаган җыелма күрсәткеч Ст. Томпсон тарафыннан төзелеп, 1928 елда инглиз телендә дөнья күрә. Шуннан соң бу хезмәт (АТ) 1961, 1964 һәм 1973 елларда төзәтмәләр һәм өстәмәләр белән шул ук Хельсинки шәһәрендә басылып килә. (Без аның 1961 елгы басмасы [3] белән эш итәбез).

Хәзерге вакытта бөтен дөньяда әкият белгечләре менә шушы Аарне-Томпсон (АТ) күрсәткеченнән киң файдалана, һәм шуның үрнәгендә әкиятләрнең күп кенә милли каталоглары барлыкка килде. Соңгылары исә, үз чиратында, АТ күрсәткечен тагын да баету, камилләштерү чарасы булып тора. Менә шундый милли каталогларның шактый абруйлысы узган гасырның 70 нче еллары азагында пәйда булды. Ул – рус, украин һәм белорус халык әкиятләре нигезендә эшләнгән «Сравнительный указатель сюжетов. Восточнославянская сказка» дигән каталог (СУС) [4]. Яңа мәгълүматлар исә АТ каталогының нәүбәттәге басмаларында исәпкә алына һәм, шулай итеп, төрле милләтләрнең әкият байлыгы дөньякүләм фәнни әйләнешкә керә, ахыр чиктә бу хәл әлеге халыкларның милли горурлыгына да әверелә.

Әкиятләрнең халыкара каталогына мөнәсәбәтле бу язмабыз да нәкъ менә шул милли горурлык хисе белән бәйле. Мәсьәлә түбәндәгедән гыйбарәт. Томпсон хезмәтенең беренче басмасы дөньяга чыгуга 80 елдан артык вакыт узган. Соңгы басмасы чыкканга да 35 елдан артык. Шушы соңгы дәвердә шактый гына милли каталоглар барлыкка килде, һәм хәзер инде Томпсон каталогының тулыландырылган яңа басмасы сорала иде. Һәм менә, ниһаять, андый басма да пәйда булды. Аны немец галиме Утер эшләгән.

Һанс-Йөрг Утер (1944 елда туган) Дуйсбург-Эссен университеты профессоры. Ул – немец әдәбияты белгече һәм фольклорчы, әкият һәм легендаларга багышланган 50 дән артык китап чыгарган зат, шулай ук немец, инглиз һәм башка телләрдә басылган бик күп мәкаләләр авторы.

Утернең инглиз телендә нәшер ителгән әлеге каталогы «Әкиятләрнең халыкара типлары. Классификация һәм библиография»

(Хельсинки, 2004) [5] дип атала. Автор, бу хезмәтенен Аарне-Томпсон системасына нигезләнүен белдерүе белән бергә, АТ каталогында шактый гына кимчелекләргә тап булуын да әйтә. Утер каталогы (ATU) өч кисәктән (томнан) тора. Беренчесендә хайваннар турындагы әкиятләрнең, тылсымлы, дини һәм новеллистик әкиятләрнең сюжетлары урнаштырылган; икенче кисәктә түбәндәге әкиятләрнең сюжетлары урын алган: аңгыра затлар турындагы әкиятләр, мәзәкләр, көлдергеч әкиятләр (небылицы) һәм чылбырлы (кумулятив) әкиятләрнең сюжетлары; шунда ук әкият тәгъбирләре (формулалары). Өченче кисәк – «Аппендикс» (кушымта) дип атала. Бу – белешмә том. Анда мондый бүлекләр бар: географик һәм этник терминнар; АТ каталогында булып та, бу каталогка кертелмәгән типлар; яңа типлар; сюжет номерларындагы үзгәрешләр; мотивлар исемлеге; әдәбият һәм кыскартмалар исемлеге; өстәмә мәгълүматлар; предметлар күрсәткече.

Күренә ки, яңа каталогның белешмә материаллар арсеналы шактый бай.

Утер каталогының төп үзенчәлеге, өстенлеге нидән гыйбарәт соң?

Утер иң элек АТ каталогына ревизия ясаган һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, анда 10 пункттан торган кимчелекләр атап үтелә. Әйтик, Томпсон каталогында, Аарне каталогындагы кебек үк, Аурупа иҗаты өстенлек ала иде. Әмма бу дисбаланс ниндидер этноцентрик идеология чагылышы түгел, бәлки шул чорда әкиятләр өлкәсендәге белемнең торышы белән бәйле булды. Мәгълүм ки, регионнарда бу юнәлештәге эш күптән түгел генә башланды. Төрле кыйтгалардагы төрле милләтләрнен әкият репертуарын барлау, сюжет типларын ачыклау, милли каталоглар төзү узган гасырның 60 нчы елларыннан соң гына тизләнеп китте. Бу процесс үзе дә Томпсон каталогының 1961 елгы басмасы гамәлгә керү белән бәйле дип уйларга кирәк. Ниһаять, бүгенге көнгәчә барлыкка килгән милли каталогларның мәгълүматлары Утер тарафыннан киң файдаланылган. Шуның өстенә, башка чыганаклар да эшкә җигелгән (аерым алганда: монографияләр, мәкаләләр, әкият җыентыклары, дәреслекләр, хәтта календарьлар да...). Тагын бер искәрмә: Томпсон, Аарне кебек үк, язма чыганакларга җитәрлек игътибар итмәгән. Хәлбуки, күп кенә әкиятләр, алардагы сюжет типлары нәкъ менә язма чыганакларда, шул исәптән әдәби әсәрләрдә теркәлеп калган. Әлбәттә, бу җитешсезлекне бер Томпсонга гына аударып калдырырга ярамый, әлеге кимчелек – гомумән «фин мәктәбе»нә хас сыйфат, ягъни төп игътибар тел-авыз традицияләренә юнәлтелеп, әдәби (язма) чыганаклар икенче планда калдырыла, еш кына әкиятләрнең

мөһим искерәк шәкелләре бәһаләп бетерелми. Утер исә әлеге хатаны төзәткән. Шуның өстенә, бу каталогта аз санлы этник төркемнәрнең материаллары да чагылыш тапкан.

Томпсонда еш кына темага кагылышлы фәнни әдәбиятка сылтамалар ясалмаган. Яисә теге яки бу әкиятнең вариантларын күрсәткәндә, яңа җыентыклар була торып, чыганак сыйфатында искерәк җыентыклар файдаланылган. Утер моны Томпсон каталогының бер җитешсезлеге итеп күрсәтә.

Утер Томпсон күрсәткечендәге сюжет номерларын үзгәртми, чөнки алар йөз елга якын вакыт дәвамында файдаланыла, аларны үзгәртү исә бик күп буталчыклык-аңлашылмаучылыкларга китерер иде. Әмма, материалның таләп итүенә нисбәтән, **сюжетларның исемнәре өлешчә үзгәртелгән,** өстәвенә, кыскача гына бирелә торган **эчтәлекне еш кына киңәйтергә** туры килгән. Аннары аерым **сюжетларның подтиплары берләштерелгән,** яисә алар кайчак хәтта **төп сюжетка кушып куелган.** Шулай итеп, әлегәчә берничә номер белән йөргән сюжет типлары бер номер белән генә билгеләнгән. Мәсәлән, 1730А*, 1730В* подтиплары 1730 белән берләштерелгән. Элеккеге саннарның урыннары исә буш калган, алар турысында (янында) 1730 номерын карарга тәкъдим ителгән. Кайбер очракта исә Томпсондагы **төрле мөстәкыйль сюжет типлары биредә бер типка берләштерелгән.** Мәсәлән, Томпсондагы 1587 нче тип Утерда 927Д тибы булып, ә 1587** тибы 1642А тибы булып теркәлгән. Кыскасы, яңа каталог камилләшкән, баеган.

Иң мөһиме шул: әкият сюжетларының халыкара каталогта теркәлүе – аларның дөньякүләм фәнни әйләнешкә керүе дигән сүз. Шуңа күрә бирегә эләгү – һәр милләт фольклорчыларының бәхете, шатлыгы ул. Руслар бу бәхеткә 1961 елда ия булды. Рус әкиятләре Н. Андреевның 1929 елда дөнья күргән күрсәткече аркасында Томпсон каталогының нәкъ менә 1961 елда нәшер ителгән икенче басмасында урын алган. Биредә татар әкиятләре юк. Ә менә Утер күрсәткечендә, ниһаять, без **татар әкиятләре белән дә очрашабыз.** Ничек килеп эләккән алар бу каталогка?

Каталогка кертелүнең шәкли шарты – әкиятләрнең инглиз яисә немец теленә тәрҗемә ителгән булуы. Мәгълүм булганча, XIX гасырның азагында фин галиме Һ. Паасонен туплаган татар әкиятләрен Е. Караһка немец теленә тәрҗемәләре белән Хельсинкида 1953 елда бастырып чыгарган иде [6]. Әмма бу басманы Томпсон, нишләптер, файдаланмаган. Утер исә үзенең каталогына шушы басмадагы һәм, өстәвенә, И. Кунош коллекциясендәге әкиятләрне дә керткән. Венгр галиме Игнац Куношның (1860–1945) Беренче

бөтендөнья сугышы чорында (1914–1918) татар әсирләреннән язып алган әлеге әкиятләрен 1989 елда Жужа Какук белән Имре Башки Будапешттта бастырып чыгарганнар иде [7].

Утер, болардан тыш, татар әкиятләренә бәйле мәгълүматлар теркәлгән тагын бер чыганакны файдаланган. Ул – Иштван Кескемети һәм Һейкки Пауноненның «Фин-угыр җәмгыяте басмаларында әкият типлары» [8] дигән хезмәте. Бу хезмәттә фин-угыр халыкларының әкиятләренә типологик анализ ясалган. Әкиятләрдәге сюжет типлары Аарне-Томпсон күрсәткече буенча билгеләнгән. Хезмәттә, дистәләгән фин-угыр халыкларының әкиятләре белән беррәттән, өч чыганак буенча татар әкиятләре дә тикшерелгән. Ул чыганаклар – Г. Балинт [9], Һ. Паасонен, М. Васильев [10] китаплары. Әмма татар әкиятләренең биредә нинди максат белән кулланылганлыгы аңлашылмый. Ярый, венгр Балинтның, фин Паасоненның фин-угыр җәмгыятенә ниндидер мөнәсәбәте булсын да ди, әмма М. Васильевның 1924 елда Казанда рус телендә басылган китабының биредә ни катнашы бар? Кескемети һәм Паунонен хезмәтендә бу турыда бер сүз дә әйтелми. Шушы уңайдан тагын бер факт игътибарны җәлеп итә. Утер каталогының библиографиясендә Паасонен хезмәте бар, ә Балинт һәм Васильев хезмәтләре күрсәтелмәгән. Библиография буенча гына хөкем йөрткәндә, Утер Балинт китабын файдаланмаган дигән нәтиҗә ясарга да мөмкин. Әмма ул Балинттан тыш әле, алда искәрткәнебезчә, Васильев китабын да файдаланган. Ә нигә ул аларны библиографиясенә кертмәгән? Бу мәсьәләдә болай фикер йөртергә нигез бар: Утер үз күзеннән үткәргән чыганакларны гына аерып күрсәткән булырга тиеш. Үз күзеннән үтмәгән чыганакларны ул библиографиясенә кертмәгән, бары типологик анализ ясаган авторларның хезмәтен (без күзәтә торган очракта Кескемети һәм Паунонен хезмәтен) күрсәтү белән генә чикләнгән. Ни очен Утер Паасоненны гына аерып алган? Безгә калса, хикмәт шунда: Паасонен китабында татар әкиятләренең немец теленә тәрҗемәләре бар, һәм бу Утерга алар белән якыннан танышу мөмкинлеген тудырган. Ә Балинт һәм Васильев китапларында андый тәрҗемәләр юк. Шуңа күрә әлеге китаплардагы әкият типларын Утер үзенең каталогына Кескемети һәм Паунонен хезмәтеннән алып керткән, чыганак рәвешендә дә шушы хезмәтне генә күрсәткән. Дөрес, Балинт китабының А. Берта тарафыннан нәшер ителгән икенче басмасында [11] әкиятләрнең немец теленә тәрҗемәләре бар, әмма бу хезмәт, күрәсең, каталог авторына барып ирешмәгән.

Ярый, ничек булса да булган – безнең өчен Кескемети һәм Паунонен хезмәтнең нәтиҗәсе мөһим. Анда шактый сандагы татар

әкиятләренең сюжет типлары ачыкланган. Өстәвенә, әлеге авторлар, М. Васильевның рус телендәге китабын да дөньякүләм фәнни әйләнешкә кертеп, мактауга лаек эш башкарганнар.

Инде төгәлрәк итеп әйтсәк, Кескемети һәм Паунонен хезмәтендә алда күрсәтелгән өч чыганактан барысы 98 текст файдаланылган (Балинттан – 22, Паасоненнан – 20, Васильевтан – 56. Безгә калса, бу санны әле беркадәр арттырырга да мөмкинлек булган). Шуларга тагын Куношның Утер үзе анализлаган 14 әкиятен дә кушсак, бу яңа каталог файдаланылган татар әкиятләренең саны 112 гә җитә. Шул әкиятләрдә якынча исәп белән 111 сюжет тибы ачыкланган (якынча дидек, чөнки Кунош әкиятләренә типологик анализ безнең тарафтан ясалды. Утер каталогы белән җентекләп танышу һәм аңа анализ ясау – киләчәктәге эш).

Шулай итеп, Утерның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә татар халкының 112 әкияте дөньякүләм фәнни әйләнешкә керде. Шәкли яктан гына түгел, бәлки гамәли яктан да ул шулай. Моңа конкрет мисал да бар. Әле Утер каталогы нәшрияттан чыгып өлгермәс борын, безгә Литва фольклорчысы профессор Леонардас Саукадан хат килеп төште. Ул шушы яңа каталогка кертелгән Кунош әкиятләренең берсен – «Айсылу» исемле әкиятне сорап җибәргән. «Мин 425М сюжеты булган бу әкиятнең барлыгын Утер каталогы аша белдем», – дигән. Өр-яңа халыкара сюжет күрсәткеченең барлыкка килүе мәгълүм булгач, без, әлбәттә, аның нинди басма булуы белән кызыксынып, хат авторына мөрәҗәгать иттек. Л. Саука үзенең җавабында бу каталогның Хельсинки шәһәрендә басылып ятуын, әмма әлегә чыгып җитмәгәнлеген, ә татар әкиятенә бәйле мәгълүматны каталогның макетында күрүен хәбәр итте. Димәк, Л .Саука Утер хезмәте белән ул басылып чыкканчы ук танышкан, шул арада анда теркәлгән татар материалына күзе төшкән һәм, кичекмәстән, аны кулга төшерү чарасын да күргән булып чыкты.

Аңлашылса кирәк, татар халкы белән чит мәмләкәтләрдә дә кызыксыналар, фольклорына да игътибар итәләр һәм аны өйрәнергә омтылалар. Гомумән, чит илләрдә татар тарихы, әдәбияте, сәнгате һәм фольклоры белән кызыксыну соңгы дәвердә шактый көчәеп китте. Моңа мисаллар җитәрлек. Әйтик, гәзитләр хәбәр иткәнчә, Америка Кушма Штатларында гына да соңгы биш елда Татарстанга мөнәсәбәтле 10 диссертация якланган. Бүгенге көндә Венгриядә һәм Төркиядә татар әкиятләре буенча докторлык диссертацияләре әзерләнә. Бу өлкәдәге тикшеренүләргә дөнья халыклары әкиятләренең соңгы абруйлы каталогы яңа этәргеч бирер дип ышанасы килә.

Шунысын да әйтергә кирәк, бу каталогка кермәгән, әмма керү ихтималы булган татар әкиятләре әле тагын да бар. Ни сәбәпледер, Утер каталогында Ж. Какукның, И. Кунош материалларыннан төзелеп, Сегед шәһәрендә басылган икенче бер китабы [12] файдаланылмаган. Анда 7 татар әкиятенең немец теленә тәрҗемәләре бар. Татар халык әкиятләренең Татар ПЕН-үзәге тырышлыгы белән Казанда «Мәгариф» нәшриятендә инглиз телендә дөнья күргән җыентыгында [13] янә 25 әкият бар. Шундагы 4 текстны чигерсәк (аларның 3 есе Балинт китабыннан алынган, ә берсе ике тапкыр басылган), Утер каталогына кертелергә әзер булган янә 22 әкиятнең читтә калганлыгы ачыкланыр. Шулай итеп, әлеге күрсәткечтә урын алган татар әкиятләренең саны 112 булса, шушы каталогка кертелү мөмкинлегенә ия булып та, очраклы рәвештә мәхрүм ителгәннәре 29 данә тәшкил итә. Болары да кертелгән булса, 111 сюжетка тагын 13 сюжет өстәлер иде. Янә татар әкиятләрендә булып та, АТ күрсәткечендә теркәлмәгән 6 сюжет та үз урыннарын тапса, татар халык әкиятләренең Утер каталогындагы сюжет типлары саны 130 га җитәр иде.

Татар әкиятләрен фәннең бүгенге таләпләренә җавап бирердәй шушы типтагы каталогларга мөмкин кадәр күбрәк урнаштырып, аларны дөньякүләм фәнни әйләнешкә тизрәк кертү өчен ни эшләргә кирәк соң? Беренчедән, каталогка кертелү ихтималы булып та, читтә калган текстларны, әлеге хезмәтнең чираттагы басмасына кертү нияте белән, каталог авторына кичекмәстән ирештерү хәстәрен күрергә. Икенчедән, әкиятләребезне инглиз теленә мөмкин кадәр күбрәк тәрҗемә итеп бастырырга. Әлбәттә, бу – идеаль вариант. Әмма бүген безнең андый мөмкинлегебез юк. Куелган максатка, безнеңчә, татар халык әкиятләренең сюжет күрсәткечен булдыру аша бару мәгъкуль булыр иде. Хайваннар турындагы әкиятләрнең сюжет күрсәткече [14], шөкер, инде төзелгән һәм Интернетка да кертелгән (www.ijli.antat.ru). Әкиятләрнең калган төрләре буенча мондый күрсәткечләрне төзү эшен, һичшиксез, тизләтү таләп ителә. Татар яисә рус телендәге сюжет күрсәткечләрен исә инглиз теленә тәрҗемә итү – башкара алмаслык эш түгел, бары теләк кенә кирәк. Якын киләчәктә бу ниятне тормышка ашыру – безнең мөкатдәс бурычыбыз булырга тиеш.

ЧЫГАНАКЛАР

1. Verzeichnis der Märchentypen mit Hulfe von Fachgenossen ausgearbeitet von Antti Aarne. Helsinki, 1910 (FF № 3).
2. Андреев Н.П. Указатель сказочных сюжетов по системе Аарне. Л., 1929.

3. Thompson S. The types of the folktale. A Classification and Bibliography. Antti Aarne's «Verzeichnis der Märchentypen» (FFC № 3) translated and enlarged. Second revision (FFC 184). – Helsinki, 1961.
4. Сравнительный указатель сюжетов. Восточнославянская сказка / Составители: Л.Г. Бараг, И.П. Березовский, К.П. Кабашников, Н.В. Новиков. Л.: Наука, 1979.
5. Uther Hans-Jörg. The types of international folktales. A Classification and Bibliography. Based on the System of Antti Aarne and Stith Thompson. Part I, II, III. Helsinki, 2004.
6. Mischärtatarische Volksdichtung, gesammelt von H. Paasonen. Übersetzt und herausgegeben von Eino Karahka. Helsinki, 1953.
7. Kazantatarische Volksmärchen. Auf Grund der Sammlung von Jgnac Kunos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk und Jmre Baski (Oriental Studies 8). Budapest, 1989.
8. Kecskemeti I. and Paunonen H. Die Märchentypen in den Publikationen der finnisch-ugrischen Gesellschaft // Journal de la societe finno-ougrienne, 1974. № 73. S. 205–265.
9. Balint Gabor. Kazani-tatar nyelvtanulmanyok. I Füzet. Kazani-tatar szövegek. Budapest, 1875.
10. Васильев М.А. Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды. Казань: Комбинат изд-ва и печати ТССР, 1924.
11. Wolgatatarische Dialektstudien. Textkritische Neuausgabe der Originalsammlung von G. Balint 1875–1876 hrsg. von A. Berta (Oriental Studies 7). Budapest, 1988.
12. Mischärtatarische Texte mit Wörterverzeichnis. Auf Grund der Sammlung von Jgnac Kunos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk. Szeged, 1996.
13. Tatar folk tales. Kazan: Magarif Publishers, 1999.
14. Замалетдинов Л. Сюжеты и мотивы татарских сказок о животных (опыт создания систематического указателя) // Типология татарского фольклора. Казань: Мастер Лайн, 1999. С. 66–87.

## СӘФӘР ЧЫКТЫМ ЕРАКЛАРГА

### Әкиятче әби

Әкиятче дигәч тә, безнең күз алдыбызга ак сакаллы бабай, һич югында өлкән яшьтәге ир-ат килеп баса. Ләкин бу әле хатын-кызлар арасында әкиятчеләр юк дигән сүз түгел. Киресенчә, Татарстан районнарына, шулай ук күрше республика, өлкәләргә оештырылган фольклор экспедицияләре нәтиҗәләренә караганда, бүгенге көндә әкиятчеләрнең өчтән бер өлешен хатын-кызлар тәшкил итә. Аларның күбесе, әлбәттә, әбиләр.

Менә шундый әбиләрнең берсен без экспедиция вакытында Буа районының 24 хуҗалыктан гына торган Аккүл авылында очраттык. Закирә Минаевага хәзер инде 88 яшь. Ул безгә уннан артык әкият сөйләде. Закирә әби аларның күбесен әтисеннән ишеткән булган. Аның репертуарындагы «Чуен бабай», «Аюхан», «Нужа бабай», «Кырык колак», һәм «Таз турында»гы әкиятләр аеруча кызыклы.

Мәсәлән, «Нужа бабай» дип исемләнгән һәм күләме белән зур булмаган әкияттә агалы-энеле ике туган сурәтләнә. Аларның олысы бай, ә кечесе ярлы. Олы туган, бурычка бер пот он биреп тору бәрабәренә, энесен һәм аның хатынын үзенең хуҗалыгында эшләргә мәҗбүр итә. Бурычка баткан кече туган, гаиләсен алып, бурлакка чыгып китә. Ә артларыннан кап-кара сакаллы берәү йөгерә, үзе: «Ник калдырып китәсез, мин бит Нужа бабагыз», – дип кычкыра. Кечкенә туган әлеге бабайны, аяк-кулларын бәйләп, тирән чокырга ташлап калдыра. Бурлактан баеп кайтып, йорт салалар, иген чәчәләр болар. Моңа агасы килә. «Сине байды дип әйтәләр, миңа бер пот он бир әле», – ди ул. Энесе бирә. Хәйләкәр агасы моның ничек баюы белән кызыксына. Энесе: «Нужа бабайны чокырга аттым мин», – ди. Агасы әлеге чокырга барып Нужа бабайны алырга һәм аны яңадан энесе янына җибәрергә тели. Ләкин кара сакаллы бабай үзенең коткаручысының җилкәсенә менеп утыра...

Кечкенә генә әкият – ә никадәр гыйбрәт.

Өлкән яшьтә булуга карамастан, әкиятченең хәтере бик яхшы. Ләкин әкият кебек зур күләмле әсәрләрнең күңелдә саклануы өчен

аларның әледән-әле сөйләнә торуы да мөһим. Еш сөйләгәндә әкиятнең ваграк детальләре дә онытылмый, әсәр камилләшә, сөйләүченең теле шомара, байый бара. Бу җәһәттән Закирә әбинең язмышы фольклор файдасына була – аңа әкиятсез яшәргә туры килми. Буада яшәүче кызларына кунакка барган чакларда, хәл-әхвәл сорашырга да өлгерми, сырып алган оныклары аны тинтерәтергә үк тотыналар:

– Әби, безгә әкият сөйләче!

Нишләмәк кирәк, әбиләре зиһенен шомарта башлый. Әкиятләрнең онытыла язган җирләре дә табылып, үз урыннарына куела. Шулай итеп, рухи җәүһәрләрнең берсе дә күгәрми, әкиятченең репертуары да тулы көенә саклана.

Хәер, балалар гына түгел, үсмерләр дә әкият тыңларга ярата. Берәр йортта аулак булып, ике-өч кыз җыелдымы, иптәшкә дигән булып, Закирә әбиләрен дә алып киләләр. Әби теләсә дә бара, теләмәсә дә бара. Аннары инде төне буе әкият – теле генә түзсен! Әкиятләре нинди бит әле, кайберләре сәгать ярымга сузыла. Инде төн авыша, әтәчләр кычкыра башлый, ләкин «әби, арыгансың инде» диюче юк. Киресенчә, «әби тагын сөйлә» дә «тагын сөйлә». Ләкин әбигә соңгы әкиятләрен сөйләп бетерергә туры килми – таң алдыннан кызлар йокыга китә. Закирә әби үзенең һәр әкиятен нечкә юморга төреп сөйли. Әмма тыңлаучыларын көлдерсә дә, үзе һич көлмәс. Әкият персонажларының диалогларын ул ике тавыш белән аеруча тәэсирле итеп башкара.

Бизәкле сары яулыгыннан чыгып торган җитен чәчләре, тоныклана төшкән зәңгәр күзләре, хисапсыз күп ерганаклар белән чуарланган рәхимле йөзе һәм, ниһаять, нәкъ тугыз дистә белән үлчәнгән гомере бу карчыкның дөньяда ачы-төчесен күп татыганлыгын күрсәтә. Әйе, алар буынына күпме газаплы тормыш, сугыш, ачлык-ялангачлык кичерергә туры килгән. Шуның өстенә Закирә әби үзенең җиде баласын җирләгән. Ә уллары Гыйльметдин белән Җәгъфәр Бөек Ватан сугышы кырларында ятып калганнар. Аннан соң карты дөнья куйган. Бер кешенең башына бу кадәр кайгы-хәсрәт күбрәк түгелме икән? Ләкин сабыр холыклы ана бөгелеп төшмәгән, язмыш афәтләренә үч итеп, ихтыярын чыныктыра барган: көнентөнен белми колхозда эшләгән, макталган, бүләкләр алган. Шуның өстенә гаиләсен тәрбияләгән, йорт хуҗалыгын алып барган һәм, әлбәттә инде, сихри әкиятләрен сөйләгән.

Хәзер ул үзенең улы Гыйлаҗ һәм килене Хәтимә тәрбиясендә яши. Халкыбызның рухи җәүһәрләрен күңелендә кадерләп саклаучы Закирә әбигә сәламәтлек һәм озын гомер телибез.

## Әкият сөйлим, тыңлагыз!..

Үткән елны мин Кама Тамагы районында фольклор экспедициясендә булдым. Авылларда әби-бабайлар теленнән әкиятләр, бәетләр, табышмаклар һәм халык иҗатының башка төрләренә караган күп кенә әсәрләр язып алдым.

Гадәттә, әкиятчеләрнең күбесе өлкән кешеләр була. Ә менә Олы Карамал авылында яшәүче әкиятчегә нибары... 10 яшь. Вәрис Әскәрев 3 нче классны тәмамлаган. Ул миңа оэын-озын 6 әкият сөйләде. Әкиятләрне Вәрис балаларга хас самимилек белән, мавыгып, хозурланып сөйли. Аның теле матур, халыкчан. «Мин озын әкиятләрне яратам, – ди Вәрис, – кыска әкият тиз бетә ул».

Аның әкиятләрендәге геройлар төрле-төрле. Әнә – тәкәббер һәм хыянәтче патша кызы. Әкият кануннары буенча ул, һичшиксез, җәзага дучар ителергә тиеш, һәм шулай булып чыга да: әкият герое – батыр егет аңа мөгезләр үстерә торган тылсымлы алма ашаттыра, ә үзе соңыннан, дәвалаучы сыйфатында килеп, әлеге патша кызын чыбыркы белән «акылга утырта». Менә – гаҗәеп көчле һәм күндәм Аю батыр, яисә үзенең акылы һәм хәйләсе белән байны «төп башына утыртып калдырган» җитез Зыя һәм башкалар, һәм башкалар...

Вәрис әкиятләрдәге циклларны да сиземли. (Цикл ул – төп герое бер үк зат булган әкиятлар төркеме. Мәсәлән, төп герое хезмәтче егет, Таз, Алдар һ.б. булган күп әкиятләр очрый.) «Зыя» исемле әкиятне сөйләгәндә, Вәрис бер урында туктады да: «Бу әкиятнең беренче сериясе шушы җирдә бетә, хәзер икенче сериясен сөйлим», – дип, сүзен дәвам иттерде.

Ул сөйләгән әкиятләрнең барысы да – халык әкиятләре. Ләкин алар 10 яшьлек малай хыялы аша үткән, аның теле белән сөйләнгән. Шуңа күрә бу әкиятләрдә кайбер үзенчәлекләр булуы табигый. Мәсәлән, аларда юлбасарлар шпионнар итеп бирелә, зур чана – трактор чанасы, атлар совхозныкы итеп сурәтләнә, йөз яисә мең урынына миллион, хәтта аннан да зуррак саннар кулланыла.

Вәрис әлеге әкиятләрне үзенең бабасыннан ишеткән. Әле дә ул Хәбибулла бабасына кунакка барган чакларда аны әкият сөйләтеп тинтерәтеп бетерә икән.

«Мин иртәгә пионер лагерена китәм, сау булыгыз, абый, очрашырбыз әле», – диде Вәрис аерылышканда.

Хуш, нәни әкиятче. Мин дә, очрашырбыз дип уйлыйм. Кем белә, халкыбызның рухи җәүһәрләрен күңелендә кадерләп саклаучы бу тыйнак авыл малае белән, бәлки, без фольклор фәнендә очрашырбыз.

## Әкиятче эзлим

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында хәзер татар фольклорының унике томлык фәнни басмасы әзерләнә. Бу басмада, әлегә кадәр тупланган әсәрләр белән беррәттән, яңа табылганнары да урын алачак.

Быел фольклор экспедицияләренең берсе республикабызның Кама тамагы районына оештырылган иде. Аның максаты, беренче чиратта, әкиятләр җыю булды.

Әмма бүгенге көндә инде оста әкиятчеләрне табу да җиңел түгел. Хәзер халык арасында әкият махсус сөйләнмәгәнгә, авылда әкиятче булган тәкъдирдә дә, аны белмиләр. Ләкин кайчакта очраклы хәлләр дә булгалый. Олы Карамал авылында Вәрис Әскәров белән әнә шулай күрештек. Вәрискә нибары 10 яшь. Ул дүртенче класска йөри. Бу яшьтәге балалар арасында әкиятләрне китаптан укып, радио аша тыңлап яисә алар буенча эшләнгән фильмнарны карап сөйләүчеләр шактый. Әмма олылар телендә генә яши торган әкиятләрне отып алып, аларны төкми-чәчми башкаларга җиткерүчеләр бик сирәк. Вәристән без алты әкият язып алдык. Ә иң мөһиме – без аның аша тагын бер әкиятченең эзенә төштек. Хикмәт шунда: Вәрис әлеге әкиятләрне үзенең бабасыннан ишеткән, һәм ул бабай әле дә исән икән. Экспедиция маршрутына төзәтмә кертеп, кичекмәстән, аның янына юл тоттык.

Хәбибулла ага Хәйруллин нибары 25 хуҗалыктан торган Яшелчә поселогында яши икән. Поселок үзе дә әкияттәге авылны хәтерләтә. Ул Идел ярындагы тирән бер чокыр төбендә урнашкан. Шуңа күрә Иделгә килеп җитмичә күренми дә. Чокырның төньяк бите урман белән капланган, ә көньяк бите буйлап басу ягыннан текә юл төшә. Чокыр төбендәге тар гына урам – ул Иделгә килеп чыга. Табигатьнең менә шундый сихри почмагында гади генә өйдә үзенең карчыгы һәм кызы белән яши бу әкиятче. Өметебез акланды: ул әлеге районда без юлыккан әкиятчеләрнең иң остасы булып чыкты.

Хәбибулла ага инде 73 яшьтә. Шулай да әле үзен әйбәт хис итә. Дөрес, хәзер инде күзләре күрми диярлек, ләкин, гомумән, саулыгыннан зарланмый. Тавышы көр, хәтере яхшы. Ул озын-озын 17 әкият сөйләде. Алар арасында «Сәүдәгәр», «Алтын алмагач», «Балыкчы», «Йөз сумлык эт» дип исемләнгәннәре аеруча кызыклы. Аның әкиятләрен без магнитофон тасмасына иртәдән алып кичкә кадәр яздык, ләкин ул «арыдым» димәде, «әкиятем бетте» дип тә

әйтмәде. Аның ннчә әкият белүе турында кызыксынгач: «Алар миндә сансыз», – дип кенә куйды.

Хәбибулла ага Кече Салтык авылында туа. Мәдрәсә белеме дә бик аз тия аңа. Әкиятләрне беренче мәртәбә авылдагы картлардан ишетә, һәм отып алганнарын үзе дә яшьтәшләренә сөйли башлый. Ләкин авылда озак яшәргә туры килми – рәхимсез ачлык 1921 елны аны да читкә чыгып китәргә мәҗбүр итә. Ул Семипалатинск якларында урман кисә, Уралда таш чыгара, Донбасста күмер чаба. Бергә эшләүчеләр арасында оста әкиятчеләр да була. Эштән соң җыелышып утырган вакытларда чиратлашып әкият сөйләшәләр.

Авылга кайткач, хәтер хәзинәсен инде ул яшьләр белән уртаклаша. «Мунчада төнге 2 гә – 3 кә кадәр сөйләтәләр иде үземне», – ди әкиятче, шул вакытларны искә төшереп.

1929 елда ул, беренчеләрдән булып, нигезе яңа гына салына башлаган Яшелчә поселогына күчеп килә. Бу матур урыннар элек барысы да алпавыт җирләре булган. Хәбибулла ага, күзләре начар күрсә дә, кулыннан килгәнчә колхозга ярдәм итәргә тырыша. Хатыны Зоха апа белән алар җиде бала үстергәннәр.

Хәзер инде Хәбибулла ага үзенең сихри әкиятләрен оныкларына сөйли, аларда батырлык һәм тугрылык, гүзәллек һәм намус тойгысы тәрбияли.

## Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым...

*Фольклорчы язмалары*

Татар халык әкиятләре җыентыкларының иң тулысы һәм абруйлысы булып саналган ике томлык фәнни басмага (I том – 1946 ел, II том – 1956 ел) күз салсак, әкият яздыручылар арасында бер генә хатын-кыз фамилиясен дә очратмабыз. Ләкин бу әле бездә хатын-кыз әкиятчеләр юк дигән сүз түгел. Соңгы еллардагы фольклор экспедицияләреннән күренгәнчә, хәзерге әкиятчеләрнең өчтән берен хатын-кызлар тәшкил итә. Биредә мин әнә шуларның берсе – оста әкиятче Миңҗамал әби Гулова турында сөйләргә телим.

Ике һәм аннан артык әкият белгән кешеләрне без, фольклорчылар, әкиятче дибез. Хәзерге вакытта әкият сөйләү гадәте бетеп барганлыктан, әкиятчеләр дә сирәк очрый. Алар әкият сакланган төбәкләрдә дә, гадәттә, авылга уртача бер кеше генә туры килә. Хәлбуки, шундыйлар арасында кайвакыт зур осталар очрый. Оста әкиятче – ул матур һәм җиңел тел белән кимендә унлап әкият сөйләгән кеше.

Кама Тамагы районында унҗиде әкият сөйләгән Хәбибулла Хәйруллин белән очрашкач, мин, бу яңалыкны халыкка да мәгълүм итү теләге белән, аның турында «Социалистик Татарстан» газетасында кыска гына бер мәкалә бастырган идем. Шуннан соң озак та үтми, редакция аша Лениногорский районының Мөэмин-Каратай авылыннан бер хат килеп төште. «Мин, Миңҗамал Гулова, – диелгән хатта, – күп әкиятләр беләм, Хәбибулла ага белән ярышырга телим».

Әбинең хаты шактый кыю язылган. Танылган әкиятчене ярышка чакыра икән – димәк, аңарда әкиятләр унҗиде генә түгелдер. Шулай да ачыкларга кирәк. Сорашып, әбигә хат яздым. Җавап озак көттермәде. Бу юлы ул, эчтәлекләреннән чыгып, әкиятләрнең исемнәрен язып җибәргән. Чыннан да әби «буш булмаска» тиеш.

Шуннан соң СССР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының 1976 елгы экспедиция планына «Лениногорский районы» дигән сүзләр язылды, сәфәрнең «май азагы-июнь башы» дип, вакыты да күрсәтелде.

Беркадәр вакыттан соң Миңҗамал әбидән тагын бар хат килде. «Улым, – дигән әби, – син берүк чебиләр чыккан вакытта килә күрмә, андый чакта керәстияннең әкият сөйләшергә вакыты булмый». Хат уйга калдырды. Фәннәр академиясе планы һәм... чебиләр! Нишләмәк кирәк, сәфәр уңышлы булсын, әкиятләр күп язылсын дисәң, алар белән дә исәпләшергә туры килә.

Юлга июньнең 20 сеннән соң чыктым. Лениногорский район советы башкарма комитетындагы иптәшләр (Рөстәм Вильданов, Гакил Вәлетдинов) әкияткә әкият итеп кенә караучылар түгел икән. Фольклорыбызның үзенчәлекле культура байлыгы икәнен, аның гаять үтемле тәрбия чарасы булуын тирән аңлаулары сизелеп тора. Алар, изге ният белән йөрүемә канәгатьләнү белдереп, эштә уңышлар теләделәр. Гакил иптәш хәтта Мөэмин-Каратайга машина белән илтеп үк куйды.

Авыл калкулыклар арасындагы бер үзәнлектә утыра. Тирә-ягы урман. Тау өстеннән караганда йортлар уч төбендәге кебек күренә. Шул йортларда күпне күргән, җитмешәр, сиксәнешәр язны каршылаган кешеләр яши. Бәлки әле өлкәнрәкләре дә бардыр. Ә аларның хәтерләрендә син эзли торган хәзинә яшеренгән. Нәкъ әкияттәгечә! Бу хәзинә матди нәрсә түгел, аны күреп тә, тотып карап та булмый. Киләсе буыннарга калдыру өчен, аны, һичшиксез, матди хәлгә эвереддерергә – ягъни магнитофон тасмасына һәм кәгазьгә язарга кирәк. Халык та бит амбарга кергән ашлыкны гына ризык дип саный.

Фольклор һәр кешедә дә булмый. Әкиятчеләр, әйткәнебезчә, аеруча аз. Аларны да, халык әкиятче икәнен белмәгәнлектән, эзләп табуы җиңел түгел. Моның өчен авылдагы барлык карт һәм карчыклар белән очрашып чыгарга туры килә. Табылгач, – аның телен ачу бәхетенә ирешергә һәм, ниһаять, аңардагы материалларны түкмичәчми язып алырга кирәк.

Мөэмин-Каратайда 170 хуҗалык булуын белгән идем. Әнә ул 170 йорт минем күз алдымда. Шуларның кайсындадыр 74 яшьлек Миңҗамал әби яши.

Менә без аның белән ничәнче көн инде бергә утырабыз. Әби үзенең сихри әкиятләрен сөйли, мин тыңлыйм, ара-тирә кайбер кирәкле нәрсәләрне язып куям, магнитофон тасмасы берөзлексез ага да ага.

Очрашасы кешеңне әлегә кадәр беркайчан да күрмәгән булсаң, иң элек күңелдә аның хыялый портреты пәйда була. Дөрес, күзаллау һәр вакытта да чынбарлыкка туры килми. Ләкин Миңҗамал әби, ни өчендер, минем күз алдыма тормыштагыча, нәкъ менә шушы кыяфәттә килгән иде: какча гәүдә, еллар төрле-төрле юнәлештә ерганаклар сызып калдырган озынчарак мөлаем йөз, җылылык сирпелеп торган сөйкемле күзләр... Табигате – тыныч, хәрәкәте – җыйнак, сүзе – ягымлы. Әллә барлык әкиятчеләр дә шундый буламы икән? Чөнки күпме сәфәр йөреп, алар арасында бер генә дорфа кешене дә очратканым булмады.

Әби, җитен чәчләрен яшергәндәй итеп, ара-тирә яулыгын төзәткәләп ала да, тәмам онытылып, сөйли дә сөйли. Мин аны көнгә дүрт сәгатьтән дә артык эшләтмәскә тырышам, талчыкмасын, кәефе гел әйбәт булсын иде, дим. Бу очракта «аз булсын, яхшы булсын» дигән принцип белән эшләү хәерле. Инде чын остага юлыккансың икән, ашыкма, вакытыңны кызганма.

Гаҗәп хәл: сигезенче дистәне ваклаучы әби ару-талуны белми икән. Әкиятләр берсе артыннан икенчесе агылып кына тора. Аларның да нindiләре генә әле! «Мөлтәки» дигән беренче әкияте үк игътибарны җәлеп итә. Бу әсәрнең «Җилбикә», «Хөр-хөр», «Мөлтәл» дигән вариантлары безгә билгеле иде инде. Димәк, болардан тыш «Мөлтәки» дигәне дә бар икән әле. Янә халык арасында киң таралган һәм дистәләп язмасы булган «Үги кыз» әкиятенең дә яңа вариантны барлыкка килде. Әкиятләрнең иң күренеклеләрен әби сөйләвендә колхоз радиосы аша да тапшырдык.

Сихри әкиятләр биредәге сихри табигатькә ярашып, аның белән бергә кушылып, бер бөтен булып киткәндәй тоела. Әйе, монда барысы да әкияттәге кебек шул. Бигрәк тә таулары. Аларның

һәркайсының исеме бар: Миңҗамал әби тәрәзәсеннән күренеп торганы «Каршы тау» дип атала, аннан соң «Кәҗә тавы», «Түгәрәк тау», «Әсән тавы», «Бәшир тавы», «Юачалы тау»... Аларның һәркайсының легендасы яки риваяте бар. Таулардагы урманнар да төрлечә исемләнгән: «Бөркет кулы урманы», «Юачалы урманы», «Имәнлек борыны», «Чаукалык»... Урман эчендәге матур аланнар (биредә «аклан» диләр), тау итәкләрендәге болыннар күңелгә аерым рәхәтлек бирәләр. Кыргый җәнлек-җанварлар да шактый монда: пошилар (биредә – «моши»), тау кәҗәләре, сыркалар, бүреләр... Инде таулардан агып чыга торган чишмәләрне бу төбәкнең бизәге дияргә мөмкин. Аларның кайберләрең елга дип тә йөртәләр. Исемнәре генә дә ни тора: «Күлле чишмә», «Ямщиклар елгасы», «Аугалак», «Кара бия», «Шобагалы», «Рәхмәнкол бабай чишмәсе»... «Зирекле» һәм «Кирәмәт» сулары торбалар буйлап авылга килгән. Бу якларда минераль сулы чишмәләр дә бар. Мөэмин-Каратайдан өч километр ераклыкта шундый шифалы чишмәсе, сихәтле ләме булган урында атаклы Бәкер курорты урнашкан.

Мөэмин-Каратайда гомер иткән бер бабай: «Без җәннәттә яшибез икән», – диде. Бу сүзләр белән килешергә туры килә. Ул күптән түгел Төркмәнстанга кунакка барып кайткан һәм үзенең гомер буе яшәгән җирен яңадан «ачкан». Шулай шул: үзеңне, үз туган җиреңне ныграк аңлау өчен, кайчак читкә чыгып кайтырга да кирәктер.

Әнә шундый тышкы гүзәллекнең, матди байлыкның эчке гүзәллек, рухи байлык белән бәйләнеше тыгыз булса кирәк. Ләкин рухи хәзинәгә игелекле мөнәсәбәт, аны ярату, хөрмәт итү булмаганда, кеше барыбер буш булып кала. Кайвакыт шул бушлыкны аклау өчен сәбәп эзләп, тормышның авыр булганлыгын искә төшерергә яратучылар да очрый. «Нужаны күп күрдек шул, әкият сөйләшү кайгысы булмады», – диләр андыйлар. Ә ул нужаны кем генә күрмәгән соң? Аларча фикер йөртсәң, әкиятне бүгенгә кадәр яшәтүчеләр кайгы-хәсрәтсез кешеләр булып чыга. Бу алай түгел, әлбәттә. Безнең оста әкиятчеләребез тормышның ачысын-төчесен җитәрлек татыган кешеләр. Шул исәптән Миңҗамал әби дә. Аның авыр тормышта, күп нужа чигеп үскәнлегенә бөтен авыл халкы шаһит.

Миңҗамал әби 1902 елда дөньяга килгән. Туган ае да, көне дә мәгълүм түгел. «Син, кызым, шомырт пешкәндә тудың», – дия торган булган аның әнисе Литафәт. Әтисе Вәлиулла авылның иң ярлы кешеләреннән була. Кечкенә генә өч тәрәзәле иске йорт, ике кәҗә – бөтен дәүләт әнә шуннан гыйбарәт. Җитмәсә, берничә елдан соң Вәлиулла абзый, авырып, гүр иясе дә булып куя. Кечкенә Миңҗамал әнисе белән генә кала. Кечкенә димәктән, кыз чыннан да

бик кечкенә һәм зәгыйфь була. «Юклык галәмәтеннәндер инде, мин итсез-нисез туганмын, – дип искә ала Миңҗамал әби үзе турында. – Әни мине кеше булыр димәгән». Ләкин шушы чандыр кыз укуга бик һәвәс булып чыга. Абыстайга сабакка йөрүче кызлардан өйрәнеп, биш яшендә инде ул яхшы гына укый башлый һәм беркөнне, тугыз яшьлек күрше кызына ияреп, үзе дә абыстайга бара. Бу көнне аңарда үз-үзенә ышаныч тагын да ныгый: баксаң, зур ук кызлар «кәлимәтен»не иҗекләп кенә укыйлар икән ләбаса, ә кайберәүләре бөтенләй дә укый алмый.

Миңҗамалның әнисе тукмак хәтле генә кызының сабакка йөрү теләгенә каршы килми – аны үз ирегенә куя. «Үзем «бу кәгазьгә нәрсә язылган икән?», «бу китап нәрсә турында икән?» дип, әрнеп гомер иттем, инде, кызым, син дә минем кебек надан булма», – ди ул.

Кызчык, башкалар кебек үк, көнгә ике мәртәбә абыстайга йөри. Иртәнге сабак таң беленгәч үк башлана. Төшке сабак дигәненең вакытын билгеләү өчен, абыстай песи күзенә карарга кушып җибәрә. Песинең күз карасы нечкә генә сызык булып калгач, кызлар абыстай өенә янә җыелалар. Бу юлы инде дәрес кичкә кадәр дәвам итә.

Абыстайга ике ел йөргәннән соң, Миңҗамал дүрт ел дәвамында мулладан сабак ала. Һәм шуның белән аның «мәктәп» еллары тәмамлана да. Йортта ир кеше булмаганга, бөтен авырлык әнисе белән аның җилкәсенә төшә. Яшь кыз тормышны җигелеп тарта башлый. Ләкин белемгә сусау кимеми кызда. Үзе киндер эрли, ә каба төбендә – китабы. Эрли дә, бер үк вакытта укый да.

Кичләрең әнисе кызына әкиятләр сөйли. Миңҗамалның күңелендә бөтенләй яңа, сихерле бер дөнья ачыла. Әкиятләрне ул йотылып тыңлый. Матур да алар, шул ук вакытта куркыныч та.

Менә, әти-әниләре кунакка киткәч, өйдә үзләре генә калган җиде кыз янына кеше ашаучы убырлы карчык юнәлә. Җитмәсә, юлда мөнәҗәт әйтә-әйтә атлый:

Каптыр-коптыр итәрем.
Кабык күпер кичәрем.
Бер өйдәге җиде кызның
Җидесен дә йотарым.

Миңҗамалның тәненә салкын йөгерә, эче чымырдап китә. Аның күз алдында куркыныч, шыксыз йөзле карчык пәйда була. Әнә карчык, юл тузанын туздырып, эре-эре атлап бара, мөнәҗәтен әйтә-әйтә, туп-туры Миңҗамалга таба килә. Кызчык, куырылып, аякла-

рын итәге астына яшерә, күзләрең чытырдатып йома, ләкин барыбер тыңлый.

Әнисе ягыннан туган тиешле Зөфәр һәм Сабит абзыйларын да аптыратып бетерә кыз: «Әкият сөйлә дә әкият сөйлә!» Нишләсеннәр, сөйлиләр абзыйлары. Бигрәк тә Сабит абзыйсы әкияткә маһир кеше була. Миңҗамал әби үзе сөйләгән әкиятләрнең кайсыларын кемнән ишеткән булуын бүген дә бик яхшы хәтерли. Төлке белән сандугач, бүре балаларын укыткан төлке, кәҗә тәкәсенә атланып сугышка барган таз малай, Төрле сурәткә керүче әби турындагы әкиятләрне әнә шул Сабит абзыйсы сөйләгән булган.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Миңҗамал, авыл буенча хат язып йөреп, өенә дә кайтып керми. Яраталар аның язуын. Чөнки кыз «тагын нәрсә языйм» дип, яздыручының әйткәнен генә көтеп тормый, үзе белеп яза, хәтта аны янында да тотмый, «бар, эшеңне эшлә» дип җибәрә торган була. Хәрефләрне көчкә-көчкә генә куя алган кайбер ярым надан солдатларның фронттан килгән хатларын уку аеруча кыенга туры килә. Ләкин Миңҗамал барыбер укый. Хәрефләрне ничек дөрес язарга һәм ике сүз арасында буш урын калдырырга кирәклегең аңлатып, сугышчыларга үзе дә хатлар яза.

Янә дә күп сулар ага, яңадан-яңа вакыйгалар чыга. Октябрь революциясе, гражданнар сугышы... Инде Миңҗамал да буй җиткергән кызлардан санала, аңа төрле яктан яучылар килә башлый. Ләкин ничек килсәләр, шулай борылып та китәләр. «Инәйне ташламыйм дигән шәфкатем бар күңелемдә, беркемгә дә кияүгә чыкмыйм», – ди кыз, катгый итеп.

Менә Мөэмин-Каратайга укытучы булып Гыйльметдин исемле яшь кенә егет килә. Авылның хәлле кешеләре аңа үзләренең кызларын димлиләр. Ләкин Гыйльметдин:«Миңа бай кызы түгел, ә укымышлы кыз кирәк», – ди һәм Миңҗамалга өйләнергә теләге булуын белдерә. Сабит абзыйсы да: «Гыйльметдингә бар син, сеңелем, – ди, – менә тиздән өйләнермен дә әниеңне үзем тәрбияләрмен».

Әмма бәхет насыйп булмаган икән: күрше авылдан сәнәкчеләр килеп, Гыйльметдинне чанага салып алып китәләр дә чәнчеп үтерәләр. Ул гына түгел, Сабит абзыйсы да шулар кулыннан ук һәлак була, бары тик истәлеге булып аның җырлары гына кала. «Сабит абзыемның ике җырын гомерем буе күңелемдә сакладым», – ди Миңҗамал әби һәм аларны көйләп тә күрсәтте. Бу борынгы җырларның берсендә түбәндәге юллар бар:

Сәхра капкасының төпләрендә
Әлванский җимешләр ашадым;

Зифа буйларымны бер күрсәтеп,
Гомерлеккә хәсрәтләр ясадым.

Миңҗамал үзенең киләчәк язмышын Харис исемле егет белән бәйли. Гаилә корганнан соң, тормыш мәшәкатьләре тагын да арта. Бер-бер артлы дүрт бала дөньяга килә. Ә еллар һаман да авыр булып кала.

Колхоз төзелгәндә Миңҗамал гаризаны беренче булып бирә һәм кая кушсалар шунда эшли: яшелчә үстерә, кирпеч суга, урман кисә, дуңгыз карый, сабан сөрә, колхозның беренче савымчысы була. Кайда эшләсә дә сынатмый, гел ударница исемен йөртә.

– Бүләккә бер елны бозау, икенче елны сарык бирделәр, – ди әби. – Шулай итеп, сыерлы да булдык, сарыклар да үрчеде, эшләп кеше үлми икән. Ни булса, барысын да колхоз бирде миңа.

Саулыгы какшаса да, Ватан сугышы елларында ясле балаларын тәрбияләгән ул. Шуның өстенә өйдә кул хезмәте белән шөгыльләнгән – бик матур паласлар суккан. Авылда аның паласы булмаган йортлар сирәктер. Күрше авылларда күпме тагын! Авыр елларда чабатаны да үзе үргән Миңҗамал әби. Хәзер дә әле ул кул кушырып утырырга теләми: өй җыештыра, гөлләр үстерә, аш-су әзерли, кош-корт тәрбияли – хуҗалыкта эш бетәмени!

Әби әкиятләрне дә, тормыш хәлләрен дә матур итеп, образлы итеп сөйли. Аны тыңлау – җан рәхәте. Әкияттәге диалогларны биргәндә, ул тәмам «рольгә керә» һәм персонажларның һәркайсы «үз тавышы» белән сөйли башлый.

Миңҗамал әби әкиятләрендәге бетемнәр дә без күнеккән традицион бетемнәрдән аерылып тора. Мәсәлән, кайбер әкиятләр болай тәмамлана: «Болар матур гына гомер итеп, максуды морадларына ирешеп, дөньядан үтеп киткәннәр ди... Кичә барып, бүген кайттым, дуга белән печән чаптым».

Мин сорый куйдым:

– Нишләп болар дөньядан китәләр соң? Әкиятләр, гадәттә, «болар әле дә булса рәхәтләнеп яшиләр» дип бетә ич!

Бу турыда әбинең үз фикере бар икән:

– Кешеләр борын-борын заманнан бирле яши алмыйлар, – диде ул. – Ә мин сөйләгән әкиятләр барысы да борын заманда булган хәлләр турында.

Чираттагы әкиятне сөйләп бетергәч, әби җитез генә урамга чыгып китте дә озакламый сөйләнә-сөйләнә килеп тә керде:

– Быел казлар белән бик җәфаландым, улым. Ике ала бәбкә чыккан иде. Шуларны ата каз минеке түгел дип талый гына бит. Атасы

талагач, анасы да талый. Каз җәмәгате бик кызык ул: төсне аера, калганына башы җитми. Бер көнне шулай бала-чагага ышанып калдырган идем, шул арада берсен тәки талап үтергән бит. Шуннан соң ата казның аягына озын бау тагып җибәрдем. Аза башласа, коймага бәйлим дә куям. Әле дә менә шуны бәйләп кердем.

Әби үзенең урынына җайлап кына килеп утырды да яңа әкиятен башлады. Шул арада оныгы – унбер яшьлек Флера – кайтып керде. Артыннан эреле-ваклы бер төркем бала-чага ияргән. Авыл балаларына хас тыйнаклык йөзеннән бусага янында туктап калган шаян тиктормасларга якты чырай күрсәтеп түргә ымлау җитә калды – тиз генә шыбырдашып уздылар да, ничек сыйганнардыр, бер диванга урнашып та беттеләр. Кичә алар Миңҗамал әбиләренең әкиятен урамда багана башындагы репродуктордан тыңлаганнар иде. Хәзер инде менә әбинең үзеннән ишетергә кергәннәр. Җитмәсә, әкияте дә башка.

Мин утыз минут саен магнитофон тасмасын алыштырып торам. Әби шул арада, «Зирекле» чишмәсенең суына катык болгатып, салкын әйрән ясап бирә, сүз җаенда бер тамчы да аракы капмый торган кияве Сабирҗанны горурланып телгә ала, я булмаса, егерме өч ел бергә яшәп тә, бер генә авыр сүз дә әйтмәгән килене Әнвәрияне мактап куя. Шунда ук, киленнең тиздән төшке ашка кайтачагы исенә төшеп, җәһәт кенә самавар куеп җибәрә.

Өйдә үзе генә чакта Миңҗамал әби берничә мәртәбә борынгы җырларны җырлады.

Биек тә генә тауның башларында
Яфрак өчен үскән яшь каен,
Җаныем, агымсу –
Үргә йөзалмыйм.
Күрми түзалмыйм.

– Без яшь чакта «Сәгыйдә» көе бар иде, – диде ул. – Ничә ел көтәм инде, радиодан шул көйне һаман җырламыйлар.

Алмалыктин алма алырга,
Сәгыйдә дускаем,
Камышлыктан юл салдым шул, гөлкәем.
Сез дусларны уйлый-уйлый,
Сәгыйдә дускаем,
Камыштин сары калдым шул, гөлкәем.

Әнә шулай юл уңаенда Миңҗамал әби башкарган көйләр белән җиде җыр язып алынды.

Кайбер тәнәфесләрдә әби үзенең гөлләренә су сибә. Ә гөлләре бик күп аның. Барысы да шау чәчәктә утыра.

– Ике шатлыгым бар минем, – ди әби, – берсе – чебиләр, икенчесе – гөлләр. Гомер буена кына гөлен яраттым.

Әби гөлләр турында тәфсилләп, онытылып сөйли. Бу вакытта аның шагыйрь йөрәкле булуы аеруча сизелә. Табигате белән шагыйрь кешеләр бик күп бу дөньяда, Шуларның бик азы гына шигырь яза. Калганнары язмыйлар, ләкин алар барыбер шагыйрь җанлы булудан туктамый. Миңҗамал әби дә әнә шундый язмый торган шагыйрьләрнең берсе. Хәер, язмый торган дию бик үк төгәлдә булмастыр. Ара-тирә үзе өчен генә шигырьләр дә, җырлар да чыгаргалый ул. Мәсәлән, аның Ташкентта олы кызында кунакта вакытта чыгарган алты куплетлы «Ташкент калалары» дигән җыры бар. Үзбәк кияве Ильяс әллә нигә бер килгән әбисен озаграк тотарга тели, әби исә берничә көннән үк кайту ягын каера. Шул чакта туган авылын сагыну хисе аның күңеленнән җыр булып ташып чыга:

Ташкент калалары бигрәк матур,
Шундый микән башка калалар!
Кошлар очып җитмәс җирләргә дә
Китерә икән газиз балалар.

Ташкент калалары гел таш кына –
Йортка чыксам, ташка абынам,
Ташкент калалары бик матур да,
Туган авылымны сагынам.

Ташкент калалары зур булса да.
Кайбер урамнары киң түгел,
Ташкент калалары бик матур да –
Туган авылыма тиң түгел.

Туган җирен, туган авылын, аның гүзәл табигатен ярату әбинең балаларына да күчкән. Мәсәлән, улы Хаҗип авылдан китүне уена да кертмәгән. Ул унике яшеннән үк колхоз атларын карый. Армиядә хезмәт иткәндә дә бар сораштырып язганы атлар һәм таллар була. Миңҗамал әби аңа, хат белән бергә, конвертка тал яфраклары да салып җибәрә. Армиядән соң да һәм бүген дә Хаҗип яраткан эшендә.

Әбинең ишеген шакыганда, мин һәр көнне бүген инде соңгы эш көнебез булыр, дип уйлыйм. Ләкин ул мине: «Улым, тагын бер әкият искә төште бит әле», яисә: «Тагын ике әкият табылды лабаса», – дип каршылый. Бик яхшы. Табыла торсын. Әкиятләр саны инде егерме дә булды, егерме биш тә булды, утыздан да узды, ләкин

әбинең хәтер сандыгындагы хәзинәнең һаман да беткәне юк. Әкиятләре нинди диген әле! Пушкин әйтмешли, һәркайсы бер поэма.

Фольклор әсәрләре халык телендә яши. Бу җәүһәрләр чыннан да җәүһәр булсын өчен, аның бөтен поэтик гүзәллеге чагылсын өчен, аларны чын талант ияләреннән язып алу зарур. Миңҗамал әби, минем карашымча, әнә шундый талантларның берсе.

Әкият сөйләү беренче карашка һәркем башкара алырдай гади эш булып тоелса да, чынлыкта ул аерым шәхесләр эше. Бу әсәрләрне талантлы башкару өчен, минемчә, төп өч шартның булуы зарур. Беренчесе – әкиятне ихлас күңелдән ярату. Икенчесе – бик яхшы хәтерле булу. Өченче шарт – әкиятләрне әледән-әле сөйләп тору. Миңҗамал әби үзенең әкиятләрен кич утырып кул эше эшләгәндә дә, басуда ял арасында да, хәтта больницада ятканда да сөйләгән. Балалары, аннан соң оныклары, шулай ук күршедәге балалар аның әкиятләрен тыңлап үскәннәр. Аларның кайсы да булса: «Әби, әкият сөйләче» дисә, ул аларның үтенечен һәр вакыт канәгатьләндерергә тырышкан. Фәрхәт исемле малай аның хәтерендә аеруча нык уелып калган.

– Бигрәк тә ярата иде инде әкиятләрне, – дип искә ала әби аның турында. – Бер мәлне башым бик авыртканда килеп керде бу: «Әби, әкият сөйләмәссеңме икән дип килгән идем», – ди. «Улым, мин әйтәм, бүген башым бик авырта шул, җитмәсә, чәй эчәргә шикәр-конфетым да бетеп киткән». Малай йөгереп чыгып китте дә бераздан тагын килеп керде. Минем өчен әнисеннән бер уч конфет сорап алган. «Әби, мин шофер булачакмын, үзеңне машинага утыртып әллә кайларга алып китәрмен әле», – дия иде. Чыннан да әлеге малай тәки шофер булды бит. Хәзер Лениногорскида автобус йөртә. Сүзендә торды: автобусы белән килеп, кунакка алып китте үземне, биш кич кунып кайттым.

Әйе, әкият ярату – һәр сабыйның табигатенә хас сыйфат. Аны хәтта табигый ихтыяҗ дияргә мөмкин. Атаклы балалар язучысы Корней Чуковский үзенең «От двух до пяти» дигән китабында: «Җиде-сигез яшькә кадәр әкият һәр нормаль бала өчен иң кирәкле азык – тәмле-томлы нәрсә түгел, бәлки бик мөһим һәм гаять туклыклы икмәк», – ди. Әкиятнең зарур нәрсә булуы бик күптәннән танылган. XVIII гасырда яшәгән немец философы һәм мәгърифәтчесе Гердер: «Әгәр сабыйга беркайчан да әкият сөйләмәгән булсалар, аның күңелендә эшкәртелмәгән кыр кала һәм шуннан соңгы елларда инде бу кырны эшкәртү мөмкин булмаячак», дигән.

Ышанып әйтергә мөмкин, Миңҗамал әби тәэсирендә булган Фәрхәтләрнең күңелендә «эшкәртелмәгән кыр» калмаган. Югыйсә,

олылар рәтенә кергән, инде үзе эти булган кеше сабый чакта әйткән сүзен оныткан да булыр иде, һич югында, әлеге вәгъдәсен хәтерләп, елмаеп кына куяр иде. Ә әкият аны игелекле һәм мәрхәмәтле, сүзендә нык тора торган чын кеше итеп тәрбияләргә булышкан.

...Менә мин Миңҗамал әбиләрнең кызгылт-көрән төстәге капкасын соңгы мәртәбә ачып керәм. Бүген инде әкият язмыйбыз, бары тик саубуллашасы, әбигә тагын бер кат рәхмәт әйтәсе, аңа сәламәтлек һәм озын гомер теләргә генә калды. Әбине, бизәкле яулыгын бәйләтеп, берничә мәртәбә фотога төшердем.

– Үзеңә бик зур рәхмәт инде, улым, – диде әби. – Югыйсә, үлепнитеп китәрмен дә әкиятләрем эзсез югалыр дип борчылып тора идем.

Әйе, болай дип теләсә кем әйтә алмый. Үзе турында түгел, киләчәк турында кайгырта әби. Моны хәтта дәүләт биеклегеннән торып фикерләү дип бәяләргә мөмкин.

Казанга кайткач, озак та үтми, Миңҗамал әбидән хат килде. Гарәп хәрефләре белән тигез итеп язылган бу хатта илле өч табышмак теркәлгән һәм янә дә җиде әкиятнең искә төшүе турында хәбәр ителгән иде.

Әйе, мондый бай репертуарлы информаторга соңгы унбиш елда бер генә экспедициябезнең дә юлыкканы юк иде әле. Гомумән, институт оештырган экспедицияләр тарихында да бу икенче очрак кына.

...Колхоз радиосыннан чыгышта мин Миңҗамал әби турында хөрмәткә лаек колхоз ветераны буларак түгел, бәлки оста әкиятче буларак кына сөйләдем һәм аны «авылыгызның горурлыгы» дип атадым. Соңыннан уйлап куйдым: арттырыбрак җибәрмәдемме икән? Шул вакыт атаклы рус әкиятчеләре исемә килеп төште. Иван Федорович Ковалев (1885–1966), Анна Куприяновна Барышникова-Куприяниха (1868–1954), Анна Николаевна Королькова (1893 елда туган) һ.б. әкиятчеләр белән илебезнең төрле шәһәрләрендә махсус очрашулар оештырылган, аларны атаклы кешеләр тыңлаган, алар Язучылар союзына член итеп алынганнар һәм, ниһаять, хөкүмәт орденнары белән бүләкләнгәннәр, ә әкиятләре аерым китаплар булып басылып чыккан. Шуларны уйладым да тынычландым: юк, арттырмаганмын икән, хәтта әле барысын да әйтеп та бетермәгәнмен, чөнки халкыбызның рухи җәүһәрләрен күңелендә кадерләп саклаган Миңҗамал әби – ул үз авылының гына түгел, хәтта районның һәм бу төбәкнең генә дә түгел, бәлки гомумән татар фольклорының, милли культурабызның да горурлыгы ич.

## Мөслимгә барам әле

Фәнни экспедицияләр планы буенча 1981 елның җәендә Актаныш районында эшләгәч (бу турыда сүз алдарак, «Халык җәүһәрләре» дигән материалда булыр), мин шуннан ук Мөслим районына юнәлдем. Бу якка барырга күптән хыяллана идем. Ниһаять, хыялым тормышка ашар кебек.

Сугышка кадәр һәм сугыштан соңгы елларда Мөслим районының Октябрь авылыннан Зариф Мөэминов дигән бер тынгысыз зат безнең институтка күп кенә фольклор материаллары язып җибәргән. Менә бүген инде нәкъ шул авылга Зариф Мөэминовның варисларын эзләп барышым. Максатым – әлеге фидакарьнең мирасында шундый материалларның калу-калмавын ачыклау.

* * *

Зариф Латыйп улы Мөэминов (1893–1966) Мөслим районының Теләнче (хәзер Октябрь) авылында туып-үскән. Риваятьләргә караганда, аның ерак бабасы (алтынчысымы, җиденчесеме) урыс Иван булган. Иван татар кызына өйләнгән, гаиләдә татарча сөйләшкәннәр, балаларына татар исемнәре кушканнар.

З. Мөэминов гомере буе башлангыч мәктәп укытучысы булып эшләгән. 1940–1941 елларда ул күп кенә фольклор материалларын, калын-калын дәфтәрләргә язып, Казанга җибәргән. Беренче дәфтәрен ул 1937 елда ук башлаган булган. Төрле жанрларга караган әсәрләр арасында 50 гә якын (төгәл әйткәндә 46) әкият бар. Әкиятләр санын аерым атап күрсәтүнең хикмәте шунда: халык иҗатының бу жанрына караган әсәрләр күләмнәре ягыннан зур булганлыктан, аларны кәгазьгә төшерүче һәвәскәрләр бик аз, хәтта бармак белән генә санарлык. З. Мөэминов әнә шундый фидакарьләрнең берсе. Ул әкиятләрне искиткеч түземлелек белән, матур, пөхтә итеп язган. Арада бик озыннары да бар. Мәсәлән, «Чабатачы карт» дигән әкиятнең беренче өлеше генә дә 85 битлек бер дәфтәрне биләп тора. Әлбәттә, мондый авыр эшкә халык иҗатына аеруча зур хөрмәт белән караган кеше генә алына ала. «Үткән елларда фольклор комиссиясенә тәмам 42 сан әкиятләр язып тапшырган идем, бу ел да аннан ким булмаска тиешлегенә шик тотмыйм. Халкыбызның үз иҗатына зур мәхәббәте һәм кызыксынуы мине бу эшкә бик каты тарта», – дип яза ул 1939 елның җәендә.

З. Мөэминов әкиятләрнең күбесен Беренче бөтендөнья сугыш вакытында Австро-Венгриядә әсирлектә ятканда үзе кебек солдатлардан ишеткән. Сүз уңаенда әйтеп узыйк; венгр галиме И. Кунош та татар әкиятләрен һәм җырларын шул чорда чех шәһәре Эгер

һәм венгр поселогы Кеньермезье тирәсендәге лагерьларда тотылган хәрби әсирләрдән язып алган. Бу материалларның бер өлеше (җырлар) 1980 нче елда Венгриядә аерым китап булып басылып чыкты, әкиятләр шулай ук якын арада дөнья күрер дип өметләнәбез.

З. Мөэминов үзе ишеткән әкиятләрне шул вакытларда ук кәгазьгә төшергән һәм зур гына җыентык әзерләгән булган. Әмма әсирләрне Босния өлкәсендәге Фрауник шәһәреннән Сараево шәһәренә күчергәндә бу җыентыкны конфискациялиләр. Ә югарыда телгә алынган дәфтәрләргә ул, чирек гасырга якын вакыт узгач, әлеге әкиятләрне яңадан искә төшереп язарга мәҗбүр булган (дәфтәрләрнең күбесе латин шрифты белән язылган).

З. Мөэминовның Бөек Ватан сугышына кадәр җибәрелгән өченче дәфтәреннән кайбер әкиятләр үз вакытында ук басылып та чыккан. 1940 нчы елда дөнья күргән «Халык иҗаты» исемле җыентыктагы әсәрләрне өйрәнү нәтиҗәсендә андагы 8 әкиятнең («Әдәм егет һәм җен егет», «Үксез кыз», «Бүре белән тәкә», «Төлке белән бүре», «Бүдәнә белән төлке», «Кәҗә белән бүре», «Аучы сөйли», «Кулсыз кияү») З. Мөэминов дәфтәреннән алынган булуы ачыкланды. Шуларның 5 есе хәзерге вакытта чыгарыла торган уникe томлык фольклор әсәрләре җыелмасындагы әкият китапларына да кертелде. Янә дә, шуларга өстәп, З. Мөэминовның үз якташларыннан язып алган 4 әкияте беренче мәртәбә басылды («Укымышлы кыз», «Белемнең төбе», «Үткен кыз», «Күрәзә карчык»). Шулай итеп, З. Мөэминовның барысы 12 әкияте дөнья күргән булып чыга. Бу – аз түгел.

Дүртенче дәфтәр хәзерге шрифт белән язылган һәм анда 4 әкият урын алган. Аларны ул 1908 елда Арслан Җәлилов дигән карттан ишеткән булган.

Г. Ибраһимов исемендәге институтның Фольклор фондында З. Мөэминовның тагын бер дәфтәре саклана. Анда гарәп шрифты белән бәетләр язылган. Бу дәфтәрне ул фольклорчы галим Х. Ярми үтенече буенча институтка 1949 елда җибәргән.

З. Мөэминов үзе дә бәетләр чыгарырга һәвәс кеше була. Беренче бәетен ул мәдрәсәдә укыганда ук чыгарган. Аннары сәнәкчеләр тарафыннан үтерелгән туганнарына багышлап бәет чыгаруы да мәгълүм. Болардан тыш аның материаллары арасында җырлар һәм табышмаклар да бар.

Менә шундый һәвәскәр фольклорчының кульъязма мирасы белән кызыксыну, әлбәттә, урынлы иде. З. Мөэминовның үзе тарафыннан 1939 нчы елда вәгъдә ителгән дүрт дистәдән артык әкиятенең язмышы күңелне аеруча дулкынландырып һәм борчып торды.

Миңа колхоз идарәсендә үк З. Мөэминовның улы Сәгыйть Зарифович белән очрашу насыйп булды. Ул колхоз бухгалтериясендә кассир булып эшли икән. Аның әйтүенә караганда, Бөек Ватан сугышыннан соң З. Мөэминов үзенең фольклор материалларын, бастыру нияте белән, Уфага илтеп кайткан. Әлеге кулъязмаларны алып калган язучы Гайнан Әмири белән хатлар аша хәбәрләшә алмагач, Зариф ага кабат Уфага юнәлә. Әмма Г. Әмири аңа: «Материалларың югалды шул», – дип җавап бирә. Кулъязмаларның кайберләре, әнә шулай төрле кешеләр кулына эләгеп, юкка чыккан, ә кайберләре яндырылган. Бары бер дәфтәр генә археографлар кулына эләккән. Туганының улы Әхнәф Латыйповның әйтүенә караганда, ул дәфтәрдә «Әхмәт» исемле пьеса (З. Мөэминов пьесалар, хикәя һәм шигырьләр дә язган), берничә бәет, бер шигырь һәм бер әкият булган. Бу дәфтәрне әле эзләп табарга мөмкиндер дип уйларга кирәк.

З. Мөэминов турында күбрәк 60 яшьлек Гафият Сәхиуллин сөйләде. Гафият аганың хәзер күзләре күрми икән, ләкин хәтере искиткеч яхшы. З. Мөэминов аның якын дусты булган. Дустының тормыш юлын, әсирлектә булган хәлләрен бик әйбәт белә. «Зариф абзый сугышка хәтле кышкы озын төннәрдә, куырган борчак ашыйашый, яшьләргә әкият сөйли иде», – дип искә ала ул.

Г. Сәхиуллин бик актив кеше, авыл советы депутаты итеп тә сайланган, хәзер дә киңәшергә еш киләләр аңа. Һәвәскәрләр концерты да аңардан башка узмый, баянда уйный икән. Күп аралаша, күп белә. Язучылар, артистлар белән очраша, актуаль мәсьәләләр буенча әңгәмәләр кора икән.

Гафият агадан мин байтак кына фольклор материаллары да язып алдым. Алар арасында әкиятләр, мәзәкләр, авыл тарихлары, риваятьләр бар. Мәсәлән, ул сөйләгән риваятьләрнең берсе Пугачев восстаниесе белән бәйле. Имештер, Теләнче авылы янындагы урманлы тауда Пугачев гаскәрләре урнашкан булган. Авыл халкы бу гаскәрләрне каладан килгән дип уйлаган. Шуңа күрә әлеге урынны «Када тавы» дип йөртә башлаганнар. Анда хәзер дә зур таш плитә бар, ди. Шуның астында пугачевчыларның кораллары саклана, имеш.

Икенче бер риваятьтә борынгы хөкем турында сөйләнә. Берсеннән 30 чакрым ераклыкта урнашкан Татар Бүләре һәм Баек авылларының арасы кара урман белән капланган булган. Шул авылларда берәү җинаять эшләсә, аны, чуен казан сөйрәтеп, урман аша икенче авылга ут алып кайтырга җибәргәннәр. Хөкем ителгән теге кеше аю яки бүрегә очрап һәлак булса, җәзасын алган дип саналган. Әгәр утны сүндермичә исән-сау әйләнеп кайтса, авыл халкы аның җинаятен гафу иткән.

Соңгы елларда оештырылган экспедицияләрдә легенда-риваятьләр җыюга күбрәк игътибар бирелә башлады. Моның хикмәте шунда: халык иҗатының бу жанрына байтак еллар буена тиешле дикъкать булмаган, һәм шуңа күрә алар бик аз җыелган. Халык иҗатының унике томлык басмасында бер том шушы жанрларга билгеләнгәч, мәсьәлә алга бөтен җитдилеге белән килеп басты. Димәк бу жанрлар һич кичекмәстән игътибар үзәгенә күчәргә тиеш. Башка халыкларда бу өлкәдә инде җитди хезмәтләр дә күренә башлады. Мәсәлән, башкорт дуслар 1981 нче елда үз халкының риваять-легендаларын бергә туплап, 26 табаклы калын китап чыгардылар. Аңа кадәр рус, латыш, литва, әрмән, грузин риваятьләре һәм легендалары дөнья күргән иде.

Риваять һәм легендалар, әкиятләр, дастаннар, бәетләр белән бергә, фольклорның халык эпосы дигән өлкәсен тәшкил итәләр. Бу әсәрләр, фәнни кыйммәтләре белән беррәттән, мөһим тәрбия чарасы да булып торалар.

Фольклор чаралары белән илебез гражданнарын, бигрәк тә яшь буынны патриотизм рухында тәрбияләүдә без шулай ук үзебезнең өлешне кертергә бурычлыбыз. Фольклорчыларга бу эштә, аерым алганда риваять һәм легендаларны туплауда, җәмәгатьчелек тә зур ярдәм күрсәтә алыр иде. Халык иҗатын сөюче һәвәскәрләр үзләре яши торган төбәктә мәгълүм булган әлеге әсәрләрне, шулай ук авыллар тарихын, нәкъ халыкта сөйләнгәнчә итеп, безгә язып җибәрсәләр, фольклор фондыбызга никадәр байлык өстәлер иде, һәм басылып чыгасы китап та сыйфаты белән генә түгел, күләме белән дә унике томлыкның башка китапларыннан калышмас иде.

### Күңел хәзинәсе җәүһәрләре

Шикләнмичә әйтергә мөмкин: Буа төбәге – фольклорга бай як. Бу байлыкны шәхси күзәтүләр юлы белән генә дә билгеләргә, ачыкларга мөмкин. Ләкин әлеге хәзинә җыелмаган булса, аны, әлбәттә, күрсәтеп тә, исбатлап та булмый. Буа районы бу җәһәттән бәхетле: анда татар фольклорының корифейлары – Х. Ярми һәм Н. Исәнбәт кебек галимнәр – халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю буенча фәнни экспедицияләрдә булып, үз вакытында халыктан күп кенә әсәрләр язып алганнар. Ә әкиятләрне җыю эшен Адав-Толымбай авылыннан чыккан язучы һәм галим Гомәр Толымбай безнең гасырның 30 нчы елларында ук башлап җибәргән. Ул 1936 елда янгын каланчасында үзенең авылдашы – 58 яшьлек Хәйретдин Хөсәеновтан бер дистә чамасы әкият язып алган. Галимгә үзе исән чагында бу хәзинәне

бастырып чыгару насыйп булмаган, әмма алар сакланып калганнар һәм хәзерге көндә татар әкиятләренең алтын фондын тәшкил итәләр. Әлеге әкиятләр арасында «Патша малае, аның апасы, юлбарыс һәм башкалар», «Үги ана белән яшь егет», «Аучы белән асрау кыз» һ.б. киң билгеле әсәрләр бар.

Бөек Ватан сугышыннан соң, төгәл итеп әйткәндә – 1945 елда – Буа районында Х. Ярми, Г. Бәширов һәм Х. Гатина составындагы фәнни экспедиция эшли. Фольклор җыентыкларына даими кертелеп килә торган «Зирәк карт» дигән классик әкият, мәсәлән, Х. Гатина тарафыннан Иске Суксу авылында шул вакытта язып алына. Аны 64 яшьлек Әхтәп Камалетдинов сөйләгән була. Яңа Чәчкап авылында 39 яшьлек Каюм Рәшитов исә «Кәтән Иваныч» дигән әкиятне яздырган. Ә менә Г. Бәширов һәм Х. Ярми Иске Тинчәле авылында «Кулсыз кыз» дигән маҗаралы әкияткә тап булалар. Аны 41 яшьлек Барый Галиев сөйләгән.

1972 елда шундый ук экспедиция вакытында Аккүл авылында мин үзем дә 88 яшьлек Закирә Минаевадан уннан артык әкият язып алган идем, шулардан «Чуен бабай» дип исемләнгәне «Татар халык иҗаты» җыелмасының «Көнкүреш әкиятләре» томында басылып та чыкты. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондында Каенлык авылыннан 82 яшьлек Низам Җәләлиев, 71 яшьлек Әбелхәер Минкин, Бикмураз авылыннан 72 яшьлек Гыйльфан Мөхәммәдишев һ.б.лар сөйләгән әкият язмалары бар.

Әлегә кадәр сүз фольклорны планлы төстә өйрәнү барышында тупланган әкиятләр турында булды. Әмма төбәккә бәйле фольклор үрнәкләрен әле узган гасыр башында ук нәшер ителгән кайбер басмаларда да очратырга мөмкин. Мәсәлән, 1904 елда Казанда чыккан «Нәмүнәи тәраккый» дигән китапта байтак кына фольклор үрнәкләре урнаштырылган. Алар арасында берничә халык әкияте һәм мәзәкләр бар. Авторы – дин эшлеклесе, язучы һәм төбәк тарихчысы, Тинчәле авылыннан чыккан Касыйм бине мелла Җамалетдин Биккулов әл-Тинчәли (1868–1937). Ул бу китабында үзенең үсмер елларында авылда ишетеп белгән әсәрләрне файдалангандыр, дип уйларга нигез бар.

Аксу авылыннан чыккан күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче, тел галиме, язучы Галимҗан Шәрәф 1918 елда Казанда халкыбызның «Гөлчәчәк» исемле әкиятен бастырып чыгара. Авылда әкиятләр тыңлап үскән 21–22 яшьлек егет, әлбәттә инде, сабый чагында үзен нык дулкынландырган сюжетларның берсен бәян иткәндер, дип гоман кылырга кирәк.

Әкиятләргә киңрәк тукталуның сәбәбе – аның татар фольклорында иң зур һәм популяр жанр булуында. Районда язып алынган әкиятләрдән бүгенге көнгәчә 20 ләп әсәр басылып чыккан. Әлеге күрсәткеч буенча ул бары Апас районыннан гына калыша.

Бу якларда фольклорның шундый ук популяр жанры булган мәзәкләр дә беркадәр җыелган. Күзби авылында туып үскән тел белеме галиме, филология фәннәре докторы, профессор Вахит Хаков туплаган Хуҗа Насретдин мәзәкләре арасындагы 30 дан артык текст 1962 елда Абдулла Әхмәт төзеп чыгарган «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» җыентыгында дөнья күрә. «Татар халык иҗаты» җыелмасындагы «Мәзәкләр» томында Буа районында язып алынган 9 мәзәк басылган. Фольклор фондында басылырга лаеклы мәзәк текстлары әле тагын да бар. Аларның бер өлеше – Аккүл авылыннан Гыйлаҗ Минаев язып җибәргән әсәрләр.

Афористик жанрлардан да басылып чыккан үрнәкләр шактый гына. Мәсәлән, Буа районында җыелган мәкаль һәм әйтемнәр Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» исемле өч томлык хезмәтендә (Казан, I – 1959, II – 1963, III – 1967) 250 берәмлектән артып китә. Алар арасында Өчмунча авылында туып үскән язучыдраматург Шәриф Хөсәенов (1929–1999) җыеп тапшырганнары да бар. Биредә тагын сынамышлар, ышанулар (юраулар) дигән жанрларга караган үрнәкләрне дә очратырга мөмкин. Н. Исәнбәтнең «Татар халык табышмаклары» (Казан, 1970) дигән китабында исә Буа төбәгендә җыелган 40 лап табышмак басылган.

Балалар фольклоры репертуарыннан да дөньяга чыккан әсәрләр бар. «Татар халык иҗаты» күптомлык җыелмасының «Балалар фольклоры» томында бу өлкәгә караган ике дистәләп текст урын алган.

Лирик жанрларга килгәндә, хәл башкачарак. Бигрәк тә тарихи җырлар, озын җырлар, шулай ук җырлы-биюле уеннар аз җыелган, ә басылып чыкканнары бер-ике берәмлек белән чикләнә. Кыска җырлар (дүртьюллыклар) исә бөтенләй басылмаган. Лиро-эпик жанрга караган бәетләр турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Гомумән алганда, Буа ягы бәетләргә дә, лирик әсәрләргә дә бай төбәк. Әмма алар әлегә аз җыелган. Бу мөһим эшкә кичекмәстән тотыну мәслихәт. Бәетләр, мөнәҗәтләр, җырлар, гадәттә, дәфтәрләргә язылган хәлдә саклана. Шуңа күрә, аларны табуга ышаныч беркайчан да җуелырга тиеш түгел. Безнең кулга, мәсәлән, Тутай авылында яшәгән Сарибә Ногманова (1925–1996) дәфтәре килеп керде. Анда 200 ләп кыска җыр теркәлгән. Мондый дәфтәрләрне һәр авылда диярлек табарга мөмкин. Бары тик эзләргә генә кирәк. Шуның

өстенә, кайбер галимнәрнең шәхси архивларында да Буа төбәгенә бәйле фольклор материалларының саклануы мәгълүм.

Ә менә риваять, легенда һәм сөйләкләр бөтенләй җыелмаган дияргә мөмкин. Бу эшне башкару өчен белгечләр катнашында махсус экспедиция оештыру максатка ярашлы булыр иде. Болар, нигездә, халык хәтерендә генә яши, шуңа күрә бигрәк тә хәзерге заман шартларында җиңел югалалар да.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Буа районы – халкыбызның күңел хәзинәсе булган авыз иҗаты әсәрләренә бай төбәк. Бу рухи җәүһәрләрнең бер өлеше җыелып, төрле китап-җыентыкларда басылып чыккан, ә икенче өлеше Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондында һәм шәхси архивларда саклана. Аларны басмага әзерләү киләчәктәге мөһим эш булып кала. Ә кайбер жанрларга караган әсәрләр, бигрәк тә музыкаль фольклор, аз җыелган яисә бөтенләй җыелмаган. Бу кимчелекне төзәтү райондагы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче зыялыларның алда торган кичектергесез бурычы булып саналсын иде. Югыйсә соңга калуыбыз бик ихтимал. Минемчә, әлеге эшне Буа шәһәрендәге төбәкне өйрәнү музее оештыра алыр иде. Чөнки музейның вазифасы – халкыбызның матди мирасын гына түгел, рухани мирасын да кадерләп саклау, аны киләсе буыннарга да илтеп җиткерү.

Соңгы нәтиҗә шул: хәзерге вакытта, моңарчы җыелган материалны файдаланып, «Буа районы фольклоры» дигән исемдә 20 табак чамасындагы бер җыентык төзеп бастырырга мөмкин. Аны, озакка сузмыйча, тормышка ашырасы иде. Бу теләкне без беренче чиратта район хакимиятенә юллыйбыз.

## Буада байлык буа буарлык

Җәй айлары – төрле фәнни экспедицияләр эшчәнлеге чоры. Быел Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фольклор экспедициясенең бер отряды республикабызның Буа районында эшләде.

Узган 20 елга якын вакыт эчендә фәнни экспедициягә чыгучылар берәм-сәрәм генә булды. Сәбәбе – акча булмау. Шөкер, соңгы вакытта хәл үзгәрде: 2007 елгы сезонда фольклор, диалектология, археография, музыка-этнография, ономастика һ.б. юнәлешләр буенча 1–3, хәтта 5–6 кешедән торган фәнни экспедицияләрнең саны 13 кә җитте.

Фольклорчы буларак, мин сыкранып уйланам: менә шушы экспедицияләр тукталып торган соңгы 20 елга якын вакыт эчендә күпме рухани хәзинәбез югалгандыр – аны бер Алла гына белә.

Югалган әлеге байлыкны кире кайтару мөмкин булмаса да, хәлне төзәтергә беркайчан да соң түгел. Бүген инде, бәлки, әкиятчеләр очрамас та, әмма халык яшәгән җирдә фольклор булмый калмый. Вакытында табып җыймасаң, алары да юкка чыгачак бит. Шунлыктан институтның экспедицияләр тарихында үзенә күрә яңа этап булырдай бу сәфәргә без рухланып әзерләндек.

Өйрәнү төбәге итеп Буа районы сайланды. Буа ягы – фольклорга бай төбәк. Биредә татар фольклористикасының корифейлары Х. Ярми һәм Н. Исәнбәт халыктан күп кенә әсәрләр язып алган. Ә халык әкиятләрен җыю эшен язучы һәм галим Г. Толымбай узган гасырның 30 нчы елларында ук башлап җибәргән. Сугыштан соң Буа районында Х. Ярми, Г. Бәширов һәм Х. Гатина составындагы фәнни экспедиция эшли. Мин дә 1972 елда Буа районының Аккүл авылында 88 яшьлек Закирә Минаевадан 10 нан артык әкият язып алган идем.

Хәмит ага Ярми «Буа ягы – әкиятле як», дип кат-кат әйтә иде. Ә әкият булган җирдә фольклорның калган жанрлары да яши. Моны безнең фольклор җыйнаудагы күпьеллык тәҗрибәбез күрсәтә.

Басылып чыккан материаллар да шактый. Шулар арасында 20 ләп әкият, 40 лап мәзәк (шуның 30 дан артыгын профессор В. Хаков бастырган), 250 дән артык мәкаль-әйтем, 40 лап табышмак һәм балалар фольклоры жанрларына караган 20 ләп әсәр бар. Калган жанрларга килсәк, хәл үзгәрәк. Бигрәк тә тарихи һәм лирик җырлар, шулай ук җырлы-биюле уеннар аз җыелган, ә басылып чыкканнары бер-ике берәмлек белән чикләнә. Кыска җырлар (дүртьюллыклар) исә XX гасыр азагынача бөтенләй басылмаган. Бәетләр, мөнәҗәтләр һәм риваятьләр турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Хәер, районның Тутай авылында туып-үскән Сарибә Ногманова дәфтәрендәге 32 кыска җыр 2000 елда «Буа ягым – тау ягым» дигән китапта басылып чыккан иде. Җырлардан тыш, Аккүл авылында яшәүче Гыйләҗетдин Микаевтан язып алынган «Ачлык бәете» һәм бүген инде юкка чыккан Тау авылының илсөяре Әминә Мохтарова чыгарган «Таң» дигән авылны уйлап...» исемле бәет дөнья күрде. Ә менә шушы район кешеләреннән язып алынган мөнәҗәтләрнең һәм риваятьләрнең әлегәчә басылганы юк.

Бер атналык сәфәр вакытында башкарыласы эш ишәеп киткәнлектән, отрядта тагын бер тәҗрибәле фольклорчының булуы зарур иде, һәм бу вазыйфага институтның элеккеге хезмәткәре – таныл-

ган фольклорчы, филология фәннәре кандидаты Флора Әхмәтова-Урманче чакырылды. Шулай итеп без, 6 кешелек төркем, Буа районына чыгып киттек. Ә 4 кешелек икенче төркем Пенза өлкәсенә юнәлде.

Флора ханым – атаклы сынчыбыз Бакый Урманченың хәләл җефете. Бакый аганың туып-үскән җире исә – Буа районындагы Күл Черкене авылы. Телдә аны Черкен дип кенә йөртәләр. Без дә үз эшебезне нәкъ менә шушы авылдан башларга карар иттек.

Мәктәпкә 50 ләп әби-бабай җыелган. Без бит Казаннан тикле шушы 50 кеше белән очрашырга килдек. Фольклор, нигездә, шуларда.

Флора ханым әбиләргә, безнеңчә әйтсәк, лекция сөйләде. Максатны аңлату өчен сүзне ерактан, тормыш-көнкүрешкә, саулыкка, гаиләгә мөнәсәбәтле фикерләр әйтүдән башлады. Бу исә – безгә кирәкле һәр кешенең, ягъни хәтерендә фольклор дигән хәзинәне саклаган могтәбәр затның иң элек игътибарын, ышанычын яулар өчен, аның телен ачар өчен зарур алым. Бу затлар белән аерым-аерым очрашканда әлеге «лекция»не һәркайсына аерым-аерым сөйләргә туры килә. Моңа күпме вакыт сарыф ителә, ә көтелгән нәтиҗә еш кына нуль дә була. Бер урынга җыелу фольклорчының күпме вакытын экономияләргә мөмкинлек бирде, фольклорны хәтерендә саклаган затларны эзләп, авыл буйлап йорттан-йортка йөрисе түгел – алар барысы да безнең каршыбызга үзләре килеп тезелде.

Әбиләрнең яше күбесенең 70 белән 80 арасында. Ә менә минем яныма утырган Һаҗәр апа Хәлиуллинага 93 яшь. Сүз уңаенда әйтеп узыйм, аңа бары 2 ай гына укырга туры килгән. Әмма надан түгел ул: гарәп графикасымы, латинмы, кириллицамы – аның өчен барыбер, укыган да, язган да. Менә шушы әбиләр бит инде – сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы чорда илне азык-төлек һәм киемсалым белән тәэмин иткән тыл батырлары. Боларны бит бүгенге көндә уч төбендә генә йөртәсе! Әмма аларның күбесенең тормышы әле дә мәшәкатьле.

Менә фольклорчыларның да эше эзгә төште. Залның бу башында да, теге почмагында да диктофоннар тоташтырылган, әледән-әле фотоаппарат уты ялтырап китә. Аспирантлар Салават Зөлкарнәев, Рәмзия Галиәхмәтова, Рәдис Хәкимов һәркайсы техниканы-электрониканы яхшы белә, көнкүреш мәсьәләләрен дә бик тиз хәл итәләр – авыл балалары бит! Әнә Салават каршында 85 яшьлек сугыш ветераны Мөнәвәрә Фәхретдинова утыра. Мөнәвәрә ханым Кронштадт заводларының берсендә снарядлар җитештергән. Әмма чәчәк кебек яшьлегенең шундый дәһшәтле чорга туры килүеннән зарланмады

ул, сугыштан соң гаиләсе, бала-чагасы булган... Тик менә картлык дигән нәмәрсә генә беркадәр комачаулый бугай. Чөнки аның мөнәҗәте шул хакта:

И син, картлыгым, ник иртә килдең –
Минем адресны син кайдан белдең?
Картлык көчле шул, яшьлекне җиңде,
И син, яшьлегем, кайтмассың инде.

Без мөнәҗәтләрне һәм бәетләрне байтак яздык. Шуның өстенә, аспирантларыбыз бәет һәм кыска җырларны Мәгъсүм ага Харисов (урыны оҗмахта булсын) инициативасы белән эшләнгән фольклор альбомнарыннан да күчереп алды.

Ә иртәгесен Күл Черкене авылының яңа мәчетенә бабайлар янына юнәлдек.

Беренче чиратта без бу тирәдәге авылларның тарихы һәм авыл исемнәренең мәгънәсе белән кызыксындык. Бу турыда мәгълүматлар юк түгел, алар көндәлек матбугатта да басылган, китапларга да кергән. Әйтик, бу тирәдәге авылның урысча рәсми исемнәре турында без профессор Гомәр Саттаров хезмәтләре буенча таныш идек. Бактың исә, бу хакта халыкның үз фикере дә бар икән,

Мәгълүм булганча, Килдураз һәм аның якынындагы авылларның рәсми исемнәре «Черки» дигән алкушымча белән башлана: Черки-Килдуразы, Черки-Ишмяково (Өчмунча), Черки-Бибкеево (Бәбки), Черки-Кощаково (Казма), Черки-Дюртиле (Каенлык), Черки-Гришино (Күл Черкене). Беркадәр сәер бит: нинди бетмәгән «Черки» инде ул?

Авыл картлары сөйләгән риваятькә караганда, Килдуразда Сергей Гришин дигән урыс бае яшәгән. Шушы төбәктәге авыллар (алар, әлбәттә, бик кечкенә булган) барысы да аның биләмәләре саналган. «Сергей» сүзен татар үзенчә «Черки» дигән. Авылларның исемнәрен сораганда, бай исемен дә кушып, «Сергей Килдуразы, Сергей Бәбкәсе...» дигәннәр. Татарча әйткәндә, Черки Килдуразы, Черки Бәбкәсе, Черки Ишмәге (Ишмөхәммәт исеменең кыска варианты), Черки Кошчагы (кеше исеме, Казма – авылның яңа исеме ), Черки Дүртөйле (Каенлык – авылның яңа исеме), Черки Күл Черкене, дигәннәр. Соңгысы артык «чыркылдап» торгангамы, рәсмиләштерүче зат Черкен исемен байның фамилиясе белән алыштыруны кулай күргән булса кирәк һәм Күл Черкененең урысча исеме Черки-Гришино булып киткән.

Менә шундый риваять бар. Дөрес, ул халык этимологиясе генә булырга да мөмкин. Әмма, барыбер, без аны белергә һәм игътибарга алырга тиеш.

Фольклорчылар Күл Черкене, Килдураз, Казма һәм Каенлык авылларында яшәүче өлкән яшьтәге кешеләрдән, шулай ук мәктәп һәм китапханәдәге альбомнардан 936 берәмлек тәшкил иткән халык авыз иҗаты әсәрләре язып алды. Шул исәптән 800 гә якын кыска җыр һәм такмак, 30 мөнәҗәт, 26 бәет, 25 мәзәк, 9 уен, 1 әкият һ.б. жанрларга караган берничә дистә әсәр. Шигъри әсәрләрнең юл саны 6,5 меңнән артык.

Без бу нәтиҗәдән бик канәгать. Экспедиция әгъзалары, районның калган авылларында да буласы иде, дигән теләк белдерде. Безгә ярдәм итүчеләргә тагын бер кат зур рәхмәт.

## Халык җәүһәрләре

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Актаныш районына барлыгы 4 фольклор экспедициясе оештырыла (1948, 1981, 1987, 2009 елларда).

Күренекле фольклорчы Х. Ярми җитәкләгән 1948 елгы беренче экспедициядә Х. Гатина, Н. Фәттах, Ш. Максудовалар катнашкан. Алар 40 көн дәвамында шул дәвердәге Актаныш районына кергән 15 авылда (Әҗмәт, Бурсык, Илчебай, Иске Балтач, Иске Кормаш, Куян, Мәсәде, Меңнәр, Такталачык, Татар Әҗбие, Татар Суксуы, Уразай, Чалманарат, Шәбез, Югары Гәрәй) һәм Калинин районына кергән 12 авылда (Әмәкәй, Әнәк, Исәнсеф, Иске Байсар, Иске Сәфәр, Мәчти, Пучы, Сикия, Татар Бүләре, Түбән Яхшый, Уразмәт, Яңа Байсар) фольклор материаллары җыйганнар. Шулай итеп, бу экспедиция 27 авылда эшләгән. Исәпләүләр буенча, җыелган фольклор материалларының гомуми саны 4746 данә.

Экспедициядә язып алынган 37 әкиятнең 9 ы төрле елларда 7 җыентыкта басылып чыккан. Иске Кормаш авылында яшәүче Насыйр Фәррахов сөйләгән «Урман каравылчысы» дигән әкият, шул ук авылдан Халисә Зиязова сөйләгән «Каракош», Әмәкәй авылыннан Шәфикъ Хөснуллин сөйләгән «Мулла остабикәне никахлый» әкиятләре татар фольклорының 13 томлык җыелмасындагы әкият томнарында (I – 1977, II – 1978, III – 1981) басылырга лаеклы дип табылды. Соңрак алар рус телендә дә дөнья күрде. Ә Татар Әҗбие авылында Шәрип Закиров сөйләгән «Җилән» дигән әкият 1956 елда ук басылып чыккан иде. Янә берничә әсәр, Х. Гатина тарафыннан төзелеп, соңгы елларда бастырылган әкият китапларына кертелде.

Югарыда искә алынган 13 томлы абруйлы җыентыкта йола һәм уен җырларыннан өч әсәр, бер риваять һәм табышмаклар,

мәкальләр, кыска җырлар урын алган, бер бәет, тарихи һәм лирик җырлардан өч әсәр, янә балалар фольклорына караган кечкенә күләмле 72 әсәр дөнья күргән.

Бу якларда композиторлар Александр Ключарев һәм Җәүдәт Фәйзи дә булганнар. Җ. Фәйзи, мәсәлән, Актаныш районына караган авылларда халыктан 20 лирик җыр язып ала (Актанышта – 5, Такталачыкта – 12, Мәсәде авылында – 2, Бурсыкта – 1) һәм аларны, ноталары белән бергә, үзенең «Халык җәүһәрләре» китабында бастырып чыгара[1]. Бу җырлар 1987 елда кабат басылды[2].

Актаныш төбәгенә икенче экспедиция 1981 елда оештырылды. Бу сәфәргә мин берүзем чыгып киттем.

Июльнең икенче яртысы иде. Кояш чамасыз кыздыра. Тезгә дә җитми катып калган игеннәр яңгырга тилмереп утыра. Хәтта җирнең үзенә дә ут кабар сыман. Елга ярлары саргаеп кипкән. Терлекләр көтүдән ач кайта. Бер капчык печән табу да – мөмкин булмаган эш. Менә шул була икән инде ул – корылык дигән коточкыч нәрсә.

Мин килгәндә КПСС райкомында зур киңәшмә бара иде. Көн тәртибендә – камыл җыю мәсьәләсе. Быел игеннәрне болай да мөмкин кадәр төптән урдыралар, аның камылы ничә генә сантиметр булыр икән соң? Әмма барыбер җыярга. Гадәттән тыш хәл шулай куша. Җитмәсә, моны ашыгыч рәвештә эшләргә кирәк, чөнки җирне туңга сөрәсе бар. Камыл җыя торган машина юк (аны җыярга бүтән язмасын да), ә инде быел җыярга мәҗбүрбез икән, моның өчен башта махсус җайланмалар ясарга кирәк бит! Әнә, «Маяк» колхозы эшчәннәре аеруча өлгерлек күрсәткәннәр – камыл җыюны башлаганнар да икән. Киңәшмәдәге халык, озакка сузмыйча, тәҗрибә өйрәнергә шунда ашыкты. Мине дә язмыш шулар арасына китереп керткән иде. Борылышта санап алам: машиналар саны ике дистәдән артык. Алдагыларында район җитәкчеләре, калганнарында колхоз-совхоз вәкилләре, белгечләр. Колонна тиз бара. Бу минутларда мин аларны бәла-казага юлыкканнар янына ашыгучы янгын сүндерү машиналарына охшаттым. Чыннан да, болар да бит коткарырга ашыга! Ничек кенә булса да терлек-туарны саклап калырга, халыкны ит-майдан мәхрүм итмәскә, сабыйларны сөтсез калдырмаска...

Актаныш ягы – гүзәл табигатьле, җырлы-моңлы як. Моңарчы бу якта булмаган берәр шагыйрь, Актанышның мәдәният сарае буса-

---

[1] Фәйзи Җәүдәт. Халык җәүһәрләре: Татар халкының хәзерге заман музыка фольклоры. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 288 б.

[2] Фәйзи Җәүдәт. Халык җәүһәрләре: Күңелем кыллары. Татар халык көйләре. Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 392 б.

гасына басып, Агыйделгә генә карасын – илһамын дөрләтергә шул бик җитә!

Агыйделдән, Сөн буйларыннан Мохтар Мутин, Әлфия Афзалова, Риза Ишморат, Гамил Афзаллар күтәрелгән, аның туфрагында киләчәктә Советлар Союзы Герое булачак биш бала тәгәрәп үскән. Шул каһарманнарның берсе – сугыштан соң күпме еллар яшәп тә, үзенең герой икәнен белми дөньядан киткән һәм шушы сокландыргыч тыйнаклыгы белән җырга күчкән Хәсән Заманов. Янә дә исеме җырда яңгырый торган Ардуан батыр – Мирсәет Ардуанов та шушы яктан, Иске Кормаштан. Монысы – тынычлык фронты каһарманы. Бу гади татар эшчесенә хәтта Татарстаннан читтә, Березники шәһәрендә һәйкәл куелган.

Кояш һаман да рәхимсез. Радио хәбәр итә: бүген Татарстанның көнчыгышында эсселек 43 градус булачак. Көн тәртибендә шул ук бер мәсьәлә: печән, печән... Бер капчыкмы, бер учмы – һәр көнне табарга, мотлак табарга. Печән генә түгел, бәрәңге дә проблема. Хатын-кыз, бакчага чыгып, бер пешерерлек бәрәңге таба алмый керә.

Менә шундый авыр шартларда, уттай эш өстендә халык авыз иҗатын җыю белән шөгыльләнү беркадәр уңайсызрак та шикелле. Халык моны ничек кабул итәр? Мондый эшкә ул ничек карар?

Печән җыюдан гадәти елда да беркем читтә калмый, шул исәптән авыл интеллигенциясе дә. Шунлыктан, печән өстендә клуб, китапханә, медпункт ябык булса да, гаҗәпләнергә туры килми. Ә ул елда... хәтта Актаныш райбашкармасы коллективының тулы составта печән өмәсендә эшләгән көннәре булды. Нинди җаваплылык!

Нәкъ менә шул җаваплылык хисе фольклорчыны да авыл хезмәтчәннәре кебек фидакарь булырга өнди. Тирәнрәк уйлап карасаң, мин дә бирегә коткаручы булып килгәнмен бит! Халкыбызның җәүһәрләргә тиң рухи хәзинәсен саклап калыр өчен! Сүз дә юк, изге эш.

Моннан берничә еллар элек язып алынып, кайберләре калын-калын томнарда басылып чыгарга да өлгергән шундый җәүһәрләрне безгә бүләк иткән, халкыбызның моңлы җырларына, серле әкиятләренә, гаҗәеп риваять-легендаларына икенче гомер бирергә булышкан хөрмәтле кешеләребезнең байтагы бүген инде дөньяда юк. Димәк, фольклорчылар да ашыгырга тиеш. Нинди шартлар булуга да карамастан, аларның игелекле эшләрен сүлпәнләндерергә хаклары юк.

Халык арасында эшне башлап җибәргәч, киеренкелек беркадәр сүрелә төште. Беренчедән, халык бәргәләнми-сугылмый, беркем дә ах-ух килми. Быелгы шартларның 1921 елгыдан да кырысрак икәнен

белсәләр дә, күңелләре тыныч, алар хөкүмәтебезгә ихлас ышаналар – ачлык булмаячак. Икенчедән, эшемнең башында ук халык миңа зур теләктәшлек күрсәтте. Фольклор туплауның, шулай ук, мөһим эш булуын яхшы аңлыйлар икән. Шул вакытта райбашкарма рәисе урынбасары Миңтимер Салихҗан улы Әхмәтхановның сүзләре искә төште. Ул мине сәфәргә озатканда: «Иске Кормашның халкы бик әйбәт, анда керсәгез, үкенмәссез», – дигән иде. Биредә халыкның күңеленә «ачкыч яратырга» өстәмә вакыт кирәк булмады.

Теге яки бу авыл халкының белемле, тәрбияле, культуралы булуы – буыннан-буынга күчеп килә торган традицион күренеш. Бу, беренче чиратта, туган җирне, аның халкын яратудан, тарихын хөрмәтләүдән килә торгандыр. Үз авылының тарихын һәм бу төбәккә мөнәсәбәтле риваятьләрне сөйләгәндә Иске Кормашта туып-үскән Бөек Ватан сугышы ветераны, 68 яшьлек Хөснимәрдән Мәрдәновның халкыбыз тарихына булган зур ихтирамын һәм самими күңел җылысын тоймый мөмкин түгел иде. Авыл кайчан салына башлаган, Кормаш бабайның ничә улы булган, соңрак нинди нәселләр яшәгән – болар барысы да Хөснимәрдән аганың хәтер сандыгында кадерләп саклана.

Риваятьләргә караганда, Иске Кормаштан ерак булмаган Умбы елгасы буенда Җизмыек дигән кавем дөнья көткән (алар күптән инде биредән күчеп киткән, шулай да, нәселләренең дәвамчыларын очраткалыйлар икән). Җизмыеклар янында, авыл булып, Нократлар яшәгән. Тик алар да, ни сәбәпледер, бу җирдән күчеп киткәннәр, елга буенда зиратлары гына торып калган.

Бу риваятьне, бер-берсен тулыландырып, Хөснимәрдән ага белән шул ук авылда яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераны Хәниф ага Миңнеханов сөйләделәр.

Хәниф ага риваятьләре буенча, патша заманында Кормаш авылы җирсезлектән интеккән. Чөнки ул башкорт булып язылмаган, типтәр (ягъни, көчләп чукындыруга каршы торганы өчен, Идел-Чулман буйларыннан куылган, тибәрелгән халык) булып калуны артыграк күргән. Ә типтәргә җир дә, болын да юк. Ләкин авыл халкы баш имәгән, көрәшкән һәм бу көрәш бөтенләй үк нәтиҗәсез дә калмаган: Кормаш халкына җир бирелгән, тик үз авыллары яныннан түгел, ә утыз чакрымдагы Чуракай авылы тирәсеннән. Бу, әлбәттә, күз буяу, халыкны мыскыл итү булган.

Күпме генә изелсә дә, гел кайгырып-хәсрәтләнеп кенә яшәмәгән халык, җырларга-биергә, күңел ачарга, кунакка йөрешергә дә вакыт тапкан. Хөснимәрдән ага бу якларда булган җыеннарның барысын да яхшы хәтерли. Әйтик, Нарат асты җыены Чалманарат авылын-

да узган. Бу вакытта инде кыраулар бетеп, игенчеләр тары, карабодай чәчкән, кыяр, кавын утырткан булган. Шуннан соң, атна саен, алар башка җыеннарга юнәлгәннәр: Олы җыен, Җамалы җыены, Кара Зирек, Элбәк, Бикә җыены, Туйра, Энҗел. Иске Кормашта уза торган Бикә җыены Туйбикә әби исеме белән бәйле. Имештер, яу килгәч, дошманнардан качып, Туйбикә әби Болгар иленнән Шәбез елгасы буена килеп утырган. Әлеге әби салдырган күперне әле дә Бикә күпере дип йөртәләр икән. Халык аның исемен җырга кертүне дә кирәк тапкан:

Безнең ындыр артларында
Була кызлар уены,
Унике айга бер килә
Безнең Бикә җыены.

Төрле җирләрдә таулар, урманнар, чишмәләр күреп, сокланганыбыз, аларның матур яңгырашлы исемнәрен кабатлап ләззәтләнгәнебез бар. Бактың исә, шигъри йөрәкле халкыбыз гади генә чокырларга да гүзәл исемнәр кушкан: Хөрмәкәй, Кымызлы күл, Нечкә әйлән, Чишмә башы чокыры, Өшмышты чокыры, Торна сазы, Кара тәкә, Сулы куак, Күперле сыза, Мүк юлы, Җилпәк нарат, Ташлы елга чокыры, Кушнарат, Алдырыш башы чокыры һ.б. Риваятьләргә караганда, борын заманда бу урыннарда кара урманнар һәм сазлыклар булган. Халык урманнарны кисеп иген чәчкән. Заманнар узу белән, сазлыклар кибеп беткән. Әлеге чокырлар шул сазлыкларның урыннары имеш.

Авыллар тарихында халык тарихы, нәселләр тарихы, гаиләләр һәм аерым шәхесләр тарихы чагыла. Ахыр чиктә, Ватан тарихы да әлеге тарихларның кушылуыннан тора бит. Халкыбызның борынгыдан килгән бер күркәм таләбе бар: һәркем ата ягыннан үзенең җиде бабасын белергә тиеш. Кайбер нәселләрнең зирәк вәкилләре, нәсел үсешен даими яза барып, зур-зур шәҗәрәләр төзегәннәр. Әнә шундый зур һәм бер үк вакытта гаҗәеп камил эшләнгән шәҗәрә миңа Яңа Балтач авылында очрады. Аны Камал Закиров (1896–1967) язып калдырган. Ул шушы авылда беренче колхозны оештырган, районда беренче электр станциясен төзегән хөрмәтле ил агасы булган. Шәҗәрәне Камал ага сугышка кадәр үк эшли башлаган булган, тик сугыш вакытында аны югалтканнар. Сугыштан соң ул үзенең әлеге шөгылен өр-яңадан башлый, төрле документлардан, архив материалларыннан файдаланып эшне ахырынача җиткерә. Шәҗәрә, Болгар иленә монгол яулары ябырылгач, бирегә килеп утырган Чуяр бабай исеме белән башланып китә. Аннары аның улы Чарлакдиван, аның

улы Шөгыльлүәт (варианты – Шәгълүвәт), аның улы Тимиян, һәм шул рәвештә дәвам итеп, нәсел агачының ботакларын түбәндәге исемнәр тәшкил итә: Туктамыш, Көтексә, Нугай, Яхшыхуҗа, Уразак, Исәндәүләт, Тунлачы, Байтирәк, Тайдым, Карач, Мөслим. Мөслим бабайның балалары Әхмәт, Мөстәкыйм һәм Мөрсәлим XVIII гасырда, Иске Балтачтан китеп, Яңа Балтачка нигез салганнар. Нәсел агачының иң очтагы ботакларын 60 нчы елларда туган балалар тәшкил итә. Ана артыннан иярә килгән балалар, авылны ташлап читкә китүчеләр, Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр һәм сугышта һәлак булучылар аерым билгеләр белән тамгаланган. Шәҗәрә зур кәгазьгә тушь белән матур, тигез итеп язылып, пыяла рамга куелган. Исемнәр хәзерге алфавит белән дә, гарәпнеке белән дә язылган. Теләгән һәр кеше аны килеп карый алган, үзенең бабаларын тапкан.

Чат авылында яшәүче колхоз ветераны Таһир Ногманов та үз авылының тарихын тәфсилләп сөйләде. Ул шәхес буларак та кызыклы кеше. Таһир ага ярлы крестьян гаиләсендә егерменче бала булып дөньяга килгән. Колхоз төзүдә һәм аны аякка бастыруда зур көч куйган. Медальләре, мактау кәгазьләре бар. Гаделсезлекне җене сөйми. Уртача гына тормышта яшәүче бу ветеран ел саен бер айлык пенсиясен Тынычлык фондына биреп бара. Шул уңай белән, Тынычлыкны саклау буенча Татарстан республика комитетыннан рәхмәт хаты да килгән үзенә...

Тарихка караган мәгълүматлар күбесенчә ир-ат даирәсендә булса, бәет-мөнәҗәт кебек әсәрләр, башлыча, хатын-кызлар тарафыннан башкарыла. Иске Кормаш авылында, мәсәлән, бәет һәм мөнәҗәтләрне мин 87 яшьлек Гыйльменур Кәшшапова һәм 70 яшьлек Бибидәнә Маннапова дәфтәрләреннән күчереп алдым.

Әбиләрдә бәеткә мәхәббәт аеруча зур. Кыр Каентүбә авылында яшәүче 71 яшьлек Хафаса Гәрәева, үзенең апасына багышлап чыгарган бәетен укып күрсәтте. Апасы, читтә картаеп, үз үлеме белән вафат булган. Әмма шушы үлем нечкә күңелле туганын гомерендә беренче тапкыр бәет чыгарырга мәҗбүр иткән. «Түтекәем турында минем моңнарым» дигән бу бәеттә күпне күргән халкыбызның олы хәсрәтләр кичергәндә дә сәламәт калган саф күңеле, шигъри йөрәге һәм балдай татлы теле ярылып ята.

Үзәккәйләремә үтеп,
Йөрәккәйләремә төшеп,
Түтекәем үлеп китте,
Кайгы утларына күмеп, –

диелә бу бәеттә. Анда күбесенчә сүзләрнең әнә шундый иркәләү формасы кулланылган: туганкайлар, бакчакайлар, васыятькәйләр, башкайларың, бәбекәйләрең, күлмәккәйләрең, бәхеткәйләрең. Хафаса ханым гади кебек тоелган сүзләргә дә, кушымчалар ярдәмендә, йомшаклык төсмере өстәгән (тилмерепләр көтү, гаҗәпләргә калу һ.б.).

Актык басуларың булган,
Түтекәм, тупсакаема;
Түзә алмыйм, түтекәем,
Сине сагынукаема.

Адәм баласының башына күп бәлаләр гыйбрәт алмаудан яисә ала белмәүдән килә. Ә бәетләрнең күбесендә сурәтләнгән трагедия халык өчен зур гыйбрәт ул. Бер бәет әллә нинди һәм әллә ничә кисәтү хатларына караганда да тәэсирлерәк булырга мөмкин! Мәсәлән, бәетләрнең берсендә башлангыч сыйныфта укучы кыз баланың үз иптәшләре белән качышлы уйнаганда кинәт юкка чыгуы сурәтләнә. Иртәгесен мәгълүм була: су торбасы өчен казылган чокырга качкан бу баланы җир тигезләп йөрүче бульдозер күмеп киткән икән. Җан өшеткеч вакыйга. Әле генә йөгереп йөргән сабый бер мизгелдә юк булган – терелэй күмелгән. Хәзер авылда аның бәете генә яши. Очраклы хәл, әмма балаларның үзләренә дә, игътибарсыз олыларга да зур сабак, үтемле гыйбрәт бу.

Әнә шундый бәетләрне язып алганда ирексездән кешеләрнең йөрәк яраларына да кагылып узарга туры килә. Нишләмәк кирәк, тормыш «Баламишкин» көеннән генә тормый шул...

1981 елгы экспедициядә, 6 көн дәвамында 5 авылда (Актаныш, Иске Кормаш, Кыр Каентүбә, Чат, Яңа Балтач) булып, 58 берәмлек фольклор материалы тупланды. Шушы материаллардан 5 әсәр 13 томлык фольклор җыелмасының «Риваятьләр һәм легендалар» томында басылды.

Актаныш районының фольклорга бай төбәк булуында шик юк иде, һәм бу янә расланды. Бирегә тагын, тагын килергә кирәк, дип кайттым мин. Мотлак килергә! һәм... мондый форсат тагын 6 елдан соң насыйп булды.

Ниһаять, 1987 елның җәендә хезмәттәшем Сәлим Гыйләҗетдинов белән икәү, Идел, Чулман һәм Агыйдел дәрьяларын кичеп, янә Актаныш җиренә аяк бастык. Бу юлы без 10 көн дәвамында 5 авылда булдык: Зөбәер, Иске Уръяды, Күҗәкә, Түке, Чәчер.

Сәяхәтебез Иске Уръяды авылыннан башланды. Бу авылның аксакалы 77 яшьлек Минсалих Кәримовның гаҗәеп шәҗәрәсе бар

икән. Минсалих ага һәркем белергә тиешле җиде бабаны гына түгел, хәтта ун бабасын белә. Иң борынгы бабасы Әсфиян Казан ягыннан килгән икән. Әсфиянның улы – Чурай, Чурайның улы – Сырам, аның улы – Уразай, аның улы – Үткә, аның улы – Шешә. Болар барысы да борынгы төрки исемнәр. Шуннан соңгы бабалар: Мөхәммәт, Колшәриф, Ибраһим, Мөхәммәтхафиз.

Минсалих аганың әтисе – Мөхәммәткәрим. Аның сигез улы булган. Улларының исемнәре дә я Мөхәммәт, я Мулла дип башлана, бары кече улына гына, миңе булганлыктан, Миңлесалих дип кушкан. Халык аны Минсалих дип кенә йөртә, һәм шушы буын белән «Мөхәммәт»ләр, «Мулла»лар тәмамлана, «Миңле»ләр башлана. Минсалих аганың улы – Миңлефеликс, абыйсы Мөхәммәтҗанның уллары – Миңлефәвасим, Миңлеәҗеп. Ә әтисе белән бертуган абыйсының оныклары – Миңлешәриф һәм Миңлегабдулла.

Заманалар үзгәрә, нәтиҗәдә «Миңле»ләр дә тәмамлана. Нәсел агачының иң очындагы яфракларын заманча исемнәр йөрткән яшьләр тәшкил итә: Таһир, Васил, Альберт, Рамил.

Минсалих аганың шәҗәрәсе – әлбәттә, зур хәзинә. Тагын бер шундый ук борынгыдан килгән шәҗәрәне без, Әбүбәк ага Шәехов ярдәме белән, Күҗәкә авылында таптык.

Күҗәкәнең 82 яшьлек аксакалы Имаметдин Гыймазетдинов, бик мавыгып, авыл тарихын, элеккеге тормыш-көнкүрешне сөйли. Алар буынына тормышның ачысы-төчесе күп эләккән. Ләкин халык, тормыш авыр дип, кайгырып кына утырмаган, бәлки иң авыр дәверләрдә дә күңел ачуны кирәк санаган, бөтен авыл бердәм булып, рәхәтләнеп бәйрәм иткән.

Бәйрәмнәрнең иң күркәме ул чорда да сабан туе булган. Сабан туе хәзерге кебек җәй көне яисә язгы кыр эшләре беткәч түгел, бәлки борынгыча, язгы кыр эшләре башланыр алдыннан, ягъни апрель аенда уздырылган. «Сабан туенда ат та йөгерде, адәм дә йөгерде, кыз ярәшкән кешеләрдән бүләк тә җыйдылар, – ди Имаметдин ага, үзенең балачагын искә төшереп. – Көрәш мәйданы кипкән, сукмаклар салынган була иде, су эчәсе килсә, чокырга төшеп кар ашый идек».

Язгы чәчү тәмамлангач, озакка сузылган җыеннар чоры башланган. Крестьян агай, арбасына гаиләсен төяп, башка авылларга – туганнарына, дусларына яисә танышларына кунакка йөргән. Иң элек, май башында, күҗәкәлеләр Юа җыенына юнәлгәннәр. Әлеге җыен (хәзер инде исеме генә калган) Үмәнәй авылында өч атна буе һәр җомга саен уздырылган. Бу җыеннан көнендә үк кайтканнар, кунмаганнар. Имаметдин ага болай дип сөйли: «Егетләр-кызлар, тау

башына менеп, түгәрәк уены уйныйлар иде, ә өлкәннәр түбәндә, гармунга, скрипкәгә кушылып, җырлыйлар иде. Аннары Бикбау авылыннан Кәлимулла дигән кеше килеп, үзе җырлый, үзе бии торган иде. Гармунга кушылып, сандугач булып та сайрады, карга булып та кычкырды. Гаҗәеп кеше иде».

Шулай, Юа җыены белән юанып, майның өч атнасы узып та киткән, ә дүртенче атнада инде Күҗәкә халкы Олы җыенга Пучы авылына юнәлгән. Бирегә кунаклар шулай ук җомга көнне килгәннәр һәм ике яисә дүрт кич кунганнар. Бер яки өч кич кунарга ярамаган, чөнки алар – так саннар.

Июнь аенда Әмәкәй авылында Мәрди җыены, ә июль башында Иске Кормашта Бикә җыены узган. Бикә җыенында шулай ук дүрт көн кунак булганнар. Бурсык чишмәсе яланына яше-карты чыккан. Егетләр кунак кызлары белән танышканнар, түгәрәк уеннар уйнаганнар, олылар исә күбрәк вакытларын, гармун-скрипкага кушылып, җырлап уздырганнар.

Бикә җыеныннан соң, июльнең икенче җомгасында Ямалы җыены башланган, ә аннан соң халык Мәлкән дигән керәшен авылына Туйра җыенына юнәлгән. Бу инде соңгы җыен булган, Туйрадан кайтуга уракка чыкканнар. Хәер, кунаклар арасында кайвакыт бу җыенга икешәр җир[1] урак урып килүчеләр дә булган. Бәйрәм барыбер дүрт көн дәвам иткән.

Шулай итеп, урак алдыннан аек халык аек акыл белән, аек хискә бирелеп, кайгы-хәсрәтләрен онытып, ихластан бәйрәм иткән, күңел ачкан. Без Имаметдин агадан әнә шуларны белдек.

Менә инде без «өметсез» дип аталган һәм ике генә карчык яшәп калган Илтимер авылы яныннан узып, күпер аша Түке авылына килеп кердек. Биредә, нишләптер, безне кәкре койрыклар һау-һаулап каршыламады. Гомумән күренмәде алар. Соңыннан белдек: авыл җыены «маэмайларсыз гына яшәргә» дигән карар чыгарган икән. Казанның үзәк мәйданнарында да зур-зур эт туйлары күреп гадәтләнгән без фәкыйрьләрегезгә бу карар хәтта сәер булып тоелды.

Уйлап карасак, чыннан да, ни хаҗәтемә соң ул маэмай?! Урлашулар булса, иң элек, ишек-капкаларны бикләп йөрерләр иде, ә биредә алар тәүлек буе ачык. Дөрес, кайвакыт йозаклы ишек очрый очравын. Андый вакытта хуҗаларның кайтканын бераз көтеп торырга туры килә. Әнә, хуҗабикә инде кайтып та килә. «Нишләп

---

[1] Чәчүлек җир мәйданын үлчәү берәмлеге: 2 дисәтинә, ягъни буе 80, иңе 60 саҗиннан гыйбарәт мәйдан.

тышта торасың, апаем», – ди ул, ягъни энем дигән сүз инде. «Соң, ишектә йозак ич», – дигәч, «И-и... ул бит фасун өчен генә. Аның ачкычы югалганга да биш-алты ел бар инде», – дип гаҗәпләндерә.

Шулай итеп, монда йозак өйдә кеше юклыгын гына белдерә икән.

Әгәр инде маэмайга мәхәббәтең зур икән, рәхим ит, асра, әмма ләкин бәйгә куй. Бәйдән ычкындырасың икән – ясинын да укып озат.

Менә шундый булып чыкты бу Түке дигән авыл. Анда этәч тавышы гына ишетелә. Хәер, тагын бер тавыш бар икән – матай тавышы. Биредә малайлар тәпи йөри башлагач ук матайга атланалар микән әллә дип, гаҗәпләнеп тордык. Басмасына аяклары да җитми, ә үзләре җилдерәләр генә. Яңгырсыз җәйге челләдә кирәксә-кирәкмәсә дә арлы-бирле тыз-быз чабып, авыл урамнарын тузанга күмеп йөргән ташбашларның бу кыланышларын бик үк өнәп бетермәсәк тә, күңелне бер сөенеч рәхәтләндереп торды: яшьләр бар биредә, техника белән җенләнгән балалар бар! Димәк, авыл яшәячәк. Югыйсә, күршедәге үк Чәчер авылында 72 хуҗалык исәпләнсә дә, яшьләр ике генә бөртек, диделәр. Алары да читтән килгән белгечләр икән. Шуннан авылның киләчәген күзаллау кыен түгел инде. Ә Түкедә без матайга атланып чапкан үсмер кызларны да күрдек хәтта.

Хуш... Сүз башым бит шүрәле дигәндәй, мин бит әле биредә әкият, җыр, бәет юллап йөрүче. Әйе, Фәрзәнә Солтановадан нәкъ менә шүрәле турындагы, Мөслимә Солтановадан өч бур, Гыйльмегали Ганиевтән бай һәм чегән турындагы әкиятләрне, ә Нурлыҗиһан Зариповадан бәет һәм мөнәҗәтләрне язып алганнан соң, мин 85 яшьлек Хәмидә әби Халикова капкасына килеп җиттем.

Хәмидә әби җырлап торды, ә мин аның җырларын кәгазьгә төшереп тордым. Ниһаять, ул: «Җыруым бетте», – диде. Таныш сүз бу, аны һәр информанттан ишетергә мөмкин. Ләкин «бетте»дән соң да, гадәттә, күп нәрсә искә төшүчән була. Әмма Хәмидә әбинең ноктасы катгый булган икән. Шуны ул тагын бер куплет җыр белән ныгытып куйды:

Бишмәтеңдә биш төймә,
Алтынчысы – каптырма;
Бар җыруым шушы инде –
Юк җыруны таптырма!

Менә шулай. Ышанабыз – җыр сандыгының бушап калуы да бик мөмкин.

Ә менә Зөбәер авылында яшәүче 72 яшьлек Мөзәянә Садыйкова 200 куплет җыр яздыргач, мин аңардан үзем сорадым: «Беттеме?» – дидем. «Һәй, җыру бетми инде ул, – диде Мөзәянә апа. – Тик менә искә генә төшми тора».

Хәер, бу 200 кыска җырны, ягъни дүртьюллыкларны искә төшерергә Мөзәянә апаның Пермь өлкәсеннән кунакка кайткан кызы Фәйрүзә дә ярдәм итте. Ул үзеннән берни дә өстәмәде. «Барысы да әни җырлары», – диде. Аның хәтере дә галәмәт икән – яшь чагында әнисе җырлаган җырларны әлегәчә исендә тоткан! Югыйсә күп гомер узган бит инде, ул үзе дә 50 не тутырган. Алар аналы-кызлы, бер-берсе белән ярышкандай, җырларны искә төшереп, икесе бер үк вакытта әйтеп яздыралар. Әйтеп торып яздырганда бер кешене ике кеше язса гына өлгереп була. Димәк, ике кешене язганда дүрт писер таләп ителә, ә мин берүзем. Язып өлгерә алмагач, кайбер куплетлар шунда ук онытылып та китә. Аннан бергәләп эзли башлыйбыз: «Беттеме?» дип соравым да «җитте инде» дигән мәгънәдә түгел, ә арыган бармакларны язгалап алганда болай гына, әлеге дә баягы «фасун» өчен генә, әйтелгән сүз. Югыйсә фольклорчы беркайчан да язып туймый, әсәрләр күп язып алынган саен: «тагын, тагын» дип кенә тора ул. Мин дә, бармакларым бераз язылгач, әлеге шул «тагын»ны кабатлыйм. Мөзәянә апа: «Искә төшми бит әле, тукта, бер әйләнеп керим», – дип, тышка чыгып китте һәм озакламый килеп тә керде. «Биш җыру искә төште», – диде ул, зур канәгатьлек белән.

Ишек алдым яшел чирәм –
Атларга кимертмәгез;
Чит илләрдә ялгыз башым –
Хатларга тилмертмәгез.

Мөзәянә апаның күп җырлары «сандугач» дип башлана иде. Соңыннан санадым: алар 31 данә. Алардан кала 20 җыр «Кулымдагы йөзегемнең» дип башлана. «Алма» һәм «Алмагач» дип башланганнары – 15, «Гармун» һәм «Уйна, дустым» дип башланганнары – 12. Аннан инде «Агыйдел», «Җырлыйк әле», «Китә казлар», «Тәрәзә төбем» дип башлана торганнар һәм башкалар. Арада шаян җырлар да бар.

Шаян җырлар уңае белән Мөзәянә апа үзенең җор телле авылдашы Нургалине искә төшерде.

Нургали үзенең хәләл җефете Саҗидә белән чүкердәшеп кенә яшәп ятканда Бөек Ватан сугышы башлана. Саҗидә иренә язган сагыну-сагыш тулы хатларының азагына җырлар да теркәп җибәрә. Аның бер җыры болай:

Стена көзгем ватылды
Ал пудр ягынганда,
Төннәргә көннәр ялгана
Өзелеп сагынганда.

Шаян кеше – һәрвакыт шаян инде ул. Утлы дәһшәт эченнән, салкын окоптан Нургали үзенең хатынына җавап юллый:

Стена көзгең ватылгач,
Ник пудр ягынасың?
Ул пудрларны ягынгач,
Ник мине сагынасың?

Хатынының икенче җыры:

Одеал микән, юрган микән
Синең ябынганнарың?
Син дустыма мәгълүм микән
Минем сагынганнарым?

Ире болай дип җавап бирә:

Одеал да юк монда,
Юрганнар да юк монда,
Көне-төне пуле ява –
Синең кайгың юк монда.

Күренеп тора: Нургали солдат – Василий Тёркиннар токымыннан. Һәр халыкның үз Тёркиннары булган, бар һәм булачак.

Мөзәянә апа тагын тукталып калды. Аннары җәһәт кенә торып, үзенең 72 яшьтә булуын да онытып, җиңел генә идән астына төшеп китте һәм шунда ук кире килеп чыкты. Тагын бер җыр артты:

Җаныемның исемнәре
Кулымдагы йөзектә,
Төштем кайгы күлләренә –
Чыгалмыймын ничек тә.

Җырчыбыз янә аска чумды, һәм бераздан апаның башы кабат күренде, янәшәдә «варенҗе» банкасы пәйда булды. «Кара син аны, базда яткан икән җырулар», – диде ул. Дәфтәргә тагын берничә куплет өстәлде:

Алларын сана миңа,
Гөлләрен сана миңа,
Өйләнмәгән булсаң гына
Елмаеп кара миңа.

Алым син, җаныкаем,
Гөлем син, җаныкаем,
Ярларымның азаккысы
Булырсың, җаныкаем.

Көмеш йөзеккәем сынды –
Бакырын киям инде;
Көзге яф(ы)раклар кебек
Саргаеп кибәм инде.

Шулай итеп, Зөбәер авылының хезмәт ветераны Мөзәянә апа Садыйкова җырлар саны буенча рекорд куйды – аның дүртьюллыклары 232 данәгә җитте. Дөрес, мондый кыска җырларны без кайбер һәвәскәрләрдән күбрәк тә алып кайтканыбыз бар. Әмма алар альбомнарга, дәфтәрләргә тупланган була иде. Ә хәтердән шул кадәр җыр яздыручы безгә беренче мәртәбә очрый. Хәтер дисәң дә хәтер!

Мөзәянә апаның җырлары гына түгел, һөнәрләре дә хәзинә икән! Ул колхозда эшләгән, балалар үстергән, палас тукыган, чабата үргән... Кирәк икән, бүген дә тукый да, үрә дә ала. Кирәкми генә. Шулай да, бүгенге яшьләргә әлеге һөнәрләрне гамәлдә күрсәтәсе иде. Гыйбрәт өчен.

Безне озатканда ул болай дип җырлады («Баламишкин» көенә):

Түбәтәең сәйләндер,
Сәйлән ягын әйләндер;
Бик сагынган чакларыңда
Зөбәердән әйлән бер.

Әйләнербез, нигә әйләнмәскә!

Зөбәернең матур су буйлары, аның искиткеч буасы, ямь-яшел чирәм белән капланган киң урамы, бигрәк тә без очрашкан гүзәл кешеләре сагындырыр, әлбәттә. Аннары бит Мөзәянә апа безне озатып калганда да «җыру бетми инде ул» дип кабатлаган иде. Бәлки әле исенә төшеп, аларны язып та куйгандыр. Әйләнербез. Боерган булса, әйләнербез. Барыбыз да сау-сәламәт кенә булыйк!

Һәм менә 22 ел гомер узганнан соң, без – тагын Актаныш җирендә. Профессор Дария Рамазанова җитәкләгән әлеге «комплекслы экспедиция»дә тел, әдәбият, тарих, музыка һәм фольклор өлкәсендә эшләүче галимнәр һәм аспирантлар катнашты. Экспедициянең эше Актанышка – 300 ел һәм районының оешуына 80 ел тулу уңаеннан тантаналы чараларга әзерләнү вакытына туры килде.

Юбилейлар уңаеннан, «Актаныш таңнары» гәзите район авылларына бәйле тарихи белешмәләр, риваятьләр, өлкән буын

вәкилләренең истәлекләрен бастыра башлаган. Гәзитнең бер санында педагог Гавис Гаязов тәкъдим иткән материалдагы риваятькә караганда, Актанышка хәзер 300 түгел, ә 470 яшь булырга тиеш. Әлбәттә инде, риваять тарихи дәлил була алмый, әмма халыкта шундый фикер дә бар икән. Хәтта бу фикерне раслый торган ниндидер документ та булган имеш.

Ә район тарихындагы әлегә кадәр ачыкланмаган мәсьәләләргә килгәндә, аларның берсе – авыл зиратларындагы гарәп хәрефләре белән язылган кабер ташларының укылмаганлыгы булып чыкты. Шуңа күрә кайбер могтәбәр затларның каберләре дә әлегәчә мәгълүм түгел икән. Бу җиңел булмаган эшне хезмәттәшебез – тарихчы-археограф Рәшит Кадыйров бик уңышлы башкарып чыкты.

Фольклорчылардан без дүрт кеше идек: фәнни хезмәткәр Ильмир Ямалтдинов, аспирантлар Гөлия Гыйләҗиева, Алсу Гайниева һәм мин. 8 көн дәвамында Актаныш районының 14 авылында булдык. Әлбәттә, татар мохитендә фольклор хакимлек иткән чорда бу вакыт кысасында эшләү өчен 4–5 авыл да җитәр иде, әмма хәзер заманы башка, кешеләр башка, рухи мираска мөнәсәбәт башка... Фольклор бүгенге көндә, аерым очракларны исәпкә алмаганда, нигездә, 60 яшьтән өлкән кешеләрдә генә очрый. Кешенең уртача гомер озынлыгы шушы сан тирәсендә тирбәлгән безнең илдә фольклорчыларның әңгәмәдәшләре (информантлары) күпме булуын чамаларга мөмкиндер. Шуның өстенә авылларның зурлыгы да элеккечә түгел ич. Дөрес, районның 540 хуҗалыктан торган Татар Суксуы, 283 хуҗалыктан гыйбарәт Такталачык кебек чагыштырмача зур авыллары бар барын. Әмма алар тирәсендә 26 йортлы Түмерҗә һәм 2 генә йорты калган Түбән Карач кебекләре дә бар бит әле...

Түбән Карачта 76 яшьлек Гөлҗәннәт әби яши. Әби фикеренчә, аның авылын, ике йорт кына калсын, дип, шүрәле каргаган булган. Аңарда башка фольклор әсәре булмаса да, без канәгать булдык, чөнки әби бернидән дә курыкмый, шушында яши бирә. Фамилиясе дә – Арсланова.

Ә менә сәнгать фәннәре докторы Гали Арслановның туган авылы Түмерҗәдә дөньяга килгән 78 яшьлек Җәмилә әби Шәмсиева, хәтере начарлыктан зарланса да, безне буш кул белән чыгармады – ике куплет кына булса да җыр яздырды. Берсе болай:

Агыйделдә ике сал:
Берсе – имән, берсе – тал;
Коммунизм яшәгәндә
Яши алмый капитал.

Совет халкының бу буыны әнә шундый җырлар җырлап үскән.

Уразай авылында яшәүче Зәкия әби Халикова да җыр ярата. Аңа 96 яшь. Дөм сукыр булса да, аның күңелен җыр яктырта. Тукай вафат булган 1913 елда туган Зәкия әбигә, әйтерсең лә шагыйрьнең халык җырларына булган мәхәббәте дә күчкән. Биш куплет җыр яздырды Зәкия әби.

Сабырлар ит, җаныкаем,
Сабырлар – сары алтын;
Мин сабырлар итәлмимен –
Эчләрем тулы ялкын.

Инде җыр турында сүз чыккан икән, авылларда җырның иң популяр жанр булуын искәртеп узыйк. Барлыгы 27 лирик җыр, 3 уен җыры һәм 72 кыска җыр (дүртьюллыклар) тупланды. 72 саны бу экспедиция хисабында иң зур сан булып тора. Ә бит әлеге шартлы рәвештә «кыска җыр» дип атап йөртелә торган, үзенә беркетелгән махсус көе булмаган һәм төрле көйләргә башкарыла ала торган мондый дүртьюллык поэтик әсәрләрне элгәреге экспедицияләр меңнәрчә данә туплыйлар иде. Мәсәлән, 1948 елгы экспедиция Актаныш районыннан 4288 кыска җыр алып кайткан! Бүген инде моңа ышануы да кыен. Әле соңгырак чорда да кыска җырлар шактый күп җыела иде. Мәсәлән, алдарак әйткәнемчә, 1987 елгы экспедиция вакытында Зөбәер авылында 72 яшьлек Мөзәянә Садыйкова, Фәйрүзә исемле кызы белән бергә, 232 кыска җыр әйтеп яздырды. Ул вакытта Актаныш районы буенча җәмгысе 267 кыска җыр тупланды. Ә быел, әйткәнемчә, 72 генә. Рухи мирасыбызның иң популяр, иң ләззәтлесе булган, күңелләрне айкап ташлый торган, җилкендерә, уйландыра, моңландыра, елата, юата, рухландыра, дәртләндерә торган төре – халыкның үз җыры, газиз баласыдай якыны, аның җан азыгы югалып бара икән ләбаса... Шуннан инде фикер йөртик: кайсы чор кешеләре рухи яктан баерак?

Кызганыч, рухи җәүһәрләр яшь буынга күчми, тапшырылмаган мирас булып, өлкәннәр күңелендә кала, әкренләп онытыла һәм, ахыр чиктә, бөтенләй югала. Югалган байлыкның күләмен кем генә исәпләп чыгарыр икән...

Мөнәҗәт әйтүче әбиләр исә без булган авылларның күбесендә очрады. Барысы 18 берәмлек (456 юл) мөнәҗәт язып алынды.

Актаныш төбәгендә бигрәк тә бәетләр популяр икән. Аеруча Такталачык авылында. 23 бәетнең (1083 юл) 16 сы биредә тупланды. Күбесе Альберт Яркәев чыгарган бәетләр. Шушы авылда үскән

яшь шагыйрь Ленар Шәехнең дә бу өлкәдә үз өлеше бар. Ә бәет өчен сәбәп, ни кызганыч, тормышта булгалап тора шул.

Инде фольклор байлыгының төп үлчәме булган әкиятләр турында берничә сүз. 1948 елгы экспедиция вакытында әкиятчеләр күп авылда булган әле. Әлеге сәяхәт нәтиҗәсендә, алда әйтелгәнчә, барысы 37 әкият тупланган. Шушы экспедициядә студент буларак катнашкан Нурихан Фәттахка Әнәк авылында яшәүче 14 яшьлек Рахмай Хисмәтуллин да (икесе дә язучы булып танылдылар, инде урыннары җәннәттә булсын) дүрт әкият сөйләгән. Димәк, ул чорда фольклор әле балалар телендә дә актив яшәгән.

1987 елгы экспедиция материаллары арасында, әйткәнемчә, Түке авылында өлкәннәр авызыннан язып алынган 3 кенә әкият саклана. Безнең соңгы 2009 елгы экспедициябез исә Актаныштан бөтенләй әкиятсез кайтты. Димәк, әкият учагы тәмам сүнгән... Кызганыч, бу хәл һәркайда да шундый хәзер.

Ә менә бу сәяхәтебездә фольклорның чагыштырмача сирәк очрый торган, атап әйткәндә, сөйләк жанрына караган әсәрләргә юлыгуыбыз экспедициянең үзенә күрә бер табышы дип бәяләнергә хаклыдыр. Реаль тормышта күптән түгел булып узган игътибарга лаек вакыйга сурәтләнгән мондый әсәрләр турында фольклорчыларның үз араларында да әлегә бердәм фикер юк. Кемдер аны истәлек белән тиңли, кемдер сөйләү үзенчәлеген жанрның төп билгесе итеп саный. Дөресен әйткәндә, бу жанрга игътибар җитенкерәми, шуңа күрә андый әсәрләр аз җыела да инде.

Менә, мәсәлән, Күҗәкә авылында Рамил Хәйбиев сөйләгән бер әсәр.

Вакыйга Сталин хакимлек иткән чорга карый. Авылның бер кешесен төрмәгә утыртырга телиләр. Әмма гаеп табарга кирәк бит. Ат белән эшли торган бу абзый кич эштән кайтыр вакытта аның юлына бер капчык ашлык ташлыйлар. Абзый шул капчыкны алып арбасына салса, ул инде урлаган саналачак. «Пүнәтәйләр күзәтеп тора. Бәхеткә, абзый арбада теге капчык ягына түгел, икенче якка карап утырган була. Шулай итеп, ул бәладән котылып кала. Соңрак, бу хәлләр мәгълүм булгач, ул үзен Алла саклаган, дигән нәтиҗәгә килә.

Тормышта булган вакыйга турындагы әлеге әсәр – сөйләк жанрына бер мисал. Ә беренче зат авызыннан сөйләнсә, ул истәлек булыр иде. Истәлек исә фольклор әсәре була алмый, чөнки фольклор кагыйдәләренә туры килми. Әмма аның бик мөһим үз вазифасы бар. Бу экспедициядә фольклорчыларга 6 сөйләк һәм 12 истәлек язып алу насыйп булды.

Фольклорның башка жанрларына килсәк, 10 табышмак, 11 мифологик хикәят, 22 мәзәк, 31 мәкаль, берничә риваять һәм дистәдән артык авыл тарихы язып алынды. Халык уеннары турында 30 дан артык язма (уеннарның саны исә 5-6 гына) тупланды.

Турыдан-туры фольклорга карамаган материаллар да читтә калмады: шәҗәрәләр, йолалар, шигырьләр һәм ономастикага кагылышлы 40 тан артык мәгълүмат тупланды. Иске Теләкәй авылыннан Әдибә Хәбирова (76 яшь) һәм Иске Ботады авылыннан Рәзилә Салихова (70 яшь) безнең Институтка гарәп графикасындагы язмалар, кулъязма һәм басма китаплар һәдия кылдылар. Бу материаллар барысы да Институт мирасханәсендә саклanaчак һәм фәнни тикшеренүләрдә файдаланылачак.

Гомумән, 2009 елгы экспедициянең эшчәнлеге уңышлы саналырга хаклы. Тугыз көндә без 14 авыл (Адай, Әҗәкүл, Әнәк, Ирмәш, Иске Сәфәр, Иске Уръяды, Карт, Күҗәкә, Такталачык, Татар Суксуы, Түбән Карач, Уразай, Чөгәнә, Чуракай) халкы белән танышып, җәмгысе 346 берәмлек хәзинә тупладык, шуның 270 е саф фольклор әсәрләре. Шигъри әсәрләрнең юл саны 1818 данә. Әлбәттә, бу нәтиҗәләрдә район хакимиятенең, җирле үзидарә башлыкларының, хуҗалык җитәкчеләренең һәм мәдәният хезмәткәрләренең ярдәме зур булды. «Юл газабы – гүр газабы», – ди халык. Әмма без юлда газап күрмәдек. Актанышлыларның олысы-кечесе безгә теләктәш булды. Шуңа күрә без Актаныш төбәгенең бик күп мәрхәмәтле затларына – җитәкчеләргә һәм мәгълүмат җиткерүчеләргә – олуг рәхмәтебезне белдерәбез.

## Әкиятчеләр төбәге

Апас районына фольклор буенча беренче фәнни экспедиция хәзерге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан 1947 елда оештырыла.

Әмма Апас якларында Бөек Ватан сугышына кадәр үк язучы һәм галим Гомәр Толымбай әкиятләр җыю белән шөгыльләнгән. Апас ягы – беренче чиратта, әкиятле як. Әкият исә – фольклорның төп жанрларыннан берсе. 1936 елда бу галим Иске Энәле авылында яшәүче 61 яшьлек Зиннәт Габитовтан 10 әкият (Институт мирасханәсе, 21 нче коллекция, 2 нче папка, 53–55, 57–61, 71, 73 нче саклау берәмлекләре) һәм Танай-Турай авылында яшәүче Кәлимулла Әхмәдишиннән 23 әкият (колл. 21, п. 1, сак. бер. 2–23, 25) язып ала. Озакламый Г. Толымбай, халык дошманы дип, кулга

алына һәм 1937 елда атып үтерелә. Бары Зиннәт Габитовның «Акыллы кыз» дигән әкияте генә 1940 елда нәшер ителгән «Халык иҗаты» исемле җыентыкта[1] басылып кала (әлбәттә, сөйләүчесе дә, язып алучысы да күрсәтелмәгән).

Телгә алынган сүз осталарының әкиятләре сугыштан соң гына дөнья күрә башлады. Бу чорда Институтта фольклорның, шул исәптән әкиятләрнең дә, фәнни басмалары планлаштырылып, аларда сөйләүченең генә түгел, әсәрне язып алучының да күрсәтелүе мотлак булганлыктан, әлеге фольклор осталары белән кабат очрашу зарурияте туа. 1947 елгы экспедициянең төп максаты да шушы хәл белән бәйле. Халык иҗаты секторының ул вакыттагы мөдире Х. Ярми туп-туры Г. Толымбай очрашкан әкиятчеләр янына юнәлә.

Танай-Турайдан 69 яшьлек Кәлимулла Әхмәдишин 1936 елда Г. Толымбайга 23 әкият сөйләгән булса, Х. Ярмигә шул ук кешедән, әмма хәзер инде 80 яшьлек карттан, бары 9 әкият язып алу насыйп була. Җитмәсә, аларның сыйфаты да галимне канәгатьләндерми, шунлыктан бу язмаларның берсе дә дөнья күрми. Язып алучы сыйфатында Х. Ярми, үз имзасын куеп, басмага әкият язмаларының Г. Толымбай вариантларын тәкъдим итә. Моның өчен Х.Ярмигә тел тидереп булмый, әлбәттә. Чөнки нәтиҗәдә, төрле абруйлы басмаларга кертелеп, фән мәйданына татар халкының Кәлимулла Әхмәдишин теле белән сөйләнгән классик әкиятләре чыга: «Алтын-көмеш сылу кыз», «Салам-Торхан», «Елан патшасы Шаһмара», «Ярлы егет белән Юха елан», «Аучы егет», «Ялчы белән сихерче кыз», «Патша малае һәм аның фәкыйрь күршесе», «Кем җиңүче?», «Балыкчы белән Гыйфрит» һ.б. – барысы 13 әкият.

Зиннәт Габитовның да, «Акыллы кыз»ыннан соң тагын ике әкияте – «Дию кызы һәм мулла белән бөлгән бай малае», «Аю-Әппәз» дигән әкиятләре дөнья күрә[2]. Бу әсәрләрнең чыганагы исә «институтның фольклор материаллары фондыннан» дип күрсәтелә[3]. Чөнки бу вакытта әле Г. Толымбай акланмаган була.

Зиннәт Габитовның әлеге әкиятләре татар фольклорының 13 томлык фәнни җыелмасындагы әкият китапларының беренчесенә[4] кертелде һәм тәүге тапкыр аларның Г. Толымбай тарафыннан язып

---

[1] Халык иҗаты / төзүчеләр Х. Ярми, А. Әхмәт. Казан: Татгосиздат, 1940. 98 б.

[2] Татар халык әкиятләре: Икенче китап / төзүчеләр Г. Бәширов һәм Х. Ярми. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Б. 194, 226.

[3] Шунда ук. Б. 384.

[4] Татар халык иҗаты. Әкиятләр (беренче китап) / томны төзүчеләр, искәрмәләрне хәзерләүчеләр Х. Гатина, Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. № 58, 79.

алынганлыгы күрсәтелде[1]. Шулай итеп, ниһаять, хакыйкать торгызылды.

Х. Ярми һәм Х. Гатина, 1947 елда бу әкиятченең шул ук Иске Әнәледә яшәүче 75 яшьлек абыйсы Сафиулла Габитов белән очрашып, аңардан да 11 әкият язып алалар (29 колл., 2 п., 13–21, 23, 25 сак. бер.). Бу әкиятләрнең язмышы бәхетле була: аларның 8 ен бүген төрле басмалардан укырга мөмкин. Бигрәк тә «Пртупи прапорщик», «Алтын башлы, көмеш beləкле» әкиятләре популяр.

Ул чорда Апас районында тагын бер оста әкиятче булган. 1950 елда Х. Ярми һәм Х. Гатина тарафыннан Олы Болгаер авылында яшәүче 62 яшьлек Айтуган Максудовтан 16 әкият язып алына (40 колл., 1 п., 2–17 сак. бер.). Шуларның 12 се басылып чыккан! Бу – бик зур сан, күркәм нәтиҗә.

Шул авылда Х. Гатина кызлар кулындагы дәфтәрләрдән 96 кыска җыр да күчереп ала.

Чирек гасырга якын вакыт узгач, Г. Ибраһимов исемендәге институт хезмәткәре буларак, Апас якларында миңа да булырга туры килде. 1973 елда Урта Балтай, Шәмәк, Түбән Балтай, Кызыл Тау, Тутай, Чирмешән, Аюкөйдергән, Хуҗа Хәсән авылларында халык теленнән 59 әкият, 17 бәет (2292 юл), 16 табышмак, 2 мәзәк һ.б. жанрларга караган тагын берничә әсәр язып алу насыйп булды.

Ул чорда бу төбәктә әле әкиятчеләр һәр авылда очрый иде. Аюкөйдергән авылында яшәүче 76 яшьлек Сабир Шакиров, мәсәлән, 21 әкият сөйләде. Кызыл Таудан Нәгыймә Дәминова 8, ә Урта Балтайда Җәләлетдин Гайнетдинов 6, Түбән Балтайдан Хәсән Сибгатуллин 5 әкият яздырды.

Урта Балтайда яшәүче 88 яшьлек Җәләлетдин Гайнетдинов әкиятчеләрнең иң өлкәне булса, иң яшь әкиятче дә шушы ук авылда булып чыкты. Ул – 21 яшьлек Әлфинур Хисамова иде. Бу кыз әбисеннән ишеткән өч әкият сөйләде, һәм шуларның берсе татар фольклоры җыелмасында (әкиятләрнең өченче китабында) басылып та чыкты[2]. Аның калган әкиятләре 2011 елда дөнья күрде[3]. Бүген инде әлеге кыз – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфинур Хисамова, – Татарстан телевидениесендә балалар өчен «Күчтәнәч» тапшыруын алып баручы буларак, бөтен татар

---

[1] Шунда ук. Б. 394, 398.

[2] Татар халык иҗаты. Әкиятләр (өченче китап); томны төзүче, кереш мәкаләне язучы, искәрмәләр әзерләүче Л. Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. 238 (№ 99).

[3] Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. Казан, 2011. Б. 320, 365.

дөньясына таныш шәхес. 2010 елда «Күчтәнәч» тапшыруы балалар өчен милли телләрдә алып барыла торган тапшырулар конкурсында Россия күләмендә беренче урынны алды. Ихтимал, әкиятләр дөньясы белән танышлык әлеге фидакарь затның профессиональ эшендә дә ярдәм итми калмагандыр. Өстәп шуны да әйтик, бу игелекле кыз, үз районының патриоты буларак, 1973 елгы экспедиция материалларын эшкәртүдә дә безгә зур ярдәм күрсәтте.

Ниһаять, югарыда искә алынган очрашулардан соң 37 ел узгач, Г. Ибраһимов исемендәге институт хезмәткәрләре һәм аспирантлары, фольклорның бүгенге торышын өйрәнү максаты белән, 2010 елның җәендә тагын Апас төбәгенә юнәлде. Бу юлы без, фольклорчылар, өчәү идек: аспирантлар Алсу Гайниева, Айнур Сөнгатов һәм мин. Без 13 авылда булдык (Коштаулы, Колгына, Дәвеш, Түбән Балтай, Кызыл Тау, Багыш, Олы Бакырчы, Дәүләки, Иске Йомралы, Идрәс-Тинки, Табар Черкене, Урта Балтай, Тутай). Бу юлы 30 дан артык информанттан 74 берәмлек авыз иҗаты әсәрләре язып алынды. Табышлар түбәндәге жанрларга карый: әкият – 3 данә, мәзәк – 2, бәет – 14 (779 юл), мөнәҗәт – 13 (441 юл), лирик җыр – 2 (12 юл), кыска җыр (дүртьюллыклар) – 21 (82 юл), табышмак – 1, риваять – 6, легенда – 2, мифологик хикәят – 8 данә.

Экспедиция барышында, әйткәнебезчә, 14 бәет язып алынды. Узган экспедиция белән чагыштырганда берничә әсәргә ким булып, юллар саны буенча өч тапкыр калышса да, фольклорыбызның бу жанры әле халыкта яши. Әмма авылларда бәет әйтүчеләр очрамый хәзер. Нәтиҗәдә бу әсәрләр бары язма рәвештә тарала. Әсәр телдә яшәми икән, ул инде эшкәртелми, шомармый, вариантлары барлыкка килми, таралышы да чикле дигән сүз. Ягъни, теге яки бу бәет аны язган кешенең шәхси иҗаты булып кына кала. Хәзерге вакытта бәет жанрының яшәү формасы әнә шундый. Яңа бәетләрдә сурәтләнә торган фаҗигаләрнең тормышта типик һәм күпсанлы булуы да теге яки бу әсәрнең таралу географиясен шактый чикли. Әмма бәетләрнең әле дә иҗат ителүе халкыбызның бу жанрга XXI гасырда да битараф булмавын күрсәтә. Мәсәлән, Иске Йомралы авылында яшәүче Әминә Мингазыева, Кызыл Таудан Шәүкәт Вафин бәетләрне аеруча актив иҗат итәләр. Аларның берничә бәете алдарак күрсәтелгән «Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас» китабында басылып та чыкты.

Халык арасында йөрүнең, фольклор туплаудан тыш, гыйбрәтле язмышлы, гаҗәеп кешеләр белән очрашу, аралашу кебек күркәм яклары да бар. Мәсәлән, Багыш авылында без Ватан сугышы ветераны Фәһим Фәсхиев белән очраштык. Какча гәүдәле, үтә хәрәкәтчән

бу кешене 85 яшендә дип уйламыйсың да. Безнең фольклор белән, шул исәптән җырлар белән дә кызыксынуыбызны белгәч, ул, гармунын сыздырып, җырлап та җибәрде:

Өй артында – шомыртым,
Тирәсендә – яшь каен,
Юк янымда якын дустым –
Ялгыз яши башкаем.

Әлеге җыр – аның җан авазы иде. Әйе, бу яшьтәге адәм балаларының күбесенә хас ул – ялгызлык дигән афәт. Фәһим ага да үзенең зур гына йортында япа-ялгыз яши. Әмма төшенкелеккә бирелми, бар вакыты эш белән уза.

Без аның белән фотога төштек. Бу рәсемгә күз салсак, бер якта җәйрәп елга ага, икенче якта чирәмдә берничә пар каен үсеп утыра, зәңгәр күктә болытлар йөзә, еракта бер авыл күренеп тора... Кыскасы, без – табигать хозурында.

Әмма чынбарлыкта без аның өендә утырабыз. Арткы пландагы күренеш – диварны капларлык зурлыкта эшләнгән рәсем-пейзаж. Бу хезмәт – йорт хуҗасының иҗат җимеше. Фәһим ага менә дигән рәссам икән ич. Аның өе дә остаханә кебек, бөтен җире төрле рәсемнәр, буяулар, пумала, кәгазь, тукыма һ.б. нәрсәләр белән тулы. Диварда Шишкин пейзажлары да эленеп тора. Болар да – Фәһим ага хезмәте, ул эшләгән репродукцияләр. Бу әсәрләрне оригиналлары белән чагыштыру мөмкинлеге булса, минем күзләр аларның аермасын сизмәс иде, мөгаен.

Фәһим ага, шуның өстенә, бакчачы да икән, бакчасында умарталар да тота. Умартачы булу һәркемгә дә тәтеми ул, бу эш бик мәшәкатьле. Ә менә Фәһим ага булдыра икән. Ул әле агач остасы – столяр, өстәвенә, пыялачы да. Тәрәзә рамнарын үзе ясый, пыяласын да үзе кисә. Өендәге артсыз урындыклар да – аның эше. Йорт түбәсен калай белән үзе яба. Кирәк булса, мич тә чыгара, итек тә баса. Андый кешенең картаерга вакыты буламыни инде! Яшьләрчә йөгереп кенә йөри 85 яшьлек сугыш ветераны.

Игътибарга лаек тагын бер фактны телгә алып узасы килә. Татар Черкене авылында татарлар һәм чувашлар яши. Мондый катнаш авылларда, гадәттә, фольклор булмый. Бу – безнең практикада расланган хакыйкать. Шуңа күрә, бирегә юл уңаенда гына кагылып чыгарга ниятләдек. Фольклор булмады, әмма игътибарга лаек бер хәлгә юлыктык биредә. Китапханәче Нина Ивановна Баранова-Орёл (Листратова) үзенең ире Сергей Пантелеймонович белән балалар йортыннан өч кыз алып тәрбия кылалар. Эш болай була.

Бу парның, уллары Сергейдан соң, балалары булмый. Кыз көтәләр, әлбәттә. Әмма, көтеп-көтеп тә булмагач, балалар йортыннан алып тәрбияләргә карар итәләр.

Балалар йортында аларга кызны үзләренә сайларга әйтәләр. Болар сөйкемле һәм тыйнак кына бер кызчыкны алырга булалар. Әмма җитәкчелек рөхсәт итми: «Бу кыз – өч бертуган кызларның берсе, без аларны аера алмыйбыз, рәхим итеп, башканы сайлагыз», – диләр.

Әмма күңелләре бу кызчыкка төшкәч, аңардан һич тә аерыласылары килми – үзара киңәшәләр дә кызларның өчесен дә үзләренә алып кайталар. Еллар уза, олысына инде хәзер 16 яшь.

Без бу гаиләнең шатлыклы чагына туры килдек: уллары Сергей кичә генә армия хезмәтеннән кайтып төшкән. Ә менә кызлар белән очраша алмадык – берсе дә өйдә юк иде. Ашыгыч булганлыктан, исемнәрен сорарга да онытканбыз.

Күренеп тора: әйбәт яши бу гаилә. Йортлары да яңа икән – Татарстан хөкүмәте салып биргән. Бу кадәресе бик яхшы.

Инде мәсьәләгә икенче яктан карасак... Тупырдап торган әлеге өч бәләкәч кызның әти-әнисе – татар авылында яшәүче ислам дине вәкилләре, эчкечелеккә сабышу сәбәпле, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән татар кешеләре. Уйласаң, уйланырлык бар ич. Кая барабыз без? Ә өч сабыйны тәрбиягә алган игелекле затлар – Нина Ивановна – чуваш милләтеннән, ире Сергей Пантелеймонович – украин. Аларга авыл халкы гына түгел, без барыбыз да рәхмәтле.

Инде кабат фольклорга килсәк, халык авыз иҗатының төрле жанрларына нисбәтле әсәрләр язып алынуга карамастан, Апас төбәге – башлыча, әкиятчеләр төбәге. Әмма, аңлашылса кирәк, бу төбәктәге халыкта фольклорның башка жанрларын үз иткән һәвәскәрләр булмаган дигән сүз түгел. Хикмәт шунда, Г. Толымбай да, Х. Ярми дә Апас төбәгендә беренче чиратта әкиятләр туплау максаты белән эшләгәннәр. Узган гасырның 70 нче еллары башында да Институт фольклорчылары экспедицияләрдә нигездә үзләре эшли торган жанрдагы әсәрләрне җыйдылар. Мин дә, эшем халык әкиятләре белән бәйле булганлыктан, шушы ук төбәктә халыктан нигездә әкиятләр язып алдым. Менә ни өчен Апас районында тупланган фольклор хәзинәсендә әкиятләр зур урынны алып тора. Басылып чыккан әкиятләр саны буенча да әлегәчә Апаска тиңнәр юк. Бу җәһәттән аларга Буа һәм Азнакай районы әкиятчеләре генә якын тора.

## ЛЕНАР ҖАМАЛЕТДИНОВ ТУРЫНДА

### Әкиятләр дөньясына сәяхәт

Бүгенге кунагыбыз – Ленар Шәйхи улы Җамалетдинов. Ул – танылган фольклорчы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галиме, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Без аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

– ***Сез ничә әкият беләсез? Гомумән, татарда ничә әкият бар икән?***

– Сүз халык әкиятләре турында барганда бу сорауны мин ике өлешкә бүләр идем. Беренчесе: бездә ничә әкият тексты бар? Икенчесе: ничә сюжет бар? Гадәттә без, кулыбызга килеп кергән китапның күләмен билгеләп, калын, юка дибез, фәләнчә табак яисә фәләнчә битле дибез. Балалар исә күбесенчә бу китапта ничә әкият булуын санап чыгалар. Менә шул әкиятләрнең саны әкият текстларының саны була инде. Әле бит басылмаган әкиятләр дә бар. Аларның текстлары архивларда, китапханәләрнең кулъязмалар бүлегендә, музейларда һәм аерым кешеләрдә саклана. Әйтик, бер бала әбисеннән яисә бабасыннан бер әкият язып алды ди, бу инде шул бала кулында саклана торган текст була. Ул да югалмаска тиеш. Әнә шундый басылып чыккан һәм әлегәчә басылмый яткан әкият язмаларының суммасы безнең татар әкиятләре фондын тәшкил итә. Шушы фондта ничә әкият, ягъни ничә текст бар дип сорасагыз, җавап бирәм: миңа мәгълүм булган кадәресе 2 мең тирәсе. Бу очракта бер әкият, ничә мәртәбә басылуына карамастан, бары бер текст булып кына санала. Мәсәлән, «Шомбай» дигән әкият 20 тапкыр басылган, әмма ул бер үк текст.

Хәзер мәсьәләгә икенче яктан килик. Әнә шул 2 мең текстка күз салсак, арада 15 «Шомбай» бар икән. Ягъни 15 текстның эчтәлеге бер үк. Әмма аларны 15 кеше сөйләгән. Болар инде 15 текст була алса да, 15 әкият була алмый, бәлки «Шомбай» әкиятләренең

вариантлары, ягъни төрдәшләре генә булып торалар. Бәс, шулай икән, әкиятләрне эчтәлекләре буенча санарга мөмкин түгелме соң? Әйдәгез, эчтәлекне гадиләштереп сюжет дип атыйк та әлеге әкиятләребез фондын сюжетлар буенча төркемләп карыйк, һәр текстта бер генә сюжет булганда төркемләү уңышлы бара. Ә менә «Камыр батыр» һәм «Турай батыр» әкиятләрен ничек итәргә? Икесендә дә бер үк сюжет: батыр егет җир астында Үзе бер карыш, сакалы биш карыш картны үтерә, җир өстеңә хәзинәләрне һәм кызларны җибәрә, үзе чыга алмый – дуслары хыянәт итә, соңыннан барыбер хаклык җиңә. Сюжетлары бер үк булса да, бу ике текстның ике мөстәкыйль әкият икәнен һәр бала да белә. Камыр батырның могҗизалы рәвештә тууы үзе үк игътибарны җәлеп итә һәм аны башка бернинди герой белән дә бутый алмыйсың. Шуңа күрә могҗизалы туу үзе генә дә аерым сюжет булып йөртелә. Шулай итеп, бер әкияттә сюжет бер генә булмаска да мөмкин. Кайбер әкиятләрдә аларның саны хәтта 4–5 кә җитә. Фәндә бу күренеш контаминация дип атала. Хәзерге вакытта дөнья халыкларының әкиятләрендә очрый торган сюжетларның берләштерелгән каталогы бар, Аларны сюжет күрсәткечләре дип атыйлар. Сорауның икенче өлешенә җавап итеп әйтәм: татар халык әкиятләрендә әнә шул халыкара күрсәткечләрдә теркәлгән 380 ләп сюжет ачыкланды. Әлеге күрсәткечләрдә булмаган сюжетларны да исәпкә алганда татар әкиятләре репертуарында алар 450 ләп булыр дип уйлыйм. Бу эш әле тәмамланмаган. Насыйп булса, якын елларда без моңа да ирешербез.

***– Сез ничә әкият китабы чыгардыгыз?***

– 6 китап. Бер китабым ике төрле булып басылды. Икенчесе яхшы кәгазьдә, төсле рәсемнәр белән чыкты, шуның өстенә ялтыравык тышлы һәм зур форматлы. Зур булганга күрә, аны бер шүрлеккә дә бастырып куеп булмый. Әнә шул гел ятып кына тора торганын да аерым китапка санасагыз, ул вакытта 7 данә була.

*– Шулар арасында үзегез очен иң кадерлесе бармы?*

– Әйе, хәтта икесе. Беренчесе – көнкүреш әкиятләре томы. Бу китап 1981 елда нәшер ителгән иде. Ул җәмәгатьчелек тарафыннан хупланган «Татар халык иҗаты»ның 12 томлык җыелмасындагы бер китап буларак кына түгел, бәлки бик күп көч кергән хезмәт буларак кадерле миңа. Аны әзерләгәндә төрле китапханәләрдә әкиятләрнең барлык басмаларын күздән кичерергә, шулай ук Казан, Мәскәү, Ленинград, Уфа архивларында да байтак кына казынырга туры килде. Нәтиҗәдә күп кенә текстлар беренче мәртәбә шушы китапта дөнья күрде. Кадерле китапларымның икенчесе – 1986 елда нәшер ителгән

«Татарские народные сказки» дигән җыентык. Урыс телендәге бу зур җыентык Татарстан китап нәшриятының элеккеге директоры Гарәф ага Шәрәфетдинов инициативасы белән әзерләнде. Зур тираж белән басылганлыктан ул халкыбызның 150 экиятен йөзләрчә мең укучыга, шул исәптән, урыс теле аша башка бик күп милләт укучыларына да мәгълүм итте. Шуның өстенә күп халыкларның фольклор галимнәре өчен дә ул мөһим чыганак булды.

– ***Сез үзегез әкияткә ышанасызмы?***

– Бу сорауда әкияттә сурәтләнгән вакыйгалар, аерым алганда, тылсымлы әкияттәге маҗаралар күздә тотыла дип уйлыйм. Әкиятләрдә чынбарлык белән фантазия бергә үрелеп бара. Ләкин һәрбер гаҗәеп нәрсә бүгенге көн биеклегеннән караганда гына фантазия дип кабул ителә. Аларны тарих сызыгына куеп карадың исә, һәммәсенең дә гадәти нәрсә икәнлеге ачыклана. Шулай булгач, убырлы карчык та, дию дә, кызларны ашый торган аждаһа да, үлгән кешене терелтү дә, карурман эчендәге шомлы йорт та – барысы да булган яисә бар дип ышанылган нәрсәләр.

– ***Әкият кешегә ни өчен кирәк?***

– Әкият кешегә беренче чиратта чын кеше булу өчен кирәк. Әкият яңа гына теле ачылган сабыйны яхшылык белән явызлыкны аерырга өйрәтсә, үсмерләрдә әдәплелек, әхлаклылык, инсафлылык, мәрхәмәтлелек, батырлык һ.б. сыйфатларны тәрбияләүдә зур ярдәм итә. XVIII гасырда яшәгән немец философы һәм мәгърифәтчесе Гердер: «Әгәр сабыйга беркайчан да әкият сөйләмәгән булсалар, аның күңелендә эшкәртелмәгән кыр кала, һәм шуннан соңгы елларда инде бу кырны эшкәртү мөмкин булмаячак»,– дигән. Димәк, ата-аналар һәм педагоглар карамагында әкият бик үтемле тәрбия чарасы булып тора. Язучылар исә халык әкиятләрен өйрәнеп, әдәби әкиятләр иҗат итәләр. Моннан тыш халык әкиятләренең фәнни әһәмияте дә гаять зур. Тарихчылар, философлар, иҗтимагый фикер тарихын, дин тарихын өйрәнүче галимнәр, этнографлар, сәнгать белгечләре, телчеләр, диалектологлар – берсе дә әкиятне читләтеп үтә алмый. Аларның һәркайсы әкиятләрдә үзенә кирәкле материалны таба, алардан нәтиҗәле файдалана.

– ***Тормыш бигрәк авырайды. Берәр әкият иленә китеп яшисегез килмиме?***

– Авырлыктан качып әкият иленә китү мәсьәләне бик җиңел хәл итү булыр иде. Ярый, мин киттем дә ди, биредә бит халык кала. Минем, киресенчә, бүген «Сабантуй» гәҗитен укучы яшьләр белән бергә мөстәкыйльлек яулаганирекле Татарстаныбызны тизрәк гүзәл әкият иленә әверелдерәсем килә.

***– Алып батыр, Камыр батыр, Тапкыр кыз кебек әкият геройлары тормышта очрыймы?***

– Безнең халкыбыз – батыр халык, гадел халык, талантлы халык. Физик җәһәттән карасак, бүгенге сабантуй батырлары, әйтик, 110–120 килограммлы пәһлеван әлеге әкият батырларына охшамаганмыни? Гадәттә мондый батырлар мәрхәмәтле дә булалар. Ә сугышта күрсәткән батырлыклар! Герой исемен алган каһарманнарыбыз гына да 200 дән артык. Безгә һөҗүм иткән дошман да Үзе бер карыш, сакалы биш карыш картка караганда күп мәртәбә көчлерәк иде. Хәзерге вакытта Татарстанның мөстәкыйльлеге, халкыбызның империя тырнагыннан котылуы хакына үлемгә барырга да әзер торган кыз һәм егетләребезнең төрле формадагы көрәшләрен мин шулай ук әкияттәге хәлләргә охшатам. Әкиятләрдә һәр очракта да хаклык җиңеп чыга, тормышта да ул шулай булыр.

***– Әкиятләр төшегезгә кереп интектермиме?***

– Юк алай, ходайга шөкер – тыныч йоклыйм.

***– Үзегезнең балачагыгызны искә төшерегез әле, әкият белән бәйләнешле берәр вакыйганы хәтерләмисезме?***

– Минем язмыш ул җәһәттән кызыгырлык булмады бугай. Сугыш чорында һәм сугыштан соң нәкъ менә әкиятләр тыңлар чагымда миңа дистәгә якын урында яшәргә туры килде. Ят җирләрдә бер яки ике ел яшәп кенә тәмам үзләшеп җитеп тә булмагандыр. Һәрхәлдә даны чыккан әкиятчеләр очрамады.

Әниемнән ишеткән берничә кечкенә әкият һәм авыл башындагы чирәмлектә кичен сыерлар саклаганда яисә атлар белән куна барганда яшьтәшләрем сөйләгән берничә әкият кенә истә калган. Аның каравы, үскәч фольклор экспедицияләре вакытында бик үзенчәлекле әкиятчеләр белән очрашканым булды. Алар турында мәкаләләр да бастырдым.

***– Безнең «Сабантуй»да балалар язган бик күп әкиятләр басыла. Аларга мөнәсәбәтегез ничек? Гомумән, бүген әкияткә урын бармы?***

– «Сабантуй»дагы әкиятләр белән хәл кадәри танышып барам. Аларның сыйфаты, әлбәттә, төрлечә. Әмма мине укучыларның әкиятләрне яратуы һәм үзләренең дә әкиятләр иҗат итүе бик шатландыра. Безнең әдәбиятыбыз, сәнгатебез, мәдәниятебез нинди генә югары дәрәҗәгә ирешсә дә, әкияткә ихтыяҗ, һичшиксез, калачак. Ихтыяҗ булдымы инде – ул яшәячәк. Димәк, әкият – мәңгелек.

***– Әкият яратучы малайларга, кызларга нинди киңәшләрегез бар?***

– Әкият яратучы балалар арасында әкияткә мәхәббәтләрен гомер буена саклаучылар булсын иде. Алар халык әкиятләре белән кызыксынып, әби-бабайлардан шуларны язып алсыннар һәм бу язмаларның коллекциясен булдырсыннар иде. Һәр мәктәптә шундый бер генә укучы табылса да, без никадәр рухи байлыкны саклап калыр идек. Магнитофонга яздырганда бу эш хәтта фәнни әһәмияткә дә ия булачак. Шундый теләге булган укучылар, бәлки, хат та язарлар әле. Мин киңәшләрем белән аларга ярдәм итәргә әзермен.

*Галим белән **Р. Мөгаллимов** сөйләште.*

## «Әкиятләрдә хаклык җиңә, тормышта да шулай булыр!»

Соңгы вакытта сәясәт белән мавыгучы бер төркем галимнәрне исәпкә алмаганда, галим-голәмә халык алдында еш чуалмый, юкка-барга кадерле вакытларын сарыф итми. Алар – эш аты, алар утрак тормышны кулайрак күрүче, утырып эшләүче, «чалбар төбе туздыручы» гыйлем ияләре. Тик менә фольклорчыларга гына «утрак тормыш» дигәне туры килеп бетми. Ни өчен дисәң, аларның хезмәтләре күбрәк фәнни экспедицияләр белән бәйле. Йөзәрмеңәр чакрымнарга сузылган сикәлтәле юллар. Аларның һәммәсе дә татар төбәкләренә илтә. Бөтен дөнья буйлап сибелгән, чәчелгән исәпсез-сансыз авылларга, төрле җирләрдә яшәгән, төрле диалектларда сөйләшүче күптөрле татарларга. Фольклорчылар үз гомерләрендә күпме әби-бабайларның телләрен ачкан, күпме әкият-хикәятләр сөйләттергән, бәет-җырулар, мөнәҗәтләр җырлаттырган, күпме табышмак, әйтемнәр әйттергән, менә-менә югалучы, шул әби-бабайлар белән бергә бу фани дөньядан китеп баручы күпме халык авыз иҗаты үрнәкләрен киләчәк өчен саклап калган. Фольклорчыларның шундый фәнни сәфәрләре аркасында халкыбызның буыннардан-буыннарга килгән күңел байлыклары бергә тупланган, соңыннан китаплар булып дөнья күргән.

Танылган фольклорчы Ленар Җамалетдиновның тормыш юлын күзаллагач, шундый кызыклы бер күзәтүгә тап булдым. Кечкенә бер Күзби авылында туган малайга, әтисенең күчеп эшләве сәбәпле, авылдан-авылга күченеп йөрергә, Тутай, Яңа Чәчкап, Васильево кебек бик күп авылларны күреп үсәргә туры килә. Галим үзе дә: «Сугыш чорында һәм сугыштан соң нәкъ менә әкиятләр тыңлар чагымда миңа дистәгә якын урында яшәргә туры килде», – ди. Егермеләп фольклор экспедицияләрендә катнашкан галимнең язмышына

кечкенәдән озын-озын юллар, сәфәрләр язган. Экспедицияләренең башы шуннандыр шикелле. Буа мәктәбен тәмамлаган Ленар техник училищеда укый, совхозда механик вазифаларын башкара. Аннары – солдат еллары... Аның тормышындагы кискен борылыш, мөгаен, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган елларда булгандыр. Үзе белән бергә укыган группадаш-сабакташларын санап китсәң дә, ул чактагы мохитнең нинди булуын күз алдына китерергә мөмкин булыр иде: шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Шамил Маннапов, Салисә Гәрәева, галимнәр Рүзәл Юсупов, Фирдәвес Гарипова, Шәрифҗан Асылгәрәев, Әнвәр Шәрипов, Фарсил Зыятдинов... Менә кемнәр белән бергә укыган, әдәбиятка, фәнгә аяк баскан булачак галим, менә нинди мохитта формалашкан аның зәвыгы, фәнгә, дөньяга карашы.

Дүртенче курста укып йөргәндә үк студент Ленар Җамалетдиновны Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясенә мөхәррир итеп эшкә чакыралар. Төгәлрәк итеп әйтсәк, ул яшьли вафат булган талантлы шагыйрь һәм композитор Ләбиб Айтугановны алыштыра. Музыкаль редакциянең эшен җанландырып җибәргән, җанын-тәнен биреп ихластан эшләгән Ләбибнең эшен лаеклы дәвам иттерү җиңел булмагандыр Ленарга. Шуңа да карамастан, биредә ул шактый озакка тuktала. Татар музыка сәнгатен пропагандалауга, халык җырларын, профессиональ композиторларыбызның әсәрләрен, шулай ук җырчыларыбызның иҗатларын халыкка җиткерүдә көчен дә, сәләтен дә кызганмый. Җитмешенче елларга кадәр ул Рафаэль Ильясов, Әхмәт Рәшитовлар белән бергә шунда эшли. Радио аша яңгыраган һәрбер җыр аның аша да үтә. Радио тыңлаучыларда халык җырларына хөрмәт, мәхәббәт уятуда, халыкның музыкаль зәвыгын тәрбияләүдә аның өлеше дә әйтеп бетергесез. Ул эфирга әзерләгән музыкаль тапшыруларны өлкән буын радио тыңлаучылар әле дә хәтерлиләрдер, сагынып искә алалардыр.

Менә чирек гасыр инде ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлегендә эшли. Егерме биш ел халык арасында, кульязмалар арасында. Ел саен диярлек фольклор экспедицияләренә чыгып китә, төрле фәнни-практик конференцияләрдә катнаша, чыгышлар ясый. Аның төп шөгыле – әкиятләр. Татар халкының бетмәс-төкәнмәс өмет-хыяллары, фантазиясе, акылы, шатлык-хәсрәтләре, тапкырлыгы тупланган ул әкиятләргә. Без укып үскән әкият геройлары – Алып батырлар, Камыр батырлар, Шомбайлар, Алдарлар – халкыбызның үз уллары шикелле. Фольклорчы әнә шундый үлемсез әкиятләрне җыя, туплый, өйрәнә. Геройларның холык-фигыльләрен, табигатьләрен,

кылган гамәлләрен тикшерә. Соңгы елларда татар халык әкиятләре турындагы мәкаләләрне, нигездә, Л. Җамалетдинов кына яза, ул әкиятләрне туплап китап итеп, нигездә, шул ук Л. Җамалетдинов кына чыгара. Андый китаплар татар һәм рус телләрендә даими дөнья күрә тора. Шунысы куанычлы, андый китаплар кибетләрдә тузан җыеп ятмый, бик тиз сатылып бетә. Димәк, фольклорга игътибар һич кенә дә кимеми.

Галим «Татар халык иҗаты»ның унике томлык җыелмасын әзерләүдә һәм чыгаруда күп көч куя, көнкүреш әкиятләре томын тулысы белән үзе эшли. Аны әзерләгәндә төрле китапханәләрдә әкиятләрнең барлык басмаларын күздән кичерергә, шулай ук Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа архивларында байтак кына утырырга, эзләнергә туры килә. Нәтиҗәдә күп кенә текстлар беренче мәртәбә шул китапта басылып чыга. Аннары фольклорчының икенче бер зур хезмәте – ул да булса 1986 елда нәшер ителгән «Татарские народные сказки» исемле җыентык. Зур тираж белән басылганлыктан, ул халкыбызның 150 әкиятен йөзләрчә мең укучыга, шул исәптән, рус теле аша башка бик күп милләт укучыларына да барып ирешә. Шуның өстенә күп халыкларның фольклор галимнәре өчен дә мөһим чыганак булды.

Тынгысыз фольклорчы һаман да эзләнә, таба. «Мирас» журналын укучылар күрәләрдер: 1993 елның февраль аеннан башлап саннан-санга «әсирлектән кайткан әкиятләр» басылып бара. Ул әкиятләрне беренче бөтендөнья сугышы чорында венгр тюркологы Игнац Кунош татар хәрби әсирләреннән язып алган булган. Аларны табуда, матбугатка әзерләүдә һәм бастырып чыгаруда Л. Җамалетдиновның хезмәте бик тә зур. Ул шулай ук Венгрия, Польша, Төркия галимнәре белән дә тыгыз элемтәдә тора, татар халык иҗатына кагылышлы материалларны матбугатка биреп бара. Хәтта үземнең дә моннан берничә ел элек Ленар ага биреп җибәргән татар журналларын, китапларын венгр галимнәренә илтеп тапшырганым булды.

Ленар Җамалетдиновны мин татар халкының төп әкиятчесе дияр идем. Әгәр бүген дә әкият жанры халык арасында, бигрәк тә балалар дөньясында һаман да популяр икән, укучылар әкият китапларын яратып укыйлар икән, аларга мохтаҗлык зур икән, монда филология фәннәре кандидаты, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ленар Шәйхи улы Җамалетдиновның да хезмәтләре зурдыр дип уйлыйм. Татар халык әкиятләре турында, ул әкиятләрнең фәлсәфи, дөньяви үзенчәлекләре турында уйланып, минем белән бер әңгәмә

вакытында ул мондый сүзләр әйткән иде: «Безнең халкыбыз – батыр халык, гадел халык, талантлы халык. Физик җәһәттән карасак, бүгенге сабантуй батырлары, әйтик, 110–120 килограммлы пәһлеван әлеге әкият батырларына охшамаганмыни? Гадәттә, мондый батырлар мәрхәмәтле дә булалар. Ә сугышта күрсәткән батырлыклар?! Герой исемен алган каһарманнарыбыз гына да 200 дән артык. Безгә һөҗүм иткән дошман да үзе бер карыш, сакалы биш карыш картка караганда күпкә көчлерәк иде. Хәзерге вакытта Татарстанның мөстәкыйльлеге, халкыбызның империя тырнагыннан котылуы хакына үлемгә барырга әзер торган кыз һәм егетләребезнең төрле формадагы көрәшләрен мин шулай ук әкияттәге хәлләргә охшатам. Әкиятләрдә һәр очракта да хаклык җиңеп чыга, тормышта да шулай булыр». Мин Ленар әфәнденең бу сүзләренә тулысынча кушылам һәм аны олуг бәйрәме белән ихлас күңелдән тәбрик итәм, беребез дә әкиятләрдән аерылмасак иде дигән теләктә калам.

***Роберт Миңнуллин***

## Әкият турында хикәят

Татар фольклор фәненең берничә гасырлык тарихы бар. Аның сәхифәләрендә урын алган галимнәр һәм язучылар турында озак итеп сөйләргә мөмкин. Әмма мин бүген безнең фольклорның үзәк жанрларыннан берсе булган әкият жанрын өйрәнү өлкәсендә олы хезмәт күрсәткән һәм бу хезмәтен яратып дәвам иттерүче галимебез Ленар Җамалетдин хакында гына берничә сүз әйтергә телим. Моның сәбәбе дә бар. Чөнки шушы көннәрдә аңа 70 яшь тула. Татар авылында туып, татар мәктәбен һәм Казан университетының татар теле һәм әдәбияте бүлеген тәмамлагач, «Татар халык әкиятләре һәм Г. Тукайның әдәби әкиятләре» дигән темага диссертация яклаганнан соң бөтен гомерен халкыбыз иҗатына багышлаган сирәк галимнәрнең берсе ул. Сирәк диюемнең бер сәбәбе бар. Чөнки бөтен нәрсә акча белән генә үлчәнә торган хәзерге кырыс, чуалчык заманда фольклор фәненә мөнәсәбәт тә үзгәрде, бу белгечлекне яшәү максаты итеп сайларга ашкынучы егетләр бөтенләй юк диярлек...

Монда Ленарның «Татар халык иҗаты» дигән 12 томлык фәнни җыелмадагы хезмәте өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булуын, шулай ук «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем йөртүен күрсәтеп үтү кирәк. Аның Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 30 елдан артык эшләвен дә истә тотыйк.

Ленар Җамалетдин – фольклор дөньясының өч тармагына да, ягъни аны җыюга да, китап итеп дөньяга чыгаруга да, фәнни тикшеренеп, хезмәтләр язуга да сокланырдай җитдилек белән караучы белгеч. Ул Татарстан районнарына, шулай ук Урал һәм Себер якларына оештырылган 16 фәнни экспедициядә катнаша, шактыеның җитәкчесе үзе була. Нәтиҗәдә, 3000гә якын берәмлекне эченә алган бай хәзинә туплана, шул исәптән Ленар язып алган 192 әкиятне аерым күрсәтергә кирәктер. Бу урында әкият язып алуның ифрат нечкәлек һәм зиһен-хәтер сораучы эш булуын әйтеп китәсе килә. Моны заманында халкыбыз әкиятләрен җыю, китапларда бастыру белән шөгыльләнгән ике олуг зыялыбыз – Гомәр ага Бәширов белән Хәмит ага Ярми дә билгеләп үтәләр. Ленар Җамалетдин менә шушы ике мәшһүр зат башкарган эшне байтак яңалык белән баетып, дәвам иттерүче. Ул үзенә фольклор хәзинәләре хәбәр иткән абый һәм апалар турындагы белешмәләрне аерым дәфтәргә язып барган. Андыйларны Ленар «Халкыбыз традицияләрен саклаучы талант ияләре» дип атый. Шуларның кайберләрен генә атап китик: Буа районының Аккүл авылыннан 10 әкият сөйләгән 88 яшьлек Закирә Минаева, Кама Тамагы районының Яшелчә авылыннан 17 әкият сөйләгән 73 яшьлек Хәбибулла Хәйруллин, Лениногорски районының Мөэмин-Каратай авылыннан 30дан артык әкият сөйләгән 74 яшьлек Минҗамал Гулова һ.б. Исемлектә халык җырларын яратып күңелләрендә саклаучылар да аз түгел. Ютазы районының Кәрәкәшле авылыннан 63 яшьлек Нәсихә Латыйпова, Курган өлкәсенең Мансур авылыннан 77 яшьлек Фәттах Кәримов һ.б. Әлеге дәфтәрдә Актаныш районының Зөбәер авылында яшәүче 72 яшьлек Мөзәянә Садыйкованың бер сөйләшеп утырганда халкыбызның 232 кыска җырын хәбәр итүе дә телгә алына. «Мөзәянә апа күңелендә тагын әллә ничә йөз җыр барлыгын әйтте. Менә бу хәтер дисәң дә хәтер», – дип язып куйган Ленар.

Авылларда йөргәндә ул үзенә очраган аерым һәвәскәрләр, телсүз осталары белән экспедицияләрдән соң да аралашуын дәвам иттерә. Мәсәлән, алда искә алган Минҗамал апа Гулова белән Ленар берничә ел хатлар алышып торды, аның хакында «Казан утлары»нда кызыклы бер мәкалә дә бастырды.

Шунысын әйтү зарур, Ленар Җамалетдин язып алган фольклор әсәрләренең күбесе, аерым китапларда, җыентык, журнал битләрендә нәшер ителеп, фәнни әйләнешкә керде. Куанычлы күренеш бу. Институтта 35 ел эшләү дәверендә Л. Җамалетдин халык әкиятләреннән төзелгән 13 китап-җыентык бастырып чыгарды. 12 томлык фәнни җыелманың бер томын тәшкил иткән һәм

1981 елда нәшер ителгән «Көнкүреш әкиятләре» томы аның беренче зур вә җитди хезмәте булды. 150 әкиятне берләштереп, 1986 елда урыс телендә дөнья күргән «Татарские народные сказки» дигән җыентык безнең әкиятләрнең урыс телендә чыкканнары арасында иң тулысы һәм камиле булып санала. Биредәге әкиятләр фәнни таләпләргә дә җавап бирерлек итеп, өр-яңадан тәрҗемә ителгән. Бу китапның төсле рәсемнәр белән бизәлгән варианты һәм шулай ук 1994 елда татар телендә сувенир басма итеп чыгарылган «Тылсымлы әкиятләр» дигән китап үз вакытында Татарстан кунакларына истәлек бүләкләр рәвешендә тапшырылуын да әйтеп китик.

Хәзерге вакытта институтның халык иҗаты бүлегендә татар фольклорының иң камил үрнәкләре 14 том булып урыс телендә әзерләнеп ята. Бу җыелманың әкиятләргә багышланган беренче өч томын шулай ук Ленар Җамалетдин төзеде. Әлеге томнарның икесе инде җәмәгатьчелеккә барып иреште һәм уңай бәя алды. Чираттагы 3 нче томы да басмага әзер. Әйтергә кирәк, бу 3 нче томның фәнни аппараты аерым игътибарга лаек. Беренче өлештә һәр әкияткә искәрмәләр бирелеп, сюжетларның типологик анализы һәм текстларда тәрҗемә ителми бирелгән сүзләрнең аңлатмалары урнаштырылса, фәнни аппаратның икенче өлеше барлык өч том өчен дә уртак итеп эшләнгән. Анда түбәндәге бүлекләр бар: «Топонимнар күрсәткече», «Исемнәр күрсәткече», «Предметлар күрсәткече», «Әкиятчеләр исемлеге», «Әкият җыючылар исемлеге», «Татар халык әкиятләрендәге сюжетларның җыелма күрсәткече» һәм «Әкиятләрнең әлифба тәртибендәге күрсәткече».

Л. Җамалетдин әзерләп чыгарган тагын бер үзенчәлекле китапны телгә аласы килә. Ул «Әсирлектән кайткан әкиятләр» дип атала. Төсле рәсемнәр белән бизәлеп, 2002 елда нәшер ителгән бу китапның өч бүлегендә 56 әкият урнаштырылган. Беренче бүлекне Беренче бөтендөнья сугышы вакытында татар әсирләреннән венгр галиме Игнац Кунош язып алган һәм моңарчы Венгрия Фәннәр академиясе архивында хәрәкәтсез яткан 21 әкият тәшкил итә. «Көттереп килгән әкиятләр» исемле икенче бүлек тә моңарчы бер җыентыкта да басылмаган әкиятләрдән тора. «Сагындырган әкиятләр» дигән өченче бүлектә исә бер мәртәбә дөнья күреп тә, соңыннан кабат басылмаган әкиятләр урын алган. Ленар Җамалетдин төзегән җыентыкларның күбесе, бер үк вакытта фәнни, гамәли һәм педагогик таләпләргә җавап биргәнлектән, кибет киштәләрендә озак ятмый, гадәттә, басылып чыккан елында ук таралып бетә. Алдымда галимнең басма хезмәтләр исемлеге ята. Баштагы бүлегендә китаплар, аннары фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре саналган. 200 дән артык

хезмәт. Аларның бер өлешен – китапларны – үзенә күрә аерым бер текстологик хезмәт дияргә була. Чөнки анда һәр әкият тексты күздән кат-кат кичерелгән, аның вариантлары (төрдәшләре) барланган һәм һәр текстның кайда, кайчан, кемнән язылган булуы турында мәгълүматлар бирелгән. Бу – төпченү, сабырлык сорый торган бер эш. Ленарның басма хезмәтләре исемлегендә әкият жанрының асыл билгеләре, төркемнәре, образлар системасы, поэтик һәм типологик үзенчәлекләре хакындагы мәкаләләр төп урынны алып тора. Алар искә алган китапларның кереш мәкаләсе буларак, яисә фәнни җыентыклар өчен язылган мәкаләләрдән гыйбарәт. Исемлектә шулай ук аерым әкиятчеләр, Тукайның әдәби әкиятләренә, әкият һәм мифология, төрле халыкларның әкият мирасы өчен уртак сыйфатлар һ.б. күптөрле темаларга багышланган мәкаләләр дә байтак.

Бу урында Л. Җамалетдинның фәнни тикшеренүче буларак башкарган һәм шактый үзенчәлеккә ия бер гамәленә аерым тукталасы килә. Сүз аның чит ил галимнәре белән элемтәләре турында бара. Венгр галиме Игнац Куношның Беренче бөтендөнья сугышы чорында татар әсирләреннән язып алынган һәм әлегәчә архивта яткан әкиятләре венгр тюркологлары Жужа Каккук һәм Имре Башки тарафыннан аерым китап итеп әзерләнеп, Будапештта 1989 елда басылып чыккач, Ленар бу хезмәтне үзендә булдыру чараларын күрә. Соңрак ул әлеге китаптагы әкият текстларын, транскрипциясен ачып, аңлатмалар һәм искәрмәләр белән көндәлек матбугатта бастырды. И. Куношның татар әсирләре арасында бер сезон эшләгәч тә язылган һәм 1916 елда ук басылып чыккан мәкаләсе барлыгын белгәч, Л. Җамалетдин аны Казанга кайтарту чарасын күреп, поляк галиме Генрих Янковскийга мөрәҗәгать итә. Г. Янковский, бу мәкаләне табып, аны венгр теленнән урыс теленә тәрҗемә итеп җибәрә һәм мәкалә «Идел» журналында (1995, №7) урыс һәм татар телләрендә дөнья күрә.

Ленар И. Кунош мирасын өйрәнүдә төрек галимнәренең дә ярдәмен күрә. Мәсәлән, Конья шәһәреннән Мәтин Эргун аңа И. Кунош хезмәтенең моннан күп еллар элек нәшер ителгән икенче басмасын табып җибәрә. Ленарның әкият турындагы хезмәтләре белән танышкач, япон галимәсе Кимико Сайто аңа: «Сезнең мәкаләгезне бик кызыксынып укыдым, ул минем тикшеренүләрем өчен бик файдалы булыр», – дип хат җибәрә.

Татар әкиятләре буенча докторлык диссертациясе язучы венгр кызы Эдина Даллош та аңа еш мөрәҗәгать итә, ә Литва профессоры Леонардас Саука безнең фольклорчыбызга аеруча рәхмәтле. Л. Саука төрле халыкларның бер үк сюжетка корылган әкиятләрен

чагыштырма планда тикшерә. Татар әкиятләренә бәйле мәгълүматларны ул Л. Җамалетдиннан алмый кемнән алсын? Үз чиратында Ленар да аңа рәхмәтле. Әгәр дә профессор Саука хәбәр итмәсә, ул күптәннән хыялланган мөһим бер хезмәтнең дөньяга чыгуын кемнән һәм кайчан белгән булыр иде? Алман галиме Һанс-Йорг Утерның быел гына Финляндиядә инглиз телендә басылган өч томлы фундаменталь хезмәте халык әкиятләре өлкәсендә эшләүче һәр фольклорчының «өстәл китабы» булачак. Бу хезмәт – дөнья халыклары әкиятләренең сюжет типларын берләштергән атаклы Аарне-Томпсон каталогының төзәтелгән, тулыландырылган басмасы. Татар әкиятләрен дөньякүләм фәнни әйләнешкә кертү әлеге хезмәт үрнәгеннән башка мөмкин түгел. Бу кыйммәтле хәзинәне Ленарга күптән түгел Һелсинки университеты укытучысы, мәгълүм милләттәшебез Окан Таһир алып килде.

Ленар Җамалетдиннең иң зур максаты – татар халык әкиятләрен дөньякүләм фәнни әйләнешкә кертү. Моның өчен ул безнең әкиятләрнең сюжет күрсәткечен төзеп, бастырып чыгаруны (әлегә өч кисәктән бер кисәге генә дөнья күргән), урыс телендәге өч томның өченчесен тизрәк нәшер итүне һәм татар әкиятләрен инглиз теленә тәрҗемә итеп, күләмле бер китап чыгаруны күз алдында тота. Моңа өстәп, янә унга якын эшнең планда торуын санап күрсәтте ул. Ахырдан өстәп куйды: «Боларның барсын да гамәлгә ашыру – татлы хыял гына. Моның өчен тагын бер гомер кирәк...» – диде.

Юбилярга озын гомер, куанычлы иҗат уңышлары телик.

***Илбарис Надиров***

### Әкиятче галим

Буа районы – татар халкына, туган Республикабызга күпсанлы һәм һәм күптөрле талантлар бүләк иткән төбәк. Алар арасында танылган дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, хезмәт каһарманнары, мәшһүр сәнгатькәрләр, язучылар, журналистлар, табиблар һәм башка һөнәр ияләре бар. Бу язмада сүз шундый мөхтәрәм якташларыбызның берсе– күренекле фольклор белгече, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Республикабызның атказанган мәдәният хезмәткәре Ленар Шәйхи улы Җамалетдинов турында барачак. Узган ел азагында галимнең дөньяга килүенә 70 ел тулды.

...Фән юлына ныклап аяк басканга кадәр аңа үзен башка шактый һөнәрләрдә сынап карарга туры килә. Буа шәһәренең Мулланур

Вахитов исемендәге урта мәктәбен тәмамлагач, ел ярым техник училищеда укый һәм үзенең хезмәт юлын авыл хуҗалыгы машиналары буенча механик буларак башлап җибәрә. Өч ел армиядә хезмәт итә, анда беренче классны радиотелеграфчы була. Ләкин әле туган авылы Күзби мәктәбендә укыганда ук аның күңелендә әдәбиятка мәхәббәт бөреләнеп кала. Бу мәхәббәт техника белән мавыгудан да өстен булып чыга һәм ул, армиядән соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга килә. Югары белем алгач, радиокомитетта музыкаль тапшырулар редакциясе мөхәррире булып эшли башлый. Монда инде аңа филологик белем дә, техникага осталык та, музыкага һәвәслек тә – барысы да бик ярап куя. Шушы вазифасын ул 6 ел дәвамында әйбәт кенә башкарып килә.

Ләкин 1970 ел азагында, 35 яше тулгач, Ленар Шәйхи улының хезмәт биографиясендә җитди бер борылыш булып куя: ул яраткан, көйләнгән, жайлашкан эшеннән аерылып, СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор бүлегенә күчә. Биредә аңа халык әкиятләрен өйрәнү вазифасын йөклиләр. Шуннан соң узган еллар дәвамында бу искиткеч мавыктыргыч, сер-тылсым белән өртелгән әсәрләрне җыю, бастыру, фәнни яктан тикшерү юнәлешендә никадәр зур һәм күп эшләр башкарып өлгерә ул!

Бүгенге көнгә галим татар әкиятләренең 17 җыентыгын әзерләп дөньяга чыгарды. Аларның гомуми күләме 399 басма табак тәшкил итеп, тиражлары 747000 нән артып китә! Татар фольклоры өчен рекордлы күрсәткечләр болар. Хикмәт, әлбәттә, саннарда гына түгел. Бу китапларның һәркайсы диярлек безнең фольклор фәне һәм күпмеңләгән укучылар өчен мөһим яңалыклар алып килде. Тирән эчтәлекле кереш мәкаләләр, киң мәгълүматлы искәрмәләр, әле беркайда да басылмаган яңа әкиятләр... Ошбу җәһәттән караганда, татар халык иҗатының 12 томлык җыелмасына кергән көнкүреш әкиятләре китабын (1981 ел) беренче нәүбәттә телгә алып узасы килә. Яисә 150 әсәрне туплаган һәм 1986 елда нәшер ителгән «Татарские народные сказки» җыентыгы. Ул – татар әкиятләренең урысча дөнья күргән иң тулы һәм камил басмасы. Чөнки андагы әкиятләр урыс теленә фәнни таләпләргә җавап бирерлек итеп, өр-яңадан тәрҗемә ителделәр. Л. Җамалетдинов бу җыентыкның төзүчесе, кереш мәкалә авторы гына түгел, бәлки махсус мөхәррире дә булды, һәр тәрҗемәнең сыйфатын энәсеннән җебенә кадәр ул җентекләп тикшереп, төзәтеп чыкты.

Ленар Җамалетдиновның күпкырлы эшчәнлегенең бер өлешен халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю тәшкил итә. Ул – 16 җәй

дәвамында, аркасына биштәрен асып, кулына магнитофонын, фотоаппаратын тотып, Татарстандагы, шулай ук Пермь, Чиләбе, Свердловск, Курган, Иркутск өлкәләрендә татар авылларын гизеп чыккан кеше. Аның халыктан үзе язып алган әсәрләре саны 3000 нән артып китә, шулардан 192 сен зур күләмле әкиятләр алып тора. Галим фольклор эзләүне архивларда, китапханәләрдә дә эзлекле алып бара һәм кызыклы-кызыклы чыганакларга юлыга. Мәсәлән, ул В. Радлов, А. Бессонов кебек тюркологларның архивларында татар фольклорына караган бай материалларга юлыгып, аларны фәнни җәмәгатьчелеккә ирештерде. Мондый рухтагы тикшеренүләре аны чит ил галимнәре белән иҗади элемтәгә дә алып керде. Атап әйткәндә, ул венгр тюркологы И. Кунош тарафыннан Беренче дөнья сугышы чорында әсир төшкән татар солдатларыннан язып алынган фольклор әсәрләрен дөньяга чыгару һәм үзебезгә кайтару юлында гаять зур тырышлык күрсәтте. Башта Ленар Җамалетдинов Кунош архивында озак еллар хәрәкәтсез яткан татар әкиятләрен Будапештта бастыруда венгр галиме Имре Башкига гамәли ярдәм күрсәтте. Китап чыккач, андагы әкият текстларын, аларның транскрипциясен ачып, кереш сүз һәм искәрмәләр биреп, үзебезнең татар матбугатында да дөньяга күрсәтте: «Әсирлектән кайткан әкиятләр» исемле бик кызыклы җыентык чыгарды. Аның чит ил галимнәреннән профессор Ханс-Йорк Утер (Германия, Дуйсбург), профессор Леонардас Саука (Литва, Вильнюс), Һенрих Янковский (Польша, Познань), Эдина Даллош (Венгрия, Будапешт), Сеит Каскабасов, Едыге Турсунов (Казакъстан, Алма-Ата) һәм башкалар белән тыгыз иҗади хезмәттәшлек итүе хакында да әйтеп үтү урынлы булыр. Табигый ки, мондый багланышлар үзебезнең Рәсәй эчендә тагын да күбрәк. Шул җәһәттән Ульяновск педагогика университеты ректоры Ю.А. Грушевский кул куйган Рәхмәт хаты игътибарга лаеклы. Анда университетның милли бүлегенә Л.Ш. Җамалетдинов тарафыннан күрсәтелгән зур фәнни-методик ярдәм тәкъдир ителә.

Ленар Җамалетдиновның татар халык әкиятләре буенча алып барган аеруча мөһим эшчәнлеген, әлбәттә, аның теоретик тикшеренүләре алып тора.Ул – әкиятләр темасына язылган 100 гә якын мәкалә авторы. Галим беренчеләрдән булып безнең әкиятләребезгә фәнни төркемләү үткәрде, аларның һәр төренә багышлап махсус мәкаләләр язды, фольклор һәм әдәбият бәйләнешләрен өйрәнүдә дә үзенең яңа җитди сүзен әйтте. «Татар халык әкиятләре һәм Г. Тукайның әдәби әкиятләре» дигән кандидатлык диссертациясендә ул бөек шагыйребезнең әдәби әкиятләр иҗат итүдә сайлаган төп принцибын ачыклады: Тукай, халык иҗатындагы сюжет һәм мотивларны

пассив эшкәртү белән генә чикләнеп калмыйча, халыкның рухын һәм милли колоритын саклаган хәлдә, әлеге әсәрләрнең сюжет һәм мотивларын татар халкының тарихы һәм көнкүреше, хәтта биографик моментлар белән, кыскасы, реаль чынбарлык белән, органик рәвештә бәйләп, халыкның ихтыяҗларына, аның өмет-хыялларына, шулай ук заманның идея-эстетик таләпләренә җавап бирердәй әсәрләр иҗат итә. Тикшеренүче, «Шүрәле» поэмасына таянып, Тукайның татар әдәби әкиятенә нигез салучы булуын дәлилләде.

Мөхтәрәм якташыбыз бүген дә мөһим иҗади планнар белән яши. Аның күптәнге бер изге хыялы – милли әкиятләребезне бөтендөнья аренасына чыгару. Моның өчен йөзләгән татар әкиятләрен башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру һәм халыкара каталоглар нигезендә зур күләмле сюжет күрсәткече төзү таләп ителә. Өч кисәкле итеп күзаллана торган бу хезмәтнең беренче кисәге инде басылып та чыкты. Кызыксынган белгечләр аның белән интернет аша да таныша алалар. Инша Аллаһ, калган өлешләре дә озак көттермәс, дип өметләник. Ә аннан соң? Аннан соң – татар әкиятләренең тулы корпусын (җыелмасын) төзергә, аларны инглиз телендә чыгарырга иде... Төрле елларда төрле газета-журналларда басылган күпсанлы мәкаләләрне бер китап итеп туплыйсы иде...

Ә без, хөрмәтле укучылар, галим якташыбызны олуг юбилее белән котлап, аңа ныклы сәламәтлек һәм яңа иҗат уңышлары телик!

***Хуҗи Мәхмүтов,***

### Волшебник из страны чудес

На книжных полках магазинов привлекают внимание красочные обложки книг. Там чудеса: Батыр прищемил палец хитроумному Шурале, красавицу Гульчечек догоняет серый волк, благородный змеиный царь Шахмара помогает попавшему в беду юноше, джигит оборачивается белым волком, спасает царевича...

С красочным миром татарских сказок вот уже около трех десятков лет знакомит читателей Ленар Замалетдинов – кандидат филологических наук, заслуженный работник культуры Татарстана, лауреат Государственной премии им. Г. Тукая Республики Татарстан, автор более 200 научных и научно- популярных работ, составитель 14 сборников сказок.

Труд фольклориста, на первый взгляд, несложен. Записывай себе у населения сказки, легенды, пословицы. Ан нет. Это очень трудоемкий процесс. На дворе летняя страда, народ в поле, огороде.

А фольклорные экспедиции проходят летом. Тяжелые сумки, рюкзаки за плечами, магнитофон оттягивают руки. Фольклористы приезжают в отдаленные села, деревни, где никто никого не ждет.

Надо быть очень увлеченным человеком, чтобы отправиться в дальние дали, найти, заинтересовать и помочь разговориться информанту, обладать исключительным трудолюбием для скрупулезной обработки материала. И ученым, чтобы издать все это в виде книг. У Ленара Шайхиевича все эти качества налицо.

Он родился 17 декабря 1935 года в сельской местности в деревне Средние Лащи Буинского района Татарстана, получил крепкую трудовую закалку. Прекрасно знает жизнь, психологию родного народа. После окончания средней школы работал в сельском хозяйстве, прошел армию, затем поступил на историко-филологический факультет Казанского госуниверситета (1960), был редактором музыкальных передач Татарского радио (1964–1970). В 1970 году он начал работать научным сотрудником в отделе народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Галимджана Ибрагимова АН РТ (ранее Институт языка, литературы и истории).

Круг его научных интересов очень широк. В области собирательства и составления татарских народных сказок ему не было и нет равных. В поисках образцов сказок – интереснейшего жанра фольклора, он объехал многие области Центральной России, Приуралья, Сибири, находил талантливых информантов-сказочников. В их числе М. Гулова, З. Минаева, Х. Хайруллин, Ф. Валиев, С. Сафина и др. Все его находки не лежат мертвым грузом, а опубликованы в виде солидных томов сказок.

Это – составление третьего тома сказок в 12-томном своде фольклора на татарском языке (1981), а также трех томов сказок из 14-томного научного свода татарского фольклора на русском языке. Он автор статей в многочисленных сборниках о фольклорных жанрах, типологии татарского фольклора, поэтике татарского фольклора. Замалетдинов ввел в научный оборот иностранные источники по татарскому фольклору. Он обнаружил, исследовал и опубликовал материалы из архивов Русского географического общества, Российской Академии наук.

Замалетдинов довел до читателей фольклорные образцы, хранившиеся в архивах Академии наук Венгрии (Будапешт), записанные венгерским тюркологом И. Куношем у военнопленных татар в годы Первой мировой войны. Они были неизвестны читателю, да и мало кто из исследователей знал об этих материалах. Публикации

Замалетдинова стали подлинным открытием, пополнив фонд татарских сказок оригинальным, богатым материалом.

За годы долгой, плодотворной работы в институте Ленар Шайхиевич обнаружил, исследовал, обнародовал многие неизвестные рукописные и печатные образцы, выяснил сюжетный состав сказок, основал построение указателя сюжетов татарских сказок на принципах международного каталога. Первая часть указателя уже опубликована. Он занесен также в интернет, где им могут пользоваться все – от студента до ученого.

В своей кандидатской диссертации «Татарские народные сказки и литературные сказки Г. Тукая», основываясь на анализе поэмы «Шурале» и выяснив основные принципы создания литературной сказки, ученый отобразил Г. Тукая как основоположника татарской литературной сказки. Это стало резкой отповедью некоторым зарубежным исследователям, выступающим с фальсификацией творчества поэта. Замалетдинов издал 14 сборников сказок. А общий объем его печатных трудов – около 340 печатных листов.

Планы его будущей научной деятельности весьма обширны. Основная цель – ввести татарские народные сказки в мировой научный оборот. Для этого, в первую очередь, необходимо завершить составление двух частей указателя сюжетов татарских сказок, а также издать татарские сказки на английском языке. В план исследователя входят и такие задумки, как издание 5 томов сказок из запланированного 25-томного свода татарского фольклора на татарском языке, составление и издание фольклорных сборников нескольких богатых материалом регионов, составление полного свода (корпуса) татарских народных сказок.

Л.Ш. Замалетдинов отмечает в эти дни юбилейную дату – ему 70 лет. Мы, коллеги, поздравляем патриарха татарской фольклористики с его творческими успехами и рады тому, что он живет большими планами на будущее. Уверены, что он их осуществит.

***Айсылу Садекова***

## Л. ҖАМАЛЕТДИНОВНЫҢ БАСЫЛЫП ЧЫККАН ТӨП ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕҢ ИСЕМЛЕГЕ*

### I. Җыентыклар

1. Татар халык иҗаты: Әкиятләр (өченче китап) / томны төзүче, кереш мәкаләне язучы, искәрмәләр әзерләүче Л.Ш. Җамалетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 360 б.

2. Татарские народные сказки / составитель, автор вступительной статьи и специальный редактор Ленар Замалетдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 464 с.

3. Татарские народные сказки / составитель, автор вступительной статьи и специальный редактор Ленар Замалетдинов. [Сувенирное издание]. Художник В. Малякин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 464 с.

4. Татар халык әкиятләре / төзүче, кереш мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче Ленар Җамалетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 480 б.

5. Өч каурый. Татар халык әкиятләре / төзүче һәм текстны әзерләүче Л.Ш. Җамалетдин. («Офык». «Казан» журналы китапханәсе. – № 1). – Казан: Татарстан газета-журналлар нәшр. типографиясе, 1992. – 48 б.

6. Три волшебных перышка. Татарские народные сказки / Составление и подготовка текста Л.Ш. Замалетдинова. («Панорама». Библиотека журнала «Казань» – № 1). – Казань: Типография Татарского газетно-журнального изд-ва, 1992. – 48 с.

7. Татарские народные сказки / составитель, автор вступительной статьи и комментариев Л. Замалетдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – 288 с.

8. Татар халык әкиятләре. Тылсымлы әкиятләр / төзүче, кереш мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче Ленар Җамалетдин. [Сувенир басма]. Рәссамы Т. Хаҗиәхмәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 416 б.

9. Татарское народное творчество: в 14 томах. – Том 1. Сказки о животных и волшебные сказки / составитель тома, автор вступительной

* Нигездә әкиятләргә караган хезмәтләр урын алды.

статьи и комментариев Л.Ш. Замалетдинов. – Казань: Раннур, 1999. – 352 с.

10. Яшәгән, ди, булган, ди... Әкиятләр / төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы Л.Ш. Җамалетдин. («Энҗе чәчтем – энҗе җыям»). – Казан: Мәгариф, 2000. – 144 б.

11. Татарское народное творчество: в 14 томах. – Том 2. Волшебные сказки / составитель тома, автор вступительной статьи и комментариев Л.Ш. Замалетдинов. – Казань: Раннур, 2001. – 400 с.

12. Әсирлектән кайткан әкиятләр / төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы Ленар Җамалетдин. Рәссамы Рушан Шәмсетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 344 б.

13. Золотой сундук сказок: Татарские народные сказки / составитель Л. Замалетдинов. Художники Р. Шамсутдинов, И. Шамсутдинов. – М.: Изд-во «Х.Г.С.», 2003. – 136 с. (Переиздание. Казань, 2003)

14. Татарское народное творчество: в 15 томах. – Том 1. Сказки о животных. Волшебные сказки / составитель тома, автор вступительной статьи и комментариев Л.Ш. Замалетдинов. – Казань: Магариф, 2008. – 455 с.

15. Татарское народное творчество: в 15 томах. – Том 2. Волшебные сказки / составитель тома, автор вступительной статьи и комментариев Л.Ш. Замалетдинов. – Казань: Магариф, 2008. – 447 с.

16. Татарское народное творчество: в 15 томах. – Том 3. Бытовые сказки / составитель тома, автор вступительной статьи и комментариев Л.Ш. Замалетдинов. – Казань: Магариф, 2010. – 543 с.

## II. Фәнни җыентыкларда һәм төрле басмаларда басылган мәкаләләр

1. Тылсымлы татар әкиятенең генетик чыганаклары // Тезисы докладов III научной конференции молодых ученых. – Казань, 1974. – Б. 30–32.

2. Әкиятче эзлим // Социалистик Татарстан. – 1974. – 22 нояб.

3. Әкиятче әби // Байрак (г. Буинск РТ). – 1974. – 26 нояб.

4. Дию кайда яши? // Ялкын. – 1975. – № 2. – Б. 30

5. Әкият сөйлим, тыңлагыз! // Ялкын. – 1975. – № 7. – Б. 23.

6. Җырлап яшәр чагыбыз // Ялкын. – 1975. – № 7. – Б. 23.

7. Маҗаралар дөньясында // Соц. Татарстан. – 1975. – 8 авг.

8. Тылсымлы әкият поэтикасының кайбер мәсьәләләре (сюжет, композиция һәм стиль үзенчәлекләре) // Материалы IV конференции молодых научных работников. – Казань, 1976. – Б. 103–110.

9. Әкиятче әби // Ильич васыятьләре. (г. Лениногорск РТ). – 1976. – 14 сент.

10. Татар халык әкиятләре // Татар халык иҗаты: Әкиятләр (беренче китап). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Б. 7–26.
11. Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым // Казан утлары. – 1978. – № 3. – Б. 139–146.
12. Әкиятләрнең килеп чыгуы // Татар фольклоры жанрлары. – Казан, 1978. – Б. 5–25.
13. Тылсымлы әкиятләр // Татар халык иҗаты. Әкиятләр (икенче китап). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 5–22.
14. Әкият искелек [кенә] түгел // Соц. Татарстан. – 1978. – 20 окт.
15. Тукай һәм әдәби әкият [Тукай и литературная сказка] // Казан утлары. – 1979. – № 4. – Б. 60–64.
16. О мифологической основе сказки «Шурале» // Габдулла Тукай. Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 90-летию со дня рождения поэта. – Казань, 1979. – С. 115–124.
17. Әкиятләр тарихыннан // Соц. Татарстан. – 1979. – 22 июнь.
18. О сказках Габдуллы Тукая // Фольклор народов РСФСР. – Уфа: изд-во Башкирского гос. ун-та, 1980. – С. 62–66.
19. Общности в сказках народов Среднего Поволжья и Приуралья // Межэтнические общности и взаимосвязи фольклора народов Поволжья и Урала. – Казань, 1983. – С. 91–99.
20. Кыйммәтле табылдык // Соц. Татарстан. – 1983. – 11 февр.
21. Алтын медальле әкиятләр // Соц. Татарстан. – 1983. – 29 апр.
22. Тылсымлы әкиятләрдә елан белән бәйле мифологик образлар // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. – Казан, 1984. – Б. 17–36.
23. Сказка – ложь, да в ней намек... // Вечерняя Казань. – 1985. – 19 мар.
24. Әкиятләр // Фольклор жанрларын анализлау: (коллектив монография). – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1986. – Б. 89–112.
25. Тылсымлы әкиятләрнең репертуары һәм сюжет типлары (XIX йөз һәм XX башындагы язмалар буенча) // Татар фольклорында социаль мотивлар (XIX йөз – XX йөз башы). – Казан, 1986. – Б. 101–149.
26. Что за прелесть эти сказки... // Вечерняя Казань. – 1986. – 13 мая.
27. Образы змея и подобных ему персонажей в татарских сказках // Фольклор народов РСФСР. – Уфа, 1986. – С. 44–49.
28. «Ак бүре»нең илгә кайтуы // Казан утлары. – 1987. – № 8. – Б. 180–183.
29. Әкият традициясе һәм заман // Татар халык поэтик иҗатының хәзерге торышы. – Казан, 1988. – Б. 5–24.
30. Колумб татарского фольклора // Наука. – 1989. – 11 апр.

31. Сюжетный состав сказок // Поэтика татарского фольклора. – Казань, 1991. – С. 60–75.

32. Әкиятләрдә халык педагогикасы // Народная педагогика и ее место в современном учебно-воспитательном процессе. Тезисы выступлений на республиканской научно-практической конференции на татарском языке. – Часть 1. – Казань, 1992. – С. 6–8.

33. Татарская сказочная традиция и современность // Фольклор народов России. – Уфа: Изд-во БГУ, 1992. – С. 74–77. 0,23 п.л.

34. Әсирлектән кайткан әкиятләр // Мирас. – 1993. – № 2. – Б. 86–88.

35. Әкиятләр дөньясына сәяхәт // Сабантуй. – 1993. – 17 фев.

36. Татар фольклоры басмалары тарихыннан: халык әкиятләре // Китапка хитап (Слово о книге). Материалы научно-практической конференции, посвященной 270-летию татарской печатной книги. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1994. – Б. 141–149.

37. Тылсымлы дөнья // Сабантуй. – 1995. – 1 апр.

38. Күләгәдә яткан әкиятләр // Мирас. – 1996. – № 1/2. – Б. 82.

39. Халык иҗаты – үлемсез // Казан утлары. – 1996. – № 7. – Б. 134.

40. Әбкәм әкият сөйләгән // Мирас. – 1996. – № 10. – Б. 56–57.

41. Яшәгән ди, булган ди... // Шәһри Казан. – 1996. – 5 июль.

42. Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә әкият традицияләре // Төркиләрнең телләре, рухи мәдәниятләре һәм тарихлары: Традицияләр һәм заман (1992 елның 9–13 июнендә Казанда узган Халыкара тюркологик конференция хезмәтләре 3 томда). – Т. 2. – М.: Инсан, 1997. – Б. 155–157.

43. Тукайның истәлекләрендә һәм юлъязмаларында фольклор // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте: Тукайның тууына 110 ел тулуга багышланган халыкара конференция материаллары. – Казан, 1997. – Б. 96–101.

44. Тукай һәм халык иҗаты // Мәдәни җомга. – 1997. – 18 апр. (№ 5)

45. Әсирлектән кайткан җәүһәрләр // Шәһри Казан. – 1997. – 31 окт. (№ 210–211).

46. Мишәр әкиятләре // Өмет (г.Ульяновск). –1997. – 22 нояб.

47. Сюжеты и мотивы татарских сказок о животных (опыт создания систематического указателя) // Типология татарского фольклора. – Казань: Мастер Лайн, 1999. – С. 66–87.

48. Татарские народные сказки. Сказки о животных // Идель. – 1999. – № 4. – С. 34–35.

49. Волшебные сказки // Идель. – 1999. – № 5. – С. 46–47.

50. Бытовые сказки // Идель. – 1999. – № 6. – С. 24–25.

51. Мишәр әкиятләре // Казан утлары. – 1999. – № 8. – Б. 152–153.
52. Zamaletdinov Lenar. The Mirror of People's Soul // Tatar Folk Tales. – Kazan: Magarif, 1999. – S. 123–126.
53. Күңел хәзинәсе җәүһәрләре // Буа ягым – тау ягы. Буинские просторы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – Б. 345–347.
54. Тылсымлы әкиятләрдә Дию образы // Фәнни эзләнүләр юлында. Илбарис Надировка 75 яшь тулуга багышлана. – Казан: Фикер, 2000. – Б. 134–157.
55. Әкиятләрнең кайбер поэтик үзенчәлекләре // Фольклор теле – шигърият теле. – Казан: Фикер, 2001. – Б. 45–54.
56. Хәмит Ярми һәм халык әкиятләре // Татар фольклоры мәсьәләләре. – Казан, 2004. – Б. 12–19.
57. Татар халык әкиятләренең сюжет күрсәткече турында // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар. – Казан: Фикер, 2004. – Б. 12–16.
58. Күңел хәзинәсе җәүһәрләре // Зөя буе – туган җирем. – Казан: «Матбугат йорты», 2005. – Б. 180–182.
59. Әкиятләребез – бөтендөнья хәзинәсе // Мәдәни җомга. – 2006. – 17 ноябрь (№ 45). – Б. 14–15.
60. Академик Радлов архивындагы татар әкиятләре // Фән һәм Тел. – 2007. – № 1. – Б. 28–33.
61. Татар әкиятләре дөнья әкиятләре каталогында // Фән һәм Тел. – 2007. – № 2. – Б. 35–39.
62. Буада байлык буа буарлык // Мәдәни җомга. – 2007. – 31 август (№ 34). – Б. 19.
63. К вопросу о создании национальных сюжетных указателей сказок // Актуальные проблемы современной фольклористики: материалы международной научно-практической конференции (Казань, 29 июня 2009 года). – Казань: Алма-Лит, 2009. – С. 63–64.
64. Академик В.В. Радлов архивындагы татар әкиятләре // Актуальные проблемы современной фольклористики: материалы международной научно-практической конференции (Казань, 29 июня 2009 года). – Казань: Алма-Лит, 2009. – С. 274–276.
65. Галимнәр районны өйрәнәләр (автордаш – Д.Б. Рамазанова) // Актаныш таңнары [Татарстанның Актаныш районы газеты]. – 2009. – 26 июнь (№ 50).
66. Безгә таныш Актаныш // Мәдәни җомга. – 2009. – 23 октябрь (№ 40). Б. 18. 0,3 п.л.
67. Халык җәүһәрләре. Актаныш төбәгендә сакланган фольклор үрнәкләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш / төзүче-мөхәррир Э. Сафина. – Казан: ТӘһСИ, 2010. – Б. 327–413.
68. Хәзерге тормышта әкият традициясенең үзгәрүе // Европа цивилизациясенә мөнәсәбәттә татар мәдәнияте. Халыкара фәнни

конференция материаллары (Казан, КДУ, 3–4 ноябрь, 2009 ел). – Казан: Ихлас, 2010. – Б. 366–367.

69. Апас – әкиятчеләр төбәге // Йолдыз [Апас районы газетасы]. – 2010. – 25 июнь. 0,16 п.л.

70. Татар фольклоры басмалары тарихыннан: халык әкиятләре // Төрки телле китап гасырлар хәзинәсе. Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной истории тюркоязычной книги (17–18 октября 2012 г.). – Казань, 2012. – Б. 260–269.

71. Халык әкиятләрен туплауда һәвәскәрләрнең роле // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар. Йомгаклау конференциясе материаллары 2012. – Казан, 2013. – Б. 311–316.

72. Күркәм кеше иде // Милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре системасында фольклор. Хәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтовнең (Хәмит Ярми) тууына 110 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2014. – Б. 304.

ЭЧТӘЛЕК

Традицияләр дәвам итә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

**Татар халык әкиятләре**

Жанрның төрләре һәм аны өйрәнү тарихы . . . . . . . . . . . . . 7

Хайваннар турындагы әкиятләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16

Тылсымлы әкиятләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34

Көнкүреш әкиятләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

**Татар халык әкиятләрен өйрәнү мәсьәләләре**

Татар фольклоры басмалары тарихыннан: халык әкиятләре . . 77

Әкиятләр тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84

Колумб татарского фольклора . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86

Тукай һәм әдәби әкият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89

О мифологической основе сказки «Шурале» . . . . . . . . . . 96

Тукайның истәлекләрендә һәм юлъязмаларында фольклор . . . 105

Хәмит Ярми һәм халык әкиятләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

Яшәгән, ди, булган, ди . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121

Әкиятләрнең кайбер поэтик үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 125

Тылсымлы әкиятләрдә Дию образы . . . . . . . . . . . . . . . . 133

Образы змея и подобных ему персонажей в татарских сказках . 152

Алтын медальле әкиятләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158

Академик Радлов архивындагы татар әкиятләре . . . . . . . . 159

«Ак бүре»нең илгә кайтуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

Әсирлектән кайткан әкиятләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

Маҗаралар дөньясында (*Әкият китапларына күзәтү)* . . . . . 176

Халык әкиятләрен туплауда һәвәскәрләрнең роле . . . . . . . 179

Татар әкиятләре дөнья әкиятләре каталогында . . . . . . . . . 184

**Сәфәр чыктым еракларга**

Әкиятче әби . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Әкият сөйлим, тыңлагыз!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Әкиятче эзлим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым... (*Фольклорчы язмалары)* . . . . 196
Мөслимгә барам әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Күңел хәзинәсе җәүһәрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Буада байлык буа буарлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Халык җәүһәрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Әкиятчеләр төбәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233

**Ленар Җамалетдинов турында**

Әкиятләр дөньясына сәяхәт (*Р. Мөгаллимов*). . . . . . . . . . . 239
«Әкиятләрдә хаклык җиңә, тормышта да шулай булыр!»
(*Роберт Миңнуллин*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Әкият турында хикәят (*Илбарис Надиров*) . . . . . . . . . . . 246
Әкиятче галим (*Хуҗи Мәхмүтов*) . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Волшебник из страны чудес (*Айсылу Садекова*) . . . . . . . . 253

Л. Җамалетдиновның басылып чыккан төп хезмәтләренең
исемлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256

**Замалетдинов Ленар Шайхиевич**

**НА ПУТИ ИЗУЧЕНИЯ ТАТАРСКИХ СКАЗОК**
(на татарском и русском языках)

Редактор *М.Г. Мортазин*
Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *Л.Ш. Давлетшиной*

Подписано в печать 9.12.2015.
Формат 60×84 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 15,35. Уч.-изд. л. 14,5
Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20